# казан утлары

2. 1998





**Гаяз Исхакый**
1878—1954

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**2**

**(904)**

**1998**

КАЗАН


## *Бу санда*


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ф. ЯРУЛЛИН. Якты ай янында... *Шигырьләр* ..... 3
М. ГАЛИ. Догалы еллар. *Эссе* ..... 9
Р. ГАТАШ. Бармы көчем — яшь моңны юатырлык... *Шигырьләр* ..... 71
Н. ХӘСӘНОВ. Инрәү. *Повесть* ..... 78

ӘЙ, ГОМЕР АГЫШЛАРЫ

Дуслык илчесе, туганлык җырчысы ..... 103
Н. НӘҖМИ. Сиксән тулганда. *Шигырьләр* ..... 106

ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Г. ИСХАКЫЙ. Ике хикәя ..... 107
Ф. ИБРАҺИМОВА. Әдипнең тормыш мизгелләре ..... 116

ПУБЛИЦИСТИКА

Ә. ГАЛИЕВ. Бер һәйкәлнең тарихы ..... 131

ӘДӘБИ МИРАС

М. ГАЙНЕТДИН. Мулла шагыйрь ..... 140
М. ИМАНКОЛЫЙ. Газәлләр ..... 142

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Х. ӘШРӘФҖАНОВ. Тамырыбыз тарихта ..... 146
М. ШАБАЕВ. Түземнәр генә бәхеткә лаек ..... 161

СӘНГАТЬ

К. ТИМБИКОВА. Чәчәк аткан гөл ..... 168

ФАТИХ ХӨСНИНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

К. МИҢЛЕБАЕВ. Гүзәл мирас калдырган әдип ..... 173

ГАКЫЙЛЬ СӘГЫЙРОВКА 60 ЯШЬ

И. ЮЗЕЕВ. Шигырьдә — рәссам, рәсемдә — шагыйрь ..... 177

КОТЛЫЙБЫЗ

Ш. МАННАП. Иман нуры *(Шаһинур Мостафинга 50 яшь)* ..... 180

Латин имласында уку үрнәкләре ..... 182
Имеш-мимеш түгел ..... 186
Укучы сүзе ..... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 190

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Хәлим Гайнуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Нажар Нәҗми**
**Рашат Низамиев**
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*
шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

# В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание отрывков из книги эссе М. ГАЛИЕВА «Книга времен», повесть Н. ХАСАНОВА «Стон»; стихи Ф. ЯРУЛЛИНА, Р. ГАТАША, Н. НАДЖМИ.
«К 120-летию Гаяза Исхаки»: два рассказа писателя и статья Ф. ИБРАГИМОВОЙ «Мгновения жизни».
«Публицистика»: А. ГАЛИЕВ. «История одного памятника».
«Литературное наследие»: стихи поэта XIX века М. Иманколый.
«Литературная критика»: статья Х. АШРАФЗЯНОВА «Наши корни в истории»; статья М. ШАБАЕВА посвящена творчеству Ф. Яруллина.
«Искусство»: статья К. ТИМБИКОВОЙ о творчестве артистки театра имени Г. Камала Н. Ихсановой.
«К 90-летию Фатиха Хусни»: статья К. МИННЕБАЕВА «Писатель, оставивший прекрасное наследие».
В номере отмечаются 60-летие Ф. Яруллина и Г. Сагирова и 50-летие Ш. Мустафина.
Навыки чтения на основе латинской графики.
Слово читателей.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: картина К. Нафикова из серии «Древний Булгар», писатель Зиннур Хуснияр.

# IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: the end of fragments from M. Galiev's book «The book of time», N. Hasanov's story «Moan»; the verses of F. Yarullin, R. Gatash, N. Nadjmi.
«Commemorating the 120 Anniversary of G. Iskhaki»: two writer's story and F. Ibrahimov's article «Instants of life».
«Publicism»: A. Galiev «Tne story of a monument».
«Literary heritage»: verses of poer XIX c. M. Imancoly.
«Literary Critique»: H. Ashraphzyanov's article «Our rools in history»; M. Shabaev's article devoted to Yarullin's creation.
«Art»: K. Timbicova's article about creation G. Kamal theatre's artist N. Ikhsanova.
«Commemorating the 90 th Anniversary of Fatih Housni»: K. Minnibaev's article «Writer's heritage».
Jubilees: the 60 th anniversary of F. Yarullin and G. Sagirov and the 50 th anniversary of Sh. Mustafin.
Reading Skill on the Basis of Latin Script.
Reader's word.
The diary of social and cultural life.
In our calendar: K. Naficov's picture from «Ancient Bulgar» serios, writer Zinnur Hisniyar.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Алмаз Гыймадиев, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.**
*Гамәли хезмәткәрләр:* Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева, Альбина Әхмәтова.

Производствога бирелде 24.12.97 ел. Басарга кул куелды 11.02.98 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 ¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 13992. Заказ Н-695.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1998 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Фәнис Яруллин

### ЯКТЫ АЙ ЯНЫНДА...

### Ни эзлим

Нәрсә эзлим мин бу җирдән,
Бәргәләнеп көн вә төн?
Дөреслек кирәкме миңа?
Таба алган аны кем?

Бәлки мин пакьлек эзлимдер
Кергә баткан дөньядан?
Дөньяларны юар өчен
Су алыйм кай елгадан?

Ни эзлим? — Алтын-көмешме?
Байлыкмы — күмелерлек?
Яңа җырмы — күңелләрдән
Тулышып түгелерлек?

Эзлимме әллә матурлык
Дөньяны коткарырлык —
Кайда ул андый матурлык,
Кешеләр таң калырлык?!

Ни эзлим? Тугры дусларны? —
Сатылмый, сатмый торган,
Дуслык хакын тәңре хакы
Шикелле хаклый торган.

Ни эзлим? Ялганның тамырын
Чабар өчен балтамы?
Кайда ул балта, әллә соң
Су төбендә ятамы?

Ни эзлим гомер буена,
Юлларга нәрсә тарта?
Яшәгән саен җанымда
Борчулар гына арта шул,
Сораулар гына арта.

## Таулар аша үтә юлларым

Язмышымнан һич тә зарланмыймын,
Ходай миңа биргән күп нәрсә:
Сулышым белән җирне җылыта алам,
Җылытырга әгәр кирәксә.

Упкыннарда биеклекләр күрәм,
Кара төннән табам яктылык.
Күккә чөйсәң утлы күмер дә бит
Йолдыз булып китә атылып.

Кирәк булса болыт булып агылам,
Яңгыр булып явам — кирәксә.
Шиңгән гөлләр кабат терелерләр
Хисләр яңгырыма эләксә.

Кояш нурларыннан камчы үреп
Яшен итеп күктә шартлатам;
Аклыгымны чәчәкләргә бирәм,
Ярсуымны җиргә таратам.

Гигант булмасам да кәрлә түгел,
Бәхетемә җитә буйларым.
Карурманнар, зур дәрьялар аша,
Таулар аша үтә юлларым.

Даным да бар минем, малым да бар,
Бөтенесе, шөкер, житәрлек:
Халкым мине үзенең иңнәрендә
Киләчәккә бара күтәреп...

* * *

Күпме юллар уздым җирдә,
Йоттым юл тузаннарын.
Кояшка кулларым сузып,
Китсәм дә күпләрне узып,
Язмыштан узалмадым.

Гел биеккә, гел үрләргә
Ашкынып торды йөрәк.
Менсәм дә биек үрләргә
Көчем җитмәде менәргә
Үземнән биеккәрәк.

Кабыздым күпме учаклар
Төшсен, дип, яктым ерак.

Җылытса да күпләр җанын
Булмады яккан учагым
Үз җанымнан яктырак.

* * *

Язмыш миңа бик күп бирде
Бәхетле мизгелләрне.
Очтым, очтым — кулларыма
Нык урап тезгеннәрне.

Сикердем упкыннар аша,
Үрелдем кыяларга.
Куркуга ирек бирмәдем
Җаныма ояларга.

Эзләдем, таптым, югалттым,
Яраттым-яратылдым.
Бер байлыгымны югалтсам,
Яңасын таба тордым.

Мин тауларга баралмасам,
Таулар килде үзләре.
Күкләр минем күкрәгемнән
Яшен уты эзләде.

Яшеннәргә утлар бирдем,
Диңгезгә — ярсуымны.
Яндырдым төнге учакта
Нәфрәтем, ачуымны.

Булды инде, бар да булды —
Агы да, карасы да.
Күпме чәчәкләр үстердем
Йөрәгем ярасында.

## Эчтем

— Эчәсеңме? — дип сорыйсың,—
Эчтем һәм эчәчәкмен.
Гел эчүләргә бәйләнгән
Үткәнем, киләчәгем.

Эчтем язлар яктылыгын,
Сарысын эчтем көзнең.
Чумып таңнар шәрабына
Ярдан ярларга йөздем.

Исереп башым югалттым,
Айныгач тагын эчтем.
Күкләр зәңгәрлеген эчеп
Кабат җирләргә төштем.

Кышларның аклыгын эчтем,
Җәйләрнең җылылыгын.
Эчтем тынга капланганчы
Рәшәләр куелыгын.

Эчтем шатлык, эчтем сагыш
Тустаганнар тутырып.
Дөнья үзе кыстап торгач
Булмый эчми утырып.

Белмим, күпме эчәчәкмен
Төрлесен шәрабларның.
Җилләр кайсы якка борыр
Тормышым корабларын.

## Айлар якты

Айлар якты, айлар якты,
Айлар яктысы күктә.
Ничек якты булмасын ул
Яшәп шундый биектә.

Айлар якты, ай янында
Якты йолдыз җемелди.
Якты ай янында — якты
Булмыйча мөмкинмени?

* * *

Күктә йолдызлар шундый күп:
Тоныгы, яктысы бар.
Һәркайсының үз урыны,
Үз төсе — чаткысы бар.

Кояш та бар күктә, Ай да,
Этешми берсе берсен.
Күкләрнең күңеле бик киң:
Сыйдыра бөтенесен.

* * *

Күкләр була җиде катлы,
Һәрбер катында капка.
Капкаларда фәрештәләр
Бик уяу тора сакта.

Күкләргә менүләр авыр,
Күкләрнең юк баскычы.

Һәркемнең үз йөрәгендә
Күк капусы ачкычы.

* * *

Һәр яз саен яңа гөлләр калкып чыга
Таҗларыннан матурлыклар саркып чыга.
Ирексездән үреләсең дә ул гөлләргә,
Яз сулышы бәреп керә күңелләргә.

Күзе барның күзе төшә гел матурга,
Матурлык та кирәк җанны уятырга.
Яз булмаса, гөл булмаса — нәрсә кала
Тамырларда аккан канны уйнатырга?!

Яздан көчле шәраб барын белмим җирдә,
Шул исерткеч шәраб исе һәрбер гөлдә.
Тик берсенә иренеңне тидерсәң дә
Фәрештәләр бии башлый күңелеңдә.

Сокланамын яңа туган һәрбер гөлгә,
Сокланамын яңа килгән һәрбер язга.
Һәммәсендә татылмаган яңа сер бар:
Язлар — язга охшаш булмый, назлар — назга.

## Сары сагыш

Сары сагыш, сары сагыш,
Каеннарга тимә ялгыш.
Алар җирнең балкышлары,
Алар җирнең аккошлары.

Сүндермә син балкышларны,
Саргайтма син аккошларны.
Җиңел түгел беркемнең дә
Бу дөньяда язмышлары.

Гөлләргә дә кагылма син,
Иңнәргә дә сарылма син.
Кит еракка, чит җирләргә,
Тимә-тимә күңелләргә.

Сары сагыш, сары сагыш,
Тормыш — давыл, ә без — камыш.
Бәхет-кайгы арасында
Бара көрәш, бара тартыш.

## Бетте дөнья гамьнәре

Алмалар өздем учыма
Мәхәббәт бакчасыннан.

Иң зур бүләк алдым гүя
Оҗмахлар патшасыннан.

Ул алмалар яфракларга
Качып үскәннәр иде.
Качып үскәнгә күрәдер,
Тулып пешкәннәр иде.

Алмаларны озак кына
Уйнаттым учларымда.
Дөрләде давыллы хисләр
Йөрәгем учагында.

Әле һаман телләремдә
Ул алманың тәмнәре.
Күңелем җәннәт бакчасында —
Бетте дөнья гамьнәре.

## Кирәк

Эшне башлап китәр өчен
Сәбәп кирәк.
Матур итеп тәмамларга
Сәләт кирәк.

Кәеф-сафа корыр өчен
Шәраб кирәк.
Дөньяда син кем булсаң да
Әдәп кирәк.

Парны парга димләр өчен
Кода кирәк.
Җанны сафландырыр өчен
Дога кирәк.

Тормыш гөрләп барган чакта
Бар да кирәк...
Кайгы-хәсрәт килгәч кенә...
Алла кирәк.

*1996—1997.*



## Марсель Гали

# ДОГАЛЫ ЕЛЛАР[1]

«Кошлар оча-оча югала...»

*Җир үбеп, дидек догалар гәүһәри,*
*һәм дәхи улсын сәналәр җәүһәри.*
Г. Кандалый.

Хәзерге Мәхмүт Хәсәнов исемендәге урамнан ул чакта Мәхмүт аганың үзе белән редакциягә таба атлыйбыз. Ул, костюмының мул итәкләрен җилфердәтеп, Азнакай җилен ерып бара. Имән бармагы белән ара-тирә төзәткәләп куйган күзлеге иркен йөзенә адашып кына килеп кунган шикелле. Уйлап куям: бу саллы, бинибая олы гәүдәне хәрәкәткә китергән йөрәккә киләчәктә язылачак күпме роман-вакыйгалар сыйгандыр...

Мин әле күптән түгел генә Белоруссиядән армия хезмәтен тәмамлап кайткан егет икәнмен. Куен кесәмә бөкләп тыгылган кәгазьләрдә җитлекмәгән шигырьләрем кыштырдый.

— Бүген шигырь укырга да туры килер үзеңә,— ди Мәхмүт ага,— Әдәби түгәрәк утырышына Әлмәт Язучылар оешмасы җитәкчесе Равил Фәйзуллин килергә тиеш. Бик талантлы егет!

Такташ булган. Туфан, Хәкимнәр бар... Бер тында әйтелә торган серле йомгак кебек хикмәтле исемнәр... Мине солдатка алып киткән еллар артыннан әнә нинди яңа шагыйрьләр үсеп чыккан: Фәйзуллин, Гатауллин, Мингалимов. Безнең авылда да бар ич мондый фамилияләр. Шагыйрь булгач, дөньяда бердәнбер исемгә ия булырга тиеш түгел микәнни?

Белоруссиядән ялга кайткан арада мин аларның «Аҗаган», «Гөлләр су сорый» кебек юка китапларын җыеп киткән идем. Укый-укый бу шагыйрьләрнең исемнәрен дә үз итә башладым шикелле. Сагыну кысып алганда туган тел, туган җир хәбәрен җиткерүче догалык сыйфатындагы бу китапларны кая барсам да гимнастерка кесәсендә йөртәм. Заманында Наполеон Бонапарт данлыклы гаскәрен җуеп кичкән Березина елгасы буена кояшта кызынырга чыкканда да үзем белән алам. Тын табигать кочагында ягымлы, эчкерсез белорус кызларының иңгә кунган кош кебек чыркылдашуына татар шигъриятенең аһәңе дә кушылып китә. Югыйсә бит алар танышканда нинди милләттән икәнеңне сорап аптыраталар.

[1] Ахыры. Башы 1 санда.

Сөйләшүеңнән урыс түгеллегеңне чамалап, сине йә хохол, йә латыш, йә булмаса молдаван итеп куялар. Татар мин, дигәч, күзләрен зур ачып карап торалар — берничек ышандыра алмыйсың. Ялган тарихтан торган дәреслекләр укып, мәктәп елларыннан ук татар — мөгезле, дәһшәт чәчеп торучы кеше — җанвар булып аңнарына сеңдерелгәндер күрәсең.

Әлеге шигырь китаплары юка булса да үтә күренмәле түгел шул... Күп кенә шигырьләренә тешем үтми. Өч нокта белән тәмамланган сүзләр артында әллә нинди хикмәтләре бар сыман, зиһенне иләсләндерә, сынык-тәтек юллар арасына кереп адашам, буталып бетәм. Әйләнә-тирәмдә киңәшерлек бер генә татар кешесе дә юк. Төшләремдә дә урысча гына сөйләшәм, әллә соң туган телнең тамырын җуя башладым микән? Дивизия штабында эшләгәнлектән, мин офицерлар китапханәсенә йөри идем. Анда Гитлер, Геринг, Отто Скорцени кебек рейх башкисәрләре, сугыш серләре хакында мавыктыргыч китаплар шактый иде. Әллә соң шуларны артыграк укып ташлап, шигъриятькә мәхәббәтне сүндердем микән?.. Әнә шундый уйлар килә иде башыма. Язмыш мине гүя нәни утравым белән чиксез дәрья уртасына китереп ташлаган да, туган телемнең ярларын кысып килгән ят-ярсу дулкыннарны аралап мин күңелемне «каната-каната» алга үрмәлим, егылам, тагын торып басам...

Пермьнең авиация мәктәбен тәмамлагач, унбиш-егерме көннәр туган якта ял итеп, патронташ урынына шигырь китаплары тезеп, Казаннан Смоленскига китеп баручы солдат егетнең якты октябрь көнендә челтәрле Идел күперенә килеп кергәч, Күк катларыннан шигырь юллары убылып төшәр дә, поэзия җене мәңгелеккә урап алыр дип кем уйлаган...

Идел, Идел!  
Күзен кыса кояш нурларыннан,  
елмая күк сине каршылап.  
Тукта, поезд!  
Нигә ашкынасың,  
карый алмый калам яхшылап.

Шушылай башланган бу шигырь тулысы белән басылып чыккач, штабның йөрәге оператив бүлектә бергә эшләгән сызымчы, сугыш вакытында укчы-радист булып хәрби самолетларда очкан Виктор Трофимычка газетаны күрсәткән идем (шатлыктан тын кысыла, елмаеп басып торам), ул минем куанычымны казарма тәрбиясеннән калган салкынлык белән сүндереп куйды:

— Мин синнән җитди кеше чыгар дип уйлаган идем...

Брежнев танкларында чабаталы кавем балалары — сугыштан соң туган буын, ягъни, минем яшьтәш солдатлар Чехословакиягә басып керергә ике ай кала, рухыма ят армия тормышы белән хушлашырга өлгердем. Ямьле җәй башында авылга кайтып төштем. Төзелеш оешмасына рәссам-бизәүче булып эшкә урнашкач, редакциягә дә сугылгалый башладым. Монда Мәхмүт Хәсәнов, Мөсәгыйт Хәбибуллин кебек язучылар эшли. Яшьләрдән үткер хәтерле, мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган Ирек Бәдертдинов та шигырь-хикәяләр яза. Актүбәдән Әнәс Исхаков килгәли. Сөйләгән сүзләребез яңа әсәрләр хакында, сулаган һавабыз да әдәбият тузаны...

Район газетасының еллык бәйләмнәрен карап чыгам — күбрәк Нур Әхмәдиев шигырьләре күзгә чалына.

Кайтмассың диделәр миңа  
киткән чакта Азнакайдан.  
Ничек соң анда кайтмыйм, ди,  
яшьлегем шунда калган.

Кем соң бу Нур Әхмәдиев дигәннәре? Мин Белоруссиянең алма-грушаларын кимереп йөргән арада студент та булып өлгергән, универси-

тетнын «Клара Булатова фасылын» кичерү бәхетенә дә ирешкән. Сез бит бер мәктәптә укыдыгыз, ул синнән бер сыйныф кына артта иде, диләр, һич кенә дә күз алдына китерә алмыйм. Үзе белән күрешкәч, аптырап калдым: бергә аулак өйләргә йөргән, безнең авылга кунакка еш килә торган Әсәй егете — Әхмәдиев Нур икән ләбаса! Кирегә әйләндереп, Нур Әхмәдиев дигәч, бөтенләй башка кеше булып тоелган, каһәр...

Азнакай — чибәр кызларга бай шәһәр. Карашларындагы яшен уты күңел тарлавыкларында сулкылдап, илһам учакларын дөрләтеп кабыза да... син чиксез сүз дәрьясы каршында көчсез калып ярдан ярга бәргәләнә башлыйсың... Яфрак өзелеп төшкәнне күрсәң дә, кош очып узса да, асфальтны яңгыр сипкелләп китсә дә шигырь туугa сәбәп була. Җирдәге кырмыскалар биеклеге туйдырса, галәми киңлекләргә чыгып китәм, туган тел кысаларына, үги булып, әллә нинди космополитик сүзләр килеп керә.

Эш урыным әйбәт. Өстәл тартмасына өрек чикләвеге тутырылган. Бер куплет шигырь язылуга, цирк манежындагы җәнлекләрне ымсындырган кебек, чикләвек алып үз-үземне сыйлап куям. Бәрәңге кәлҗемәсе парыннан баш миендә юньле фикер тумый, янәсе...

Беркөнне шулай биш-алты шигырьне берочтан язып аттым да редакциягә Ирек Бәдригә телефоннан чылтыраттым:

— Бүгенге көндә Азнакайда иң көчле шагыйрь дип кемне саныйсың?

— Үсепес дип торапыс-с, — ди Ирек.

— Бер ел вакыт бир, сытам! — дим мин.

Ирек шаркылдап көлә. «Син бит әле шигырьдә аякланып кына киләсең, күзе ачылмаган көчек кебек», — ди.

Менә бүген мин Казанның үзендә яшәп, мәркәзи мәктәп бетереп килгән тере шагыйрьне — Равил Фәйзуллинны күрәм. Текә маңгай. Кыска гына калдырылган чәч. Һәр сүзен бик чамалап, кадерен белеп кенә әйтә. Шагыйрь генә түгел, җитәкче дә икәнен ул бер генә мизгелгә дә онытмый иде шикелле. Үз-үзен тоту рәвешенә карап, аны шактый олы яшьтә дип уйларга мөмкин (ул чакта аңа егерме биш яшь булган).



*Әгъзәм Сәгыйтдинов, Марсель Галиев, Равил Фәйзуллин, Ирек Бәдертдинов, 1968 ел, сентябрь.*

Ул көнне Равил Фәйзуллин безнең каршыда «Менә без дә үсеп життек, әни» һәм «Кер чайкыйлар кызлар» дигән шигырьләрен укыды.

Шул мәлдә минем алда күк капусы ачылгандай булды. Хикмәте бик гади икән: мин бәләкәйдән үк шигырьләрне билгеле бер көй кысаларына салып укырга күнеккәнмен. Ә ирекле шигырь ритмы башка, һәр сүзнең мәгънәсен аерымлап, төрле аһәңгә буйсындыра. Шул минутта минем өчен классик шигырьләрнең бәясе төште. Әнә бит, ирекле шигырьнең график сурәте дә нинди төрлелеккә ия: иркен җөмләләр, яңгыратып сал авазыңны, кирәк җирдә үз фикереңне, баскычла, өч нокта белән пышылдатып бетер!

Шул танышудан соң без, берничә Азнакай егете, шигырьләребезне тотып, айга бер Әлмәткә юл тота башладык. Равил Фәйзуллин безне ачык йөз белән каршы ала, вак-төяк эшләрен җайлый да безне стадионга алып китә. Чирәмле аулак урында чишенеп ташлый, плавкидан гына кала. Бөтен тәне кояшта янып, бронза төсенә кергән. Мускулларын уйнаклатып ул, күрәсезме мин нинди, дигән канәгатьлек белән, безгә күз төшереп ала.

— Һәйкәл булырга җыена бу,— дип куя Ирек Бәдри пышылдап кына.

Без дә чишенеп, аерткан сөт йөгертелгән сыман зәңгәрсу-ак тәннәребезне кояшка таратып ташлаган булабыз. Эссе, тын хозурлыкта шигырьләрне укып тикшерү башлана. Шигырьдән арыганнан соң куллар талганчы бадминтон уйныйбыз.

Кыш көннәрендә килгәндә Фәйзуллин безне өенә алып кайтып китә. Бүлмәсе иркен. Алагаем калын бер өстәл дә берничә урындык. Ә стенада сыңар энә белән каптырылган ак кәгазь битләре. Аларга, үтеп китешли генә, бер йә ике юллык фикерләр язылган. Пегас канатыннан сибелеп калган каурыйлар.Арада — иң тәҗрибәсез каләм миндә. Рәссам булырга хыялланып мин әдәбиятны аңсыз рәвештә, кызык эзләп кенә укыганмын, гыйбрәт алып, нәни ачышларын сеңдереп кала белмәгәнмен. Менә хәзер инде миңа әдәбият лабиринтларына кереп үз теләгем белән адашырга һәм дөньялыкка үз кыйбламны табып чыга белергә кирәк. Моның өчен иң башта ни кылырга? Егетләр инде юлны сызып та бирделәр: алдагы елга — Казан, университет. Имтихан билетларына керәчәк роман-повестьларны хәзердән үк укый да башладым инде. Шәйхи Маннурның «Муса» романын гына мылтык терәсәләр дә ахырынача укып чыгарга түземлегем җитмәячәк. Легендага әверелгән Җәлилне кабат проза биеклегенә төшерү кирәк микән?..

Минем шигырьләрем — йомырканы ашыгыбрак тишеп, эче җыелмыйча чыккан чеби кебек. Үзем дә аңлап бетермәгән юллар арасында Фәйзуллинның каләме шактый озак бутала, аннан сипли, моннан сипли, егетләр белән киңәшеп алган була, теш белән дә сүтә алмаслык төенләнгән юллар арасыннан артык гади, җырлап торганын табып ала да, елмаеп:

— Бусын фәлән шагыйрь язсын. Аның өлешенә кермә! — дип, шактый исемле әдиптән мыскыллы көлеп куя. Мин сискәнеп китәм. Күп нәрсәне инкяр итү, җимергеч фәлсәфә, хаксыз икәнеңне белгәндә дә үҗәтләнеп үзеңнекен исбат итү — холкыма, вөҗүдемә хас булса да, китапка, ташка басылган әсәргә һәм аны язган кешегә хөрмәт белән мәҗүсиләрчә табынып карау каян бирелгәндер! Бу беркатлылыктан котылу өчен миңа да Казанның кырыс мәктәбен үтәргә кирәктер, мөгаен.

Талчыккан рухны тән саулыгы төзәтә. Шигырьдән соң, чәйләп тә алгач, Фәйзуллин җиңнәрен сызгана башлый. Үзе әйтмешли: «Беләкләләр җитә, теләкләләр кирәк, көрәшчеләр кирәк!..» Безнең арада Ирек Бәдри иң калкурак, тазарак күренсә дә, талканы озакка бармый, Фәйзуллинның маңгаен тирләтеп озак азапламыйча гына бирелә. Мин исә дер селкенгән йорт диварларына сыенып кына судьялык итәм. Әнәс Исхаков белән көрәш озаккарак сузыла, киләчәктә, шигъриятен читкәрәк куеп, комсомол вожагы, аннары район хуҗасы буласы егет билен бирми, бөтен дәрманын салып тартыша, кыргый авазлар чыгарып, бер-берсенә уралып бетәләр — мәхшәр куба: авыр өстәл мамык җиңеллеге белән почмакка

барып сылана, урындыклар чәчрәп китә. Дивардагы шигырь кыйпылчыгы язылган кәгазь битләре, безнең дә кирәгебез калмады бугай, дигәндәй, энәсеннән кубып очып йөриләр.

Җинелгәнне җиңел кичерә белгән кешеләр сирәктер дөньяда. Әгәр җиңүне мизгеллек ләззәт итеп кенә карамасаң, вакыт яссылыгындагы көрәш ул җинелеп җиңә белү кебек фәлсәфи отышлардан да тора... Шигърияттә... ак кәгазь, ак кыр киңлекләрендәге ярыш, асыл бәя, хак сүзне байрак итә алу тоталитарлык хөкем сөргән җәмгыятьтә була алмый иде шул. Без Туфан пьесасындагы кебек, бөтен кеше җомга дип кычкырганда, шимбә икәнен белсәк тә, кычкырасы авазыбызны җан ярасына күмәргә мәҗбүр идек.

Дөнья күрү, аралашу, тере мохит — язучы өчен ут-су-һава белән бер. Мин моны Полтавада үткән шигърият фестивалендә, Мәскәүдә узган яшь язучыларның бөтенсоюз семинарында катнашкач аңладым. Ә инде Казанның үзендә үткәрелгән әдәби форумнар, саный китсәң, бихисап. Әмма миңа 1969 елда Әлмәттә оештырылган семинар, аннан алган тәэсирләр бөтенесеннән дә кадерлерәк. Анда Зәй, Ык, Бөгелмә, Чирмешән, Агыйдел елгалары төбәкләреннән бик күп яшьләр җыелган иде. Танышабыз. Аралашабыз. Шәһәр үзәгендәге кунакханәдә менә дигән урыннар әзерләнгән. Ресторанда официантлар баш иеп кенә каршы алалар. Иртән дә, кичен дә акча сорау дигәнне бөтенләй белмиләр.

Безнең каршыда нефть корольләре чыгыш ясый. Казаннан Әмирхан ага Еники белән шагыйрь Марс Шабаев килгәннәр. Зур-зур мәдәният сарайларында алар катнашында кичәләр уздырылды.

Семинарда Марс Шабаев минем дүрт йөз илле шигыремне тулыкманы белән күтәрде дә:

— Күпме вакытта яздың боларны?! — диде. Аның корыч тавышыннан мин куркыбрак калдым, ике айда, дисәм, сүгеп ташлар кебек тоелды.

— Бер елда... — дидем каушап кына.

— Бер ел эчендә шушы кадәр шигырь яздыңмы?! Нормаль хәл түгел бу!.. — дип Марс Шабаев мине битәрләргә тотынды. Ярый әле, ике айда дип әйтмәдем, дип эчтән куанып бетә алмыйм. Марс абый кайбер сүзне әйтер алдыннан тотлыгып кала, урт теше арасында нидер чыкырдап куя — сискәнеп китәсең. Җиңел гәүдәле, ап-ак чәчле. «Р» авазын йомырылап бетерми, французларча, тибрәтеп кенә уза. Тәмләп тәмәке тартканда да үткен-кырыс карашы үзгәрми.

Тәнәфестә килеп Равил Фәйзуллин аңа:

— Казанга укырга керә алса, бу егетне үзеңә ал, — дип минем хакта искәртеп китте.

— Маңгай астыннан сөзеп карый егетең, бик тешләк күренә, — диде Марс Шабаев.

Семинардан соң Гамил ага Афзал өендә шаулы мәҗлес узды. Без, яшьләр, бер тирәдәрәк утырабыз. Равил Фәйзуллин безнең тәртип өчен борчыла ахрысы, сынатмагыз, дигән кебек һәммәбезнең җилкәсеннән кагып-кагып киткәли. Юкка борчыла, безгә әле сындырып сыный торган Казан мәркәзендә кайнаган шагыйрьләргә җитү кая, «бөеклек» авыруы да йокмаган, хәмергә дә әллә ни исебез китми. Кителе генә түгел, күнеле дә портупея белән тарттырылган офицерлар мохитеннән соң миңа монда бар да кызык, чын безнеңчә милли тоела.

Өлкәннәрдән Шамил Бикчурин белән Мәхмүт Хәсәнов алданрак кызышып өлгергәннәр. Мәхмүт ага җәелеп утырган, аптыраганнан гына бөдрәләнгән шикелле саргылт чәчле башын кәнәфи артына салып черем итә. Табынның ганимәтле шавын түш белән өн арасындагы урталыкта тотып ул бик сак йоклый, мин монда, дигән шикелле, вакыт-вакыт ухырып, аваз биреп куйгалый иде.

Шамил Бикчурин исә гел үзе генә сөйләп торырга тиеш дип саный. Озын, какча гәүдәсен урталай сындырып өстәл артыннан калкуга, мул чәчләре, түбә саламыдай, ике яклап ишелеп түшә дә тар йөзен томалап

куя. «Үтә күренмәле», ябык бармаклары белән ул чәч учмасын артка яткырып куя гына, сүз әйтергә өлгергәнче, чәч учмасы тагын таралып төшә. Ул тагын кадерләп кенә чәчен артка таба сыпыра. Тыңлаусыз чәчен шулай тыңлата алмаудан үзенә бер ләззәт кичерә иде бугай ул.

— Диуаналар...

— Чип-чиста, зәңгәр күзле Шамил абыйның бу сүзенә берәү дә үпкәләми, чөнки ул аны шулкадәр җылы итеп, Сәйдәшнең «бәгырь» дигәне кебек яратып әйтә, шуның белән бу сүзнең мәгънәсен гөнаһсыз итеп калдыра. Кемдер аны җиңеннән тартып утырта. Ул олы бер фикер әйтергә теләгән кыяфәт белән тагын торып баса, әмма эчке уе белән сүз сөрешен тәңгәл китерә алмау сәбәпле, без ул әйтергә теләгән фикернең сәләмә хәрабәләрен генә шәйләгән кебек булабыз.

— Диуаналар...

Мәҗлес артык кыза башлагач, кемдер:

— Сезне бик тынычсызламыйбызмы? — дип табындагы иң өлкән әдибебез Әмирхан ага Еникигә эндәште. Борынгы Хазәр каганатының аксөякләре — яһүдиләр нәселеннән килгән кыяфәтле Әмирхан ага, башын иеп, үз-үзе белән эчтән киңәшеп алды да:

— Мәҗлеснең шулай булуы бик табигый,— диде.

Шул вакыт Гамил ага эчендә алтынсу күбекләре «сөйләшеп» торган шампанлы фужер күтәреп, иң шәп тостка конкурс игълан итте:

— Кем дә кем шушы шигырьнең калган ике юлын таба... Шуңа иң тәмле шәраб!

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мәхмүттер...

Барыбыз да кәнәфине сытарга җитешеп кырынайган Мәхмүт агага карап куйдык. Иң беренче яшь шагыйрьләр берәм-берәм чәчрәп чыгып шигырьнең соңгы юлларын әйтеп карадылар — атмый гына бит! Бәлки Гамил ага үзе уйлап та куйган булгандыр, шулчак Марс Шабаев кул күтәрде, кулына ияреп үзе дә сикереп торды. Без аңардан әллә ни өмет итмичә генә тыңларга әзерләндек. Әмма ул бер дә тотлыкмыйча ярып салды:

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мәхмүттер.
Мәхмүтнең тын утыруы —
Үзе зур бер бәхеттер!

Шәп бит шабайгыры! Табын күкрәтеп кул чапты. Шампанлы фужер Марс абыйга таба йөзеп китте. Мәхмүт ага да башын күтәреп, шатлыклы гүләүләргә үзенең гөрелдәве белән кушылып алды. Табын гүли... Табын кыза... Нәкъ шушы кешеләр белән нәкъ шушындый мәҗлесне мәңге кабатлап булмаячак. Бу мизгелдә ул турыда уйламау бәхете бирелгән безгә. Гамил Афзалның хатыны чибәр Нәфисә апайның бер-бер артлы өстәлгә куна торган тәмле ризыклары арасында тәнәфес игълан ителгәч, тәмәкеләп алган бер арада Марс Шабаев — баягы җиңү шатлыгыннан аның кәефе тагы да күтәрелгән иде — мине читкәрәк алып китте:

— Казанда шигырьләрне күтәреп туп-туры үземә киләсең. Фәйзуллиннар буынын мин тартып чыгардым әдәбиятка. Шактый чиләнергә туры килде алар белән. Монысы тыңлаулы иде арада,— дип ул Фәйзуллин ягына ымлап күрсәтте.— Менә Рәдиф Гатауллин дигәне бар әле Казанда. Баргач, танышырсыз. Ашыкма шигырьләреңне бастырырга, сабыр ит, вакыты җитәр, шаулап килеп керерсең, дим. Юк, һаман үзенекен тукый. Давыт Сөнгатовлар, фәләннәр басыла бит әнә, нигә мине тыясыз?! Болай булмый, асылынам! — дип дулый башлый. «Мә каешны!» — дип мин аңа бил каешын салып бирәм... Әнә, хәзерге көндә ул әйткән Давыт Сөнгатовлар-фәләннәрнең әдәбиятта эзе дә юк, ә Рәдиф

Гаташ беренче өчлектә бара! Менә шулай, дустым... Сизеп торам, синең белән дә авырга туры киләчәк...— дип Марс Шабаев, каты чикләвек ваткан сыман, урт тешләрен шыкырдатып куйды.

Мине куркыта да, ымсындыра да бу ләззәтле һәм газаплы иҗатка илтәчәк язмышым. Әмма шунысы күңелне җылыта: олыны олы, кечене кече итә белгән, тугандаш бер гаилә кебек әдәбият дөньясының бик күп аяк эзләрен хәтерләгән бусагасы төбендә басып торуымны аңладым мин. Бу ишектән кергәннәр кире чыга алмый инде...

* * *

**А**битуриент... Бу сүз миңа ят яңгырашы, аңлашылмавы белән ошаган иде. Университетка керү имтиханнары биргәндә мин аны иңемдә таш кебек йөрттем дә, студент булгач, кагып төшердем.

Кай арада укулар да башланды. Тәрәзәсеннән Идел, Ослан таулары күренеп торган аудиториягә ул сиздермичә генә, песи йомшаклыгы белән басып килеп керде. Җитез генә түргә узышлый, үзалдына сөйләнгән кебек итеп:

— Мин — Мөхәммәт Сөнгатович Мәһдиев булам. Сезгә татар фольклорын укытачакмын,— диде дә кафедра янына барып кырын басты. Мин белгәнне сез белмисез, сез белмәгәнне мин беләм, дигән вәкарьлек белән әрле-бирле йөренә-йөренә сөйли дә башлады.

«Эллада... Грек мифлары... Кешелекнең гүзәл балачагы...»

Көтмәгәндә шулай безнең эраның аргы ягына «сикерүе» белән ул игътибарыбызны җәлеп итте. Профиль шәп. Маңгай өстеннән башланып, муенга кадәр төшкән күперенке, пөхтә таралган чәч. Зур чалма кигән очракта да әллә каян күренеп торырлык нәселле борыны озынча йөзенә күркәмлек бирә. Бүтән бер заман булса, вәгазь сөйләп, авызына каратып, табын сандугачы булып йөрисе ахун кыяфәтле. Кара костюмы гына бер-ике размерга зуррак шикелле — иңе салыныбрак тора. Гадәттә, сугышка кадәр туганнарның шулай була: әткәсеннән йә абыйсыннан калган мул кием киеп үскәнгә күрәдер, алар тәнгә чат кына ятып торган өс киеменә күнегә алмыйлар...

— ...Сиреналар утравыннан ишетелгән кызлар җыры күпме корабларны тукталырга мәҗбүр итә. Элладаның гаярь ирләре шул утрауга төшәләр дә... гаип булып, туган якларына мәңге әйләнеп кайта алмыйлар. Одиссей исә бу мәкерле утрауга җитәрәк, бөтен матросларын да трюмга бикли, үз-үзен мачтага бәйләп куя. Сихерле җыр-моң яңгыраган утрау яныннан алар, тукталмыйча, хәвеф-хәтәрсез генә үтеп китәләр...

Сүз күәсенә бирелеп, Мөхәммәт ага, яхшы айгыр кебек, башын астан-өскә, өстән-аска чайкап-чайкап ала. Мут карашы белән текәлебрәк караса, чибәр кызларның күзендә тояклар уйнап ала. Мин авылның идарә капка төбендәге алгы аякларын биетеп торган райком айгырын күз алдына китерәм.

Бәрхет тавыш, бернигә дә карамыйча, без авыл гыйбадларын Олимп тавыннан Аллалары күзәтеп торган Эллада илендә, Эгей диңгезенең кипарислы ярларында йөртә.

— ...Одиссей хушлашканда сөйгән хатынына: әгәр кайта алмасам, киткәнемә нәкъ унсигез ел тулган көнне кияүгә чыгарсың, дигән. Менә бүген Одиссей киткәнгә унсигез ел тулган көн. Гүзәл Пенелопаның ишегалды тулы кияү егетләре, төрле ил-шәһәрләрдән килгәннәр. Кияү егетләре, ярышып, Пенелопа каршында үз көчләрен күрсәтергә тиешләр. Әнә, бер урынга унике балдак тезеп куелган. Шул алтын балдаклар эченнән, берсенә дә тигезмичә, ук атып чыгарырга кирәк. Әмма Одиссейдан калган җәянең керешен тартырга да кияү егетләренең көче җитми. Шул чак ишегалдына йөзен сакал-мыек баскан сәләмә киемле

бер мөсафир килеп керә. Егетләр аны мыскыллап каршы алаларЮлаучы ук белән җәяне ала да иңрәеп тартып җибәрә, ук сыгырып, унике балдак эченнән атылып чыга. Шул мәлдә Телемах әтисе Одиссейны танып ала...

Мин бу кыйссаны сулышсыз калып тыңлыйм. Шушындый да могҗизаи әсәр язылган микәнни дөньяда. Моңарчы нишләп белмәгәнмен мин боларны, юк-бар укып күпме вакытымны заяга сарыф иткәнмен.

Мөхәммәт абый бер тынга сөйләгән җиреннән вакыт-вакыт пауза биреп ала, иреннәрен елмаерга көйләгән сыман киереп, кинаяле-мут караш ташлый: «кеше чыгар микән сездән, мокыткайларым...»

— Сезгә Элладаның бөек шагыйре Гомерның, сукыр Гомәр инде ул безнеңчә, «Илиада», «Одиссея» поэмаларын укып чыгу мәҗбүри түгел. Китап тышлыгының нинди төстә икәнен әйтсәгез, имтиханда шул җиткән...

Укытучының бу сүзе мине аптырашта калдырды. Шушындый гаҗәеп вакыйгаларга бай поэмаларны укымау гөнаһларның гөнаһы булыр иде. Тәнәфес булуга, аудиториядән атылып чыктым да китапханәгә йөгердем. Шактый авыр китапларны әләктереп чыктым, менә хәзер шаулы шәһәр галәменең тыныч бер почмагын табам да ерак гасырларга кереп чумам, олы ләззәт кичерәчәк күңел хәтта түземсезлектән рәхәт калтырый сыман.

Юк икән, бакый мөгарә ишеге алай җиңел генә ачылмый икән шул. Шактый авыр тел белән метеклэп язылган бу дастаннарны укып чыгарга гаять зур түземлелек, тәндә йөгергән кан тибешенең сабырлануы, акыл утыруы, атлы гасырларны юксынырлык олыгаю кирәктер ахрысы. Иртәрәк, иртәрәк әле миңа бу поэмаларга тотынырга. Урыс шагыйре Николай Рубцов (бәлки ул иртә үләсен алдан сизенеп ашыккандыр), «Илиада»ны укып чыккач, без язарга хыялланганның барысы да монда әйтелгән икән инде, дигән. Нурихан ага Фәттах унике мең бер йөз юллык «Одиссея»не илле җиде яшендә иҗат йортында — Пицундада укып чыкты. Диңгез ярына килә, үҗәт-чандыр гәүдәсен йомарлап кызган ташлар өстенә утыра да... берегә китапка. Вакыт-вакыт күзен ял иттерергә дип башын күтәрә, чибәр, яшь хатыны Руфия ханымның судагы чыр-чу эченнән ерак китмәгәнлегенә инангач, тынычлап, тагын китапка иелә. Йөрәгендәге ярле атын кешнәтеп, шанлы дәверләргә китеп бара. Абхазия кояшы астында ял иткән егерме дүрт көн эчендә поэманы ул тулысынча укып чыкты, шактый битләренең кырыена үзе генә белгән тамгалар да төрткәләгән иде.

— Төрки-татарга караган шактый нәрсәләр бар монда,— диде серле канәгатьлек белән.

Әгәр җирдә кешелек тарафыннан кылынган золымны — бер тәлинкәгә, «Илиада» белән «Одиссея» дастаннарын икенче якка куйсаң, тарих бизмәне тигезләшер, инсанның яшәвен акларга мөмкин булыр иде.

Үзен шагыйрь санаганнарга бу дастаннарны кайчан да булса бер укып чыгу зарурдыр. Теге дөньяда, гарше көрси каршында җавап тотканда, һичшиксез, бу дастаннар хакында да чын шагыйрьләргә сорау бирелер дип фараз итик... Мөхәммәт аганың лекцияләрен язып бару мөмкин түгел. Шулкадәр тәэсирле сөйли — каләм-кәгазь кыштырдатып, бу илаһи мизгелне бозарга берәү дә җөрьәт итми. Сугыш чоры фольклорына җиткәч, ул Гадел Кутуйның нәсерен яттан сөйләп безне сулышсыз калдырды.

«...Сагындым, бик сагындым сине, туган ил! Мин шаулап аккан елгалардан, тирән коелардан алып сап-салкын су эчәм. Әмма күпме эчсәм дә, сусавымны баса алмам. Мин үз илемнең борынгы Иделен, Тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам...»

Аудитория бер йөрәк булып кысылган. Күзләргә яшь килә. «Бегемот» дип йөртелгән бинаның икенче катында утырабыз (Дәүләт музее бинасы, бездән өске каты бүгенге көндә сүтеп ташланды). Күңел нечкәрүен тыю өчен, таяныч эзләгәндәй, тәрәзәгә карыйм. Аннан ак диварлы Кремльнең

Спасс манарасы, алтын уклы сәгате, узган гасырлар ташы түшәлгән урам-мәйдан, Муса Җәлил һәйкәле күренә.

«...Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем. Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!..»

Күңел касәләре мөлдерәмә тулганны сизенеп алган Мөхәммәт ага нинди дә булса кинаяле, нинди дә булса йомры сүз әйтеп, аудиторияне бушандырып ала. Берчак шулай сүз арасында, артык басым ясамыйча гына: «Галимҗан Ибраһимовның «Татар хатыны нилэр күрсәтми» дигән әсәре бар бит әле...» — диде дә, гадәттәге рәвешендә кырын басып, бер мәлгә тынып калды. Көтә бу. Утыз шәкерт арасыннан бер мәхлугы табылмый кала димени! Әнә бит, ярып та салды:

— «Татар хатыны нилэр күрми» бит ул, Мөхәммәт абый!

Әһә! Булды! Корбанын күргәч, ташланыр алдыннан бөркетнең канатын төзәтеп алуы кебек рәхәтлек кичереп, Мөхәммәт абый калкынып куйды һәм:

— «Татар хатыны нилэр күр-сәт-ми» дидеммени? Ялгышканмын... Рәхмәт сезгә...— дип яңакларын буразналап төшкән сызыклар арасына елмаюын яшерде, Галимҗан Ибраһимовның халык иҗатына мөнәсәбәте хакында сөйләп китте.

Беркөнне ул тәрәзә ягына ымлап, Муса Җәлил һәйкәленә игътибарыбызны юнәлтте дә:

— Әнә бит, һәйкәл куйдылар Жаботинскийга. Шагыйрь һәйкәле шундый була димени! — дип чын йөрәгеннән ачынып әйтте. Штанга күтәрү буенча дөнья чемпионы, өреп кабартылган кебек гәүдәле Жаботинский сурәтен ул елларда күпләр белә иде. Мин Җәлил һәйкәленең рәсемен ясарга Азнакайдан махсус килеп киткән идем. Һәйкәл ничек бар шулай минем аңымда сурәтләнеп калган иде. Шуңа күрә Мөхәммәт аганың бу фикерен үз вакытында кабул итә алмадым. Әмма аның фикере, гел хәтергә төшкәләп, аңыма йогынты ясый торды. Шагыйрьгә һәйкәл... Ул нинди булырга тиеш? Революциядән соң, гомумән, сәнгатьле һәйкәлләр куелганмы?

Дистә еллар үткәч, бер мәҗлестә Мөхәммәт аганың «...шагыйрь һәйкәле шундый була димени...» — дигән фикерен искә алган идем, ул, ялтырып китеп:

— Чынлап та шулай әйттеммени? Жаботинский дидем, ә?! Кара инде, мин ул чакта кыюрак булганмын икән! — дип балаларча сөенгән булды. Әйткәнен әллә чынлап оныткан иде, әллә инде бүтәннәр хәтерендә дә ныграк калсын өчен юри кыланган булды...

Беренче курсны тәмамлар алдыннан Мөхәммәт ага без егетләр адресына мондыйрак фикер әйтеп куйды:

— Бер-ике ел да үтмәс, кайберләрегезнең шигырьләре журналларда басыла башлар. Аннары инде рестораннарда, банкетларда очрашырга туры килер. «Әй, син, тартырга бир әле!» — дип фильтрлы сигаретны кулдан тартып алучылар да булыр.

Без моңа ышанасы килмичә, елмаешып куйдык. Ә Мөхәммәт ага үз башыннан кичергәннәрне сөйли икән. Дөнья гел хәрәкәттә, кабатлана тора шул...

* * *

Фарсы теленнән Мостафа ага Ногман укытырга тиеш икән. Ниндирәк ул — яшьме, өлкәнме, усалмы, юашмы — көтәбез. Кыңгырау чылтыраганнан соң ул бераз соңарыбрак килеп керде. Кара шәп костюм кигән, ап-ак күлмәк, галстуктан. Туры текә маңгаен каймалап төшкән бөдрә чәч. Башны артка ташлабрак горур тота. Көязлеген яшерми, безнең күзләрне көзге итеп үз-үзенә читтән карый белә иде ул.

Фарсы теленә үтәли гашыйк, бу борынгы телнең бер-берсенә тәңгәл үрелеп барган сүзләрен көйгә салып әйткәндә, Тәһранның фирүзә гөмбәзле сарайларыннан чыккан урта гасырлар зыялысы кебек, чын шәрекъ кыяфәтле чибәр йөзе аның илһамланып яктыра, эчтән нурлана иде.

— На-ма-ре-сан... Нинди матур яңгырый, ә?! Хат ташучы дигән сүз була. А-һәң-саз...— Мостафа ага сузып әйтә дә, шул сүзнең күңелендәге кайтавазын тыңлаган сыман, башын кырынайтып, бер мәлгә оеп тора.— Аһәңсаз... Композитор дигән сүз.

Шуннан соң ул тактага гарәп хәрефләре белән сүзләр яза башлады. Гаҗәп житез, гаҗәп җиңел яза — исебез китеп карап торабыз. Бармак арасыннан сүзләр савылып кына бара. Бу хикмәтле хәрефләрнең үрелмә камиллегендә гасырлар сере, ата-бабаларыбызның җан тибрәнеше чагыладыр кебек. Акбур белән язылган ак юллар, озак карап торгач, миражга әверелеп, сәфәр юлыннан тезелешеп барган дөя кәрваннарын хәтерләтә. Бу кәрваннарга ияреп китә алмыйбыз инде, без — бүтән яссылыкка ыргытылган, ата-бабалар рухыннан төшеп калган, тарихның үги милләт балалары...

Кышкы буранлы көннәрдә дә Мостафа ага өеннән килешли Кремль күперен җәяүләп кенә чыга, аудиториягә бит очлары алланып, тәмам яшәреп килеп керә иде (ул чакта аңа илле җиде яшь булган). Юлда туган шигырен ул баскычтан менешли, гарәп имлясы белән тиз генә язып куйган була, безнең алда, күн папкасыннан ачып ала да:

— Менә, улларым, кызларым, юлда яңа шигырь яздым, тыңлап карагыз әле,— дип көй сорап торган шигырен җырлатыбрак укып җибәрә. Без, күп нәрсәне инкяр итеп, бөек булырга җыенган егетләр, аның артык самими шигырьләреннән көлеп утырган булабыз. Ярый әле кызларыбыз итагатьле, бер-берсен уздыра-уздыра мактап, укытучы-шагыйрьгә канат куялар. Аеруча Шәмсия Җиһангирова (ул чакта Гарипова) көчле тавыш белән башкаларны басып китә. Арттырып җибәрмә, ышандыру көчен бетерәсең, дип мин аңа астан төртеп куям.

Мостафа ага фарсы теленең аһәңен безнең күңелләргә оеткы итеп салыр өчен артистланып та ала, менә ул чибәр кыз янында туктала:

— Мән то-ра хейли дустдорам (Мин сине бик яратам),— дип кызыйның иңеннән сыйпап куя, чәченә кагылып китә.— Мән монтазәре то һәстәм, чера то нәмирәви? (Мин сине көттем, син нишләп килмәдең?) — Бу мизгелдә аның күзләре мут очкыннар чәчеп кысыла, иреннәре сөйкемле бөрешеп килә, бөтен вөҗүденнән дәрт ташып тора иде.

Кызганыч, ата-бабалар мәдрәсәдә җиңел өйрәнгән бу телне без өйрәнә алмадык. Укыту методикасы башны бутау өчен махсус эшләнгән. Мостафа ага Ногман, башка укытучылар кебек үк, ул кысаларны җимереп чыга алмый иде шул.

Дәрес азагындарак, Мостафа ага шигыренә язылган берәр җырны, Тукай әйткәнчә, авызны кәгазь калынлыгы гына ачып, күмәк җырлап алабыз. Моны тавышы белән дә, кыяфәте белән дә Нонна Мордюковага охшаган Шәмсия башлап җибәрә. Юк, юк, дәрес вакытында ярамый, дип Мостафа ага юаш кына каршы килгән була, аннары үзе дә җырга кушыла, дирижерлык итә, сабый бала кебек, сөенеч дулкынында йөзә иде. Кемдер тавышын көчәйтеп җибәрсә, ишек ягына ымлап кисәтү ясаган була, рәхмәтле карашына күләгә төшермичә генә, рәтләр арасыннан йөри-йөри, җырның азагына кадәр безне бер учта тота иде.

Журналистика бүлегенә күчкәч, уку сәгатьләре туры килмәү сәбәпле, мин фарсы теле дәресләренә тәртипле йөри алмадым. Имтиханны да ничек кирәк алай биреп чыккан булдым. Шуннан соң инде Мостафа аганы сәнгатьтә исем-дан алган ханымнар уртасында театр холларында, концерт залларында читтән генә күргәли идем. Университетны бетергәнгә ике ел узгач, нәшрият бинасында мин аны якыннан күрдем. Шагыйрь Зөлфәт белән киң баскычлардан төшеп килә иде. Күрешкәч, Мостафа ага иңемә кулын салды да, Зөлфәткә борылып:

— Менә, бу улым фарсы телен бик үк өйрәнә алмады. «Җ» белән «Х» хәрефен аера алмаса да «дүртле» куеп чыгардым имтиханда,— дип яратып кына көлгән булды. Шул мәлдә игътибар иттем: Мостафа аганың безне укыткан чактагы тере-бөдрә чәче үзгәргән иде. Картайган димим, ничектер, арган шикелле, учак урынындагы көл сыман сүнгән кебек тоелды миңа.

Бу — соңгы күрешү дип кем уйлаган. Ике көннән көтелмәгән хәбәр: дачасында... йөрәктән... (1976 елның 4 сентябре). Язучылар союзы коридорына куяр өчен миңа, аның фоторәсемен кара кайма белән әйләндереп, вафаты хакында кара хәрефләр белән язарга туры килде. Ирексездән күзгә яшь килә. Без аны вакытында аңламаганбыз. Әдәбиятта ул кадер-хөрмәт күрмәде шикелле. Ул бит шигърияткә, милли сәнгатькә чын йөрәктән бирелгән эчкерсез шәхес иде. Онытылмас җырлары гына да ни тора! Талант нинди микъдарда иңдерелгән — анысы инде Аллаһы кодрәтендә. Якыннан белгән беренче язучыны югалту, беренче тетрәнү иде минем өчен. Кеше кадерен, тормыш мәгънәсен аңлауга үлем дигән хакыйкать аша килүнең ачынулы күз яшьләре иде бу.

Мостафа аганың мәшһүр аһәңсаз Рөстәм ага Яхин белән язган «Бөдрә таллар» җырын мин бүген дә тыныч гамь белән тыңлый алмыйм. Әллә каян, бәгырьдән әрнүле сулкылдау күтәрелә дә... назлы моң үзе үк сине өметсезлектән йолып алып, тирбәтә, юата башлый, талгын сагышлы халәткә кереп җаның тынычлана, чистарып кала. «Бөдрә таллар» — шагыйрьнең дөньялык белән бернинди үпкәсез, якты сагыш белән бәхилләшү җыры булгандыр кебек тоела миңа.

* * *

Төннәрен бөтен тәрәзәләренә балкып торган карабны хәтерләткән студентлар йортының без дүртенче катында, шәһәр ыгы-зыгыларыннан өстен биеклектә яшибез. Тимер юл кырыендагы бу калкулыктан заманында большевиклар шәһәр ягына каратып туптан атканнар, шуңа күрә Арча кырының бу төбәге «изге урын» санала, урамыбыз да Кызыл позиция дип атала.

Шагыйрь әйтмешли, «кефир малае» — студент халкын өч омтылыш алгысытып яшәтә: мәхәббәт, ачлыктан курку, белемгә сусау... Алдагы икесе үзеңнән тора, ә менә укуга килгәндә... Толстойлар, Горькийлар укып үскән акыл хәзинәсе безнең дәвер өчен тыелган. Платоннарны, Ницшеларны укыйсы, чит телләр беләсе, кырыс тормышта югалып калмас өчен яшәү фәннәрен өйрәнәсе килә дә бит. Ярамый! Баш очына күзгә күренмәс «ярамый» кылычы кылга асылган. Грекларның безнең эрага кадәрге V—IV гасырлардагы гимнасийларыннан көнләшерлек. Кадими мәдрәсә шәкертләреннән көлгән булып, үзебез дә шулардан ерак китмәгәнлегебезне дә беләбез югыйсә. Ләкин...

Коммунизм тәгълиматына ышанган кебек шикелле кыяфәт чыгарып студентлар имтихан тоталар, укытучылар җитди рәвеш белән, ышанган кебек шикелле имтихан алалар — ил буенча әнә шулай гигант спектакль, рухны кимсетә торган икейөзлелек уены бара...

Әмма яшьлекнең үз кагыйдәләре. Хыялның биш кеше гомеренә тапкырланырлык чагы. Канат очын кисә торалар, урынына яңасы үсә тора. Дүрт кешелек «каютабыз»ның шыксыз ярлы стеналарына җан кертим дип, һәр караваг турына рәсемнәр ясаган идем. Бүтән группа студентлары да бу рәсемнәрне карарга кереп сокланып чыгып китәләр иде. Беркөнне, яраннарын ияртеп, тулай торак коменданты бүлмәбезгә бәреп керде. Запастагы полковник, матурлыкны җимерү һөнәренә өйрәнгән империя солдафоны соклану дигән хистән мәхрүм иде шул. Безне куып чыгару белән янап сүкте-сүкте дә, буяучыларын чакыртып, стеналарны яңадан элекке хәленә кайтартты. Болай да шәп икән лә, стеналар ялангач

булса, игътибар читкә юнәлми, үз күңеленә генә төбәлә. Ә анда — шигърият коесы...

Дүрт төрле холык сыйган бүлмәбезнең уртак тәрәзәсе поездлар үтә торган тарлавыкка карый. Тоннельнең кара авызыннан шым гына сузылып чыккан поездны яшел еланга охшатып — мин, шәһәр тәненә кадалучы энә белән чагыштырып — Фәннур Сафин, шигырьләр дә язып ташладык...

Бүлмәнең шигърият аурасын ерып йөрүчеләрне сурәтләп китик. Минем каршыда, тәрәзнең сул ягында Мөслим яғы егете Наис Гамбәров караваты.

Ул үзе укыган Уразмәт мәктәбен яратып искә ала, мин ул йотылып сөйләгәннәрне кызыгып тыңлыйм һәм шулкадәр ачык итеп күз алдыма китерәм... Менә ул — әтәчләре чын татарча кычкырып таңны уяткан, зәңгәр кое сиртмәләре Чулпан йолдызга терәлгән, ягымлырак булсын өчен «аем»ны кушып, бармаем, кайтмаем, дип сөйләшә торган — Уразмәт атлы авыл. Мәктәп гөр итә. Күтәренке рухлы алтмышынчы елларда тагын бер вакыйга — яңа укытучы килгән. Казаннан. Шагыйрь!..

Байроннарча, күлмәгенең ак якасын өскә каратып кигән Рәдиф Гаташ, башын артка ташлабрак, эре бөдрә чәчләрен кыю селкеп, партага таянып шигырь сөйли. Мәктәп сулышсыз калып тыңлый. Гаҗәп бит, үзе укытучы, үзе шагыйрь...

Сары яфракларны куып йөрткән сентябрь җиле яңа хәбәрне авыл буйлап тарата. Рәдиф Гаташка әсир калып авызы ачылган Уразмәт малайлары, бераздан аңга килеп, үз горурлыгына кайталар.

— Беднең үдебеднең дә шагыйребед бар. Дәлфәт Маликов! — дип җиффәрәләр. Такташның зәңгәр күзләрен Тәңре мирас иткән Зөлфәт исә каһәр суккан шөпшә чагу аркасында мәктәпкә килә алмаган, шешенке чыраен ватык көзге каршында салкын су белән чылатып өендә ята. Дәрестән соң малайлар аның өенә бәреп керәләр.

— Нишләп ятасың! Укытучы булып шагыйрь абдый килде. Рәдиф Гатауллин!

— Ишеткәнем юк андый бердәнбер шагыйрьне! — ди Зөлфәт.

— Тор әйдә, киттек мәктәпкә! — дип нык, каты кул Зөлфәтне селкетеп торгыза. Бусы — Наис Гамбәров.

Әнә шулай шигърият җенен алып килгән бер кеше аркасында Уразмәт мәктәбе лицейга әверелә. Бөтенесе дә котырынып яза, рәсем ясарга тотына. Әдәбият «чире» авыл агайларына да йога. Хәтта, Фәрит Гыйльметдиновның абыйсы көтүче Хираҗ да: «Тулстуй малаҗис, «Әннә Кәрининә»се үде бер роман бит аның», — дип, язучыларны үз күзе белән күрергә теләп, Мөслим белән Казан арасын бер итеп йөри башлый. Үзен яраттыра, Батулла әсәрләренә холык-кыяфәтен үзгәртмичә керә. Бервакыт ул Тукай клубында язулчыларның ел йомгаклары дип аталган шаулы җыелышында утыра. Соңыннан Хираҗдан «йә, ничек, Хираҗ абзый, ошадымы җыелыш?» — дип сорыйлар.

— Беднең колхуд җыелышыннан артык җире юк, инәңне шулай итәем... — ди Хираҗ, — чәйниләр дә су эчәләр... чәйниләр дә су эчәләр... Йөргән буласыд инде бер-берегедне макташып... Саный китсәң, инәңне шу-лай итәем... бу дөнҗада кулга тотардай ике генә ядучыгыд бар... Берсе — Лив Тулстуй да икенчесе — Әмирхан Җенеки...»

Уразмәт мәктәбе кайный. Телләрдә — Шекспирлар, Гамлетлар... Шул чорда Наис Гамбәр беренче шигырьләрен язып укытучысына күрсәтә, өметле каләмен тибрәтергә фатиха ала. Мөслимгә килгән Хәсән Туфан аның шакмаклы дәфтәр битенә утыртма хәрефләр белән тезеп язган шигырьләренә яшел каралы ручкасы белән матур тамга куя. Ак чәчле Дәвер үзе егетнең иңеннән сөя.

Наис һаман да әле шул мактау җылысында яши, университетта язып торуны кирәк дип санамый, безнең язганнарга да эчтән көлебрәк карый иде. Кичләрен ул штанга түгәрәгенә йөри, арып кайта да, караватына

чалкан сузылып, сакаллы ияге белән түшәмне «терәп» йокыга тала, без әле төнге өчләргә кадәр мәш килә идек.

Университеттан соң китап нәшриятында, классик китапларны гына редакцияләгән Рәис Даутов кул астында эшләп, саллы мәкаләләр язып, Наис Гамбәр дигән тәнкыйтьче калка, дигәндә генә... рәтләнә алмаган шәхси тормышы нигезеннән чатнады да... рәхимсез язмыш егетне Казан галәменнән читкә алып ыргытты. Менә шул чакта инде зәңгәр күген җуйган хыялы, рәшәткәле диварларга сыеша алмыйча, сыгылып бәргәләнгәндер дә, тирәндә йокымсырап яткан шигырь учакларын кабаттан тергезеп, җанын җылыткандыр. Бөтен ил зинданга әйләнгән кырыс елларда ышаныч күзенә карап, «Бәхет бар ул! Бар ул! Бар ул!» — дип әрнеп кычкырган өлкән шагыйрь мисалында үз-үзенә канат куя алгандыр.

Аннары мин Наисны туган ягында күрдем. Музей оештырып, борынгылык тәменнән исереп йөри иде. Чабагачлар, булат кылычлар, хаситәләр, күкрәгенә патша сурәте төшкән самавырлар, мамонт тешләре — кыскасы, ни генә җыймаган! Һәр әйбердән шигърият аңкый. Шул төбәктәге халыкның хәтере, тарихы, уй-хыялы, осталыгы әнә шул бакый әйберләр затлылыгына нәкыш булып өртелгән. Бүтән төбәкләргә үрнәк булырлык бу музейны — хәтер йортын тантаналы ачуга кадәр түзә алмыйча, Наис яшьлеге үткән Казанга ашыкты. Туган ягының тел коелары аңа көч-дәрман биргән, моңга бай урман-сулары рухын дәвалаган, күңелендә ятимсетелгән хис-тойгылары терелеп, сагыш-үкенүләр томаны аша сулкылдаган шигърият акны мәркәзи Казанга алгысыта иде. Калган икән бит әле кырыс башкалада кеше хәленә керә белә торган мәрхәмәтле Фәрваз Миңнуллин, Рәис Даутов кебекләр... Үзгәргән шул дөнья, үзгәргән. Күр инде, Наисның куе, шәп сакалына да, электәге кебек, төртмә сүз әйтүче юк. Алласын яшьлегендә җуйган, шәригать кушканча түгәрәк сакал-мыек йөртүдән мәхрүм картлар да хәтта бәйләнмиләр үзенә... Әйе, бер кергән елгага яңадан да кереп була икән, тик аның суы бүтән, колач салуларың да бүтәнчә шул инде...

Ниһаять, Наис Гамбәрнең соңга калып та соңармаган шигырьләре беренче китап булып басылып чыкты. Студент чакның шаулы мәҗлесләрендә Наис гел бер шигырь — «Сентябрь малае»н укый иде. Артык хискә бирелүдәнме, шигырьнең соңгы юлларын тәмләп йотып җибәрә, ничә тапкырлар тыңлап та мин ул шигырьне тулаем аңлап бетерә алмый идем. Хәсән Туфан сыйпаган бу шигырьнең азагын ниһаять, егерме елдан соң үз күзем белән уку бәхетенә ирештем.

Карт тупыллар уфылдап куя;
Сары күбәләкләр куна иңнәремә —
Сентябрь малае эзенә
Сентябрь яфраклар коя...

Наисның аяк очында — үтә кыска буйлы Илгизәр Сабиров ятагы. Кызлар бүлмәсенә керсәм, ул артымнан күләгә кебек иярә. Сүзгә катышмый, дымсу-калын иреннәрен җәеп, елмаю рәвешендә оеп тик утыра, вакыт-вакыт, тамак төбеннән чикаклау булып чын көлү хәбәре ишетелгәли. Мондый да рәхәт чигеп утырган тамашачың булганда очынмый нишлисең, йөзәм генә, сүзләр сәйлән кебек сибелеп кенә тора. «Нигә миңа ияреп йөрисең?» — дигәч, «Синнән мин кызлар белән сөйләшергә өйрәнәм, бер кыз белән дә йөргәнем юк бит әле минем»,— диде Илгизәр. Наис Гамбәр, якташы буларак, аны вак-төяк йомышка йөгертергә тырыша, малайсытып куйгалый иде. «Укып бетергәч, күп булса биш-алты ел үтәр,— дим Наиска,— Илгизәр энекәшебез мәктәп директоры булып, тыйнак кына корсак үстереп җибәрер. Без фәкыйрьләр яныннан, үз машинасында, тузан гына бөркеп үтәр». Илгизәр, гадәтенчә, ваемсыз елмаеп тыңлый.

Укуны тәмамлап, берничә ел үткәч, Наис болай диде:

— Илгизәрне күрдем. Син әйткәннәр барысы да дөрескә чыккан. Күрәзәче икәнсең...

Дүртенче бүлмәдәшебез — Фәннур Сафин. Аның караваты көянтә кебек бөгелеп тора. Хикмәт шунда: Фәннурның кайтып керүе гел бер төрле ритмда була, киемен салып шкафка элә дә капкачын шапылдатып яба, бөтен авырлыгын салып, гөрселдәп караватына килеп утыра. Без аңа әйтеп-әйтеп тә бу кыланышыннан туктата алмадык. Шагыйрьнең бүтән кешеләрдән үзгә бер сыйфаты булырга тиешлекне дәгъвалаучы мисал иде бу ахрысы. Фәннур кайтып керүгә үк аның караваты куркудан бөгелеп килә иде шикелле. Ул елларда йөзләгән милләт шагыйрьләренең урысчага тәрҗемә китапларын чыгаралар иде. Фәннур шул юка китапларны җыеп кайта да, кефир шешәсенә су тутырып кырыена куя, кырын ятып укый башлый. Үз хисен кузгатырдай берәр фикергә төртелсә, калын тышлы дәфтәрен, каләмен кулга алып, стенага таба борылып ята... Көне буе кузгалмыйча ятып ул дәфтәр битендә энә төртерлек тә урын калдырмыйча, сызган-бозган, өсте-өстенә язган сүзләр белән тутыра, шул вакыт эчендә дүрт-биш шешә су эчеп бетерә иде. Шигырьне ташбака күкәй салган шикелле хәйран интегеп яралдырса да, бер тында язган шикелле, йөгерек хис белән сәхнәдән укый белә иде.

Синең якка карап бер кычкырдым:
— Миңа булмас синнән башка яз!
Биек тауга килеп бәрелде дә
Егылып төште җиргә кайтаваз.

Фәннурның шигырьләре газеталарда басыла һәм ул редакцияләргә үз кеше булып кереп йөри иде. Мин дә дәфтәр битенә кулдан язылган шигырьләремне күтәреп, бусын укыгач аһ итәчәк, дип Марс Шабаев янына барам. Нәшриятның кечерәк кенә бер кабинетында ул шигырьләрне сүтеп ташлый. «Ну и что?» дип куймагыз әле шигырь азагына, дигәч, «Йә, шуннан?» — дип үзгәртә. «Бүтәннәрнеке дә минекеннән артык түгел, матбугатта басылалар бит», — дим. «Каешны салып биримме?!» — дип Рәдиф Гаташны искә төшерә. «Өлгереп җитмичә ашыкма! Менә күрерсең, бүген ашыкканнарның күбесе такмакчы булып кына калачак!» — ди. Мин, барыбер килешмичә, Марс Шабайга рәнҗеш, урамнан үз-үземә сөйләнеп, җыларга җитешеп кайтып барам. Берничә көн үткәч, хәрабәләргә әйләнгән шигырьләремне алып карыйм да... Марс абыйның урт тешләре арасында вакланган сүзләре искә төшә дә... кәгазьләремне читкә куеп, янә бер үҗәтлек белән яңаларын язарга тотынам.

Ике ел буе мин шулай, үз теләгем белән килеп, Марс Шабай каршында башны «бүкәнгә» куя идем. Бер көнне килсәм, остазымны бүтән кабинетка күчергәннәр. Кая диген, татар китаплары пирамидасының иң биек ноктасына, баш редактор итеп... Мин ике катлы ишекләрне шапышопы ачып килеп кердем дә, каушап туктап калдым. Еракта... түрдә... самавыр аяклы, бинаһая зур һәм калын имән өстәл артында, тау-тау кульязма-папкалар арасында бәләкәй генә ак баш күренә. Тез буыннарым калтырап, өстәл янына барып җиткәч, Ак баш Марс Шабайга әйләнеп күтәрелде һәм... күз алдында зураеп китте. Мин аны таныйм да, танымыйм да кебек. Менә ул, дөньяның кендегенә баскандай, тәмәкесен көллеккә басып сүндерде дә, сүз сөрешенә фаҗига төсмере биреп, кешене өметсезлек диварына терәргә һәм шул өметсезлектән чыгу юлын үзе үк өйрәтергә яраткан холкына тугры калып, миңа шундый фикер ташлады:

— Синең урында булсам, берәр заводта токарь булып эшләр идем. Сиңа тормыш мәктәбе узарга кирәк!

Күз карашында хакими салкынлык, бөердән чыккан тавышы — хакими кисәтүле иде аның. Шагыйрьне шытымда үтерә торган бу сүзләргә бүтән берәүнең ышанып куюы да ихтимал иде бит. Әмма миндәге үзсүзлелек Минзәлә кәлҗемәсе ашап үскәннәргә генә бирешә торганнар-

дан түгел иде. Ниһаять мин, бу затлы кабинетка дәфтәр битенә язылган фәкыйрь шигырьләремне тотып бүтән керә алмасымны сизенеп, хушлашырга ашыктым. Остаз белән ара ярты юлда өзелсә дә укучысы аны барыбер узарга тиеш... Еллар үткәч мин аңа, чын күңелемнән: «Шабай крематориен исән чыга алдым. Рәхмәт»,— дидем.

Безнең бүлмә кай ягы беләндер үзенә тартып тора, студентлар өзелми, мәҗлесләр еш була иде. Аспирантлар торагында яшәүче Азат Ганиев тә сирәк кенә булса да килеп чыга. Ул — группада иң өлкән яшьтә. «Тагын күченәбез» дигән китабы да чыккан булгач, мәктәпне генә бетереп килгән кызлар-малайлар өчен ул ата кебек тоела иде. Ул бик аз сөйләшкәнгә бик акыллы күренә, сагындырып кына елмая, бармагын борын буйлата яткырып, гел уйланып утыра иде. Үсмер чагында ул, поезд астында калып, сыңар аягын тездән өстә өздергән, протез аягына аксабрак йөри, үзе беркайчан зарлануны белмәс, күзләре тыныч, тормыштан канәгать күренә иде.

Беренче курсның беренче аенда безне эшкә җибәрделәр. Балтач районының Норма авылында без Азат, мин, Рөстәм Фәйзуллин (берничә елдан соң ул Акъегет дигән шагыйрь булыр) бергә фатирда тордык. Хуҗа абзый тома сукыр иде, күз нурлары да теленә күчкәнгәме, ягымлы сөйләшә, безгә матурым, дип кенә эндәшә, атна саен мунча яга иде. Мунчада Азат шагырдатып протез каешларын чишеп ташлый, ләүкә тирәли сыңар аякта титаклап йөри. Без аны кайнар пар белән пешекләп ду китереп чабабыз, ул, рәхәт кыраклап, түзеп ята, мунча ләззәтен ала белеп кинәнә иде.

Айлы төннәрдә су буендагы өянкеләр ышыгыннан кәбестә урларга барабыз. Азат, безне дә уздырып, койма башларыннан елгыр үрмәли. И ул Норма кәбестәсенең сусылдан-сусыл тәмлелеге! Ярыша-ярыша толыкманы белән ашыйбыз. Таза, яшь тешләр арасында кәбестә кетердәми, ә дөнья күкри сыман.

Ындыр табагында эшләгәндә ул авыл малайларыннан велосипед алып тора, хут белән җилдереп килә дә икмәк көшеленә барып керә. Велосипед белән бергә мәтәлчек ата-ата көшелнең икенче ягына ук барып төшә, без куркудан тынсыз калабыз. Ә ул, берни булмагандай сикереп тора да, сабыйларча сулкылдаган кебек итеп, иңнәрен сикертә-сикертә онытылып көлә. Велосипедның рулен турайтып, хуҗа малайга кайтарып бирә дә кулына агач көрәк ала. Йөзе шомарып беткән көрәкнең сабын көшелгә батырып куя, каршысына берәр кызны утырта, кесәсеннән рәссамнарда гына була торган юан карандаш чыгарып, сурәт төшерә башлый. Көрәк — мольберт, Азат — рәссам (ул Лениногорск сәнгать мәктәбен бетергән). Шулай итеп, сурәтле көрәкләр арта бара, без аларны эшкә җигәргә кызганып, читкәрәк алып куябыз. Безнең тарафтан «Фантомас» кушаматы алган, муены борылмас ындыр мөдире сүгенеп, көрәкләрне җыеп йөри. Бәләкәй генә түрә — «ярамый!» көен белә, каһәр!

Фольклор экспедициясендә дә Азат белән бергә туры килдек. Кичләрен концертлар куябыз, көндезләрен — өйдән-өйгә тел хәзинәсе җыю. Азат атна-ун көнгә түзде, гел уйда үзе, эчтән нииндидер гамь кимерә моны. Күпмедер вакыттан соң ул серен ачып салды: фантастик повесть язарга икән исәбе. Ачылып китеп әзер өзекләрен дә укытты. Аның космик киңлекләрдә ватылып калган ракетасы колхозның чытыр арбасы кебегрәк тәэсир калдыра иде. Тәнкыйтьләп ташладык үзен.

Бакалы ягында борынгы китапларны мәет белән бергә зиратка күмәләр икән. Утызынчы еллардан калган курку шаукымы һаман да бетмәгән күрәсең. Исән калган китапларны да бик үк күрсәтергә теләмиләр, яшерәләр, күңелләрен ачар өчен үтә сак, тәмле тел кирәк. Азат белән килеп кергән йорттан шунда ук кире әйләнеп тә чыгасың, тыңлап та тормыйлар. Тел ачкычлары — Фәннур Сафиндa, ул инде өлкәннәрне авызына каратып, күгәрчен кебек гөрли.

Шушы төбәктә йөргәндә без революциядән соңгы халык иҗатына хас бер җырга тап булдык:

Өйгә килеп кергәч тә
иң уртада — бер мич.
Бик вакытсыз үлеп киттең,
Быладимир Ильич.

Бер авылда мин Азнакай мәктәбендәге укытучым, математик Әхсән ага Туйкинның туганы белән таныштым. Фазыл Туйкиннар кебек үк, затлы нәселдән чыккан кеше буларак, ул да укытучы иде. Әтисе мулла булган. «Утызынчы елларда китапханәбезне өч ат йөге белән төяп алып киттеләр. Юк иткәннәрдер инде аларны. Тышлыклары алтын белән язылган фолиантларга кадәр бар иде»,— дип әрнеп сөйләде ул. Шулай авылдан-авылга йөри торгач, Фәннәр академиясен баетырлык шактый китаплар җыелды. Хатип ага Миңнегулов бер йортка ике көн буе барып, тәмам ышанычка кергәннән соң, кош тоткан кебек кайтты. Аның кулында — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы иде. Шәп сакланган калын тышлы китапны ул, сабый баланы тоткандай сак кына алып, озын бармаклары белән битләрен ачып сыйпый-сыйпый, безгә күрсәтте.

— Безнең ата-бабаларыбыз бу поэманы яттан белгәннәр, кулдан-кулга күчереп алганнар. Илнең төрле өлкәләрендә поэманың йөз иллегә якын күчермәсе табылды. Дрезден китапханәсендә дә бер данәсе саклана. Урысларның мактанычы булган «Слово о полку Игореве»нең чордашы бит югыйсә... Күпме янгыннардан, сугыш-кырылышлардан исән калган...

— Ә «Слово...»ның ничә данәсе табылган?

— Берәү диләр... Ярый әле, төп нөсхәсе янасын алдан сизенеп, Мусин-Пушкин күчереп язарга өлгергән...

— Тирәнгә кермик, егетләр! — дип Хатип ага, күзлек өстеннән сөзебрәк карап, безнең чишелеп киткән телләрне төйнәп куйды.

Сизеп йөрибез: таланган, туздырылганнан соң да әле һәр өйдә азмы-күпме китаплар сакланып калган. Әмма бу борынгы ядкярьләрдән җиңел генә аерылырга теләмиләр, иске татарча укый белгәнебезгә ышангач кына бераз йомшаралар, каядыр яшергән төенчекләрен бәгырьдән өзеп кенә чыгаралар.

Хозурлык бу якта, таулы ярлардан карасаң, офыккача япан киңлекләр ачыла. Ике республиканың чик сызыгы икәнен үзе дә белмәгән Ык елгасы, бормаланып, тугайлар кочагында иркәләнеп, тал тамырларына уралып ага. Кайчандыр Мәскәүнең Кремль большевиклары карта өстеннән канлы каләмен йөртеп чик сызганнар да... Азнакай ягындагы Урсай, Саскүл, Тымытык, Сарлы, Сөендек кебек авылларның җир биләмәләре елга белән бүленеп калган. Шуннан соң халык бирге якка чыгып, Яңа Урсай, Яңа Саскүл, Яңа Тымытык, Яңа Сарлы, Яңа Сөендек авыллары корып, «су»ны «һу» дип әйтергә тиешле республикада ике сәгатькә аермалы вакытка күчеп яши башлаган.

Урманлы тау куенына урнашкан гаҗәп матур авылда без татар әдәбиятына берьюлы ике язучы бирәчәк йорт каршыннан да үтеп киткәнбез. Агалы-энеле Зөлкарнәевләр — Фәиз белән Ләис такырайткан капка төбендә эчкә үтәргәме-юкмы дип үзара киңәшеп тә торганбыздыр әле. Университетның чын, тере студентларын күрергә дип Фәиз Зөлкарнәй Куштирәк авылына, безнең концертны карарга да килгән булган.

И ул Ык буе авылларының ак яулыклы, ак табынлы, каен яктыларына тиң түти-әбиләре... Унҗиде яшьлек кызлар кебек, бит очлары кызарып, оялып кына аяк башына карап торулары. Сөтле чәй табынын түгәрәкләп алгач, үзләшеп китеп, курай моңына ялындырып кына кушылып җыр сузулары...

«Кыланып утырмасана, Нуриәсма, син бу җак җардан җырлап җибәрсәң, Сөендек җегетләре, атыннан да төшеп тормыйча, Ыкны җөзеп чыга торганнарые...»

«Җә-җә, нәстәкәй дип иманга оеп утырасың, Шәмсенур кодагый, скрипкәңне чыгар, курай-кубызларыңны ал! Тымытыкның күпме дастуен җегетен акылдан җаздырдың җәшлегеңдә. Казан җегетләре каршында сынатып утырма, нибуч!..»

«И-и-и Бибинур кодагый, ул җегетләрне әйтәм, берсе дә әйләнеп кайтмады бит сугыштан. Аймыл итте җазмыш...»

Тәрәзә төпләрендә — ярмаланып чәчәкләнгән яраннар, тамчылап торган тамчы гөлләр, кашагаларда чүпләмле сөлгеләр, ярлылыгы да ягымлы йорт эче пөхтә җыештырылуы белән җанга сабыр рәхәтлек иңдерә. Борынгы моң-аһәңнән карчыклар күз яшен күрсәтмичә, күңел яше белән җылыйлар кебек. Ә тышта сентябрьнең тоҗымлы җиле тәрәзәгә сары яфраклар сибә. Ничә еллар узган инде — тавышлары истә, йөз-кыяфәтләре бүгенгедәй күз алдымда. И ул догалы, азанлы гасырда туып үскән әникәйләр, бисмиллалы әбекәйләр... Андый да нурлы күзле, бит очлары җиләк кагы сыман кызарып торган әбиләр бүтән кабатланмас инде. Кәбисә ел бураннары аларны мәңге аклык иленә, оҗмах катларына алып киткәндер...

Сәяхәтебез дәвам итә. Әрәмәле яр өстендә, кызыл маңгайлы таулар кучкарына урнашкан авылга килеп кергәч, аптырап, як-ягыбызга карана башладык. Кычыткансы-алабуталы бакчалар. Ихатасыз, кыеш-мыеш йортлар. Арада хәтта салам түбәлеләре дә күренә — сугышка кадәрге авылны кинофильмга төшерергә менә дигән манзара. Урыс авылы булып чыкты бу. Һавасы бүтән, өйләр каршында, җыбылҗык ис чыгарып, үзе хасил иткән лайлага чумып, тоз күзле дуңгызлар кинәнә.

— Безне коммунизмга илтәчәк өлкән туганнарыбыз менә шушылайрак яши, җәмәгать! — дип сөрән салган идем дә, дусларымның көлешүе сыеграк чыкты. Саксызрак әйтеп ташлавымны аңлап, мин дә сагаюлы тынлыкка кушылдым.

Бер йортның биек баскычыннан мендек тә, гадәтебезчә, аяк киемнәрен салып эчкә атладык. Ишекне ачсак... торараш калдык: каршыбызда — беләүләнеп беткән, пычак кайрарлык җир идән иде. Чебен җыелган өстәл янында гәҗит кәгазенә тәмәке төреп бер карт утыра. Түр почмакта — нәзек шәменә ут элеңгән икона.

Хәл-әхвәлләр сорашып, карт белән шактый гәп корганнан соң, урысларның кульязма-китаплары хакында да кызыксынып сораштык. Безнең нәрсә теләвебезне карт бик озак аңлый алмады, аннары, төшенеп алгач, тәмәке төтене белән ысланган мыек арасыннан шундый сүз әвәләп чыгарды:

— Илленче елгы пужарда Библиям янды. — Карт кызганыч иде, каядыр шәһәргә китеп олаккан малайлары моны бөтенләй онытканнар, кайтып бер дә күренмиләр икән. Түзеп утыра торгач, шуны да аңладык: өстәл куелган турда идән такталары шәйләнә, җир идән түгел икән лә, бары тик соңгы ун елда кырып юылмаган икән...

Карт болдырга кадәр озата чыкты, төтен бөркеп, ютәлли-ютәлли:

— Пужарда Библиям харап булды, — диде.

Икенче йорт баскычыннан эчкә үтә алмадык. Кап-кара яулыгын шакмаклы иягеннән үк төшереп бәйләгән, үткен карашлы карчык ишеккә аркылы басып, безнең белән бик теләп сөйләште дә, ниятебезне белгәч:

— Сатана китаплары тотмыйбыз өйдә! — дип кырт кисте.

Шуннан соң без, дуңгыз исе тешкә сылана башлаганчы дип, бу авылдан тизрәк китәргә ашыктык.

Авылны чыккач, Азат Ганиев черт итеп теш арасыннан төкерде дә:

— Боларда китап юклыкка татар-монгол гаепле, — диде. Киңаясен аңламый калуыбызны сизенеп, шәрехләп куйды. — Урысның дуңгыз баласы читәнгә кысылса да татар-монгол гаепле була...

Шушы сүз житә калды: студент кавеменнән бит әле без, тарих буразналары аша йөри-йөри тел чарларга җай чыкты. Академик Лихачевка да шактый эләктердек. Аның борынгы Русьта шаккаткыч укымышлылык,

гажәп китапханәләр хакындагы уйдырма әкиятләрен тетеп салдык. Хуҗа Насретдин шикелле, үз ялганына үзе дә ышанып, бүтәннәрне дә исертәм дип уйлаучы мондый академиклар борынгы баба, олы тарих ясау юлында, галимнәр дөньясында астыртын елмаю уятып, тамак ялына бүген дә хезмәт итә.

Дүрт йөз ел буена патша тикле патша хәзинәсе — Иван Грозный китапханәсенең табылмавы да сәер түгелме?.. Бу очракта «Клим Самгин» романындагы канатлы сүз искә төшә:

«А был ли мальчик?..»

Кызганыч, без ул чакта фикерләребезне юлның як-ягыннан озата баручы каеннар белән генә уртаклаша ала идек шул.

Азат Ганиев фольклор байлыгына үзе өлеш кертергә булды. Сәнәкчеләрдән өй түбәсенә качып, морҗаны кочаклап катып үлгән укытучы кыз турында бәет язды да җитәкчебез Хатип Миңнегуловка тапшырды.

— Таптым,— диде Азат.

Күсәк белән башка ору, бәкегә салу, асу-кисү, кан агызу кебек вакыйгалы, төннәрен саташып уяныплык бәетләрдән туйган булгандыр Хатип ага, Азатның дүрт куплетлы бәетен күз алдында укып чыкты да:

— Шәп бит бу! Профессионально! Талантлы шул безнең халык! — диде. Укытучының башы әйләнгән арада Азат кайтып китәргә рөхсәт тә алды.

Коеп яңгыр яуган көн. Тәрәзәдән карап, кызлар хакында гәп корып утырабыз. Ишек ачылган тавышка борылып карасак, Азатыбыз кул чемоданын тоткан, протез аягын бусаганың теге ягына салган — чыгып барышы.

— Әллә кайтып китәсеңме? — дип сорады Фәннур.

— Әһә,— диде Азат.

— Сау бул алайса!

— Әһә,— дип Азат чыгып китте. Без аның томалап яуган яңгыр эченә саллы адымнар белән кереп югалуын карап калдык.

Аның шул елны язган повестен проза белгечләре — искергән тузлар — басаргамы-юкмы дип икеләнгән арада «Казан утлары»нда Мөхәммәт ага Мәһдиевнең «Чишелеш нүлгә бетә» дигән мәкаләсе басылып чыкты. Басылмаган әсәргә карата мәртәбәле журналда мондый бәя бирелү — сирәк була торган хәл иде.

Әлеге шаудан соң Азат Ганиев университетта озак тоткарланмады. Кулы эш сорый иде ахрысы, белем мәгарәсенең ишекләрен шапылдатып япты да Бөгелмә-Әлмәт юлы өстендәге Габдрахман авылына кайтып китте. Толстой да шулай университетка кул селтәп, үз белемәсенә кайтып киткән булган. Әмма ул Толстой булу өстенә граф та бит әле... Коръән, Инжил, Талмудларны, кешелек тудырган мораль-этик философияне ул егерме яшенә кадәр үк аңына, канына сеңдергән шул. Язма акыл дөньясыннан үзенә тиңдәш Руссоны табып, философ иненә басып үз дөньясын ачарга үрелү аңа кыен бирелмәгәндер. Дөнья бәһасе шәхесләр белән көнаралаш сөхбәтләшеп тору да зиһенен чарларга ярдәм иткәндер. Азат Ганиев тә үз күңел тирәнлегенә төшәргә ярата, мәгълүматсыз кешене аптыратырлык гыйбарәләр таба белә иде. Әмма үзешчән философия — маңгайга кунган чебеннең «Мин — Сократ!» дип аваз салуы кебек тәэсир калдыра шул.

...Чишелеш нүлгә бетә...

* * *

Сәясәт ул — олы гайбәт. Шигърияттән туйган чакларда без студентларның гадәте — тыюлы сәясәт болынын таптап чыгу, бәхәс кузгату, акыл көрәштерү иде. Тулай торакның бүлмәдән-бүлмәгә күчеп йөрүче әрсез тараканнары (Аурупага бу хәшәп бөҗәкләрне урыс

солдатлары ияртеп бара, шуңа күрә алманнар тараканны «русак» дип йөртәләр) күпме булса, әйләнә-тирәбездә шымчы-сексотлар да шулкадәр. Без моны чамалыйбыз, әмма телне тыеп тору мескенлек санала, куркасың икән, одеал астыннан башыңны чыгарма!

Күпме еллар узса да, барыбер, сексотларны моңсыз мөһер сугылган эчтәлексез күзләреннән танып була. Ходай тәгалә кеше үтергән һәм кеше саткан бәндәләрнең күзендәге мәрхәмәт нурын тартып ала, һәм андыйлар күз алмасындагы каһәрле нокталарны мәчеттә көне-төне намаз укып та, кырык тапкыр тәүбәгә килеп тә кабаттан тергезә алмыйлар инде.

1971 елда кинәт кенә бөтен газеталар, радио-телевидение Леонид Ильич Брежневның төчкереген дә цитата итеп китерә башладылар. Без моңа башта көлеп кенә караган идек, ләкин бу чир торган саен ныграк тарала төшкәч, аптырап, күнегергә мәҗбүр булдык.

Референтлары чыгыш әзерләгәндә «экономика должна быть экономной» дигән кебек сафсата фикерләрне юри тыгып җибәреп генсекның үзен дә тәмам исәнгерәттеләр, офыкта аны икенче Ильич булу бәеклеге көтә иде.

Шул елда, йөзләрчә студент каршында:

— Брежнев культы башланды! — дип беренче булып ярып әйткән кыю профессор КПСС кафедрасы мөдире Рәфыйк Измаил улы Нәфыйков иде. Моның өчен аның башыннан сыйпамаганнардыр, махсус органнар тарафыннан нинди ау-ятьмәләр корылганын үзе генә беләдер.

Кешедәге баш миенең уннан бер өлеше генә актив эшли, калган ягын Аллаһы тәгалә запаска калдырган, диләр. Димәк, бер үк демагогик фикерне тамчылап тамыза торгач, адәм баласында битараф ышану, хайвани күндәмлек тудыру авыр түгел.

Адәм баласының ихтыярын яулау, аны маңкортка әвереллдерү алымнарына ирешү өчен галимнәрне эшкә җигеп, телепатия дулкыннары, нейроэнергетиканы яшерен лабораторияләрдә өйрәнеп, фәнни тәҗрибәне гамәлдә сынатып караган большевикларның бу өлкәдә нигезе нык иде. Идеология сөременә сукырларча бирешмәс өчен, һәр әйтелгән фикергә каршы бернечә тармаклы логик чишелешне секунд эчендә табу сәләтенә ия булу өчен күп укырга, акыл күнекмәләрен бер дә туктатмаска кирәклеген үз аңым белән чамалый идем мин. Мальтус тәгълиматының дөрескә чыгуын күрү, җирнең табигый байлыклары кими барганда муллыкка коенасы «якты киләчәк» хакында хыяллануның көлке икәнлеге аз гына мантыйгы булганнарга ул елларда ук ачык иде инде.

Гаҗәп бит, вак милләтләрнең алдануы бер хәл, ничә тапкыр цивилизация кичергән, ничә тапкырлар империя төзегән Күк асты иле — кытайларның алдануын, хунвейбинлык җүләрлегенә төшүләрен ничек бәяләргә? Ярый, халыклар бер хәл ди, Франция кебек рәтле илдә, җан һәм иҗат иреге тоеп яшәгән Ромен Роллан, тагын башка мәшһүр язучы әдип һәм сәнгатькәрләрнең Сталин гипнозына бирелүе акылга сыямы? Нәкышчырәссам Альфаро Сикейросның, автомат тотып, бер төркем башкисәрләр белән бергә Троцкийны атарга дип кирмән кебек йортына бәреп керүен ничек аңларга? Картиналарына төс аша җан өретүче һәм корал тотып җан кыючы бер үк кешедә гәүдәләнә түгелме?! Соңыннан ул, айнып, гомер буе үкенгән диләр. Болар бит барысы да тарихтан сабак алырлык шәхесләр. Тәхет биләүчеләрнең үз-үзенә һәйкәл куйдырулары, кояшка тиңләтеп ода җырлатулары, акыл ияләренең башын кистерүләр, соклангыч ораторлык сәнгатенә ышыкланган золым, азгынлык, шымчылык — болар барысы да Рим империяләре чорыннан килә һәм кабатлана бит югыйсә...

Соңлап кергән акыл аша мин үземә дә читтән карыйм. Сталинның гәүдәсен мавзолейдан алдыру вакыйгасын тетрәнеп кичергәнем хәтердә. Сталинград шәһәренең исемен Волгоградка алыштыргач, Хрущевка булган ачуым өчләтә арткан иде. Без беренче курсны бетергәндә Ватан сугышының егерме биш еллыгын бәйрәм иттеләр. Шул бәйрәм

алдыннан, Сталинград исемен кире кайтарачаклар, йөз-меңнәрчә солдатлар, үлем алдыннан шушы исемне кабатлап җан биргәннәр, шулар истәлегенә... дип, ярсып сөйләгәннәрем бүгенгедәй хәтердә. Ә инде Хрущевның үз гаепләре дә ачыла башлагач, кешегә кое казыма... дип эчтән сөенгән идем. Гомер буе Жуковтан көнләшеп, соңлап булса да түшенә аныкыннан да арттырып Алтын йолдызлар тезеп, «агач маршал» дәрәҗәсенә ирешәсе Брежневның да гаебен табачаклары минем башыма килми иде әле ул чакта. Баксаң, Рус тарихы Аурупа каршында акланудан, үзен аклар өчен гел гаеплене эзләүдән тора икән. Әнә бит, кыпчак рухлы Гоголь «Россиядә һәрчак гаеплене эзлиләр, нинди дә булса Ивашканы табып алып манарадан ыргыталар», дип бөек халыкның милли холкына үтергеч бәя биргән. Патшадан башлап көтүчегә кадәр гаепләнеп үтерелгәннәр урыс тарихында бихисап. Гаепне ничек итеп зурга җибәрү карангы-төмсә илдә ничек оста эшләнгәнлеге хакында бер мисал китерик. Аны Иван Грозный кул астында опричник булып хезмәт иткән Генрих Штаден язып калдыра. Олуг кенәз Иван IV кә гарәп белән бергә фил бүләк итәләр (Фарсы шаһы Таһмасп). Гарәпкә Мәскәүдә яхшы хезмәт хакы түлиләр. Моны урыс бражниклары (юлдан язган эчкечеләр) белеп алалар да гарәпнең хатынын талап, үтереп чыгалар. Бу чорда Русьта үләт чире таралган була. Бражниклар, эз яшерү өчен, Мәскәүдә үләт таралуга фил белән гарәп гаепле дигән хәбәр тараталар. Күзен кан баскан халык Мәскәүдә бөтенләй чир таралмаганлыгы хакында оныта. Фил белән гарәпне Городец бистәсенә сөрәләр. Яңа җирдә гарәп үлә, шуннан соң олуг кенәз (Иван Грозный) филне крәстиәннәр ярдәмендә үтертергә дип бер дворянын җибәрә. Гарәпне фил торган сарайдан ерак түгел генә бер урынга күмгән булалар. Фил текмә читәнне җимереп чыга да хуҗасының кабере өстенә барып ята, беркая кузгалмый. Шул урында аны кыйнап үтерәләр. Казык тешләрен каерып алып, Иван Грозныйга күрсәтергә дип алып кайталар. Мең үлемнең берсе — менә шул. Кеше булып туганың өчен Алла каршында оялыр хәлгә җиткергән мондый вакыйгалардан үзе бер энциклопедия төзерлек.

* * *

Беренче курста укыган чак иде, Рөстәм Фәйзуллинның алкалы каен күләгәсе төшкән сыңар тәрәзәле тын бүлмәсендә магнитофон тыңлап, әнисе Әминә апаның тәмле ризыкларын капкалап утырабыз. Ярый әле, туксан ике тиенлек кызыл шәрапны төпләп өлгергән идек — шау-гөр итеп бүлмәгә Фәрваз Миңнуллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Равил Фәйзуллин килеп керделәр. Язучылар союзында бик мөһим җыелыш булган да Әлмәткә кайтып китәсе Равил Фәйзуллинны озату сылтавы белән керешләре икән боларның. Ул арада Равил, табын хәстәрен күрергә дипме, олы якка, әнкәсе-сеңелләре ягына чыгып китте. Укытучыбыз Мөхәммәт ага каршында без уңайсызланыбрак калдык. Тиз генә кубып чыгып китү дә малайлык булыр сыман, кул кушырып басып тору да әллә ни егетлек түгел. Әрсез студент кавеменнән болай гына котылып булмаячагын яхшы белгән Мөхәммәт ага, ниһаять, хәлне җиңеләйтте:

— Әнә тегендә — крокодил тиресеннән эшләнгән портфель торамы? Ачыгыз әле, икенче бүлегендә, минем якланмаган докторлык диссертациясе кырыенда бер шампанское булыр, шуны алып өстәлгә куегыз. Булдымы! Син, Гамбәров, штангист бит әле, ачып бир, булмаса...

Наис мондый шәрапне ачып өйрәнмәгән булса да, укытучы каршында сынатмас өчен, көч белән каерып, «елатып» диярлек бөкене ачты.

Мулла нәселеннән буларак, бүлү эшен Мөхәммәт ага үз кулына алды. Шәрабның күбеген котыртмыйча гына, үз юмартлыгын бәрабәр юкалыкта, стакан төбенә ябыштырып кына бүлә белде.

— Беренче курслар белән чәкештергән юк иде әле, сез ерак китәрсез, егетләр,— диде.

Тел очына сеңеп калган затлы шәрабның ерак кайтавазы зиһенне ачып җибәрде — безгә кузгалырга вакыт иде. Дәрәҗәләрнең буталмавын оста кайгырта белгән Равил Фәйзуллин сәбәбен дә тапты: аэропортка барып, билетны хәл итә торырга кирәк икән, озата килүчеләр аны туп-туры самолет трабына кертерлек булсын. Инде чыгып китәбез дигәндә, Мөхәммәт ага йөзе белән Фәйзуллин ягына, күз кырые белән безгә карап:

— Соңгы арада чит илгә угоннар көчәйде, карабрак кайтырсың инде, Бөгелмәгә дигән самолетыңны Базарлы Матакка алып китмәсеннәр...— диде. Дәррәү көлешеп без чыгып киттек.

Мөхәммәт аганың имтихан алуы — үзе бер дөнья. Ул дүрт якны да берьюлы күрә, дүрт якны да берьюлы ишетә алучы затка әйләнә. Елгыр, төлкеле карашы керфек селкенүен дә сизеп ала. Шпаргалка белән тотылмыйча, аның әчке теләгенә бушану ләззәте бирмәү гөнаһ шикелле тоела башлый.



*Татар язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында узган җыелыштан бер күренеш. Алгы планда (сулдан уңга) Фәннур Сафин, Мөхәммәт Мәһдиев, Туфан Миңнуллин. 1993 ел.*

Иртәгә имтихан дигән көнне тулай торак Париж салонына әверелә: кызлар ду килеп күлмәк сайлыйлар, үзендә булмаганнар күршесеннән алып торалар, шау-шу, елаш, үгетләү, соклану ымлыклары төн уртасына кадәр тынмый. Арада бер Шәмсия генә тыныч, соңгы моданы чамалап, күлмәкне алдан ук тегеп куйган. Стенадан кубарып алып, мендәргә сөяп куйган көзге каршында бөтерелмә итәкле күлмәген киеп ыспай боргалана.

Кызларның чибәрлектән мәхрүмнәре дә имтиханга әчтән балкып, яңадан туып киләләр. Хатын-кызның бик чибәренә — акыл, бик акыллысына чибәрлек бирми Ходай, диярга яраткан Мөхәммәт ага бу өлкәдә талымлы эстет, югары кимәлдән торып бәя бирә белә иде.

Менә без Азат Ганиев артыннан (бер кыз, бер егет — аралаштыру алдан уйланылган) бер төркем булып кереп утырдык, билетларны алдык. Азат Ганиев озаклап мыштырдамады, укытучы каршына барып утырды да, виолончель тавышы белән, бер генә җөмлә әйтте:

— Болгар бабаларыбыз ислам динен 922 елда кабул иткән.

Мөхәммәт ага: «Җил тегермәне икәнен үзем дә беләм, суы каян килә соң аның?» — дигән шикелле, канәгатьсез калып, Азатның тел ачкычын табарга тырышып сораулар биреп карый. Юк, Азат ләм-мим, бармагын борын буйлата яткырып куйган да үз эченә йомылган. Мөхәммәт ага аның сул ягына да, уң ягына да чыгып кузгата алмыйча аптырап бетте, ниһаять, Азат, куе кашларын уйнатып алды да, Аспарух ханнардан килгән кырыс сүзне кистереп әйтте:

— Мин әйттем...

Мөхәммәт ага, кинәт кубып, ачу белән аның зачеткасын алды да, эре хәрефләр белән басып-басып язарга тотынды:

— Мин синең фольклорны белмәгәнеңне белә идем инде. Мә, өчле!

Азат, калын табанлы ботинкалары белән шыкы-шыкы басып, ишекне төбенә кадәр ачты да, артка каерылып:

— Атаңны суйдың, дигән кебек булды бу, Мөхәммәт абый! — дип, ишекне шапылдатып ябып китеп барды. Мөхәммәт аганың йөзе агарып чыкты, бер мәлгә каушап калгандай булды, кесәсеннән сигаретын алып кулында әвәләргә тотынды. Коридорга чыгып тартып та керде бугай.

Бераздан инде имтихан барышы үз көенә салынган иде. Миңа ул «бишле» куеп, университетның «Ленинец» исемендәге күптиражлы газетасында шушы имтиханнан репортаж чыгар, киләсе атнага, дип әмер бирде.

Чырайны сытып булса да язылган бу репортаж, русчага тәрҗемә ителеп, газетаның беренче битендә дөнья күрде. Мөхәммәт ага белән коридорда очраштык. Ул беркайчан да туктап җәелеп сөйләшеп тормый иде, кырын баса, гәүдәсе каядыр ашкына (якын ара калдырсаң, татар эчкә төртеп сөйләшә башлый бит, шуны өнәмәгәннәндер):

— Син, егетем, заданиены үтәмәгәнсең бит. Кая репортаж? — дип сүзен теш арасыннан сытып чыгарды. Мин, тыныч кына, портфельдән газетаны алып күрсәттем.

— Ә-әә... Гафу үтенәм. Газеталарның беренче битен укырга гадәтләнмәгәнмен шул,— дип, стенаны ышкый язып китеп барды. Коридор уртасыннан, рәхәтләнеп күкрәк киереп барганын мин аның беркайчан да күрмәдем...

Дөрес фаразлаган икән Мөхәммәт ага. Еллар үткәч, күп кенә банкетларда аның белән өстәлдәш булырга туры килде, бергә шактый юллар да үтелде, учак янында таңнар каршыланды, купедаш булып, поезд тәгәрмәчләре җырын тыңлап ерак араларга да бардык, кунакханәләрдә дә бүлмәбез уртак иде. Аның кебек тә кызыклы әңгәмәдәшне, вакыйганың өресен генә җыя белеп, вакыты белән үзеннән дә көлеп, ялыктырмыйча, хикмәтле сүзләрне бик тә урынлы кулланып, хәтер шәплегеннән тантана итеп, сабыр-үтемле итеп сөйли белүчене бу дөньялыкта бүтән очратмам инде мин. Ул, кешене күңел мендәренә утыртып, холык-фигыленең үзе генә белгән якларын шундый яратып һәм купайтып сурәтли иде ки, чынбарлыктагыдан кызыклырак итеп күз алдына бастыра да куя. Кәгазьгә төшергәндә генә саранлык күрсәтә, гомер чиге көтмәгәндә кисеп куясын онытып, мактыйсы сүзләрен алдагы көнгә дип калдыра иде бугай.

* * *

Артык дөрес яшәгән, изүе ябык кешеләрнең дөньяда барлыгы белән юклыгы арасында әллә ни аерма сизелми. Яфрак кебек өзелә гомерләре, хәтер иелеп алырлык берни калмый. Көчле шәхес үткән

еллар эзендә исә моңланып та, елмаеп та сөйләрлек гыйбрәтле, мәзәк хәлләр бер гомергә генә сыя алмый икән шул. Бу җәһәттән Мөхәммәт ага Мәһдиев — бай тарихлы гомер хәзинәсе иде.

Дисбенең еллар төймәсен чигерсәм... Зур тәрәзәдән еракта Идел көзгесе күренер, нәшриятнең җилле көннәрдә хәтәр җуылдап каядыр очып китәргә җыенган шикелле бинасының унынчы катында мин, проза бүлеге редакторы («Казан утлары») урындыгын җылытып, «Торналар төшкән җирдә» исемле повестьны редакцияләп утырам. Мөхәммәт аганың кульъязмасы ярыйсы гына чиста була, өтерләрне бик үк «кешегә санамаса» да, тары ярмасы кебек мулдан сибеп чыга, редактор өлешенә дә уйдыклар калдыргалый иде. Кызганычка күрә, мин дә абзацлап укырга күнеккәнлектән, өтерләр белән бик үк вакланмыйм, аннары, укытучымның язмасына кул тыгу, нидер төзәтергә тырышу да уңайсыз кебек.

Менә шул «кебек», «бугай»лар аркасында шактый талкынып алырга да туры килде. «Торналар төшкән җирдә» басылып чыккач, аның үтә дә кызыклы урыннарын яттан сөйли-сөйли «юып» йөргән көннәрдә... язмышыңны бөгәрләп учында тоткан хәтәр йорттан — өлкә комитетының культура бүлегеннән редакциягә шомлы кәгазь килеп төште. Баш редактор Зәки ага Нури бөтен редакцияне аякка бастырды. Шамкин дигән берәү жалоба язган икән. Имеш, Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» повестенда 199 өтер хатасы киткән (дөрес урында куелмаган йәисә бөтенләй төшеп калган). «Җитлеккән» социализмга кереп барганда... Яңа кеше тәрбияләгән дәвердә... бер әсәрдә генә 199 өтердә хата җибәрелсен әле, чаң сугарлык вакыйга ич бу! Теге еллар булсамы... Шушы кадәр өтерне укмаштырып, халык дошманы ясарга да мөмкин иде.

Минем космос белән хыялланып йөргән чак иде бу. Сирәк басыла торган сихерле язмалар укып, тормышның ваклыгына, адәм балаларының кырмыска оясы кебек мыжгу-чәбәләнүенә галәми биеклектән көлеп кенә карарга кирәк, дигән һавалы бер фикергә ирешеп килгәндә генә... өтер ыргаклары көтмәгәндә чабудан тартып төшерсен әле... Партия йортыннан сузылган кул чигенүне белми, барны юк итә ала, юкны бар итә... Берәү сөйләгән иде: Казан артындагы бер районнан обком секретарьлары яши торган йортка азык-төлек китергәннәр. Әйберләрне бушатып, машина китеп баргач кына икенчеме, өченчеме секретарьның хатыны капчыктагы кишернең юылмаган икәнен искәреп ала, ду килеп иренә телефоннан шылтырата. Шунда ук, Табеевтан гайре, бөтен секретарьлар, бүлек мөдирләре, инструкторлар аякка бастырыла. Юылмаган кишер җибәртергә кайсы мәгънәсез җөрьәт иткән? Кайсы район, кайсы авыл? Өлкә комитеты моны ачыклау өчен көне буе дер селкенә, телефоннар кыза, йөрәк дарулары эчелә, йодрыклар төйнәлә. Ниһаять, район хуҗасы да, гаепле авыл да, шофер да ачыклана. Кемдер урындыгы белән хушлаша, кемгәдер шелтә бирелә. Шуннан соң гына өлкә комитетына тынычлык иңә. Ә бу очракта кишер генәме сиңа, 199 өтер бит, өтер! Урыс патшасының «Казнить нельзя помиловать» дигән өч сүзле әмерендә әнә өтерне кая төртүгә карап баш йә бүкәнгә куелган, йә исән калган.

Зәки Нуриның чырае агарып чыккан. «Казан» рестораны буфетыннан, такси белән барып, өч мәртәбә коньяк эчеп кайтты — кәефе барыбер алама, җитезлеге генә элеккечә: каяндыр, адрес юнәтеп, Шамкинга кеше җибәртте. Икенче берәү тел белгечләрен чакырырга дип китте. Мин исә, телефоннан шылтыратып, Мәһдиевне редакциягә дәшәргә тиеш идем.

— Ул бәндә мине гел бимазалап тора. Органнар тарафыннан махсус куелган түгел микән?.. Өтердән политика ясамасыннар, Шамкин белән алыш-бирешем юк! — дип ул телефон трубкасын куйды.

Шамкин редакциягә ясканып килеп җитте. Үткен карашлы, хәрәкәтчән пенсионер. Заманында укытучы булып эшләгән. Бүген-иртәгә көя төшәсе пинжәгендә медаль планкалары да бар иде шикелле. Бөтен

редакцияне хәрәкәткә китерүенә ул эчтән бик канәгать, рәхәт дулкынлануы йөзенә чыккан иде.

— Мин яңа чыккан әсәрләрне түкми-чәчми укып барам. Мине зур-зур язучылар да беләләр,— дип Шамкин елмайды. Ләкин аның күзләре елмаймый, үзайры салкын иде.

— Нигә обкомга жалоба яздыгыз? — дип туп-туры сорадым мин, чиркануымны яшермичә.

— Әгәр нәтиҗәсе күренмәсә, болай гына калдырмыйм. Үзәк Комитетка да язарбыз! — Шамкинның юка иреннәре кысылды, күзләрендә зәһәр очкыннар кабынды. Сизеп торам: гомере буе язучы булырга хыялланган яисә алардан көнләшеп яшәгән булса кирәк. Ябага койган атның сыртына кунып төк чүпләгән чыпчык халәтендә кукраюлы иде ул бүген.— Мин заманында Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмирләргә дә ярдәм иттем. Һәр чыккан романнарын укып, өтер мәсьәләсендә киңәшләремне язып җибәрә идем. Алар миңа рәхмәтле булдылар. Гариф Ахунов та әнә бер хатымны да җавапсыз калдырмый. Мәһдиев кенә әллә кем булган! Мин аңа күпме киңәшләр язып җибәрдем — ләм-мим. Күптән түгел театрда күреп, мин Шамкин булам, дип танышырга килгән идем. «Мин сезне белергә теләмим, иптәш...» — дип кул сырты белән генә мине этеп куйды да аркасын борды. Ул гына әллә кем! Бик үпкәләдем мин аңа. Тукта, минәйтәм, кикриген шиңдерим әле моның обкомга чакырттырып. И язып та җибәрдем! Ә нигә, күпме күз нурларымны түгеп... күпме әсәрләрне укып... өтерләрен җеген-җеккә китереп чыгып... Ә ул! Белергә дә теләми, имеш! Нибуч, белдерербез! Карагыз аны, монда бер нәтиҗәсе дә булмаса, туп-туры Мәскәүнең үзенә язачакмын! Зәки Нури иптәш акыллы сезнең, сыразы чамалады кем белән эш иткәнен.

Мин бу кеше белән сүз көрәштерүнең файдасыз икәнен аңладым. Аның күңел күзе нәкъ безнең җәмгыятькә кирәкле ике төсне генә аера иде. Совет власте, белем бирәм дигән булып, күпләрне жалоба язарлык кына укытып, үзенә файдалы мәшәкать әзерли ахрысы.

Шул мәлдә мин, таяныч эзләпме, чистарыну тойгысы беләнме, балачакның күптән инде онытылган бер хатирәсен күз алдыма китердем. Безнең күрше Әгерҗе авылыннан төшә торган юл, арыш кыры уртасыннан тау битенә килеп чыга иде. Шуннан иңенә киндер капчык аскан озын ир заты күренүгә, без, малайлар, аны танып алып, күпер турына йөгерешә башлый идек:

— Баттый килә! Баттый килә!

Баттый олы авызлы, ямьшек йөзле иде. Мин аның ап-ачык итеп нинди дә булса сүз әйткәнен хәтерләмим. Олы гәүдәле сабый кебек акылга таман бу кешене без үртәргә ярата идек.

— Бат-тый! Бат-тый! Бат-тый! — дип хор белән кычкырабыз, аңа вак ташлар ыргытабыз. Ә ул исе дә китмичә бара. Кыюланып китеп төртәсуга башлагач кына ул, кинәт борылып, безне куа башлый. Туктала да, малайларның куркышып йөгергәненнән шулкадәр күңеле булып, бөтен йөзенә таралып елмая иде.

Үзен акыллы санаган кешеләрдән явызлык күрсәм, шул гадел җүләр мәҗүси җанлы Баттыйны күз алдыма китерәм: әнә ул, сары арыш кырыннан тарау атлап килә. Киндер капчыгында сохарилар. Аңа бүген берни кирәкми. Балачакның шамаиле кебек бу манзара еллар үткән саен кечерәя бара һәм мин, энә күзе аша чыгып яңадан бүгенгемә кайтам...

Ул көнне редакциянең корректорлар бүлмәсендә ябык киңәшмә уздырылды. Тел белгечләре: университеттан — профессор, институттан — фән кандидаты чакырылган иде. Шамкинның кулында саргайган тышлы китаплар. Өтерләргә караш аңарда утызынчы елларда ук шәкелләшкән булырга тиеш... Галимнәрнең исә тыныш билгеләре хакындагы китаплары яңа тышлы иде. Шамкин белән галимнәр кара-каршы утырып, бер-берсенә юл бирә-бирә, өч сәгать буе бәхәсләштеләр. «Торналар төшкән җирдә»не суеп, тунап, сөяген сөяккә, итен иткә аерганнан соң

шундый нәтиҗәгә килделәр: әсәрдә, Шамкин язганча, 199 өтер түгел, ә телнең яңа шартларда үсешен, кагыйдәләрнең «җитлеккән» социализмда үзгәрешләр кичерүен искә алып, җәмгысе 99 өтернең дөрес куелмавын раслап килешү төзеделәр.

Соңыннан Шамкин безнең кабинетка кереп чыкты. Кем әйтмешли, шатлыктан күңеле мәтәлчек ата иде. Безнең Зәки ага Нури да аның янәшәсендә кечерәеп калган кебек. Белорус урманнарында партизанлык иткән, чорыбызның күз уңындагы кешесе — ниндидер Шамкин каршында җебеп төшсен әле. Эчкерсез, киң күңелле, егет кеше иде ул, астан уеп эш итүчеләрне өнәмәгәнгәдер, тизрәк котылу ягын карагандыр, ахрысы. Шул чакта ул Шамкинга гонорар язу хакында да сүз кузгатты шикелле. Канәгать иде өтер белгече. Нәтиҗә — көткәннән артык. Баш редактор урынбасары Әхсән Баянга һәм миңа — шелтә бирелде. Шамкин кулларын уа, Шамкин шат. «Тәһран-43» дигән кинофильмны күпләр хәтерлидер. Анда киңәшмәгә киләсе өч илнең олуг җитәкчесен юк итәргә тиешле агентны актер Джигарханян бик шәп уйный. Террор булмыйча кала, шуннан соң дистә еллар үткән инде, агент-Джигарханян өендә шул чорның документаль кадрларын карап утыра. Экранда Черчиль, Рузвельт күренгәч ул: «Мин аларны шул чакта атып үтерә ала идем бит, алар минем кулда иде...» — дип, үкенечле ләззәт кичерә. Шуның шикелле, телевизорда язучылар күренгәч, мин аларның фәлән әсәреннән фәлән өтер таптым, мин алардан акыллырак! — дип, йодрык төйнәп, «Үлгәч, аларга гына шәп итеп некролог бирәләр!» — дип кызыгып, ишекле-түрле йөренәдер Шамкин.

Әлеге өтер мәрәкәсен, еллар узгач, Мөхәммәт ага белән искә төшереп көлешә идек. «Син шуннан соң тыныш билгесе кагыйдәләрен шактый өйрәндең бугай...» — дип төрттереп куя иде Мөхәммәт ага.

Әйе, мин бу фамилияне онытмам ахрысы: Шамкин. Символ булырлык, нинди хәтәр яңгыраш!

Ун еллар элек без, берничә язучы, төрмәдә (СИЗО) чыгыш ясадык. Киң җилкәле, елмая белми торган полковник артыннан лабиринт коридорлардан барабыз. Тимер рәшәткәле, электр йозаклы саллы ишек борын төбендә шаңлап ачыла да, атлап чыгуга, арт чүмечкә салкын сулыш өреп, шаңлап ябыла. Икенче ишек тә шулай, өченчесе, дүртенчесе... Йөрәк кага, кире чыгып булмас инде, дигән хәвефле уйлар килә... Авызда тимер тәме. Күз алдында ихтыяр көчеңне ала торган рәшәткәле ишекләр әле ачыла, әле ябыла. Тимер ишекләрнең дәһшәтле кайтавазы рухны яньчи: — Шам-кин! Шам-кин!

Һәр буынның үз шамкины була икән...

* * *

Безнең Васильево янындагы дачалар бер меридианда, араны ике күл дә чаукалык бүлеп тора. Алдан сүз куешабыз да... Мин икенче кат тәрәзәсеннән менеп карыйм, Мөхәммәт ага балкон капкачын ачып куйган булса, эш беткәч, уйнарга ярый, дигән сүз. Тиз генә велосипед багажнигына кипкән балыкны аркылы кыстырам да — әллүр!

Утырабыз истирәхәт кичереп ачык верандада, агачлар күләгәсендә, Мөхәммәт аганың суыткычыннан чыккан тирләгән шешәле сыраны эчеп, вобланы урталай аерып ташлап, чекердәп янган уылдыгын чеметеп каба-каба, янәшәдә нидер эшләп йөргән Лилия ханымга комплиментлар әйткәли-әйткәли...

Әнә, каршыдагы ихатадан пединститут укытучысы Фәрит Хатипов «Волга»сын чыгарып маташа. Төтен бөркеп киткән машина артыннан Мөхәммәт ага йотылып карап кала да:

— Профессорлыгың, «Волга»ң бер кырыйда торсын. Утыз градуслы челләдә, менә шушы минутта салкын сыраң булу — зур бәхет,— дигән булды (ул елларда ике нәрсә — алтын һәм сыра дефицит иде).

Бервакыт «Россия» кунакханәсендә, Мәскәү Кремленең чиркәү гөмбәзләреннән тәрәзәгә алтын шәүләләр төшкән номерда икәү генә гәпләшеп утырабыз. Мин аңа күптән борчып йөргән сорауларымны бирәм. Татар кафедрасы берчак тоташы белән картаячак. Көчле алмаш турында махсус кайгыртмыйлармы? Сезнең дә эшне дәвам итәрлек, фәнни белем алган укучыгыз юк, дигәч ул: — Миңа аспирант бирдермәделәр. Бер үкенечем кала, ничә еллар буена туплаган картотекамны тапшырып укучы әзерли алмадым,— диде.

— Аспирантурага да студентның башына карап түгел, аягына карап алалар, йә биюче, йә җырчы... Нинди шәп, кыю егетләр бар иде, мескенлек белән килешмәүче егетләр! Талантлы икәнен белеп алуга, шуларны төрле сәбәпләр тапкан булып, университеттан куа тордылар. Бүтәннәрне әйтмим дә инде, менә сез, Мөхәммәт ага, үз вакытында нишләп шуларны яклап калмадыгыз. Курыктыгызмы?

— Мин ничек батыр була алыйм. Җиде яшемнән халык дошманы баласы дип башыңа сугып үстерсеннәр әле. Гомер буе шуның белән әзәрлекләсеннәр әле. Юк, син аны күз алдыңа да китерә алмыйсың. Шөкер, сезгә бүтән заман туры килде...

Бу сүзләрне әйткәндә Мөхәммәт аганың күзләре дымлы иде. Мин аның бәгырен шунда аңладым. Кара елларда коточкыч сынау-золымга дучар ителгәннәргә карата ашыгып хөкем чыгармаска икәнен дә шунда төшендем.

Мөхәммәт ага, табигатьнең исен тоеп, шуны хисси сурәтли белгән сирәк прозаикларның берсе иде. Бу бәлки — чык тамчысына туган җиренең кыр-тугайларын сыйдырып яза белгән Солоухин иҗатының шифалы йогынтысыннан килгәндер. Туган авылы Олепинаны, һәр капкасына тукталып, үзенчәлекле холыкларны яратып сурәтләгән урыс язучысы кебек үк, Мөхәммәт ага да гомере буена үзенең агач бишеге — Гөберчәген язды. Сәламәт рухлы көлеп тә, күз яшьләре аша елмаеп та, бәгыреннән әрнеп тә язды, иҗатында бәхилләшергә дә өлгерде.

Ул Шукшинны ярата, Проскурин, Абрамов романнарын югары бәяли, империя хуҗасы саналган халыкның вәкилләре буларак, алардан бераз көнләшә, кызыга да иде бугай...

Бер мәлне ул Василь Быков романнарына тәмам «чумып», аны бөек дип атый башлады. Студентлар каршында эффектлы сөйләр өчен генә түгел, ә тирәнтен уйланып укыган очракта Быков прозасының эчке хасияте юшкын булып өскә калкыр иде. Кеше — табигате белән явыз, дигән бер философ. Быков прозасы шул явызлыкның анатомиясен ачарга тырышуда түгел, ә бар золымны дошман як — немец иңенә салып, үзенең уйдагы, эчке садизмына чикләнмәгән мөмкинлек биреп, кан исеннән ләззәт алуда иде. Ватан сугышы чорында ике ут арасында калып аяусыз кырылган (бер яктан партизаннар изә, икенче яктан — немецлар) белорус халкы язмышы Быков кебек көчле каләм иясенә иҗади тәҗрибәләр ясарга менә дигән җирлек иде.

Бу хакта Мөхәммәт ага белән бәхәсләшәбез, әмма ул, тыйнак кына юл биргән шикелле булса да, барыбер, үз фикерендә кала иде. Дөньялар үзгәреп китеп, ил тарихына караган яшерен катламнар ачыла төшкәч, күп нәрсәләрнең асылы, җан өшеткеч сурәттә, өскә калыкты. Фашист дип аталмаган үзебезнең җантимерләр, үзебезнең Урал-Себер арасын биләгән концлагерьлардагы коточкыч зәһәрлекләр беленгәч, Быков романнары тоныкланып калды, Мөхәммәт аганың «бөек» дигән мөһере дә, өзелгән кое чиләге сыман, тирәнгә төшеп йомылды.

Онытылмас хатирәләр... Чаллыда ике тәүлек буе, көнен дә, төнен дә төрле даирәдә бергә булуыбыз бүгенгедәй хәтердә. Автобус белән кайтканда да, керфек тә йоммыйча, гәпләшеп кайтып җиткәч тә, Казанның тын урамнарында, аерылыша алмыйча, берничә сәгать йөрүләр... шушы кадәр вакыт дәвамында сүз егәрен тотып, бер-береңне тыңлый, юл бирә белеп, ялыктырмыйча йөрү өчен күңел берлеге, рухи тәңгәллек, кан тибешенең туры килүе, фикердәшлек кирәктер, мөгаен.

Юл җилләре сагындыра башласа, Мөхәммәт ага Азнакай якларын урап кайта, укучысы Илдус Гыйләҗевтә кунакта була, төне буена аның яңа шигырьләрен тыңлап чыга иде. Үзебезнең илдә дә, чит илләрдә дә югары зәвык белән әзерләнгән шактый бай табыннар күргән Мөхәммәт ага сый-хөрмәт арасыннан нәкъ менә Азнакай ягына хасны — каклаган каз, казылыкны, шәфәкъ кызыллыгын чагылдырган чөгендер катыгын, патшалар табынына гына куела торган, дип, карабодай коймагын тәмле сүзләр белән мактый белә иде.

Университеттан киткәч, ул кинәт картая башлады. Яшьлек галәме, шаулы аудиторияләр, үзенне һәрчак пөхтә-киеренке халәттә тоту, эчкерсез-ышанучан күз карашларының рәхмәтле алкышы җитми иде аңа юаныр һәм юатылыр өчен...

Безнең дуслыктан көнләшәләр иде. Арабыздан Есенин шигырендәгечә «кара кеше»нең үтеп китүен сизми дә калдык бугай. Мин аны еш юксына идем, кызышып алган чакларда: нишләп ул безнең кампаниядә түгел соң әле, дигән җүләр уй башка суга да, телефоннан шылтыратам, аның тавышы бөтенләй бүтән яссылыктан ишетелә, үзе әйтмешли, волналар туры килми, күңелдә әзерләнгән җылы сүзләр сул ягы белән капланып, бөтенләй бүтән яңгыраш ала. Очрашкач инде — аңлашу, гафу үтенү, кул бирешү. Ә «кара кеше»нең хөсетле калканын ачасы көннәр алда әле. Хәзергә... язылачак роман исемен кабатлыйк: «Тимә, яшәсен!..»

Гомеренең соңгы елларында Мөхәммәт ага «Алланың кашка тәкәләре» яшәячәк йортка күченү уе белән янып, бөтен нервысын талкып, тәмам «чирләп» йөрде. Шул дәвердә мин аңа: «Алтмыштан узгач, урын алыштырмау хәерле, өй иясен рәнҗетүең бар...» — дигән идем. Ишетте дә, ишетмәде дә кебек. Күк катлары белән хәбәргә кергән җаны каядыр алгысыткандыр аны, йөрәгеннән түгелгән мөкаддәс иҗатын калдырып, үзенең дә бу дөньялыктан узып барышы булган икән.

Аны соңгы юлга озаткан кояшлы көнне, өйдә ялгызым гына калгач, тәрәзә каршындагы каен белән күзгә-күз карашып торганда бәхилләшү сүзләрен әллә мин, әллә яфраклар пышылдады:

...Аның, дөнья читлеген тарсынып, күккә ашкан җаны нәкъ менә Тукайлар, Мәрҗанилар катына менеп җиткәндер дә, энциклопедик акыл иясен алар үз араларына алганнардыр да:

— Кичер безне, ашыктырдык, син монда — Күк тәхетенә кирәгрәк, — дияләрдер кебек. Мөхәммәт ага анда да югалып калмагандыр, мәртәбәле җаннар каршында башын игәндер дә, гарәп халифәседәй кыяфәтенә нур иңдереп, бер дога кылгандыр.

Ә җирдә хакыйкать пышылдый: Кеше китә, җыры кала...

Юксынырбыз сине, Остаз! Күңел син яратып әйтә торган сүзне тәкрарлый: затлы идең...

* * *

Мәхмүт Хәсәнов урамыннан ялгызым гына барам. Сентябрь җиле агачлардан сары яфраклар коя. Кесәмдә — утыз өч төймәле Истанбул дисбесе. Хәтер төймәләрен тартып барам, кемнәр бар да кемнәр юк... Күңелгә күптән язылган шигырь юллары килә:

> «Кайтарыгыз безне!» — дигән әрнү
> килә икән
> Йолдыз аша баккан күзләрдән;
> Кичерегез, әгәр ишетмәсәк,
> без бит инде шундый үзгәргән...

Урам чатыннан кәкре башлы, бинибая юан таягын тотып Мәхмүт ага үзе килеп чыгар сыман. Килеп чыгар да, сагынулы елмаеп: «Йә, нишлибез?» — дияр кебек. Дәшмә, җил, беләм, үзем дә беләм...

Кабатлану була алмый. Шагыйрь әйтмешли, «Кошлар оча-оча югала...»

Урамның сул ягында — ул эшләгән редакция бинасы. Әз генә югары күтәрелгәч, ул яшәгән йортны күрәсең. Бераз арырак — Азнакай музее булачак бина. Анда Мәхмүт аганың әйберләре белән бергә Кара диңгез буенда соңгы сулышына кадәр янәшә «атлаган» кәкре башлы таягы да сакланачак.

Мәхмүт аганы илленче еллар азагында мәркәзи Казаннан Азнакайга «сөргенгә» җибәрәләр (сәяси сәбәптән түгел, әлбәттә). Язмышының болай текә борылышын ул башта бик авыр кичергәндер, ләкин торабара разый калгандыр. Башкаланың мәкерле хатын-кызларыннан таланган күңеленә дәва бирерлек эчкерсез, тугры кызга ул монда гашыйк була. Кырыеңа килеп басса, кояшны капларлык дәү гәүдәле иргә курыкмыйча кияүгә чыга бит Мәрьям дигән кыз. Ачлы-туклы чорларны кичергәндә дә Мәхмүт ага талчыбыктай нәзберек хатынга таяна, язганнары Казан каласыннан тибәрелеп кайтканда, өмете өзеләм дигәндә дә җанга юанычны аңардан таба. Күндәм-тырыш хатын тынгысыз әдипнең колы да (роман-кулъязмаларын гомере буена төннәрен кат-кат машинкада басты), иң беренче укучысы да, гадел хөкемдар да, холыксыз сабыйланган иргә Мәрьям ана да була белә. «Мәрьямне миңа Ходай тәгалә үзе җибәрде»,— дияргә ярата иде Мәхмүт ага.

Мәскәүләрдә укыган, тере классиклар белән аралашкан, Переделкино иҗат йортында чакта Фадеевны атылыр алдыннан берничә минут кала күргән Мәхмүт аганың үсмер чагы болытлы елларга туры килә. Исхакыйсыз, Ибраһимовсыз, «Идегәй»сез ятим әдәбияттан тәрбия-зәвык алган Мәхмүткә яшьлек кодрәте җимерер киртәләр күп очрагандыр. Милләтнең Атлантида кебек югалган һәм талана барган хәтерен уяту тыелган заманнарда әдәби вакыйгалар табып, иҗатка бирелә алу — үзе бер фидакарьлектер бәлки. Алласыз һәм тарихсыз проза вәкиле булырга тиешлеге белән эчтән килешмичә яшәү — яшь Мәхмүтне кайчакларда дуамалланып, дөнья белән тешләшеп алырга да этәргәндер...

Азнакай халкы Иван Грозный яуларыннан соң үзәктән, Идел буйларыннан күчеп килеп, «оҗмах ягы» дип аталган төбәкне колачлап алган. Үҗәтлек, ирекккә сусау, ихтыяр көче, тормыш сәхнәсендә үзен каһарман итеп тою — бу төбәк халкының йөзен-холкын билгели. Пугач яуларына икеләнүсез кушылып аягүрә күтәрелгән, революциядән соң, сәнәкчеләр булып, «кызыл авыз»ларга дәһшәт салган гаярь халык яши монда. Шаңлы чорлар дәвамы — бүгенгеләрдә. Мут хатын-кызларның күзләрендә илаһи нур көйри, ирләре — чакматаш, тыштан сабыр күренгәннәренең дә күңелендә — гамьле дәрья.

Легендаларга торырлык гаҗәеп вакыйгалар, дан җиле кагылмаган батыр кешеләр, вакыт учында, ак кәгазьне буразналыйсы каләм очына үзе килә, романнарга агылып керә. Менә шуңа күрә дә мең рәхмәтле иде Мәхмүт ага бу якларга. (Чалтаймас урманының җидегән чишмәсеннән су эчкән Гомәр ага Бәширов та, Мөсәгыйт Хәбибуллин да үз әсәрләренә бу якларның ганимәтен алдылар).

Якташларым үз күзләре белән күргәнгә, үз куллары белән тотып караганга гына ышаналар. Кичер, граф хәзрәтләре, син Азнакайда булмагансың, дип Толстой исемендәге урамны үзгәртергә дә кыюлыклар ı җитә. Әнә Сөембикә, Солтангалиев урамнары. Николай Островскийның да бу шәһәрдә нәфесе юк иде, менә хәзерге көндә урам Мәхмүт Хәсәнов исемен йөртә.

Сентябрь җиле урамга сары яфраклар төши. Юкәләр арасыннан күренгән җете зәңгәр күктә пәрәвезләр яшьнәп китә. Хисләрнең дә пәрәвез җебе кебек нечкәргән мәле. Туган ягымның йөгерек юллары хәтергә урала. Ык буе әрәмәлекләре хәтерлиме икән балыкчы шалашын? Анда калган Хәким, Туфан эзләренә бөрлегәннәр шыттымы? Ышыкла

син, рух белән үлчәшер Чатыр тау! Ә син дәшмә, жил, беләм, үзем дә беләм...

Хәтер күгеннән сары яфраклар коела.

Моңсу...

## Бисмиллалы табын күрке

*Шәригатьтән тыш тарикать булмас,*
*тарикатьтән тыш хакыйкать булмас.*
Г. Утыз Имәни.

Төн. Мин балконга чыгам. Шәһәрнең үзенә бер төрле шавы, болганчык авазлары тынлыкка сусаган җанга һич тә шифа бирми. Чөнки бу авазларга мин бала чактан күнегеп үсмәгән.

Тәмәке кабызам. Тәүге кат эчкә алган ләззәтле төтен белән бергә тирәндә йокымсырап яткан сагыну хисе дә савылып уяна сыман. Кырпак карлы төннәрдә чыгып тәмәке кабыздыңмы — гел шулай, «үткәннәрне сагыну өянәге» кысып ала. Юаныч эзләгәндәй күккә карыйм. Төсе, тирәнлеге башка шул: шәһәр күгенең йөзе күренми.

Киек каз юлы астында җәйрәп яткан авылымның тынлыгын йомшартыр өчен генә хөсетсез этләр өреп куядыр (Сукбай шәһәр этенең өрүе белән хуҗалы авыл этенең өрүе арасында аерма бар). Йорт хуҗасының тамак кыруын кабатлап кече капкалар ачылып-ябыладыр. Морҗалардан кайнап чыккан төтен, салкында оеп, әкияти баганалар булып күк гөмбәзен терәгәндер.

Хыялымда, карлы киңлекләр аша сузылып, хәтеремдә генә калган өйнең бозлы тәрәзәсеннән карыйм. Әни оек бәйли, песи идәндә ак йомгакны тәгәрәтеп уйный. Әнә, өстәл башында әти елкылдап торган пычакларын кыныларыннан алып тезеп куйган. Сугымга әзерләнә. Бер кырыйда — игәүләре. «Бусы — алмаз кайрак, — дигән була ул. Вак-вак ташлары җем-җем итеп торган кайрак чынлап та затлы токымнандыр. — Бусы — имән кайрак. Имән тамыры сазлыкта, кырык ел буе су төбендә ятса, чын тимергә әйләнә, менә кара, чынлап торамы?..»

Мин чынлап та тимергә әйләнгән агач кисәгенең авырлыгына, катылыгына хәйран калып, учымда әвәрә китерәм.

Әти пычакларын үзенә бер көйгә җырлатып иги, чарлый, кайрый — мәш килә. Шулкадәр тәм белән бирелеп эшли, сабыйларча, тел очы иреннәре арасына кысылып калган. Аннары... пычакларны тезеп куя да бер мәл сокланып карап тора, әллә инде әфсен өреп, нидер пышылдый, гүя коралларның эчтә уянып, үрсәләнгән җанын тынычландыра...

Аннары... аслыннан чөйгә эленгән озын каешны сузып тота да пычакның әле бер ягын, әле икенче ягын әйләндереп, шундый бер житезлек белән ышкып-ышкып ала. Ялык-йолык иткән пычак йөзеннән чагылган ут яктысы әтинең күзләрендә хәтәр очкыннар булып җемелди. Бу мизгелдә минем әти — салкын коралның кодрәтен тойган мәҗүси, кыргый җәнлек эзенә төшкән аучы, иртәгә хәрби сәфәргә кузгаласы яугир... Юк, бу турыда ул үзе белми-уйламый да, мин дә аны читтән күзәтеп хыялга гына бирелэм. Пычак йөзендә уйнаклап алган ялкын шәүләсендә атабабамнарның ерак гасырларда айкаган кылычындагы елдырым-яшен кайтавазын тойгандай булам. Элеккеге дәверләрдә коралны сәнгатьле итеп ясау бер хәл, аны сурәтләгәндә дә никадәр матурлыкка ирешкәннәр. Мин аны «Идегәй» дастаныннан сокланып укыдым:

Шаң-шаң иткән шам кылыч —
Идегәйнең кылычы.

Төндә балкыр ут булган,
Көндә балкыр су булган,
Ут елдырым яшен таш —
Чын булаттай корычы,
Аждаһадай сулаган
Ул кылычның сулышы.

Гаҗәп бит: сулышы... ди. Чынлап та, мин әтинең тетрәп яткан саллы пычакларына орынырга куркам, аларның салкын сулышын тойгандай була идем. Иң ошаганы миңа — әтинең баш бармак бите белән, арфа кылын чирткән кебек итеп, пычак йөзенең үткенлеген сынавы, аннары пычакларның кайсын күн, кайсын киндердән эшләнгән кынысына тыгып, матчага кыстырып куюы иде. Бу күренешнең инде бүтән мәңге кабатланмасын белсәм дә, моның белән килешәсе килми, шуңа күрә үҗәт акылым бу кадерле чорны алдагыга күчерә торып, кабат-кабат алдану рәхәте кичерә иде.

Кырпак карлар төшә. Авылда сугымнар башланыр чак. Минем әти, бик күп һөнәрләр белү өстенә, сугымчы да иде. «Кулы тәмле» дип аны өйдән-өйгә йөртәләр. Тире җыючы да: «Кем суйды? Ә-әә, Баян абзыймы, алайса, тиреңне җентекләп тормыйм, беренче сорттан алам», дия торган иде. Бөтен эшне дә бөртекләп, җиренә җиткезеп эшли белгән әти малны бик пөхтә итеп туный белә иде шул. Әти чалган мал итенең казанда гөбердәп пешүе, тел өстендә мәмрәп эри торган гаҗәеп тәме әле дә хәтеремдә тора сыман. Мин андый тәмне бүтән беркайчан да, беркайда да кабат татый алмам инде...

Рәтен белеп малны чалу, кышка ит ризыгы, җәйгә казылык, каклаган каз, җилдергән ит әзерли белү — татарның милли сыйфатларыннан берсе. Базарларда искәргәнегез бардыр: өлкәнрәк апалар, хәзер инде ушлырак яшьләр дә, мөселман өммәтеннәнме, үзебезнең татар чалган мал итеме, дип, кат-кат сорашып, сатучыны сөйләштереп карыйлар (тәмле теллеме, бисмилласын оныткан хуҗа түгелме, туктаусыз әр-сүгенү, кычкыру астында үскән малның ите дә ташка үлчим). Әйе, төрки-мөселманнар борын-борынгыдан мал суюның рәтен белгәннәр, дөньялыкта җан асрар өчен кирәкле бу шөгыльнең серләрен буыннан-буынга тапшыра килгәннәр. Бу — корбан чалу, корбан итен сәдака итеп өләшү, ашка җыю кебек матур гадәтләргә күчеп, дини йолаларга да кергән.

Ә менә бүтәнчә итеп, тәненнән канын чыгарып бетермичә, үтереп суйган мал итен тәҗрибәле мөселман кешесе базарда төсеннән үк таный һәм ул турдан, читкә карап, тизрәк үтеп китәргә тырыша. «Бабушка, очень хорошое мясо, дешево отдам!» — дип хуҗасы никадәр төчергәләнсә дә ул якка әйләнеп бакмый инде ул.

Төрле халыкларда мал чалу ритуалы төрлечә шул. Чыңгыз ханның кануннар мәҗмугасы «Яса» да шундый маддә бар:

«...Хайванның аякларын бәйләргә, корсагын ярып җибәрергә һәм йөрәген учка кысарга, хайван җан биргәч кенә итен ашарга ярый; әгәренки кем дә кем мөселманча хайванны чала икән, аның үзен шулай чалып ташларга!»

Бүгенге көндә калмыкларда һәм бурятларда җәнлек-хайваннарны шушылай, «Яса»да күрсәтелгәнчә җыештыралар икән. Алтай-Саян төбәкләрендә берничә ай яшәп кайткан рәссам Надир Әлмиев, тауларга чыккач, мөселманча сарык суюы турында сөйләгәне бар. Аны бурятлар дикъкать белән карап торганнар. «Болай тәмлерәк икән», дип итне яратып ашаганнар. Берничә гасыр буе кыйтгаларны тетрәтеп торган Чыңгыз хан «Яса»сының көче бүгенгә кадәр килеп җиткән булса, әлбәттә, Надир Әлмиев Казанга исән-сау әйләнеп кайта алмас иде.

* * *

Көзге авыл... Ишегалды — минем олы дөньям. Монда һәммә җан иясе үз гамендә... Көр сыерның мөгрәп куюы... Тук казларның, утырган җиреннән генә түшен биетеп, борын эченнән генә ган-ган килеп гәпләшүләре... Юеш танаулы сарыкларның мекер-мекер печән уртлавы... Гөнҗәлә койрыклы әтәчнең, күрше тавыкларын койма ярыгыннан күзәтеп, баскан урынында тәкатьсез тыпырдавы... Мендәр өстеннән уянып чыккан песинең ак тәпиләре белән салкын җиргә басарга теләмичә, баскыч биеклегеннән әлеге малларга — «кара халыкка» түбәнсетеп кенә карап торуы... Әнә шулай ишегалды яши, озын кышка әзерләнә. Кышкы аклыкка күзне иләләштерер өчен күктән көмеш сыкы тузаны сирпелә. Нинди рәхәт, күкрәккә иркен көмеш һава ургылып керә.

Эре мал — башмак тананы чалыр алдыннан берничә көн кала әни печәнне аның алдына мулдан сала, иркә тавыш белән генә эндәшә, сөеп, тамак астын кашып куя, бер читкә китеп, күз яшен дә сөртеп ала. Күңеленнән генә шулай танабыз белән хушлашкандыр ул. Мин дә, үсмер малай, тананың тамак астын кытыклыйм, ул күзләрен челт-челт йома, рәхәтлектән, муенын сузып, башын учыма сала.

Әмма барыбер, нидер сизенәдер кебек малкай...

Сугым буласы көнне иртүк өйдә ыгы-зыгы куба. Кайнар су, зур-зур коштабак-савытлар, чормага ит асарга тәләкәләр әзерләнә. Эчәге-бавыр юышырга әйтелгән күрше апалар керен хәл белешеп чыгалар. Тананы егышырга таза-таза ир-атлар керә. Башта йомшак арканның ныклыгын сынап карыйлар. Менә бисмиллалар әйтелә. Тананы араннан алып чыгып, муенчак кидереп, бакча ягында җитәкләп бераз йөртәләр. Бусы инде — хайванкайның күңелен әзерләү, тәнен җиңеләйтү өчен кирәктер мөгаен. Тананы абзар артындагы карлырак җиргә гөрселдәтеп егып, аякларын чалыштырып бәйләгәндә мин читкәрәк китәм, соңгы мизгелне карап тора алмыйм. Тик шуны гына беләм: әти пычагын итек кунычыннан сиздермичә генә ала да... малны куркытмыйча, каһәрен алмыйча... йоклаткан кебек кенә оетып, тәненнән җанын аерачак. Үзе генә белгән нинди тылсымы, серләре бардыр, бусы миңа караңгы, әтинең бу осталыгы миндә дәвамын тапмаячак.

Әти җитмешкә җитәрәк шундый хәл булды. Ул көздә безнең кап-кара үгез бозавыбыз гаяр булып үсеп җиткән иде. Тыгыз гәүдәле, терекөмеш күзле, баскан җирендә ут чыгара, таптый, җимерә, ыргый — тотып тыеп булмый. Арканын ычкындыргач, болынлыктан аны ихатага алып кайту үзе бер бәла иде. Кышлатып чыгарсаң, язга ул беркемнең көче җитмәслек буйволга әвереләчәк иде. Ул көздә... чалыр алдыннан үгезне биш-алты адәм көч-хәл белән җиргә аудардылар. Әти, сыңар кулының баш бармагы да учы гына булуы сәбәпле, арканлауга катышмый, өйрәтеп кенә тора иде. Менә ул, бисмилла әйтеп, үткен пычагын бозау муенына салуга, кара үгез йомарланып килде дә, арканнарын шартлатып өзеп, сикереп торды һәм бәрәңге бакчасы буйлап үлем исереклеге белән чаба башлады. Муеныннан кан ага, күзләре иләсләнгән. Үгез бозауны шактый азапланганнан соң гына тотып алып, бәйләп, кабат ектылар. Әтинең кулы калтырый иде. Кара үгездән җиңелгән тореодор шикелле, әти бу хәлне бик авыр кичерде. Юк, картаю түгел, бу — күктән иңдерелгән хәбәр-кисәтү иде. Шуннан соң аның пычаклары берәм-берәм «югала» башлады. Мал суярга дип дәшсәләр, ачуы килә, җанын кая куярга белмичә бәргәләнә иде. Күк хәбәре дигәнемнең хикмәте шунда: мал җанын кыю бер кеше өчен билгеле бер санда гына саваплы эш санала, аны һәр сугымчы үз күңеле белән чамалый, гөнаһ сызыгын үтмичә вакытында туктарга кирәк икәнен беләдер мөгаен.

* * *

Сыйфатлы ризык — яшәү чыганагы. Яшьлектә моңа бик үк игътибар бирмисең. Олыгая барган саен кеше нәзберекләнә, сайлана башлый һәм аның чыраена карап, нindirәк сыйфатлы ризык куллануын чамалый аласың. Язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең кызыклы күзәтүе хәтергә төшә. Өлкә комитетына яисә министрлыкка эшкә күчкән иптәшнең күпмедер вакыттан соң бит-тән тиресе алышына, дия иде ул. Хикмәт нәрсәдә: иптәш чиратларда торып йончымый, югары калорияле ризыкны өенә ташып торалар, эш урынындагы махсус ашханәдә бик арзанлы хакка байларча ашаталар. Шулай итеп, иптәшнең эчке әгъзалары — ашказаны, бөер-бавырлары шәп эшли башлый, җитмәсә моңа хакимлек-дәрәҗә ләззәте дә кушыла. Аксым бөтен күзәнәкләргә җитәрлек микъдарда тарала һәм кешенең йөзе шомарып, тыгызланып, чиртсәң, кан чыгарлык булып җитешә. Кинәт кенә эшеннән алсалар, иптәшкә яшерен складлардан партия ризыгы китертү туктатыла. Эчке әгъзалар — тәрбиягә генә күнеккән бөер-бавырларга кара халык ашый торган ризыктан авырлык килә башлый. Иптәшнең йөзе сула, иңсәсе шәлперәя һәм ул күзгә күренеп бетеренә, картая башлый.

Ризыкның кеше гомерендә нинди әһәмияткә ия булуы, ашау культурасы хакында сүз кузгатуны бәрәңге һәм ипине культ итеп куйган совет илендә өнәмиләр иде. Партия әһелләренең генә өстәлендә булып, халык исемен генә ишетеп белгән татлы ризыкларның зыяны хакында гына язалар иде.

Ризык культы — фәлсәфи мәгънәләрне эченә ала. Без җир-су, җиләк-җимеш аша кояш нурын эчәбез, тәнебезгә кояш нурын сеңдерәбез. Шулай итеп туктаусыз космик энергия алабыз. Гади генә тәҗрибә ясап карыйк. Нәкъ бер үк төрле ике чүлмәк алыйк, аларга бер үк төрле гөлләр утыртыйк. Аерма шунда: берсенең туфрагы туклыклы, икенчесенеке — ярлы. Суны да берсенә краннан килгәнне, икенчесенә табигыйне сибеп торыйк. Боларның кайсысы күкрәп үсеп, көлеп торган чәчәк атасын чамалау кыен түгел.

Һәммә нәрсәнең асылына төшеп уйлана белми торган, җүләр ритмга корылган дәвер бу. Теләсә кайда, кем пешергәнен дә уйлап тормыйча, алга куелган ризыкка тотынабыз. Күпләребез, хәтта, дуңгыз итен ашаудан да чирканмыйбыз.

Казан университеты профессоры Карл Фукс моннан йөз илле ел элек, Казан татарларын читтән күзәтеп, болай дип язып калдырган. Татар купецлары, мещаннар трактирга күңел ачарга киләләр, сыра эчәләр, чөгә балыгыннан пешерелгән солянка яраталар, ди ул. Әмма урысларга бик үк ышанып бетмиләр икән, дуңгыз ите салып кайнатырлар дип, шикләнеп, үзләре белән үрдәк түшкәсе яисә сыер ите алып килеп, солянка пешерттерәләр икән. Кызык бит: үзләре хәмер эчәргә дип киләләр, үзләре, шул ук вакытта, мөселманга дуңгыз ите язык икәнен дә онытмыйлар. Менә бит, гасыр ярым эчендә күпмегә үзгәргәнбез...

Гомумән, ризыкның хәтергә, аңга, кәефкә тәэсире турында галимнәргә ныклап өйрәнү мөмкинлеге бар бүгенге көндә. Менә сәер хәлләрдән берничә генә мисал: үлем түшәгендә яткан өлкән кешенең кинәт кенә авылына кайтып, чишмә суын эчәсе килә башлый. Байлыкка коенып яшәгән олы гына түрәнең көлдә пешкән кабыклы бәрәңге ашыйсы килеп теле кычыта. Соңгы тапкыр, ди ул инәлеп. Шул теләгемне үти алсам, бәлки, терелер дә идем, дигән өмет тә ташламый үзен. Нилектән бу? Хәтерме? Ерактa, бала чакта калган ризыкның чакырып асылыңа кайтаруымы?

Күпме кешеләрнең тәнендә йә балык, йә чия зурлык миң, йә миләш тәлгәше сурәтләнеп калганын күргәнем бар. Моның сәбәбе бик гади аңлатыла. Балага узган әнкәнең, билгеле бер сәгате суккач, ни дә булса ашыйсы килеп тәкате корый башлый. Нәкъ үз вакытында ул әйткән

ризыкны табып китерә алмасалар (әйтик, кыш уртасында яңа өлгергән чия) яисә авырлы хатын-кызның көйсезләнүе дип игътибарга алмасалар, туасы бала тәненә шул ризык сурәте мәңгелек мөһер булып сугыла икән. Әнкә теләгән ризыкның булмавы аркасында баланың гарип туу очраклары да бар. Моның сәбәбе нидә? Кем идарә итә бу хикмәт белән?

* * *

Бер районда халык каршында чыгышлар ясап йөрибез. Беркөнне мин, бераз шаяртып, ирләр пешергән ризыкның ни өчен хатын-кызларныкыннан тәмлерәк булуы хакында сөйләдем. Биш йөз кеше сыйдырышлы зал тын да алмый тыңлады. Кыйссам болайрак иде:

— Бу блюдоның исеме — «Аллалар ризыгы»,— дигән булып, олыдан кубып башлап җибәрдем.— Ашарга пешерер алдыннан кеше мәҗүси хәлгә килергә, кулыннан сәгать, балдак ише әйберләрне салып куярга, борчулы уйларыннан арынырга, фәрештә кебек чистарып калырга тиеш. Шулай булмаса... Онытмагыз, һәммә нәрсәнең дә җаны бар. Син кагылган кишернең дә, суганның да җаны бар. Килеп кагылуга, алар күңелең пакьмы икәнен шунда ук сизенеп алып, гөнаһлы кулга карыша башлыйлар.

Йә, бисмилла әйтеп тотыныйк әле, җәмәгать!

Иң башта кәбестәнең эре яфракларын казан төбенә катлап җәябез. Үрдәк түшкәсен ваклап, култык асларына сарымсак, лимон телемнәре кыстырып, яфрак өстенә куябыз. Араларына эре бәрәңге, тәгәрмәчләп туралган суган, кишер тезәбез. Тагын... берничә помидорны икегә ярып, әче алма турап, шалканны коймак калынлыгы гына тәлинкәләп кисеп, болгар борычы белән бергә салабыз. Кинзә, борыч, әнис орлыгы, яшел укроп сибеп, петрушка, рәйхан яфраклары кушабыз. Ике-өч кара җимеш төртеп куябыз. Инде болар өстенә тагын анар (гранат) төшләре сибәбез дә, эре кәбестә яфраклары белән томалыйбыз. Аннары, икенче, өченче катка, казан тулганчы шуны кабатлыйбыз. Иң соңгы катны кәбестә яфраклары белән томалар алдыннан бер стакан суга чамасын үзең белгәнчә тоз кушып болгатып саласың да, бер мәлгә сулышыңны тыеп карап торасың. Якут йолдыз кебек янып торган ит кисәкләре, кишер, суган, гранат төшләре, мул яшеллек — нинди кызыктыргыч төсләр бәйрәме — мозаика! Менә шул мәлдә кәефең шәплеге, күңел кытыклануы пешәсе ризыкка күчә. Шуннан соң, кәбестә яфраклары белән казанны томалыйсың да өстән сулы авыр миски белән бастырып куясың. Хәзер инде талгын ут үз эшенә тотыначак.

Бүтән уйларга бирелеп онытылуны ризык өнәми, үчләшеп, ташый яисә төмен яшерә. Шуның өчен ут өстендәге казан тирәсеннән ерак йөрмә, вакыт-вакыт килеп, тоткасына булса да кулыңны куеп киткәлә. Син — хуҗа. Син — янәшәдә генә. Бервакыт казан эченнән саркып кына сабый ис күтәрелә башлый. Эчтә үзара сөйләшү-килешү башлана. Һәммә ризыкның үз исен, тәмен бөтен юмартлыгы белән чыгарып каласы килә.

«Аллалар ризыгы» инде пешеп җитә дигәндә, син үзеңне кая куярга белми башлыйсың.

Ул — мондый да куе, тәмле исләрнең котыртып, борыннарны ярып керүе!..

Ул — казан астындагы утның тәкатьсез калып үрсәләнүе...

Юк, мондый да ганимәтле хушлыкны берүзең генә иснәп хозурлык алу гөнаһтыр, шулчак, түзмичә, форточканы ачып җибәрәсең. Тәрәзәдән татлы куәт, бәрәкәтле дулкын булып, урамга ургыла. Бу полосаны үткәндә этләр абынып егыла, песиләр саташып койрыгын болгый, таныш түгел кешеләр бер-берсе белән ялгыш исәнләшеп үтә.

Ә инде пешеп чыккач... Юк, мин бу ризыкның никадәр тәмле икәнен сурәтләргә сүзләр таба алмыйм. Шуны гына әйтә алам: бакча башында үсә торган гап-гади кәбестә... тел өстендә эреп югала. Кәбестә — гап-гади

авыл малаеннан Сорбонна университетын бетереп кайткан интеллигентка әверелә!

Мин шулай дип сөйләп бетерүгә, зал бермәл тын утырды, аннары кул чаба башлады, әле аннан, әле моннан сорау биреп кычкыручылар да табылды. Ә-әә, онытып җибәргәнмен, ни өчен ирләр пешергән ризык тәмлерәк була? Юк, бернинди фәрештә дә канатын тыкмый, аларның мәшәкате болай да муеннннан. Сәбәбе бик гади: ирләр мондый ризыкны елга бер генә пешерә, хикмәт шунда!

Кичә бетмәгән иде әле. Әмма мин сөйләп туктагач, күпмедер тамашачы, әле аннан, әле моннан кузгалып, чыгып китәргә ашыкты. Мин аларның ашказанындагы «бүреләрне» уяттым ахрысы.

Икенче көнне район үзәгендә ярминкә иде. Халык кайный, иң үтемле тауар шул булды — үрдәк итен кырып кына алып бетерделәр...

* * *

Өстәл янында ипле генә утырып, ризыкны тәнгә сеңдереп, ашыкмыйча тамак туйдыру — ата-бабаларыбыздан калган инсафлылык булган. Кызганыч, болгавыр чорларда кергән рәтсез гадәтләр моны оныттыра бара. Ташкент шәһәрендә бер ресторанда күзәтеп утырганым бар. Эре, сәламәт йөзле үзбәкләр, шәрык гадәте буенча, ипле генә сөйләшеп, әрмән коньягын тел өстенә генә сеңдереп, ашап-эчеп утырдылар. Аларның пычак-чәнечке тотулары да, саллы гранатны алты таҗлы чәчәк итеп кисүләре дә — үзе бер сәнгать иде. Ризыкны олылау, ризыкка табыну — соклангыч ашау культы. Тормышның кадерен белү, сабырлык, итагатьлелек, бер мизгеллек ләззәтне суза белү осталыгы иде бу. Мин аларга карап, үзебезнең хапыр-хопыр капкалап, тизрәк өстәл яныннан торып китәргә ашыккан әдәпсез гадәтебездән оялып утырдым.

Гомумән, Шәрык халыкларында ризык әзерләү, аны табынга чыгару — әллә нинди хикмәтле гадәтләрне берләштергән, югары зәвыклы сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелгән бәйрәм. Ризыкның төрлелеге, эчке хасиятендәге тәменнән кала тышкы бизәлеше, нәзакатле сурәте — искиткеч бай, төрле; монда син рәссам күзен дә, скульптор кулын да, җырчы аһәңен дә, нәгышчы осталыгын да тоясың. Бу инде тамак туйдыру өчен генә түгел, кешенең көнен бизәү, кәефен күтәрү, тәнгә сихәтлек өстәү һәм... бер генә бирелгән гомернең көндәлек тантанасы да.

Фәлсәфи ягы... дигәннән... Японнарның чәйгә әзерләнү һәм чәй эчү ритуалы — үзе бер симфония, яшәүгә мәдхия, үткәнең, бүгенең, киләчәгең каршында сабыр олуглык тантанасы. Ходайның бирмеш көнендә ашыкмыйча, микъдарлап истирәхәт алу, тотрыклы иман, борынгыдан килгән итагатьле тәртип, гореф-гадәтне санлаучы һәр ым — тән һәм җан хәрәкәтенең галәми мәңгелек белән кушылу мизгелен раслау бу!

Кояш бишеге илендә туган, ташларның да күңелен тыңлый белгән бу гаҗәеп сәләтле милләтнең һәр йоласын сәнгатькә әйләндерә белүенә карап, ашыгучан, кыйбласыз Европага кызыгырга гына кала...

* * *

Милләтнең сау-сәламәтме икәнен өлкәннәрнең йөз-кыяфәтенә карап белеп була. Алтмышынчы еллар азагында әле Казанда татар театрына гаҗәеп матур йөзле карт-карчыклар йөри торган иде. Яшьли, тән ныгыган чакта химиясез икмәк, бисмиллалы ризык ашап үскән, иске тәрбия алган бу буынның йөз-кыяфәтендә сәламәт рух әллә каян сизелеп тора иде. Актан-ак шәлъяулыклы, нурлы йөзле, шәрык кайнарлыгын җуймаган күмер күзле әбекәйләр, түгәрәк сакаллы, мәгънәле сабырлыгын тел байлыгына күчереп сөйләшә белгән олпат ил

агалары — кайда сез бүген? Театрның изге бинасына керүгә, сезне юксынып эзлим. Юк шул, юк инде... Кәбисә бураннары Яңа бистә зиратыннан үкенүле авазлар гына алып килә: соңладың... соңладың...

Намазлык яктысы, ислам диненең итагатьле тәрбиясе, Мәккә мәкамендә яңгыраган аятьләрдән күңеленә нур иңдергән соңгы могиканнар иде шул алар. (Яшьлегендә — утызынчы елларда — имансызлык байрагы күтәреп йөргәннәр матур картая алмый шул.)

... Кызганыч, койма буйый торган төсләр белән арзанлы сурәтләр ясап йөргән рәссамнарыбыз илаһи йөзле ул картларны рәсемгә алып кала алмадылар. Югыйсә, шул ук профессор Карл Фукс менә ни дип язган булган: «Казан татарлары таза гәүдәлеләр. Сынны горур тотып йөриләр. Мәчеттә аларның олпат картларына сокланып карап торганым бар. Борынгы Италиянең мәшһүр рәссамнары Тәүраттагы тарихи вакыйгаларны чагылдырганда бу могтәбәр картларны, һичшиксез, файдаланырлар иде».

Әйе, чит милләт кешесе күргәнне үзебез дә күрә белсәк, борынгы шагыйребез Кол Галине безнең кавемгә бөтенләй ят булган сурәттә көрәк сакаллы итеп азапланып ясап китергән рәссам Тавил Хуҗиәхмәт рәсемен күтәреп йөрер идекмени! Протопоп Аввакумның да ул кадәр гөнҗәлә сакалы юк бугай. Әкияттәге Хоттабыч карт белән генә чагыштырсаң инде... Никадәр зәвыксызлык үрнәге. Үз дәүләте булган, ислам дине чәчәк аткан чорның шагыйре шундый чаплашка кигән йончу карт була димени! Мин Кол Галине андый итеп күрергә теләмәс идем.

Әлбәттә, бу рәсем өстәгеләр күңеленә хуш килерлек итеп ясалган иде. Ул чакта партия хакимлеге иде бит. Татарның шагыйре берүк горур кыяфәтле була күрмәсен! Үзбәкләр әнә борынгы шагыйрьләрен зур-зур чалмалар кидереп, шәп итеп ясыйлар. Аларга килешә, алар бит союздаш республика... Безгә ярамый... Мәскәүнең кашы җыерыла күрмәсен...

Хәер, өстән басым ясамаганда да безнең рәссамнар аягүрә баскан каһарманнар иҗат итә алмадылар. Нишлисең, тәрбия... Гаҗәп бит, үз-үзен кечерәйтүдән, үз-үзен мыскыллап изүдән тәм таба алган мазохист милләт тагын бар микән дөньяда? Моны без һәртөрле сәнгать әсәрләрендә күрәбез, тоябыз. Хәтта, шәп кыяфәтле, ат күзле татар рәссамы көзгедән карап үзенең автопортретын да кысык күзле итеп ясый. Чөнки мәскәүлеләр татарны шулай күрә. Милли колорит. Хәтта безнең милләт кешеләре 1917 елгы революциягә кадәр кысык күзле булган, аннан соң гына күзләре ачылган, диючеләр дә бар. Алайса, кайбер кысык күзле Азия илләрендә бер түгел, өчәр революция ясап саташып йөрделәр, нишләп күзләре һаман шулай солы кибәге сыярлык кына ачыла икән соң?

«Андрей Рублев» фильмында татарлар ролендә казах артистлары уйный. Кысык күзле, җәлпәк йөзле кешеләр нәфрәтле-явыз булып күренә ахры урыска. Бу фильмның авторы Андрей Тарковский Казанга килгәч, Яшьләр үзәгендә очрашу булган иде. Бу хакта сорагач, ул болай дип җавап бирде:

— Элек татарлар шундый булган. Сез — башка татарлар. Тарихны белмисез!

«Сез — хәзерге арысланнар, элек ишәк булгансыз, яки сез — хәзерге ишәкләр, элек арыслан булгансыз»,— дигән кебегрәк җавап иде бу.

* * *

Төн. Мин балконга чыгам. Оялчан ай урагы читләтеп кенә йортлар арасыннан күтәрелеп килә. Каядыр сукбай этләр өрә. Күзгә моңсулык. Тагын мин, авылымны искә төшереп, ерактан балачагыма иеләм. Түбән оч малайларының тавышлары аермачык ишетелә:

— Гурт килә! Гурт килә!!

Бер-беребезне уздырып, кычкырыша-кычкырыша авыл башына йөгерәбез. Әнә, тегермән яныннан ишелеп бозау көтүе килә. Гурт көтүе — колагына тимер алка тагылган хөкүмәт маллары. Якын-тирәдәге районнардан кан-яшь чыгарып җыелган маллар (Гурт — сугымга куылучы көтү, алман сүзе, диелә Даль сүзлегендә. Гур — борынгы төрки телдә халык, күп дигән мәгънәне белдергән. Алманнарга бу сүз һуннардан кергән булырга тиеш).

Кичкә көтүне Хөсниттәйнең иркен ихатасына ябачаклар. Бездән кырык чакрымдагы Бөгелмә шәһәренә, ит комбинатына куыласы көтү башлыгы — гуртотправ дип атала. Ул бердәнбер ир кеше, калганнары — көтүче хатын-кызлар. Хөсниттәйнең мондый чакта төне буе өендә ут сүнми, мәҗлес бара, итле аш исе урамга ук саркып чыга.

Гуртотправ белешеп тора: әгәр инде Бөгелмәдә, төрле яклардан көтү килеп тулу сәбәпле, чират икән, гуртны куарга ашыкмый, хуҗалык көтүен болынлыктан бер читкә этәреп, үләнлерәк җирдә атналар буе хөкүмәт малларын көтәләр.

Хөсниттәйнең ихатасы киң булса да, барыбер, эре мал өчен кысанрак шул. Кай төннәрдә, таналар тынычсызланып, бер-берсен таптау очраклары да була. Мондый чакта, караңгылы-яктылыда килеп, гуртотправ сугымчыларны уятып йөри, минем әтигә дә чират җитә. Төш җиткәндә генә ул арып-талып кайта: «Биш сыер җәнлеген суеп-тунадык...» — ди. Шул көндә үк гуртотправ тана түшкәләрен атка төяп, Бөгелмәгә юл тота. Илленче еллар бит, каты заман, малның бер башын җуйса да үз башын бүкәнгә куячаклар.

Хөсниттәй өендә көн дә сый-мәҗлес, табын иттән сыгылып тора, диләр. Бу сүздә бераз хаклык та бардыр, чөнки авыллар аша үткән чакта гурт көтүенә хуҗалык маллары да ияреп китә, бер-ике көннән иясе табылмаса, алкасыз малны чалып, корбан итәләр.

Без малай чакта авылдан шулай көзләрен ничә тапкырлар гурт узгандыр: танасы, сарыгы, тай көтүе... Хөсниттәйнең ишегалды дуңгыз көтүен дә күрде. Лайлага баткан бу шыксыз җанварларны тамаша кылырга бөтен оч җыелды. Борыны такта белән бәреп тигезләнгән сыман, тасрайган күзле бу хәшәп хайваннарны минем беренче күрүем иде. Аптыраудан гаҗиз калып, өлкәннәрнең сүзләренә колак салам:

— Әннекәйгенәм! Урыс шушы нәмәстәкәйне асрый микәнни?!

— Табигать ялгышыдыр бу!

— Бу шакшының итен ничек ашамак кирәк!

— Ничек кенә ашадык әле! Сугышта Әмерикә салосы булмаса, ачка киселәсе идек.

— Күзеңне йомып кабып җибәрәсең тоз сибелгән кара ипекәй белән... Ашказаны телсез Нуриәсма кебек шым була. Өшетми дә...

Дуңгызларның җыбылҗык исе Хөсниттәйнең ихата-курасында икенче язга да сакланып калган иде әле. Шуннан бирле аның ишегалдында бер чеметем дә үлән баш төртмәде.

Ә бер елны авылга каз гурты килеп керде. Казлар, бер эзгә тезелгәннәр дә, гамьсез генә гаң-гаң зарланышып киләләр. Каз көтүенең бер очы Туйкә белән ике арадагы Җайлы яр чокырында, икенче очы, кәс-кәс басып, ашыкмыйча гына басу капкасыннан кереп килә. Ике яклап, шактый ара калдырып, сыек чыбык тоткан хатын-кызлар тезелеп бара. Бу бичара казларны, шулай тәпиләтеп, Бөгелмәгә кадәр ничекләр исән-имин илтеп җиткергәннәрдер...

Кар төшкәнче, кара күз буена шулай авылыбыз аша үткән гурт көтүләреннән тәэсирләнеп, әнидән: «Боларны кая алып баралар?» — дип сораганым хәтердә.

— Бөгелмәгә, улым, — диде әни. — Аннары, вагоннарга төяп, Мәскәүгә алып китәләр. Анда ил башлыклары яши. Рәсемнәрен күргәнең бар бит. Сталин бабаң. Ворошилов. Буденный. Тагын... Аларның эшләре авыр. Кайсы ат ите ярата, кайсы каз ите, кайсы чучка... Тьфү, тьфү...

Шул төндә мин гаҗәп төш күрәм: Мәскәү каласы безнең Суыр тавы артында гына, имеш... Һау-һаулап, безнең авыл болыныннан шул тарафка гурт куалар. Кызыл мәйданга Сталин бабай чыгып баскан, аның янәшәсендә Ворошилов, Буденный... Өчесе дә авызларын киереп ачканнар. Көтүнең бер башы безнең авылда, икенче очы, борыла-сырыла, Кызыл мәйданга барып җиткән. Әнә, Сталин бабайның авыз-мәгарәсенә тезелешеп казлар кереп бара. Ворошилов авызына дуңгызлар ыргыла. Мыеклы иң зур авыз — Буденныйныкы. Анда, кешни-кешни, атлар көтүе агылып керә.

Бу төшемне сөйләгәч, әни бермәлгә тынып калды. Авыз эченнән ниндидер дога укыды, иреннәре пышылдавыннан «...әшшәде әннә...» дигән сүзен генә абайлап калдым. Бу доганы ул яшен яшьнәп, күк күкрәгәндә укый иде бугай. Бераздан ул миңа тыныч кына итеп: «Төшеңне беркемгә дә сөйләмә, улым»,— диде. Бер генә әйтте. Һәм шунда төшемдә ярамаган нәрсә күрүемне аңладым, башымнан ниндидер дәһшәт канаты сыйпап алгандай булды. Әни акыллы булган, оныттырырлык итеп бер генә әйткән, кат-кат кабатлап, мине ачуланып ташлаган булса, кирелегем уянып, мин ул төшне, һичшиксез, бүтәннәргә сөйләүдән тыелып кала алмаган булыр идем.

Бүгенге көннән торып уйлыйм: нинди дәверләр булган, ачлы-туклы авылларның бәгыреннән өзеп алып, этап белән, көне-төне мал кудылар ул елларда. Каядыр, этап белән, кешеләр төркеме, кешеләр генәме — нигезеннән кубарылган халыклар болыты Себер якларына куылды. Ил эчендә гел хәрәкәт, коллар хәлендә — маллар, маллар хәлендә — коллар. Империянең бирән авызы ачылган, барысын йота, кайнатып юк итә тора.

Россиядә кешене ачлы-туклы тотып, хакимиятнең күзенә генә карап торган күндәм-ихтыярсыз коллар итү борын-борыннан килә. Урта гасырларда оброк җыйган кебек, комсызланып, бер кулга азык-төлекне туплап, әрәм-шәрәм итү — җәмгыятьнең законлаштырылган җинаяте иде. Элеваторлар, ит комбинатлары, гадәттә, тимер юл яисә зур сулар ярына урнашкан була. Моннан байлыкны каядыр алып китү уңайлы. Ачка интегә башласа, искереп, тәмен җуйган азыкны шул ук өлкәләргә саран гына кайтарырга да мөмкин. Рәтле илләрдә эткә дә бирелми торган ризыкны ашханәләргә, санаторийларга, балалар бакчаларына таратып:

— Мәгез, коллар! — дип өләшергә була.

Күп еллардан соң миңа Бөгелмә ит комбинатында булырга туры килде. Һәркайдагы кебек үк анда да — чират, мәхшәр иде. Кан, үлем исе... Алда котылгысыз үлем көткәнен сизәләр икән шул мәхлук малкайлар, сизенәләр, шуңа күрә алларына салган азыктан да баш тарталар. Бәлки алар, соңгы минутларында чарасыз калып, адәмнәрнең вәхшилегенә моңсу күзләре белән карап, эчтән генә каргый, ләгънәт укыйлардыр. Алла каһәре өстенә мал каргышы да төшәдер адәми затларга.

Мин мондагы мәхшәрне күрдем дә күрмәдем дә шикелле. Сурәтләргә алынсаң, каләм калтырар... Чиратта озак торудан һәм куркудан шактый авырлыгын җуйган сыер терлеге тар аралыктан куып кертелә дә электр тогы белән бәреп үтерелә. Шул мәхшәрдә мал тәненең һәр җепселенә, һәр күзәнәгенә коточкыч курку, тетрәнү, дәһшәт дулкыны күчеп кала. Мондый куркулык коелган ит ризыгы ничек инде җанга ятышлы булсын! Нигә безнең илдә кешеләрнең күбесе сытык чырайлы, салкын күзле, шикчел, дуамал дип уйлыйсыз? Иҗтимагый сәбәпләрдән кала, кешенең сәламәтлеген какшата торган үләксә ите ашаудан. Бәлки большевиклар дөньяны басып алу максатын тормышка ашыру өчен махсус шулай кешеләрне биологик яктан үзгәртеп, күндәм-буйсынучан, кирәк чакта ярсу-дуамал итеп тәрбияләргә теләгәннәрдер. Адәм баласын маңкортка әверелдерү өчен алар юкка гына әллә нинди биологик һәм химик тәҗрибәләр үткәрүче лабораторияләр ачмадылар бит.

* * *

Ризык җыю, мәҗлес, табын мәдәнилеге — бу тормышның кадере хакында уйланганнар өчен зур фал. Кызганыч, без ашау-эчү белән бәйле табын гадәтләрен оныта барабыз, булганнарын күрсәтә белмибез. Кытайлар, японнар әнә миллионнарча кеше яшәгән, үзе бер ил булырлык Нью-Йорк кебек шәһәрләрдә дә үз йөзен югалтмыйлар. Үзәктә тулы кварталлар алар кулында. Үз клублары, үз ресторанбарлары. Күз алдына китерәм: син анда кереп, кытайның нәни генә дөньясына эләгәсең. Идән-түшәм, диварлар кытайча бизәлгән. Сыгылмалы музыка сине Күк асты иленең серле халәтенә кайтара. Үзләре өчен монда керү еракта калган илен сагынып юану да, менә без шушылайрак яшибез инде, дип бүтәннәргә күрсәтәсе килеп горурлану да, чит-ят арасында милли рухыңны саклау өчен дәрман алу үзеге — нәни ватан да бу... Чит милләтнең табынган төсе, көе, гадәте, син аңламаган теле һәрчак кызыктыра, ике арадагы мәңге үтеп булмастай сергә төшенәсе килү хисе бу дөньяның олуг мәгънәсен аң-зиһен биеклегеннән тагын да югарырак чөя.

Нигә соң әле мин, төшенкелеккә бирелеп, әллә кая, океан артындагы илгә китеп бардым? Менә ич, үзебезнең Казаныбызда, Үзәк урамда татар йөзен күрсәтерлек урыныбыз бар — «Бату хан» кафесы. Менә мин Мәскәү кунагын — рус язучысын хәзер шунда алып керәм. Саллы имән ишек ачылуга, эчтә зелиң-зелиң көмеш кыңгырау тавыш бирә. Ул арада каршыбызга елмаеп, калфак кигән ут-күмер күзле чибәркәй килеп баса, үтә дә ягымлы, йомшак тавыш белән аяк киемнәребезне салырга куша, йомшак эчле чүәкләр тәкъдим итә.

Без, малай чакта яланаяк йөгергән үлән йомшаклыгын хәтергә төшереп, калын келәм өстеннән эчкә үтәбез. Җиләс һава. Җир йөзендәге ике миллиардтан артык халыкның колагына ятышлы татар музыкасы саркып кына ишетелә. Тыенкы аһәң, җилпәзә җиле кебек кенә сирпелеп, тәрәзә төбендәге гөлләрне иркәли. Без ишек төбеннән бер-ике адым атлауга, эчке тарафтан чыгып килгән Хуҗа күренә. Кырпу бүрек кигән, түгәрәк сакаллы Хуҗа, чын гәрәбә ташларыннан һиндстанның үзендә эшләнгән дисбе төймәләрен бармагы белән ыспай гына тарта-тарта: «Хуш килдегез, мөхтәрәм кунаклар!» — дип ике куллап күрешә. Кулларны юып алырга тәкъдим итә. Шул мәлдә кафе хәрәкәткә килә. Юк, монда кычкырып, бер-беренә әмер бирү, буталыш кебек, музыка агышын сискәндерерлек кискен хәрәкәт сизелми, оҗмах бакчасында чагылып киткән фәрештәләрнең өнсез ак күләгәләре йөзеп үткән сыман тын рәхәтлек.

Утырышабыз. Өстәлгә кыл нечкәлегендә киселгән казылык, җилдергән ат ите куела. Десертка — буза. Кунагым ап-ак буза салынган бәллүр графинга ымлап:

— Башка китәме соң моны эчкәч? — дип куйды.

— Китә... Күп эчсәгез,— диде Хуҗа.— Русларда бузатер дигән сүз бар. Менә шушы татарның бузасын мичкәләп эчеп исергән кешегә карата әйткәннәр инде аны.

Тышына ак бүре сурәте төшерелгән ризык исемлеге — меню үзе бер китап кебек. Авыз суын китерә торган нинди генә ашамлык исемнәре саналмаган монда; юк, боларны тыныч кына укып булмый, күз йөгерә, кул калтырый, аң томалана — бөтенесен берьюлы татып карар өчен гомереңжитмәс шикелле комсызлык уяна.

— Кунак теләге каршында без — кол,— диде Хуҗа.— Әгәр үз милли ризыгыгызны теләсәгез — боерыгыз, әзерләп китерерләр.

Менюны караштырган кунагым:

— Мин монда рус ашлары бүлегендә пилмән күрмим,— диде.

— Пилмән уйгыр халкыннан кергән ризык. Шул бүлектән карагыз.

— Блины?..

— Коймакмы? Ул — татар ашларына керә. Элек «белен» дип аталган. Яшь киленнәрне таба ашы — белен пешертеп, уңганлыгын сынап-белеп караганнар.

Май өреләре энә күзе кебек кенә шытып чыккан казылык кисәкләрен тел өстенә сала-сала шулай сөйләшеп утырган арада табынга кайнар бозау ите, сай тәлинкәдә көмешсу әрем учмасы чыгардылар.

— Мөселманча, бисмилла әйтеп суелган иттән авыз итегез,— диде Хуҗа.

— Ничек була инде ул? — диде кунагыбыз.

— Аны болай гына аңлатып булмый. Аның өчен мөселман булып туарга кирәк,— дип Хуҗа әремле тәлинкәне безнең алгарак этәрде.— Иткә үреләсе бармакларыгыз белән әрем учмасын башта тотып-тотып алыгыз. Әремнең әчкелтем тәме бармактан иткә күчеп, кайбер соусларны алыштырыр.

Бераздан түрдә, айлы манара белән бизәлгән сәхнәдә музыкант кызлар пәйда булды. Чулпылар таккан, энҗеле калфаклар кигән кара толымлы кызлар, тезелешеп утырдылар да, уен коралларын, сабыен тоткан кебек, иркәләп кенә алларына куйдылар.

— Ни боерасыз, әфәндем? Болар виртуозлар,— диде Хуҗа.— Әнә, сез гусли дип йөрткән уен коралы. Гөслә — марийларныкы, балалайка — яһүдләрнеке, думбра — казакътан. Курай, саз, кубыз — татарныкы. Мондый уен кораллары белән теләсә нинди халык көен уйнап була.

— Мин казак көйләрен яратам. Тумышым белән Доннан,— диде кунагыбыз.

Кызлар, күндәм баш иеп алганнан соң, Дон казаклары көйләрен уйнарга керештеләр. Бераздан Хуҗа үзе дә түзмәде, эреле-ваклы курайларын алып, кызлар янына барып басты, дәртләнеп, уенга кушылды.

Кайнар шулпа, пәрәмәч килгәч, ул янибызга төшеп утырды.

— Дон казакларының төп өлеше — кыпчаклар, безнең борынгы бабаларыбыз. Чын казак көйләре нәкъ безнең керәшен татарларныкы кебек,— диде Хуҗа.

Бузага ак аракы кушып эчәргә өйрәнеп алган кунагыбыз, иркенәеп, кулларын җәеп җибәрде дә:

— Без руслар да шул ук керәшен татарлары ич! — дип, кызмача тавыш белән «Эй, ухнем!»ны сузып җибәрде.

Хыялдагы кафедан без төн уртасында гына чыктык. Кәеф шәп, Казан төне җылы, күге биек, урамнары киң иде.

Мин бу төндә үзем өчен бәләкәй генә ачыш ясадым. Бу дөньяда һәммә кеше кебек үк, һәр халык та үзенең барлыгын, өстенлеген расларга тырыша; һөнәре, сәнгате белән мактана, көч сынаша, булдыклылыгын күрсәтә — җир йөзендә мәртәбәле урын даулый. Менә шул күп һөнәрләрнең берсенә — затлы ризык әзерләү осталыгы да керә. Гаҗәп бит, кунак булган җиреңдә татып караган бик тә тәмле ризык гомерең буена онытылмый, хәтергә сеңеп кала. Димәк, тәнгә сихәтле яткан ризыкның илаһи тәэсире бар. Димәк ул канга турыдан-туры шифа булып күчкән. Кан сафлыгы исә тәнгә кунаклаган рухның канатын сугарып торучы галәми куәт — Җил-Су-Кояш хәрәкәте.

Әнә шул галәми бәрәкәт каршында бер дога кылыйк әле.

Амин.

## Йа раббым

*Йа сакалым, сән юк идең, бән хуб идем,*
*Кызларның каршысында мәхбүб идем.*

Г. Кандалый

— Саумы, яшь дустым!

Бүлмәне корыч ныклыгы һәм бәрхет йомшаклыгы үзара ярашкан көчле тавыш биләп ала. Мин бу тавышны әллә кай заманда ук ишетеп,

хәтеремә сеңдереп калганмын икән бит. Авыл клубының сәхнә алдына тезләнгән ачык авызлы малай, пәрдә артыннан шигърият җилен ияртеп Фәйзи Йосыповның килеп чыгуын хәтерлисеңме син? Һәр сүзнең нәзберек таҗларына тере сулыш өреп, һәр сүзнең җанын имгәтмичә, камил матурлыгынача җиткереп, һәр сүзнең яңгырашын йөрәк тибешенә тәңгәл китереп, гомумән, Сүз кодрәтенә мәҗүсиләрчә табынган һәм тамашачының да күңеленә шушы илаһилыкны иңдерә белгән Фәйзи Йосыпов бит ул!

Төрле тарафлардан халкымның өметен тарткан кыйбла — мәркәзи Казан теленең матурлыгын сәхнәдән сәхнәгә, төбәктән төбәккә җиткерүдә Фәйзи ага Йосыпов үз дәверенең кабатланмас шәхесе иде.

— Нихәл, яшь дустым! Военкоматка барышлый сугылып чыгыйм дидем. Гел чакырып йөдәтәләр бит шунда. Минсез хәрбиләрнең дә эш бармый күрәсең...

Бусы инде яшьлеген җуясы килмәгән Фәйзи аганың кыланып әйтүедер. Аның тавышы Язучылар йортының мәһабәт кридорларына ташып чыгуга бүлмәгә берәм-берәм яшь шагыйрьләр җыела башлый. Дәверләр кул бирешә... Фәйзи ага очынып китә, кызыксынучан күз карашларын алкышлар итеп тойгандай, үзе сөйләгән хатирә-ис¬әлекләр эчендә кинәнеп яши бирә. Аның өчен тормыш белән сәхнә арасы — бер адым. Аңы, уй сөреше акырынайган өлкәннәр янында читкәрәк тартылырга тырышкан яшьләрне дә үзенә карата ала шул кинаяле, хәрәкәтчән акыл... Шунысы гаҗәп: тавышы бер дә картаймаган икән бит аның!

Каршыбызда күпме мәшһүр шәхесләрне күреп калган сиксән яшьлек тарих басып тора.

Исемнәре легендага әверелгән затларның кайчандыр җирдә гадәти рәвештә яшәп киткәнлекләренә инде ышануы да кыен. Ышанасы килеп, Фәйзи аганың сүзләре аша булса да бөекләрнең җиң очына «кагылып» алу теләге уяна. Китә сораулар: Ибраһимов, Җәлил, Такташ, Сәйдәш... Тагын әллә кемнәр...

* * *

— Мусанымы? Күрмәскә... Муса Җәлил мине беренче мәртәбә кызлар янына алып барды. Үтә елгыр, хәрәкәтчән кеше иде ул. Хатын-кызларга бик игътибарлы иде... Кыяфәт, гәүдә тотышы ягыннан Мәхмүт Хөсәен аңа тартымрак...

— Сугыштан соң Муса Җәлил турында илен саткан, дигән хәбәр таралган. Сез ул рәсми яланы ничек кабул иттегез?

— Җил кайсы яктан иссә, шул якка бөгелергә торган кайбер черек бәндәләр таратты ул яланы. Мин аның шигырьләрен кая барсам да сәхнәләрдән сөйләп йөрдем, ул ялага ышанмадым. Ничек алай дисеңме? Тормыш, энем, уен да бит әле ул...

Филармониядә репертуар өчен җаваплы кеше булып Фатыйх Зәйни абый эшли иде. Коточкыч калын күзлек кия, шуның өстенә язуга лупа аша да карый иде. Мин шагыйрьләр язылган исемлегемне моның алдына китереп салам. Зурайткыч пыяла аша карый бу, Муса турына җиткәч, бармагы белән төртә, әмма бармак бөтенләй башка шагыйрь турына эләгә. Мин дәшмим. Шулай итеп Муса Җәлил «исән» кала торган иде. Репертуарга мөһер сугылган, кул куелган, кем бәйләнә алсын.

Сугыштан соң, Зәйни абый мине беренче мәртәбә тыңлагач: «Синең репертуарыңда Сталин турында бер генә шигырь дә юк, бар, өйрәнеп кил, шунсыз беркая да чыгармыйм!» — диде. Ул чакта Әхмәт Ерикәй бик популяр шагыйрь иде, җитмәсә, Язучылар союзы председателе дә, үзең беләсең, җитәкче чакта бик мактыйлар бит язучыларны, урыннан төшкәч, нишләптер, аларның сәләте бик тиз шиңә... Өйрәнеп килдем мин моның Сталинга багышланган шигырен, сөйләп бирдем Зәйни абыйга.

«Менә булган, хәзер инде теләсә кайсы төбәккә чыгарга хакың бар»,— ди Зәйни абый. Ул шигырьнең азагын сөйләп күрсәтимме үзенә:

Кояшыбыз безнең, аллабыз,
Синнән башка тын да алмабыз!

Фәйзи ага буылып-буылып көлә башлый, мин дә аңа кушылам. Әйе, рухны гарипләткән, акыл галәмен таш гасырына кире кайтарган җәмгыятьтә мәсләк тә, күндәм иҗат та чын пародиягә әйләнә икән шул. Миллионнарның кан-яшен койдырган кара еллар искә төшереп җыларга гына түгел, ә шаркылдап көләргә дә җирлек калдырган. Мин Фәйзи агага карыйм да уйлап куям: әгәр ул тоташ изелеп кенә яшәгән булса, заманыннан көләргә үзендә көч тапмаса, бу яшькә кадәр җитә алыр иде микән?..

— Чистай районының Яуширмә авылыннан бит мин. Гаяз Исхакый эчеп үскән чишмә суын татыган малай мин. Әтисе ачкан мәдрәсәдә Гаяз Исхакыйның энесе Хәсән абый укыта иде безне. Ялгышмасам, 1918 ел иде бугай. Коточкыч ярлы чак. Кышкы суыкта кайсыбыз яланаяк, кайсыбыз сүсәргән чабатадан мәдрәсәгә йөгерәбез. Идәнгә салам җәелгән була, шунда тезләнеп, аякларны аска салып утырабыз. Беркөнне Хәсән абый дәрескә таныш түгел кеше белән килеп керде. Бик пөхтә киенгән, уртача буйлы, чәчен матур итеп тараган абыйга карап: «Менә бу Гаяз әзи була»,— диде. «Нихәл, канатләр, исәнмесез, балалар...» — дип Гаяз абый бер мәлгә сүзсез калды. Безнең сәләмә өс киемнәрен шаккатып күздән кичерде дә, кесәсеннән ак кулъяулык чыгарып, тәрәзәгә таба борылды, күзләрен сөртте. Шул дәрестә без аның авызыннан яңа сүз ишеттек. «Менә революция булды, сез бәхетле яшәрсез әле, балалар»,— дип Гаяз абый революция дигән сүзнең мәгънәсен аңлатып бирде. Авылда ул озак тормады. Безне өч айлап укыткannan соң Казанга китеп барды. Без аны басу капкасына чаклы озата бардык. Бүгенгедәй күз алдымда: чана артына матур итеп үрелгән сандык бәйләнгән иде. Басу капкасына җиткәч, Гаяз абый атын туктатып, чанадан төште. Безнең белән саубуллашкач, энесенә карап: «Хәсән, Сәйяр абзыйның менә бу малае бик үткен күренә, аны үзең белән алып кил Казанга, укыт син бу баланы»,— дип, минем якка ым какты.

Хәсән абый мине, ятим малайны, Казанга алып килеп балалар йортына урнаштырды. (Сталин җәлладлары утызынчы елларда Хәсән абыйны аттылар).

Педагогия техникумына укырга кергәч, театрларга, концертларга йөри башладым. Җае чыкканда сәхнәдән шигырьләр дә сөйли идем. Бервакыт Галиәсгар Камал яныма килеп: «Сиңа, энем, артист булырга кирәк, театр техникумына кер син»,— диде. «Мин педагогия техникумында бит, директорыбыз Нургали абый бик усал, җибәрмәс шул»,— дим. Галиәсгар абый кайнар сөйләшә торган кеше иде, кистереп кенә куйды: «Әйт Нургалигә, Галиәсгар абый кушты диген!» Мин кайтып техникум директорына аңлатып бирдем. Үземнең дә артист буласым килә, дидем. «Кәҗә — мал түгел, артист — кеше түгел! Рәтле артист булырлык булсаң гына бар!» — дип кычкырды Нургали абый.

Артык тәбәнәк буйлы идем мин. Егерме яшькә кадәр сантим да үсмәдем, техникумга кабул итүчеләр «моның буе бик кечкенә бит» дип пышылдаша башлагач, дилбегәне Кәрим ага Тинчурин үз кулына алды: «Энем, бас әле урындыкка!» — диде. Шулай итеп, урындыкка кунаклап, мин Такташның «Нәни разбойник» дигән шигырен сөйләдем. Сөйләп бетергәч, Кәрим ага Тинчурин: «Менә күрдегезме, ничек үсеп китте бала!» — диде. Әнә шулай итеп мин театр техникумына кабул ителдем.

Фатыйх Әмирхан бер ел буе дәрес бирде безгә. Колляскасы белән аны баскычтан күтәреп мендерә идек. Бик ягымлы, даһи кыяфәтле кеше иде

ул. Шәп киенә. Кара күзләре гаҗәеп матур иде. Без аның һәр сүзен тын да алмый йотып утыра идек.

Унбиш яшемдә мин Татар мәдәният йортында, Касыйм Шамил кул астында балалар театрында уйный башладым. Еллар үткәч, бер гаплэшеп торганда: «Касыйм абый,— мин әйтәм,— яшь ягыннан син безнең иң олы артистыбыз инде»,— дим.

— Алай димә, алай димә, миннән олыраклар бар! — ди бу.

— Кем ул? — мин әйтәм.

— Сара Садыйкова,— ди Касыйм абый.

Туксан яше туларга тугыз көн кала үлде ул. Ә Сара ханым Садыйкова аңардан соң ун елдан артык яшәде әле. Яшьрәк күренәсе килеп, яшен яшерү артистларга борын-борыннан хас гадәт инде ул, нишләтәсең...

Хәтерлисеңдер, Сара ханымның соңгы иҗат кичәсен уздырдык. Вафатына берничә генә көн калган булган икән. Шифаханәдән генә чыккан Сара ханымны сәхнәгә менгердек. Ул анда «Сайра, сандугач»ны җырлады. Концертны мин алып бара идем. Микрофон барын бөтенләй онытканмын. «Маладис, Сара ханым, йөз яшендә берәү дә болай җырлый алмый!» — дим. Сара ханым шундый усал итеп карады миңа — балта тел, дип үз-үземне сүгеп тә куйдым. Әнә шулай, өлкән яшендә, сәхнәгә чыгып, халык белән хушлаша алуы белән бәхетле иде ул. Зал аягүрә торып кул чапты. Соңгы тапкыр икәнен бәгыре белән сизгән күпләрнең күзендә яшь иде ул минутта...

Фәйзи ага бер мәлгә тын кала... Без, үзебез дә сизмичә, исеме тарихта калган шәхесләр аша хатирәләргә күмелеп барабыз икән. Сораштырып каласы килә шул.

— Камил Мотыйгыймы? А-аа, ул бөтенләй башка иде. Гәүдә-кыяфәт белән дә, акыл иясе буларак та, татарның беренче сәхнә җырчысы буларак та олы шәхес иде ул. Тавышы бас, дөресрәге — баритональ бас иде. Опера җырчысына тартым иде ул. Калын тавышлы җырчының, гадәттә, моңы булмый. Менә безнең, гаҗәпкә каршы, Сөләйман Йосыповның тавышы калын, ә моңы бар. Андыйлар сирәк була ахрысы.

Соңгы елларында Камил Мотыйгыйны бик җәберләделәр. «Красная Татария»дә тәрҗемәче булып эшләде ул сугыш алдыннан. Үзенә каршы язылган төрле әләк-доносларны үзе үк тәрҗемә итеп утыра иде. Моңа ничек түзмәк кирәк! Әхмәт Фәйзинең Тукай турындагы пьесасында Камил Мотыйгый образы начар итеп бирелә, булачак шагыйрьгә зур әдәбият дөньясына чыгарга ярдәм итүче булып сурәтләнми. Мотыйгый бу спектакльне караган булырга тиеш. Барысын да йөрәгенә җыеп килгәндер инде, ул 1941 нче елда асылынып үлде. Типографияләр тоткан, булдыклы, татарның карап торырлык зыялы кешесе әнә шулай яңа хакимияткә ярамады.

Салих Сәйдәшев — безнең бәхетебез дә, үкенечебез дә... Хәзер генә аның турында дөресен яза башладылар. Искиткеч мөлаем, олы җанлы, шул ук вакытта кече җанлы да кеше иде Салих ага. Һәркем белән исәнләшер, туктап сөйләшер иде. Еш кабатларга яраткан бер сүзе хәтеремдә калган: «Әткәй мәрхүм әйтә торган иде, баш исән булса, мал табыла ул, дип. Башыма чыртым да булмады, ә мал юк та юк». Аны мәҗлесләргә еш дәшәләр иде. Исерер өчен эчми иде ул. Түмен белеп, утырдаш булып, ачылып сөйләшерлек кенә... Шаулы мәҗлес вакытында, кинәт торып, сызгырына-сызгырына барып, пианино каршына утырыр иде.

Казанда дан-шөһрәт тоткан гүзәл бер ханымга өйләнде ул. Урамнан барганда бөтен халык туктап гаҗизләр иде ул ханымга. Бәлки шул гаилә мәхәббәте аңа чиксез илһам биргәндер. Салих абыйның «Кандыр буйлары», «Ил» драмасына язган искиткеч музыкасы шул чорда туды. Аннары... Әлеге гүзәл ханымның хыянәте... Салих Сәйдәшев аны бик авыр кичерде. Аннары... Кәрим Тинчуринны — композиторның кулга кул тотышып эшләгән зур иҗат кешесен кулга алулар... Талант иясенең

самими күңеле моңа ничек чыдасын. Бер очрашуыбыз аеруча истә калган. Салих абыйның йөзе агарып киткән, кыяфәте монсу. «Нихәл, бәгырь?» «Үзегездә ни хәлләр, Салих абый?» «И-ии, сөйләмә инде... Менә кемнәр кулына калдык без... Радиога, Кәрлә Зәйнәпкә кергән идем. Бар, исерекбаш! дип куып чыгарды». Салих ага шунда гарьлегеннән җылады. Менә, Коръән тотып ант итәм, бер сүзен дә арттырмыйм да, киметмим дә,— дип Фәйзи ага әрнүле тавыш белән әйтеп куйды.— Кешене тереләй үтерү бит бу! Ә шул ханым, музыка белгече түгел, музыканы бөлдерүче Зәйнәп Хәйруллинаны әйтәм, бүгенге көндә имеш Сәйдәш турында китап яза, диләр. Моны ничек аңларга?! Мин ул язган сүзләрнең ихласлыгына ышана аламмы?!

— Сәйдәш күгән томаларга тырышкан зуррак типлар да бар бит әле...

— Нәҗип Җиһановны әйтүеңдер инде бу. Ул көнләшеп яшәде. Халыкның Сәйдәшне ни өчен болай кадерләп яратуын аңлый алмады ул. Кызганыч, Җиһанов исән чакта Сәйдәшкә һәйкәл куярга өлгерми калдык.

— Җиһанов — һичшиксез, зур композитор. Ул дистә еллар буена татар музыкасының башында торган шәхес. Үз дәверендә нинди игелекләр кылган, талантларга карата күпме гөнаһлар эшләгән — моны бизмәнгә куеп ачыклауны теләсә кем түгел, ә намуслы, шул чорны яхшы белгән фәһемле кешеләр башкарырга тиеш. Салих Сәйдәшевнең бөеклеген, ниһаять, 90 яшьлеге тулган көннәрдә генә бөтен тулылыгы белән күз алдына китердек. Бәһа биргесез талант. Халкыбызның рухын бер башка югары күтәргән бу тантана элгәрәк булса иде, дигән нәүмиз уй күпләр күңелендә тугандыр мөгаен. Элек моңа мөмкинлек бирмәделәр шул. Сәйдәшне күтәреп, үзләре бәләкәй калудан курыктылар. Әйе, вакытлы дан хакына рухи җинаять кылганнар иртәме-соңмы җавап тотырга тиеш. Гыйбрәт алу өчен кирәк бу. Берни дә эзсез югалмый тормышта. Күпләрнең кара эшләре архивлардан калкып чыгачак әле. Балаларымның, оныкларымның — нәселемнең йөзе кызармасын дисәң, намуслы яшә, җирдә моңа мөмкинлекләр бар!

Минем шулай кызып сөйләвемне сүндерергә теләгәндәй, Фәйзи ага сәхнәви тавышын әкеренәйтеп, киңәшләшкән кебек әйтеп куйды:

— Мин бер нәрсәне аңладым озак яшәгән гомеремдә: намуссыз иҗат кешесен күпме генә чөй, күпме генә макта, лауреат ит, һәйкәлләр куй — барыбер әкренләп таркала, онытылуга дучар ителә. Сәйдәш кебекләр иҗаты исә вакыт узган саен үсә, зурая гына. Гали затлар үз йөрәгендәге кояшның нурын соң тамчысына кадәр кызганмыйча иҗатына салып китәләр.

Эчемнән генә уйлыйм: тормышның шундый язылмаган кануны бардыр ахырысы. Татарның бөек уллары йә башын кистереп, йә тарих тәгәрмәче астына үзен аямыйча ташланып кына һәйкәл булуга ирешә. Үлгәннән соң да яши алу бик авыр бирелә татарга. Ә бәлки бөек шәхесләрнең трагик язмышка дучар ителүе — табигый фалдыр?.. Бәхетле канәгатьтән фидакяр талант иляре чыга димени... Галимҗан Ибраһимов төрмәдә тәмам череп беткән үпкәсеннән бәреп чыккан соңгы кан тамчысы белән «этләргә хезмәт иткәнмен икән» дип язып калдырган. Аның кульъязмаларын яндырган палачлар әле бүген дә исәндер... Шамил Усманов, малай чакта ук комиссар булуга ирешкән атаклы Шамил Усманов, борын астыннан юеше дә кипмәгән коммунист-җәллад сузган хыянәтчел язуга кул куярга теләмичә, үз күзенә инрәеп каләм белән кадый...

— Артык бай бугай без, артык чәчелгәнбез. Барлыйсы бар халыкның улларын,— ди Фәйзи ага.— Менә Фәйзулла Туишевны гына алыйк. Дөнья гизгән гаҗәеп кызыклы кеше иде Фәйзулла ага. Манчжуриядән ул башта Мәскәүгә кайтты. Урыс концертларында уйнап йөрде. Аннары үз халкына хезмәт итәргә кирәклеген аңлап, татар эстрада коллективы

оештырды. Анда Галия Кайбицкая, Асия Измайлова, Наилә Рәхмәтуллина, Зөһрә Бәйрашева кебек атаклы артистлар арасына мин фәкыйрең дә эләктем.

— Нindирәк кеше иде ул? — дигән соравыма каршы Фәйзи ага жыелыбрак утырды, күкрәгенә сулыш җыеп, Туишев роленә керде, мишәрчәләп сөйли башлады:

— «Дәшмә, молокосос!» — Мине шулай атап йөртә иде ул. «Нихәл соң, Файзулла абзый?», «Какой халь монда, юкька катьтым, киредән Манчжуриягә китәрмен, ахры...» «Нишләп алай, Фәйзулла абзый, син безнең эстраданың главный кадры бит?!» «Кадр, кадр, үземә дә юк кадер! Тукайны да ачтан үтердегез, мине дә үтермәкче буласызмы?!» — ди бу. Япон императорыннан алган грамотасы, Петербургта галиҗанәб патша хатыны таккан Георгий тәресе бар иде Фәйзулла абзыйның. Сталин дәверендә андый нәрсә өчен башыңны себер җибәрергә мөмкиннәр иде. Беркөнне миңа бирде дә: «Бар. Болакка илтеп ташла кеше-кара күрмәгәндә», — диде. Георгий тәресен учыма кысып бардым да Болак суына ташлап килдем. Нишлисең инде, үтенгәч... Фәйзулла абзыйның бер бүлмәсендә этләр генә яши иде. Шул уникe этнең берсе үлде бер заман. Мине күмәргә җибәрде бу. Аптырап беттем аулак урын эзли-эзли. Ул чакта хәзерге цирк урынында баткаклык иде, шунда илтеп күмдем мин аның затлы нәселле этен. Так что, цирк бинасының нигезенә Фәйзулла Туишевның эте күмелгән.

Ни өчен легендар артист санала иде дисеңме? Ул эреле-ваклы гармуннарда искиткеч оста уйный иде. Бармакларына дүрт-биш гармун кия, уйнау гына түгел, жонглерлык та итә белә иде ул. Нәни гармунның берсен чөеп җибәрә, бүтәннәрендә уйный тора, гармунны тотып алуга аның да төймәсенә баса, икенчесен чөеп җибәрә, ә көй өзлексез дәвам итә. Болай ук эффектлы уйнаучы урысларда да, бүтән халыкларда да юк иде. Төрле милләт көйләрен дә уйный белә иде ул. Һәр гармунының исеме бар иде: йә Сәҗидә, йә Зөләйха, йә Маруся, йә Оксана... Әлбәттә, бу исемнәр һавадан алып кына кушылмаган иде...

Фәйзулла Туишев бай яшәде. Ак генерал кызына өйләнеп кайткан иде ул. Хатыны яһүдә иде. Ачлык елларында сатканнан калган әйберләре дә әллә нихәтле иде. Көмеш-бәллүр канделябрлар дисеңме, кыйммәтле агачтан эшләнгән мебельләр, затлы рояль, алтынланган вазалар, Петербургта, Япониядә, Америкада чыккан газеталар, аның рәсеме белән бирелгән мәкаләләр, әллә күпме истәлекле бүләкләр, бихисап баянгармуннар дисеңме — барын да санап бетергесез. Әзер музей ачарлык иде. Чит милләт кызына өйләнгән татар иренең язмышы ничек бетә — Фәйзулла абзыйның да язмышы шулай тәгәлләнде. Үзе үлгәннән соң аның бөтен әйберләрен исраф итеп бетерделәр. Эзе дә калмады. Үзенең асыл улларын кадерли белми шул безнең халык. Әле беркөн күрәм, Туишев портретын ясарга диеп рәсемен эзлиләр. Калмаган. Радиодагы язмаларының сыйфаты начар, ул чактагы мөмкинлекне үзең беләсең, Фәйзулла абзый үзе исән чакта, шаяртып, Казандагы гармун фабрикасына минем исемне бирергә кирәк, ди торган иде. Фабрика һаман бар, ә исеме юк...

Бүгенге сәнгать әһелләреннән Фәйзи ага Илһам Шакиров хакында яратып сөйли. Олугъ сәнгатькә ирешкән шәхес каршында ул соклануын яшерә алмаган малай хәлендә, талантка табыну ләззәтен кичерә белә:

— Миңа, концертларны алып баручы буларак, Илһам белән егерме еллап сәхнәдә бергә эшләргә, иҗат итәргә туры килде. Ул килгәч, безнең филармониядә татар җыры, татар моңы үзенең колачын җәйде. Илһам халыкка гына түгел, җырчыларга да җырчы булды. Аның моң мәктәбеннән күпләр сабак ала башладылар. Илһам җырчы гына түгел, артист буларак та, сәхнәдә кайчакларда юморист та булып китә, тапкыр сүзгә дә оста иде. Бервакыт шулай Мәскәүнең Колонналы залында концерт бирәбез. Җыр тынган арада бер мишәр агае сикереп торды да: «Иптәш

Илһамов, ничава гына ерлыйсың икән, ну, гел татар да татар, ә син менә урысча җырла!» — ди бу.

— Абзый кеше,— ди Илһам.— Без бит бүген татар җырын тыңларга җыелдык, анысын белеп килгәнсездер шәт...

— Минем хатын марҗа, аның өчен җырла!

— Хатының марҗа икән, өйгә кайткач үзенне урысча җырлатыр да, биетер дә.

Илһамның бу сүзеннән халык шау итеп көләргә тотынды.

Баянчы Рамил Курамша аның белән күп еллар буена гастрольләргә йөрде. Илһам бик төгәллекне ярата торган кеше. Концертка соңга калган артистларны җене сөйми иде. Бервакыт, Әлмәт ягындамы икән, бер авылдан икенче авылга машина белән илтергә тиешләр, клуб янына иртән җыелдык, Курамша юк та юк, котәбез. Илһам: «Әйдә, киттек!» — дип шоферны кузгатты. Курамша клубка каршы гына фатирга төшкән иде. Кузгалып маташканда күрәбез: баянын күтәреп чыгып килә бу. Әйдә, утыртыйк, дибез. Илһам: «Баянын күтәрсен дә җәяү барсын, туктатма!» — диде. Шулай итеп кузгалып киттек. Ә теге авылда концерт көндезге уникедә башлана, халык шыгрым тулы. Илһам бер әргәнче таптырып, шуңа кушылып, ә күп кенә җырларны болай, ялгызы җырлады.

Илһам Курамшага бер сүз әйтмәде. Ни хикмәт, оста баянчы Рамилебез шуннан соң гаҗәеп төгәл кешегә әйләнде дә куйды.

Илһам бөтен халәте белән зыялы шәхес. Аның әйткән фикерләре әле дә колагымда яңгырап тора: «Кайберәүләр монысы иске, монысы яңа җыр дип сөйлиләр. Чын җыр беркайчан да искерми, кайберәүләрнең җырга булган карашы гына искерә. Җыр — бөек сәнгать төре, аны халыктан алырга кирәк тә, халыкка үз йөрәгең аша кайтарып бирергә кирәк...»

* * *

Фәйзи аганы мин озата чыгам. Бөдрә күбек сыман чәч муллыгы өстенә ул җиңелчә бүреген болай гына чәпәп куйган. Тавышы урамны ярып бара. Теге яктагылар да хәтта борылып-борылып карыйлар. Каршы килүчеләрнең өлкәнрәкләре баш кагып, аның белән исәнләшеп үтә. Таныйлар. Сизеп торам, моны белү Фәйзи агага рәхәт.

— Сез чибәр кеше, Фәйзи ага. Заманында бик популяр булгансыз. Концерт бетүгә кызлар урап алгандыр инде үзегезне. Бу мәсьәләдә Муса Җәлил укучысы буларак, шактый кызларның башын әйләндергәнсездер, ә?!

Минем бу сүзләрдән соң Фәйзи аганың күзләрендә мут очкыннар кабына:

— Есениннан бу турыда сорагач: «Санын белмим», дигән. Мин дә шулай: санын оныттым,— Фәйзи ага гөргелдәп көлә.

Фәйзи ага бер-ике сүзне тынычрак әйтә дә, тагын сәхнәви тавышын үз көенә ташлый. Аты булса, атын да һич авызлыкламас иде ул, билләһи. «Төзәтергә» соң инде аны, гомеренең унбиш елын зур артист булырга әзерләнгән генә бит ул, калган алтмыштан артык елын сәхнә иҗатына багышлаган. Артистның шәхси тормышы калын пәрдәләр артында. Күпме кешеләрне уйландырып та, көлдереп тә ягымлы сүз аша шифа биргән Фәйзи ага ничә еллар буе сабый хөкеменә калган авыру хатынын — үзе белән бергә утлы сугыш кырларын кичкән Мәгъсүмә ханымны сыкранмыйча, берьялгызы тәрбияләде. Беркайчан зарланмас, сиздермәс үзе. Бәлки ул, мәшәкатьле өеннән дөньяга чыгып, әнә шулай кешеләр арасында азга гына ял итеп, җылыйсы килгән чакларда да көлеп, кешеләргә нур өстәп китә беләдер?!

Мин аңардан сугышта күргән михнәтләре турында да, хөкүмәтнең саран кулыннан нинди бүләкләр алуы хакында да сорамыйм. Сәнгать әһеле үзе зур бүләк. Балтыйк буеннан алып, Татар бугазына чаклы

сибелгән милләттәшләр «И-ии, безнең Фәйзи абыебыз килгән икән!» — дип каршы алганнар икән, артист өчен шуннан да зур бәхет бармыни!..

— Мин үлгәч, некролог бирмәгез газеталарда. Белмәсеннәр. Фәйзи абый һаман яши, дисеннәр. Минем адреска хатлар килеп торсын! — дип шаярта ул хушлашыр алдыннан.

Менә ул Лядский бакчасындагы йөзьяшәр юкәләр арасына кереп китә. Җылы карлар аклыгына күмелә бара, күмелә бара. Йа Раббым, озын гомер бир аңа, дөньябызны Фәйзи Йосыпов кебек кызыгыннан мәхрүм итә күрмә, дип йөрәгемнән пышылдыйм. Йа, Раббым...

Татар галәменең бөекләре — Гаяз Исхакый игътибар иткән, Кәрим Тинчурин фатиха биргән зат ул. Такташның шигъри кулы сыйпаган баш ул...

* * *

**P. S.** Шушы язмам басылып чыккан көннәрдә Аяз Гыйләҗевтан хат алдым. Ул туган ягы Зәй төбәгендә, ата-анасы каберләренә сәҗдә кылып кайткан, төзелеп килгән мәчетләргә химая акчасы керткән икән.

Хаты, нәкъ Аяз агача, бик кайнар язылган, шул ук вакытта ниндидер моңсулык та, эчке бер ачыну да сизелә. Мин шул хатның әлеге язмама караган өлешләрен генә мисал итеп китерәм.

*«...Атналык почта бер эскерт! Шәһәрдән аерылып торган мәлләрдә, газеталарны җыеп укыганда милләтнең алга талпынышын ачыграк сизәсез. Бу юлы да шулай булды, бик кызыксынып «Идел»нең 4 нче санын караштырдым.*

*Син татарлар турында очынып-очынып, каләм очыңа кан тамчылары элеп тә яза аласың икән! «Йа Раббым...» дип исемләнгән язмаңнан аерата шушы мәгълүматларга куандым:*

*— Сәйдәш — Кәрлә Зәйнәп мөнәсәбәтләре.*

*— Сәйдәш — Җиһанов күләгәсе.*

*Җиһановның гомере буе (Сәйдәш үлгәннән соң да!) Салих абыйдан көнләшеп яшәвен беләбез. Шушы кара юнәлешне куәтләп, аңа көч өстәп яшәгән кешеләр бар әле безнең арада. Бу үтә җитди мәсьәлә тәгәллек, ачыклау сорый. Юк ла, Җиһановның... ялап Сәйдәшкә кара ягарга тырышучыларны сафка тезүләрен теләмим, шул кешеләр аша, әйтик Зәйнәп Кәрлә вә К° аша, Сәйдәшнең фаҗигасын тирәнрәк ачарга була лабаса! Кызыклы хатирәне күңеленә йозаклаган Фәйзи ага Йосыпов!..*

*Тагын бер факт мине тетрәндереп җибәрде... 1944 елда университетта татар әдәбияты һәм теле кафедрасы ачылды. Татар театр училищесы оешты. (Нур Гайсин завуч, Сәет Булатов директоры иде). Училище шәкертләре белән без, университет студентлары, бик тыгыз аралаша идек. Ул дәвернең атаклы шагыйре Мәүлә Солтан белән аерата якын яшәдек без. Мәрхүм Шамил Бикчуринга кат-кат ялындым: «Училище елларын, Мәүлә Солтан, Рифгать Әминнәр хакында хатирәләреңне яз, бәлки синең әдәбиятка керткән төп эшең шул булыр», дип үтендем, язмады. Искиткеч гыйбрәтле язмышлар бар иде бит, әй! Мәүлә Солтан Фәйзулла Туишевның секретаре булып байтак вакытлар эшләде. Көн саен йортына барып йөрде һәм Фәйзулла аганың квартирасын музей итеп әзерләде. Фәйзулла ага инде олыгайгач шигырьләр яза башлады һәм бер вакыт Тукай клубына халык җыеп әдәби кичәсен үткәрде. Мәүлә — театр училищесы шәкерте — аның шигырьләрен сәхнәдән укырга тиеш иде. Кичә башланыр вакыт җитте, ә Мәүлә юк. Фәйзулла Туишев халык арасыннан мине эзләп тапты. «Мәүлә кайда?» дип сорады. Мин ык-мык килебрәк: «Чирләмәдеме икән, кичә «тамак авырта» дип торган иде», дидем. Ул башын чайкап: «Чирләмәгән ул, читенсенә генә, өс-башы начар бит, менә синеке кебек», дип минем кыршылып беткән гимнастерка якасына, тышын әйләндереп теккән сусәргән бушлатыма төртеп күрсәтте...*

*Бар иде бит Фәйзулла Туишев музее! Үзе исән чакта ук нык-лы нигез салган иде ул аңа! Мәүлә андагы экспонатларның төрлелегенә, күплегенә шаккатып, сокланып кайта торган иде. «Очрашулардан алып кайткан пионер галстукларына кадәр саклый!» дип гаҗәпләнеп сөйләгәне хәтеремдә. Мәүлә белән без соңгы тапкыр 1947 елның язында очраштык, соңра ул Горький шәһәре төрмәсендә асылынып үлде...*

*Туишев музеенда татар мәдәниятына кагылышлы күпме кыйммәтле хатирәләр булгандыр. Кая таралган алар? Кайтмаслык югалганмы? Нәсел-нәсәбе исәнме аның? Бармы, юкмы?.. И мескен — хәтерсез татар! Инде үз замандашларының да эзен хәтәр җилләргә биреп җуйган халык, бичара буын!.. Юкса Фәйзулла Туишев татар тарихында якты эз калдырган, гыйбрәтле язмыш кичергән шәхесләребезнең берсе лабаса!.. Ә яшьтәшем Шамил Бикчуринны әйт, әгәр Мәүлә Солтан язмышын өйрәнеп кенә әсәр язса да... Бергә укыдылар. А-а, татар яшьтәшләренең иң мәшһүре иде Мәүлә Солтан. 1944-45 елларда матбугатта, шул җөмләдән, «Совет әдәбияты»нда да шигырь-поэмалары басылды... Аңа мөнәсәбәтле шактый кешеләрне дөньяга чыгарырга булыр иде. Җөмләдән берсе, Казанның иң атаклы сылуы Соня Чабдарова училище студенткасы иде. Заманнар уткәч кенә мин Соняның Рәисә Ишморатованың бертуган сеңлесе икәнен, аның урыс генералына кияүгә чыгып, әнисен кумәргә дә кайтмавын белдем. Урыс генераллары татар сылуларын яраталар шул, нишлисең...*

*Фәйзи аганың тагын бер кыйммәтле сүзе бар: «чит милләт кызына өйләнгән татар иренең язмышы ничек бетсә — Фәйзулла абыйның да язмышы шулай тәмаланды», ди ул. Бу фикерне син бүтән мисаллар белән ныгытканда да начар булмас иде...*

*Ә болай — молодец. Минем вә бүтәннәрнең, заманча тавык күзе булганнарның күзе төшмәгән почмакларга нур йөгертәсең. Афәрин!*

*Ихтирам белән Аяз* ГЫЙЛӘҖЕВ.

*18 август, 1991 ел. Казан».*

## Илһамлы халыкның илханы булыр

*Иляһи бу асыл кошны*
*Тубай агачына кундыр.*
Г. Кандалый.

Җир йөзендә аңа үз гомереннән дә артып калырлык рәхмәтләр ишетергә язгандыр. Якты намазлык өсләрендә күпме садә җаннар аңа исәнлек теләп дога кылгандыр. Ул әсир иткән залларда яңгыраган алкышларны бергә тупласаң, Ниагара шарлавыгына тиң кодрәтле ташкын-күкрәү хасил булыр иде. Ходай биргән сәләтен ул, тамчысына кадәр халыкка биреп, дан-шөһрәт тәхетендә ләззәтле алкышларга коенган һәм иҗат эшенең газаплы да, татлы да мизгелләрен аз кичермәгәндер.

Ул — кичәге, бүгенге, киләчәкле Илһам...

Кичәге дим... Татар җыр галәменә илленче еллар уртасында кинәт сызылып кергән йолдыз, Эстониянең Татарика күленнән алып Ерак Көнчыгышның Татар бугазына чаклы киңлекләргә таралган халкыма сихәт-дәва, яшәүгә өмет-юаныч биргән, кабатланмас аһәңнәре белән хәтер-рухны уята алган Илһам ул.

Бүгенге Илһам... РСФСРның, Татарстан һәм Каракалпакстанның халык артисты, Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, милләтебезнең гасырларга тиң мәхәббәтен казанган Илһам Гыйльметдин улы Шакиров. Аның хакында мәшһүр язучыбыз, галим, халык академигы Нәкый Исәнбәт болай дип язды: «Татар җырчылык тарихында үзенә аерым эз

һәм мәктәп тудыра алган җырчыларыбыз, баксаң, күп түгел. Шулар арасында халыкта аеруча зур мәхәббәт һәм дан казанганы, әлбәттә, Илһам Шакиров».



*Атаклы җырчы Илһам Шакиров Мәскәүдә узган триумфаль концерттан соң.*

Атаклы пианист, композитор, заманында Лев Толстойга фортепьянода уйнап күрсәткән Мәскәү консерваториясе профессоры Александр Гольденвейзер 1959 елда Илһам Шакировның җырлавын Чайковский залында тыңлап таң кала һәм янәшәсендәге Нәҗип Җиһановка болай ди:

— Какое чудо вы к нам привезли!..

Багышлаулар мирасына күз салсаң, татарның чал әреме — Хәсән Туфаннан башлап, бүген исеме туып кына килә торган яшь каләм ияләренә кадәр Аңа мәдхия язмаган шагыйрь, йөрәктән чыккан сүзен әйтмәгән әдип, галим-голәмә, сәнгать белгечe юктыр, мөгаен. Ә инде халык авазы — үзе бер дәрья.

Киләчәкле Илһам... Тарих катламнары астында калып, онытылырга дучар ителгән күпме борынгы җырларны табып алды да ул, аларны эшкәртеп, үз аһәң-бизәкләре белән баетып, киләчәк заманнарга юллады. Чор идеологиясе тыюлы мөһер суккан, милләтнең моңзарын сыктап белдергән күпме җырларны үз вакытында кыю яңгырата алды.

Яңа язып китергән көйләренә җан-сулышын үзеннән бүлеп биргән өчен аңа кайсы композитор гына мәңге рәхмәтле түгел икән?! Илһам Шакировның җыр сәнгате өлкәсендәге гыйльми-фольклор эшчәнлеге аерым өйрәнүне сорый. Тукайча әйтсәк, ул — коеп куйган җырчы гына түгел, композитор да, сәнгать белгечe дә, остаз да... Кыскасы, без аның күпкырлы иҗат эшчәнлегенең бар асылын бу гасырда гына аңлап та,

аң-зиһен кысаларына сыйдырып та бетерә алмабыз шикелле. Нишлисең, кешелек тарихы гел шулай, хакыйкать юлында үкенечле соңарулардан тора.

Сез карагыз аңа сөеп, назлап
Нәкъ иң соңгы кабат күргән кебек.
Сискәндерә бер сүз: «Ул да фани...»
Тик бер өмет җанда — җыр мәңгелек!..

*(Флера Низамова)*.

Илләр тәхетен яулаган тираннар, тарих агышын үзе теләгән якка борырга теләгән король-шаһлар исән әле. 1935 ел. Илләр кайный, андамонда канлы бәрелешләр кабына, дөнья астыртын гына зур сугышка әзерләнә.

Ә менә Сарман төбәгендә, Яңа Бүләк авылында иген игеп, игелекле көн күреп яшәүче Гыйльметдин белән Нуриәсма гаиләсендә алтынчы сабый дөньяга килә. Унбишенче февраль, зәмһәрир салкыннан өй бүрәнәләре шартлап ярылган көн, мамык шәл бәйләгәндә өлге итеп алырлык кар-бизәкләр тәрәзәләргә сарылып туңган көн. Күкнең аязлыгы, сыкылы кырлар сафлыгы сабый күңеленә күчәр көн... Бу баланың үсеп, мәшһүр кеше буласын алдан белгәнгә Аллаһы Тәгалә үзе иелеп, аның әткә-әнкәсе колагына тылсымлы исемне пышылдагандыр:

ИЛҺАМЕТДИН...

Әмма аңа язмышның ак кырларыннан гына эз салып барырга насыйп булмаган икән шул. Көтелмәгән кайгы-хәсрәт ачысын да аңа бәләкәйдән үк татырга туры килгән.

Утыз җиденче елның караңгы бер төнендә, ишекләрне каерып ачып килеп керәләр дә, өй хуҗасы Гыйльметдинне приклад түтәсе белән төртеп торгызалар. Куркудан өнсез калган Нуриәсма кечкенә улы Илһамны күкрәгенә кыскан. Бала әле берни аңламый. Олыраклары берәм-берәм ата кешегә тартылалар, ләкин аларны кургаш карашлы НКВД ялчылары селтәп кенә ыргыта. Балаларын кочагына алып хушлашудан да мәхрүм ителгән Гыйльметдинне кара төн кочагына алып чыгып китәләр. Гаилә, олы тетрәнү кичереп, ятим кала. Шул китүдән ата кеше, авылның оста куллы бердәнбер тимерчесе, бер хәбәрсез мәңгегә югала.

Илһам үсеп килә. Туган як бишеге — Яңа Бүләкнең дә кинәнү өчен табигать хозуры — каенлы урманы, колынлы болыннары, таллар күләгәсен сыйпап аккан инеше, чишмәләре, тургайлы тугайлары бар. Авыл халкы, бил бөгеп, авырлык белән көн итсә дә, барыбер күңел ачарга җай таба, дөньясына үч итеп бии-җырлый. Тургай биеклегенә карап арышлар буйга сикергәндә, чык суын эчкән җиләкләр өлгереп килгәндә, чормадан төшерелгән чалгыларны көйләп-чөйләп куя да Сабантуй бәйрәмен үткәрә. Мәйдан — чигүле түбәтәй. Мәйдан — төрле чәчәкләрдән үрелгән тәкыя. Елга бер килгән шаулы бәйрәмдә кинәт... Юрга атлар тоягыннан килеп бәрелгән афәтле җил... Сугыш... Мәйдандагы халык капылт убылган бу кайгыдан сыгылып куя. Уй-хыялларны, бөтен тормышны сызып, тын-сулышсыз калдырган шомлы хәбәр өлкәннәрне кинәт картайтып җибәргәнен, бәгырь авазы белән сыктап, бер-берсенең иңенә сыенуларын мәңге онытасы юк нәни Илһамның.

Ерак чик буйларыннан килгән золым шаукымы иң беренчеләрдән булып аларның ишеген кага. Илһамның олы абыйсы Имамны сугышка алалар. Әрәмәле юл читендә Нуриәсма, нәни Илһамын итәгенә кысып, яуга китәсе егетләр төялгән атларны озата кала. «Соңгы тапкыр... Соңгы тапкыр...» дип пышылдый тәкъдир тавышы, әмма ана улын рәхимсез үлем кочагына озатканын белми әле, исән-имин әйләнеп кайтуын теләп, эченнән генә дога укый. Гомере санаулы көннәр генә

калган егет-җиләннәрнең актык җырын өянкеләр, кырлар хәтеренә алып кала.

Без авылны чыккан чакта
Күтәрелде томаннар.
Дөнья хәлен белеп булмый,
Сау булыгыз, туганнар...

Купшы сәнгать сарайлары, алтын нәкышлы галеркалар, бәллүр тамчылары яшьнәп кабынган саллы люстралар, калын пәрдәләрнең диңгез дулкыныдай вәкарь белән генә ачылуы... Һәм син — атаклы җырчы — меңенче тапкыр сикергәндә дә, беренчесендәге кебек үк каушау кичергән парашютчы халәтендә, зал тулы тамашачы каршында бергә-бер каласың.

Менә залны киереп моң агыла башлый.

Каядыр балачак ызаннарыннан адаша-адаша килгән беркатлы малай, мәһабәт сарай диварлары аша үтеп кергәндер дә, почмакка посып кына сине өзелеп тыңлыйдыр кебек. И син, садә малай, бәләкәй чагыңда, ничекләр җөрьәт итеп, «Сарман», «Кара урман», «Тәфтиләү», «Әллүки»ләрне җырладың икән? Бу җырларда халкыңның әйтеп бетермәгән зар-өметләре, тарихи сагышы моң аша бирелә түгелме?! Еллар бożрасы өстәлә барган саен, халкыңның шанлы үткәнен, бәгырь тарлавыкларын ача-ача, моң хасияте дә тирәнәя, мәгънәле аһәңнәргә баеганнан байый. Җырчы белән бергә җыр да олыгая...

Ә залда керфекләр яшькә чыланган. Бу елау башка... Кая ул Яңа Бүләк авылының ярлы клубы! Матчаларга асылган бишле, җиделе лампалардан төшкән сүрән-җылы яктылык... Улларын сугышка озаткан аналар, ирләрен җуйган тол хатыннар, солдат хаты көткән җитү кызлар... Алар башка иде, аларны җырлап елаткан малай да кыенсыну кичерә иде... Ә бүген... Атаклы җырчы бәхет эзләп чит якларга китеп гомер сөргән милләттәшләренә аяусыз сүзләр әйтә:

— Елагыз, ела! Кайтыгыз, анда сезне туган җирегез көтә!

Анда минем газиз халкым,
Анда мин дә сандугач...

Җыр арты җыр. Алкышлар, дулкын-дулкын булып, йөрәккә кага ләззәтле тетрәтә. Бу — җирдәге бернинди ганимәт-байлыкларга да алыштыргысыз илаһи халәт. Сәхнә — яшәүнең иң гадел, иң бөек кимәле! Пәрдә артында ыгы-зыгылы, вак мәшәкатьле, күләгәле тормыш.

Моң арты моң. Тамашачының бер йөрәк булып типкән җанын агымсуларга салып чайкар, утларга салып алыр, күкләргә ашырып, йолдыз бишегендә тибрәтеп алыр ул — ихтыяр көченең ияреңдәге зат.

Моң тәэсире бөтереп ала да, кайчакларда үзенең дә күңел касәләре мөлдер-мөлдер тула. Әмма ярамый! Зал еласын, син сабыр кал! Бу — борынгыдан килгән сәнгатьнең язылмаган кануны! Ку син хәтереңнән, әнисенә ияреп, басу капкасыннан күрше авылларга хәер сорашырга чыгып киткән ятим малайны онытып тор әлегә... «Тавышың бигрәк моңлы, бәхетең була күрсен инде», — дип әнкәңнең башыңнан сыйпап әйткән тәшвишле сүзен дә исеңнән чыгарып тор хәзергә. Яп хәтер пәрдәләрен, зал синнән елатып юатуыңны көтә. Зал рәхимсез, ул синең керфегең дымлануын кичермәячәк...

Бөек тылсымчыдыр ахрысы син,
Гади генә кеше түгелдер.

Синең җырлар үзләре бер дөнья,—
Сине тыңлау үзе бер гомер.

*(Фаил Шәфигуллин).*

Гасыр азагы һәм гасыр башында җәмгыятьләр зур үзгәрешләр, тектоник тетрәнүләр кичерә. Мондый чакта һәр халыкта поэзия алга бәреп чыга. Гасыр уртасында исә, балигъ булган вакыт утырып уйлана шикелле, мондый мәлдә инде музыка сәнгате күтәрелеш ала. Илленче еллар уртасында Илһам Шакиров сәхнәгә менгән вакытта татар музыкасы талантларга бай иде. Үзе мәңгелеккә күчсә дә Сәйдәшнең моңы-рухы яши, классикага керәсе композиторларыбыз Нәҗип Җиһанов, Александр Ключарев, Рөстәм Яхин, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Заһит Хәбибуллин, соңрак боларга Сара Садыйкова, Фасил Әхмәтовлар кушылып, җиң сызганып эшләгән дәвер бу. Шушындый мәртәбәле корифейлар белән бер заманда яшәп иҗат итү — Илһам Шакировның кабатланмас бәхете булгандыр бәлки.

Поэзиягә чал Урал аръягыннан Хәсән Туфанның кайтуы... Нәкый Исәнбәт, Сибгат Хәким, Әхмәт Фәйзи, Мостай Кәримнәрнең сугыштан соңгы яңа сулышлы шигърияте..... Алтмышынчы елларда бер дулкын булып яшь шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхимнәрнең күкрәп килеп керүе...

Театр сәхнәсендә — Хәлил Әбҗәлилов, Фуад Халитов, Габдулла Шамуков, Хәким Сәлимҗанов, Хөсәен Уразиков, Гөлсем Камская, Фатыйма Ильская, соңрак Шәүкәт Биктимеровларның каһарман образлары... Аларның мәктәбен дәвам итеп Ринат Таҗетдинов, Равил Шәрәфиев, Әзһәр Шакиров, Наилә Гәрәева, Нәҗибә Ихсанова, Гөлсем Исәнгулова, Наил Дунаев, Хәлим Җәлаловларның килүе...

Драматургиядә Тинчурин «шинелегннән чыккан» Хәй Вахит, Шәриф Хөсәенов, Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗевләрнең театр офыган киңәйтүләре...

Җыр сәнгатендә — Фәридә Кудашева, Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Фәхри Насретдиновларның кабатланмас тавышы...

Татар галәменең мәккәсе — Казан учагының шифалы ялкыны берләштергән бу мәртәбәле исемнәр (олпат кыя — Бакый Урманчене дә кертеп) — үзе бер эпоханы эченә ала. Шушы эпохадан үзе дә илһамйогынты алып, гасырга бер генә туа торган сәмави тавышы, моң-аһәңе белән халыкны юатып, наз-рух чишмәсе белән сугарып торучы моңдаш, заманга аркадаш — Илһам Шакиров булды. (Аның янәшәсендә — сөекле җырчыбыз Әлфия Афзалова аерым урын тота!).

Тормышында ул хакими түрәләргә ярашып яшәмәде, иҗатында да горур бәйсезлекне саклый алды. Казан консерваториясен тәмамлаганнан соң, рус һәм Европа классик арияләрен, романс-җырларын башкарып дан-дәрәҗәләргә мулрак та ирешә алган булыр иде, әмма ул үз халкына тугры калды. Гаҗәеп бай хасиятле, дөнья халыклары арасында сирәк очрый торган үз ганимәте булган татар җырын башка милләтләргә җиткерү, таныту максатын үзәккә алды.

Ул заман-чор күңелендә сирәк яңгыраш тапкан «Сәгать чылбыры», «Мәдинәкәй», «Кара урман», «Уел», «Тәфтиләү» кебек дистәләрчә җырларга канат куйды, тамашачыга сәгадәтле минутлар бүләк итте.

Дала күкрәгеннән сүнгән учак урыннарын актарып, аннан тере күмер табып алган кебек, ул йөргән ил-җирләрдә өлкәннәр белән аралаша, күңел колагын һәрчак сизгер тотканга, бакый заманның онытылган көйләрен табып алып кайта иде. Аларга яңа гомер биреп, үзе әйтмешли, халыктан ала да, йөрәге аша үткәреп, яңадан халыкның үзенә кайтара иде. Шундый онытылган җырлардан «Бик еракта идек без», «Таң җыры», «Керфекләрең синең нигә кара», «Кораб» (Дәрдеменд шигыренә), Разил

Вәлиев шигырь язган «Бер алманы бишкә бүләек» һәм «Дулкын» жырларын мисалга китерергә була. Әлбәттә болар Илһам Шакировның жыр фольклористика өлкәсендә эшләгән хезмәтенең бер өлеше генә.

Илһам Шакировның жырлау алымын күздә тотып, күпме композиторлар фәкать ул башкарырдай булсын дип көйләр яздылар. Классик дәрәжәле дәгъва итәрлек мондый жырлардан түбәндәгеләрне искә алырга була: «Өченче көн тоташ кар ява» (Сара Садыйкова-Мостай Кәрим), «Менәргә иде Урал тауларына» (Мансур Мозаффаров-Гөлшат Зәйнашева), «Төннәр буе йоклый алмый ятам» (Вадим Усманов-Әхмәт Ерикәй), «Китмә, сандугач» (Рәстәм Яхин-Гөлшат Зәйнашева), «Ачуланма» (Сара Садыйкова-Әхсән Баянов), «Башка берни дә кирәкми» (Мансур Мозаффаров-Сибгат Хәким), «Кайтырсың шикелле тоела» (Бәхти Гайсин-Хәсән Туфан).

Хәер, саный китсәң, бик күп икән бит соңгы берничә дистә ел эчендә ижат ителгән һәм Илһам Шакиров башкаруында аерым бер гүзәллеккә ирешкән жырлар.

«Син сазыңны уйнадың» (Нәкый Исәнбәт шигыре) жырын кем генә белми икән?! Бу көйне үзе язганлыгы хакында Илһам Шакиров күп еллар буе шытымады. Бүгенге тавышсыз жырчыларның кайберләре эт сикертә торган кылтый-былтый көй язып та үзен композитор дип санаганда, әлеге тыйнаклыкны аңлау кыенрак, әлбәттә.

Әгәр Илһам Шакиров шушы бер көйне генә язса да, татар музыка сәнгатендә җуелмас эз калдырган булыр иде. Ләкин мондый әсәрне биргән кешедән безнең тагын да күбрәкне көтәргә хакыбыз бардыр. Шик юк, ул бик күп жырлар яза алган булыр иде, әмма ул үзен мәжбүри тыеп, бу шөгыльне башкалар хозурына калдыргандыр шикелле тоела миңа. Ник дисәң, «Һаман истә» (Ләбиб Айтуганов шигыре), «Гөлмәрьям» (Гамил Афзал шигыре), «Очрашу» (Гөлшат Зәйнашева шигыре), «Идел буе каеннары» кебек онытылмас жырлар композитор Илһам Шикровның ижади мөмкинлеге чиксез бай булуы хакында сөйли.

Илһам Шакировның үлемсез ижатка, классик әсәрләргә тартылуы бер яктан күңел кушуы буенча эшләнсә, икенче яктан, монда заман-чор мәктәбенең дә шифалы йогынтысы булгандыр.

1966 елда Казанга Натан Рахлин күчеп килә һәм симфоник оркестр белән житәкчелек итә башлый. СССРның халык артисты,профессор, танылган дирижер белән Илһам Шакиров арасында ижади дуслык урнаша. Шаулы диңгез дулкыннарын иярләгән кебек, ул оркестрга кушылып, киң сулышлы жырларын башкара.

Үз чорының танылган затлары — Оскар Фельцман, Арно Бабаджанян, Михаил Блантер, Александра Пахмутова белән дә Илһам Шакиров якыннан аралаша, үз ижатына карата фикерләр ишетә.

Зур сәхнәләрдә ул Мөслим Магомаев, Батыр Закиров, Марлен Дитрих, Дин Рид, атаклы бию остасы Мәхмүт Әсәнбаевлар белән бергә чыгышлар ясый, ижади багланышлар мәктәбе уза.

Татар әдәбияты классикларының олы юбилей кичәләрендә, Мәскәүнең Колонналы залындамы, Казан театр сәхнәләрендәме — кайда гына чыгыш ясамасын, Илһам Шакировның жырлавы бер генә милләт вәкилен дә битараф калдырмый. Концерттан соң аны Сергей Михалков, Лев Ошаниннар котлый. Әрмән шагыйрәсе Сильва Капутикян дулкынланып аңа болай ди:

— Сезнең жырлавыгызны тыңлаганнан соң мин татар халкының жанын аңлагандай булдым. Бу халык, читләрдән таптатмыйча, үз тарихын үзе язарга тиеш...

Муса Җәлилнең 60 еллык юбилеенда аны язучы Леон Небенцаль котлый, жырчының башкаруын югары бәяли. Бәлки ул борынгы төркиһуннар белән арий-алманнар бәйләнешен канында тоеп, мең еллар аша сакланып килгән уртак моң кайтавазын татар жырында ишетеп дулкынлангандыр.

Гарәп язучысы Сәхип Җамалның Илһам исемен дөрес әйтеп, кулын кысуында да хикмәт бардыр. Изге китап белән гарәп мәкаме безгә килгән. Моң шулай күңелләрдән-күңелгә күчеп яши, төрләнә, үз нурланышын саклый бирә.

Моң — бүтән телләргә тәрҗемә ителми торган, Ходай сулышы белән яратылган тылсымлы сүз. Галәми чиксезлекнең бер ноктага кысылган тыгыз матдә-төше кебек ул, аны таратып карыйсың икән, хисапсыз йолдызлар чәчрәп таралачак. Моңның мәгънәсен аңлатып карау һәркемнең ирегендә, үз заманында аны Илһам Шакиров та бик гади, үтемле итеп аңлатырга тырышкан. Менә аның эфирда яңгыраган язмасыннан бер өзек:

«...Моң ул бик күп компонентларны үзенә туплаган нәрсә. Кайберәүләр кайгы-сагышлы җырлар моңлы була, диләр. Монда да хикмәт башкаручыдан тора. Чөнки эчтәлеге белән сагышлы җырларны да бөтенләй моңсыз башкаручылар азмыни! Аннан соң еш кына без мондый сүзләр кулланабыз: «Мәйдан өстендә шатлык моңнары яңгырады». Берәү әйтә: «Салих Сәйдәшевнең «Совет Армиясе маршы» үзе тантаналы, үзе моңлы». Әнә бит Фәридә Кудашева нинди генә көйләр җырламасын — авыл көеме яки шаян җырмы — барысында да моң ишетәбез. Безнең татар-башкорт көйләрендәге традицион бормаларны, милизмнарны моң дип атаучылар да бар. Беренчедән, бормаларны куллана белергә кирәк. Икенчедән, бормалар гына моң була алмый. Бормаларны саран гына кулланып та, үзәк өзгеч моңлы җырлаучыларны беләбез. Алайса, ул моң тембр, тавышның буявыдыр? Мисал китерик: берәү өздереп скрипкада уйный, бөтен уйларыны әйтә дә бирә. Икенче берәү шул ук скрипканы алып, шул ук көйне, шул ук ноталарны уйный, ләкин моңның әсәре дә юк. Күрәсез, ул тембрны, тавыш буяуларын чыгарыр өчен дә табигатьтән килгән йөрәк сиземләве һәм осталык кирәк. Тагын без моңлы күз карашы, моңсу кыяфәт, моңсу күренеш дигән әйтелешләрне дә еш ишетәбез. Кеше җырламый да, көлми дә басып тора. Киләбез дә: «Нигә болай моңланып басып торасың?» — дибез. Аның эчендәге тирәнлеге, уйларының катлаулылыгы тышкы кыяфәтендә чагылган булыр.

Нәкый ага Исәнбәт болай ди: «Җәйге кичтә, су буенда үзәнлектә ат караучы егатләр учак якканнар. Ерактан шуны күрәсең дә бу манзараның моңлылыгыннан хисләр тулып ташый. Ә шул учакны көпә-көндез, кояш кыздырып торганда ягып кара син, моңлылыгын табарсың микән?»

Димәк, безне урап алган мохитнең, атмосфераның да моң тууга тәэсире бар. Ә җырчы кеше тыңлаучы алдына басу белән шундый моңлы атмосфера тудыра алырга тиеш.

Әйтик, шундый ук учакны әллә кайда, бик ерак бер чит илдә күрдек ди. Барыбер үзебезнең Идел, Зәй, Кама, Агыйдел, Ык, Мишә буендагы учакларны сагынырбыз. Моң ул үзеңнең туган җир, туган туфрагыңнан, туган халкың-милләтеңнән чыккан хисләр, кешенең күңелендәген әйтеп бирә белү — ягъни «чын безнеңчә матур, милли көй...»

Зуррак шәһәрләрдә яшәүче аксөяк балаларына, әз генә талант әсәре шәйләнү белән, махсус стипендияләр билгеләнә. Бу иркә балалар төрле конкурсларда катнашып чарланалар, ун яшьтән узганда инде күп кенә чит илләрне күреп өлгерәләр. Аннары, тотрыклы обоймага эләгеп, гомере буе дан бишегендә тирбәләләр. Татар баласына исә, гәрчә ул ун башка сәләтлерәк булса да, мондый бәхеткәйләр тәтеми шул. Үз көченә таянып үсү юлында андыйларның меңнән бере генә бишмәттән фракка кадәр араны үтеп чыга ала. Шунысы аяныч, һәр яңа буын шушылай ук нульдән башлый, көчлеләр иңенә таянып, алга сикереш ясый алмый. Моңа мисалларны сәнгать һәм спорт өлкәсеннән хәтсез китерергә була. Ләкин без бу очракта, хискә бирелмичә генә, Илһам Шакиров язмышының дисбе төймәләрен күз алдыбыздан чигерик әле...

Ул Теләнче Тамак мәктәбенә йөреп укый. Сигездән алып унга кадәрге сыйныфлар түләүле. Әтисе «халык дошманы» булганга, йорт-

жиргә налогны да башкалардан икеләтә күбрәк салалар. Ятим малай мондый авыр шартларда укуын ташлап, тамак ялына бирәр эшкә керергә мөмкин идеме?..

Мәктәпне тәмамлагач, Алабуга педучилищесына имтихан тота. Инде укулар башланыр көннәр җиткәндә генә Казанга китәргә алгысына башлый. Чаллы пристанендә ыгы-зыгылы халыкка исе китеп карап торган үсмер егетнең фанер чемоданын урлап китәләр. Бар булган документлар эзсез югала. Берәү булса, канатын салындырып, кире авылына кайтыр иде. Юк, Илһамны ниндидер үҗәтлек һаман алга этәрә, ничек кирәк алай пароходка эләгеп ул башкалага юл тота.

Дөньяда Чаллы элеваторыннан да зур бина юктыр, дип уйлаган егет Казан урамнарын шаккатып карап йөри дә музыка училищесына барып керә. Әмма анда инде имтиханнар беткән, кабул ителәсе укучылар ачыкланган була. Ләкин Илһам чигенүне белми, директор кабинетына барып керә. Әгәр шул көнне училище директоры Ильяс Әүхәдиевнең кәефсез чагы булып, урамнан килеп кергән билгесез егет белән сөйләшергә дә теләмәгән булса... Ни хикмәт, ул Илһамны җырлатып карый да... кинәт кубып, тиз генә кабул итү комиссиясе җыеп, имтихан алалар да, яшь җырчыны училищега кабул итеп тә куялар. Ләкин... Язмыш тагын Илһамга көзгенең арт ягын бора. Армиягә алыну шаукымыннан котылып кара! Империя карынына күпме татар улларын озаткан шыксыз, өчәр ярусны казармадан ул, җаны тарыгып, шәһәргә ыргыла. Теләсә кая кунып йөри торгач, мәрхәмәтле кешеләр табыла... Соңгы өмет. Менә ул Казан дәүләт консерваториясенең ректоры кабинетында. Беренче карашка кырыс күренгән Нәҗип Гаяз улы Җиһанов егеттән тегесен-монысын сораштыра, күпереп торган вак бөдрә чәчен сыпырып куя да клавишларга кагыла. Америкада эшләнгән ап-ак «Стэнли» рояле кырыена басып, кирза итектән, кара сатин күлмәктән фуфайка кигән егет «Туган ил» көен җырлап күрсәтә. Нәҗип Җиһанов бу ярлы авыл егетенең талантка никадәр бай икәнен шунда ук сизенеп ала. Әгәр ул, тавышын ошатып та, консерватория студенты дигән белешмәне яздырып Илһамга бирмәгән булса!.. Юк, башкача мөмкин дә түгел, бер елдан чынлап та студент буласы егетнең ул зур киләчәген алдан күрә, шуңа изге ялганга бара да...

Илһам белешмә кәгазен тотып хәрби комиссариатка йөгерә. Анда егетне кабинеттан-кабинетка йөртеп шактый «иләгәч», бер майор хәрби этлеген эшләп кала, башта Илһамга такыр иттереп чәчен алдыртып килергә куша, шуннан соң гына армия хезмәтеннән азат ителүен хәл кыла.

Консерваториядә Илһам Шакиров Елена Александровна Абросимовадан вокал буенча дәресләр ала. Укуны тәмамлагач, кая барырга, дигән сорау аны да борчып ала. Опера-балет театрына эшкә керергәме? Имтиханнарда ул Рахманиновның «Сирен»ен, Гендельнең «Ксеркс»ын, Синдингның «Романс»ын, Гуноның «Фауст» операсыннан эпиталама, Җәүдәт Фәйзинең «Тапшырылмаган хатлар»ыннан Искәндәр монологын җырлап, иң яхшы билгеләре алып чыга бит. Юк, сәхнәдән кешегә күренеп җырлыйсы килми Илһамның, радиодан гына җырласаң икән ул. Башкортлар елгыр бит, нәкъ шундый эш, әйбәт фатир тәкъдим итеп аны Уфага килергә кодалыйлар. Илһам инде ризалаша да язган була...

Шулчак аны ак рояль хуҗасы үз кабинетына чакырта:

— Ни оятың белән китеп барыр идең! Без сине чит республика өчен укытып, кеше иттекмени! — дип, Нәҗип Җиһанов аны яратып кына битәрли дә филармониягә эшкә керүен хәл итеп куя.

Күрәсез, кеше язмышы гел очраклыклардан тора. Шуларның тик берсе язмыш бураэнасын тискәре якка борып җибәрсә җыр сәнгате нинди үкенечле югалту кичергән булыр иде. Аллаһы бар ул! Хак Тәгалә гүя үзе аны этеп йөртә, әйләнә-тирә мохитне мәрхәмәтле итеп, гел аны алга әйдәкли. Шәмдәлләрендә соңгы ялкыны сулкылдаган татар халкына нәкъ менә Илһам кебек моңлы шәхеснең кирәклеге зарури булгандыр.

— Илһам әфәнде, җыр сәнгатендә Тукай булып каласыгызга шагыйрьләр сезне ышандыра алдымы?
— Юк, ышандыра алмадылар әлегә...
— Яңа бер жанр — бәет-мөнәҗәтләр җырлап карарга ниятегез юкмы?
— Безнең бүгенге тормышыбыз үзе бәет...
— Йөзләгән шәһәрләрдә булып, нинди генә заллар, сәхнәләрдә чыгыш ясарга туры килмәгәндер. Шулардан нинди зал күңелегезгә иң хуш килгәне?
— Мәскәү филармониясенең Чайковский исемендәге залы. Гаҗәеп акустика. Анда җырлавы рәхәт. Судагы балык кебек тоясың үзеңне.
— Кызыклы иҗат чоры, истә калырлык еллар-юллар хакында китап язарга ниятләмисезме?
— Истәлекләр күп тә... Кул җитми.
— Моннан унбиш еллар элек шагыйрьләр, артистлар белән бер мәҗлес корган идек. Анда Башкортстанның халык артисты Мәгафур Хисмәтулин да, Бәхти Гайсин да бар иде. Шунда мин шаяртыбрак: «Төрки-татар дөньясында бүгенге көндә ике генә бөек җырчы бар, аның берсе — Илһам Шакиров, икенчесе — Фәридә Кудашева, калган урыннарны үзегез бүлешегез», дигән идем. Артистлардан кала, бу фикер белән күпләр килешкән иделәр. Әйтегез әле, хәзерге көндә бу ике исем янына өченче шәхесне өстәргә буламы?
— Булыр иде дә... Җәмгыятьнең болай үзгәрүе җырчыларны да саектырды шул. Гомумән, сәнгать кешеләрен ваклады. Сәләтлеләр бөтән өлкәгә күчә башлады.
— Дөнья җәннәте — Багам яки Канар утрауларына барып ял итәсегез килмиме?
— Килә дә бит... Тукай әйтмешли: «...Хәл җыеп, күккә карап...» ятарга иде дә бит...
— Кайчакларда Сез кешедән көләргә яратасыз. «Сиңа рәхәт, син — җүләр» дигән канатлы сүзегезне күпләр беләдер. Мәскәүдә укыганда мин аны бер рус язучысына да әйткән идем, бик ошаткан иде, «тебе хорошо, ты — дурак» дип, мин әйткәнчә, китабына да керткән. Сез аны үзегез уйлап чыгардыгызмы, әллә халыктанмы?
— Ваемсызраклардан көлеп әйткәнмендер инде. Бу илдә акыллы булып яшәү авыр бит.
— Сугышта һәлак булган Имам абыегыздан кала сез бишәү үскәнсез. Бүгенге көндә барыгыз да исәннәрме?
— Иң өлкән апам Гыйльмисафа үлде... Гөлсем, Зәйнәп апалар исән. Төп йортта Кыям абый яши.
— Җырга һәвәслек кайсы яктан бирелгән?
— Әни ягыннандыр. Ул Таулык дигән авылда туып үскән. Абыйсы Мөхтәрулла бик шәп җырчы булган. Әнинең дә тавышы матур иде.
— Әниегез, мәрхүмә, Нуриәсма апа инде йөз яшьтән узган булыр иде. Аның концертларыгызны зур залларда утырып тыңлаганы бардыр. Соңыннан ни дә булса әйтә идеме?
— Шулай булырга тиеш дип уйлый, мактап та, хурлап та бер сүз әйтми иде.
— Их, шул кеше бүген дә исән булса иде, дип композиторлардан кемне сагынасыз?
— Мансур Мозаффаров белән Александр Ключаревны. Мансур ага миннән гел яңа шигырьләр таптыра, музыканы бик тиз яза, минем сүзгә дә колак сала иде. Аның белән эшләве рәхәт булды.
— Александр Ключарев татарча белә идеме?
— Белә, әмма сөйләшми иде. Берәр сүздә хата җибәрсәң, шундук төзәтә үзе. Көй язасы шигырьдә басымы дөрес килмәгән юллар табып, шагыйрьләрне кат-кат эшләтеп тилмертә иде. Ул Оренбургта туган,

татарның җанын-тәнен бәләкәйдән үк тоеп үскән. Аның кадәр дә татар җыр фольклорын тирәнтен белүче бүтән берәү дә юк иде.

— Нәҗип Җиһановка карата төрле фикерләр яши. Сез...

— Зур композитор. Татар кадрларын үстерүгә күп көч куйды. 1945 елда Казан дәүләт консерваториясен ачтыра алу... Аны бары тик Җиһанов кебек авторитет кына эшли ала иде. Гомеренең соңына кадәр шул консерваторияне җитәкләде. СССРның халык артисты, Социалистик Хезмәт Герое булу өстенә, ул бик кешелекле шәхес тә иде. Иҗат кешеләренә һәрчак игътибарлы булды.

— Элеккеге партия җитәкчеләреннән Сез якыннан белгәне һәм истә калганы?

— Кунаев. Бик гади, ачык күңелле кеше иде. Милләте буенча аны казакъ дип әйтеп булмыйдыр. Әнисе — татар, әтисе — уйгыр.

— Аның белән беренче очрашуыгыз кайчан булды?

— Ул үзе бер кыйсса... Арча ягында концерт куеп йөрибез. Җитмеш беренче ел иде, хәтерем ялгышмаса. Тукайның туган авылы Кушлавычта: «Сезне Казанга чакырталар, обкомнан!» — дип кәнсәләрдән килеп әйттеләр. «Обкомның кеме генә юк, бетмәс, бер чыккач йөрибез әле»,— дидем дә Наласага китеп бардык. Буранлы көн. Бервакыт фатирыбыз каршына УАЗ килеп туктады. Аннан карга уралып, берәү килеп керде:

— Мин Зәйнуллин булам, Арчаның райком секретаре итеп бүген генә расладылар, бүген үк, сезнең аркада, обкомнан шелтә дә бирделәр. Җыеныгыз, Табеев чакырта! — ди бу.

— Табеев үзе чакырткач инде, кайтмый булмас,— дип җыена башладык. Зиннур Гыйбадуллин белән икебезне «арестовайт» итеп алып киттеләр. Казан аша туп-туры — Боровое Матюшиного. Анда, Идел буенда, партия җитәкчеләренең ял дачасы барлыгын күпләр беләдер. Шул... Барып җиттек. Агач төбе саен сак куелган. Кем-кем диген, Политбюро члены Динмөхәммәт Кунаев үзе килгән икән! Кердек, таныштык. Табеев, Батыев, Усмановлар аның бер алдына, бер артына төшеп торалар. Барысы да хатыннары белән. Кунаев та. Зөһрә ханым — Петропаул шәһәрендә туган чын татар хатыны. Шушы танышудан соң инде алар Алма-Атада минем концертларга килә торган булдылар. Алдагы җиде рәт гел түрәләр белән тула иде. Кунаев булмаган чакта командалык Зөһрә ханым кулында. Аның каршында бөтен министрлар «Баш өсте!» дип кенә торалар. Безнең татар хатыннары шулай бит ул: ире дәрәҗәле түрә булса, хатыны дәрәҗәне иреннән бер башка югарырак тота.

— Кунаев белән сөйләшә алдыгызмы мәҗлестә?

— Мин аңа мондый сорау бирдем: «Казагыстанда уйгыр театры, немец, рус, корея театры бар, йөзмеңнәрчә татарның берние дә юк», дидем. «Атнага бер сәгать татарча концерт бирәбез радиодан»,— ди Кунаев. «Тыңлап барам. Анда һаман шул илленче еллар җырлары гына, күбрәк үзешчәннәр, программасы бик искергән», дим. Исендә калдырган икән, ул китеп, ун көннәр үтте микән, Алма-Атадан радиокомитетка килеп, яңа концертлар яздырып киттеләр.

— Мәҗлес ничегрәк узды соң?

— Өстәлләр сыгылып тора иде. Бүлмәдән-бүлмәгә күчә-күчә ул төндә утызлап җыр җырлаганмындыр. Бер арада Табеев янга килеп: «Ну ты спас меня... Ни кирәк, әйтегез генә, барын да эшлим»,— ди бу. Зиннур Гыйбадуллинның каушаудан теле тотлыкты, фатир сорарга итенә — ык та мык. Табеев тыңларга азапланып карады да: «Не умеешь говорить, отойди, Илгаму скажешь...» — дип миңа борылды. Икебезгә дә фатир кирәклекне аңлатып биргән булдым инде. Нишлисең, ул елларда Мәскәвендә дә, Ленинградында да шулай артистлар партиянең крепостнойлары иде бит... Ике-өч көннән соң кайсы йортта телисез, шуннан сайлагыз фатирны, дип килеп әйттеләр. Әнине машинага утыртып чыгып киттем. Сиңа, әни, кайсы йорт ошый, шунда күчәбез, дим. Йөри торгач, Горький урамындагы бер йортны ошаттык. Барып әйткән идем, син

нәрсә, ул бит тулай торак, диләр. Сайлый торгач, әни Тукай һәйкәле артындагы йортны ошатты...

Талантлы булу бәхет кенә түгел, фаҗигадер дә. «Күңелендә шуның чаклы моң саклаган кешенең күңел кыллары да бик нечкәдер. Ул без сизмәгәнне сизәдер, без тоймаганны тоядыр. Ә дөнья, тормыш вакыты-вакыты белән шактый ук тупас. Шушы тупаслык талантның нечкә кылларына килеп бәреләдер дә, кылларының берсе шартлап өзеләдер. Шушы каршылыкны талант ифрат авыр кичерәдер, хәтта ул каршылыкның асылын аңлап та бетерә алмыйдыр. Аптырагач, интеккәч, бәргәләнгәч, вакытлыча гына булса да онытылып тору өчен «синдәй-миндәй» «бозаулар» түбәнлегенә төшеп, бүтәннәр сыманрак кыланып карарга мәҗбүр буладыр. Талантлар сирәк. Шуңа күрә кешеләр аларга сокланып карау белән бергә, аларның талантлы булуын гафу да итмиләр (ямьсез кызлар чибәр кызларны яратмаган шикелле). Дөньядагы бөтен гайбәтнең күпчелеге талант ияләре турында...»

— Сезгә карата бу сүзләрне күренекле драматургыбыз Туфан Миңнуллин әйткән. Хак сүзләр... Илһам әфәнде, үз гомерегездә гайбәтләрне күп ишеттегезме?

— Һи-ии, аларның исәбе-хисабы юк. Студент чорыннан ук башланды ул. Бервакыт Сарманнан Кыям абый телефонга чакыртты. Тавышы бик хәвефле. «Син авырмыйсыңмы?» — дип сораган була. Соңыннан белдем. Рәшит Ваһапов, көнләшеп, Илһам Шакировны атып үтергән икән, дигән хәбәр таралган. Киресе дә булды: имеш, Рәшит Ваһаповны мин агулап үтергәнмен... Бер елны Себердә гастрольләрдә йөрибез, кунакханәгә Казаннан берәү шалтырата бит. «Син исәнмени?» — ди. «Сон исән булмасам, синең белән сөйләшер идеммени!» — дим. «Юк, ышанмыйм, син исән түгел...» — ди бу. Күпмедер вакыттан соң кайтып төштек... Илһам Шакиров үлгән икән, дигән хәбәр бөтен Казанга таралган. Үз куллары белән кабергә төшерүчеләр дә байтак икән. Бу гайбәтне туктату өчен телевизордан концерт бирдем. Юк, барыбер ышанмыйлар, иске язма ул, ялган, диләр икән. Шуннан соң Казанның мәдәният сарайларында ун көнлек концерт бирдем. Халык өстендә халык, бер-берсен таптап керәләр. «Сезнең нигә килгәнегезне беләм мин...» — дим сәхнәдән. Зал көлә. Шулай итеп, мең мәртәбә терелттеләр мине ул елларда.

— Туфан Миңнуллинның алда китергән сүзләрен искә төшерик. Әйе, тормыш — олы сәхнә бит ул. «Кешелек комедиясе»нең үзәктә торган каһарманнарына мөнәсәбәтле карашны ул бер учка җыеп әйткән. Шулай... Артык зур талант каршында үзеңнең көчсезлекне сизүдән туган ризасызлыктандыр бәлки, даһины билгеле бер биеклеккә җиткәч, салып таптау, аннан соң инде үлеп ятуыңны, сагынуыңны белдерү... Бу — җирдә яшәгән һәр халыкка бик тә хас холык-сыйфат, моны бернинди әхлак кануннары белән дә бетерә алмыйсың. Бу — адәми затларның тән күзәнәгенә тумыштан сеңгән сыйфат. Һәм аның иң көчле мисалы — Гайсә пәйгамбәрне бердәм күтәренкелек белән каһәрләп хөкем итү, аннары, гомер буена, рухына табыну... Дөресен әйткәндә, кеше дигән затның шундый психологиясе аркасында нинди шәп драма әсәрләре дөньяга килгән.

— Патшалар даирәсендә дә гайбәт булган, теге дөньяда да юк дип уйлама», — дип Илһам Шакиров көлеп куйды. Шушы форсаттан файдаланып, мин аңа үзе турында берничә әйбәт гайбәт сөйләргә булдым.

1968 елның көзендә Илһам Шакиров бер төркем артистлар белән фин татарларына концертлар бирә. Хельсинкида аларны президент Урхо Кекконен кабул итә. Югары кимәлдә очрашудан соң татар миллионеры боларны үзенең супермаркетына (зур кибет) алып бара. «Миннән бүләк — җаныгыз ни тели, шуны сайлап алыгыз», — ди. Артистлар ябырылалар. Үз илендәге кибетләрдә кара трусиктан, «Спартак»ның кара ботинкасыннан гайрене күрмәгән кеше шушы кадәр әкияти байлык

уртасында торып калсын әле... Бер читтәрәк торган Илһам Шакировны чакырып китерәләр дә бусын алыйкмы, тегесенме, дип киңәшә-киңәшә зур-зур каплар күтәреп килеп чыгалар болар. Илһам Шакиров кулында — чеметеп кенә тоткан бер пар носки... Һотельгә кайтсалар... ни күрәләр, Илһам Шакиров бүлмәсендә — ул магазинда нинди әйбер турында тукталган, шуларның барысы да матурлап төрелеп, китереп куелган. Ул әйберләрне Казан вокзалында ук, үзен каршыларга килгән музыкантларга һәм дус-ишләренә таратып та бетергән ди. Дөресме шул хәл?

— Булгандыр инде,— ди Илһам Шакиров, һәм мин аңа тагын бер кыйсса сөйлим.

...Илһам Шакиров яңа бер җыр дулкынында тәэсирләнеп өеннән чыккан. Урамда гына искәрә бу — аягында өйдә генә кия торган артсыз чүәк. Кире борылыр иде... әйбәт фал түгел. Сак кына атлап бара торгач, урам чатына җитә. Ничек чыгарга инде дип аптырап торганда, урам уртасындагы милиционер аны танып ала, сырлы таягын селкеп, шунда ук машиналар өерен туктата. Илһам Шакиров вак-вак кына атлап, аяк табанын шудырып, иплəп кенә урамны аркылы чыга. Казан урамы тын калып аны күзәтә. Бөтен татар халкы аны шулай, сулышын тыеп, мөкиббәнә тыңлый иде бит. Иде... дим. Бүгенге шау, шлягерлыкка бирешмәгән акыллы-зәвыклы катлау әле дә шулай...

Соңгы «гайбәтнең» әйбәте — күренекле язучыбыз Батулла дәфтәреннән:

«Кыш уртасында Илһам Шакир Әстерхан ягында гастрольләрдә йөри. Бер авылда концерт куйганнан соң, артистларны ике ат чанасына утыртып, Иделнең аръягына, Болгар авылына илтергә булалар. Яр буена килеп җиткәч, ни күзләре белән күрсеннәр: Иделне урталай ярып көчле бозваткыч узган, юл өзелгән. Уртада — актарылган боз ватыклары арасыннан каракучкыл булып су ташкыны елтырый. Нишләргә? Ничек чыгарга? — дип баш ваталар болар.

Артистлар: «Кире борылыйк та шушы яктагы берәр авылда куйыйк концертны»,— диләр. Ләкин аргы якта Болгар авылы Илһамны көтә.

— Боздан-бозга сикереп чыгабыз! — ди Илһам. Артистлар моңа риза булмыйлар. Илһам, күп уйлап тормастан, чемоданын алып яр буена төшә, тирбәлеп торган бозга сикерә, артистлар җан атып карап торалар. Шулай бозларны чайпалдыра-чайпалдыра тәки аргы якка чыгып җитә бит. Артистларның моңа йөрәкләре җитми, атларга утырып кире борылалар.

Болгар авылында Илһам берүзе җырлап, таңга кадәр концерт бирә. Икенче көнне, авыл халкы Илһамны кулларына күтәреп, күрше авылга кадәр озатып куя».

Илһам Шакиров бу кыйссаны бераз елмаеп, бераз моңланып, тәрәзәгә карап тыңлады. Шунда минем башка мондыйрак уй килде: әгәр без, халык җыелып, «Идегәй» спектаклендәге Туктамыш хан тәхетенә Илһам Шакировны утыртып, юбилей кичәсенә, өеннән театрга кадәр күтәреп алып барсак, ә?!

Вакытында бүген исән
Чын Тукайларны күрик.
Яратып кына, көнләшеп,
Даһига «Даһи!» — дик.

* * *

«Улыбыз туды. Сезнең хөрмәткә Илһам исеме куштык. Исән-имин үсеп житеп, Сезнең кебек олы хезмәтләр кылып, халкыбызга иманлы ир-егет булып ирешсен иде, яраббым...»

Шушындый эчтәлектәге хатлар җырчының үзенә, филармониягә, радио һәм телевидениегә еш килә. Элеккеге тулаем илнең һәммә төбәкләрендә яшь Илһамнар меннәрчә бүген. Шакиров Илһамнар гына да йөзләрчә. Бу инде хөкүмәтнең әллә нинди рәсми бүләкләреннән дә олырак, бу — халыкның эчкерсез, чын мәхәббәтен чагылдыра. Бер генә яшәгән гомереңдә шуны белү — җанга шифа түгелмени?!

Шунысы кызыклы: «Кайберләре белән гастрольләр вакытында танышырга да туры килде,— ди Илһам Шакиров.— Арада төрле эш кешеләре бар, ләкин бер генә Илһам да җырчы булырга максат куймаган, сәнгать юлыннан киткәне булыр микән арада, дип уйлый идем, ниһаять, берәү табылды бит».

Сүзне — Азнакай Илһам Шакировына (гимназия укучысы) бирик әле...

«Илһам абый белән минем арада күңелдә мәңгегә истә калырлык вакыйга булды. 1993 елның март аенда Кәрим Тинчурин исемендәге театр бинасында «Чатыр тау» якташлык җәмгыяте оештырган концерт-тамашада безне Илһам абый белән очраштырдылар. Илһам абый белән сәхнәгә җитәкләшеп чыгу — минем өчен кételмәгән бәхет булды. Башта мин җырладым. Илһам абый утырып торды, аннан Илһам абый җырлады, мин утырып тыңладым. Халык бик яратып кул чапты. Концерт бик озак барды. Шунда Илһам абый безнең чират җиткәнне өч сәгать буе көтеп торды. Шаяртып: «Кайгырма, адаш, зур артистлар җырлап бетерсен әле, бәлки синең белән миңа да чират җитәр»,— дип көлдерде.

Мин татар гимназиясендә укыйм. Музыка мәктәбенә дә йөрим. Җырларга бик яратам. Үзешчән сәнгатьтә катнашучылар белән чыгышлар ясарга туры килә. Алып баручы: «Җырлый Илһам Шакиров!» — диюгә, халык дәррәү кул чабарга тотына, Илһам абый дип белеп. Мин чыгып баскач, халык башта көлә, шактый озак җырлый алмый торам. Җырлагач, тагын кул чабалар, бусы инде бәләкәй Илһам өчен дип, эчемнән уйлап куям. Илһам абыйны халык бик ярата шул. Ул кабатланмас моңга ия булган бердәнбер кеше...».

* * *

Әйе, зур талант ияләре гамәли тормышта үзләрен бәхетле сизә алмыйлардыр. Чөнки аларның йөрәгә аша чор гаме уза. Даһилар — трагик шәхесләр, ди мең еллык философия. Ходай Тәгалә бизмәнне тигезли, күрәсең: башта дан ләйсәненә коендырып мәйдан тоту тантанасы бирә, аннары — шул данның кайтавазында нәүмизле яшәү моңсулыгы...

Егерменче гасырда Европаны шаккатырган «оча торган татар», «Чыңгыз хан варисы» — Рудольф Нуриевны гына алыйк. 1964 елда ул бер тиенсез, йорт-җирсез Париж уртасында басып кала. Титаник тырышлыгы белән, каядыр ике дистә ел эчендә ул дөнья театрларын яулап ала, балет сәнгатендә революция ясый. Кыска гына арада әкияти байлыкка ирешә. Зиннәтле сарайлар, виллалар, бер-берсе миллион доллар бәһаләнгән картиналар, Урта диңгездә утраулар... Европа талантны бәяли белә! Әмма Рудольф бу байлыклар белән кинәнә алмый, аның төп тормышы — сәхнә. Дан һәм алкышлар кытыклавыннан башка аның өчен яшәү юк. Ул үзен бөтен дөньяныкы дип исәпләде, шул ук вакытта ул беркемнеке дә түгел иде. Кем аның таяныр ноктасы? Европа байлыкны бирдебирде дә, аның бөтен тән-ихтыяр көчен тамчысынача сыгып бетереп, вакытсыз гүргә керткәннән соң, бар байлыгын кире тартып та алды. Кабере дә чит җирдә. Үз халкы сугарып тормагач, исеме дә әкренләп онытылыр... дим дә, әлбәттә, аның иҗади мирасын саклаpлар. Бездә ул мәсьәлә ничегрәк тора соң? Тарихыбызда алтын багана булырлык шәхесләребезнең эзләре кала барамы? Ерак китмичә, шушы гасыр эченнән

берничә мисал алып карасаң да аяныч хәл күрәсең. Дәрдемәнд. Акчуриннарның йортлары туздырылган, әйберләре таралып беткән. Ибраһимов, Тинчурин кебек әдипләрнең кульъязмалары юк ителгән. Галия Кайбицкаяның тавышы яздырылган тасмаларны махсус юкка чыгарганнар. Инде ничә еллар буена, фәкыйрьлеккә сылтау итеп, радио һәм телевидениедә кыйммәтле язмалар сөртелә бара. Саный китсәң, чәчләр үрә торырлык. Үзенең культура мирасына бу кадәр битараф булган милләт тагын бар микән?!

Илһам Шакиров башкаруында йөзләрчә җыр яздырылган. Аңа багышлап кино төшергәндә оператор һәм режиссер егетләр аның бөтен язмаларын да бик игътибар белән тыңлап чыктылар. Бүгенге сизгер техника язып алырлык сыйфатлы җырны нибары уникене сайлый алдылар. Калганнары искереп беткән тасмаларда, утыз ел буена әйләндереп, тузып беткәннәр. Чаң сугарлык хәл бу! Илһам Шакиров башкаруындагы халык җырлары сәнгатебезнең милли банкы, милли байлыгы лабаса! Аларны махсус тасмаларга яздырып, кагылгысыз фондта саклый торганын булдырырга кирәк түгелме! Әдәбият-сәнгатебез казанышларын, аны тудыручы әһелләрнең тавышын һәм сурәтен кино һәм магнитофон тасмаларында киләчәккә калдыра алмыйбыз, аны саклау шартларын таләп итә алмыйбыз икән — безгә, киредән маймыл хөкеменә кайтып, башны салырга гына кала...

Менә бит, Нуриев һәм Парижда башланган фикерем кая алып кереп китте. Шунысы хак, исән чакта ук кеше кадерен белү өчен үз дәүләтең булу кирәктер шул. Халыкка хәләл көчен биреп, чын мәгънәсендә фидакарьләрчә хезмәт иткән Илһам Шакиров та житкелекле, бай яшәргә хаклы. Әмма тоталитар җәмгыятьнең үз кануннары бар иде бит. Бүгенге көндә сәләте чамалы эшем ияләренең бөтенләй башка яшәү рәвеше белән чагыштыргач кына үкенечле уяну килә. Ачынып, «рәтле илдә булса...» дияргә кала. Төркиядә генә яшәсә дә, мондый җырчы Босфор ярында үз вилласы, үз җире белән хөрмәтле картлыгын каршылар иде. Әмма без аклануга тиң юану таба белүчән кавем. Шулай, олуг җырчыбыз тормышта байлыкка ирешмәсә дә (үзе ул моңа омтылмады да), иҗатта ул — халык йөрәгеннән аерылгысыз. Бу аның гомер аръягына чыгачак бәхете...

Мәскәү. 1972 ел. Тимер юлчылар институтының мәдәният сараен «штурмлау» бара. Илһам Шакиров концерты. Кайный башкала татарлары. Урамда — атлы милиция. Мәскәү җырчыларына мондый галәмәтне күреп көнләшергә генә кала.

Илһамның грим бүлмәсенә клуб директоры йөгереп керә:

— Ростропович дигән кеше билетсыз кермәкче. Кем ул — танышыгызмы әллә?

— Ростропович — сезнең Мәскәү кешесе. Дөньяның атаклы музыканты, виолончелист, дирижер. Кертегез! — ди Илһам Шакиров. Бераздан тирләп-пешкән, кешеләр урманын көч-хәл белән ерып кергән житез хәрәкәтле Ростропович үзе дә пәйда була.

— Миңа сәхнә кырыеннан гына тыңларга рөхсәт итсәгез иде.

— Рәхим итеп, залга төшеп утырыгыз,— дигән була Илһам, белә югыйсә, залда энә төртер урын да юк, хәтта сәхнә артлары да тулган.

Ростропович концертның беренче өлеше беткәнче сәхнә кырыенда басып тора. «Кара урман»ны исе китеп тыңлый да, артык нык тәэсирләнүдән иләсләнгән кыяфәттә, сәхнә артына кереп Илһамның кулын кыса:

— Бу җырыгыз белән Сез мине үтердегез...— ди. Шунда ук визиткасын чыгарып бирә.— Иртәгә кич безгә кунакка киләсез, көтәбез,— дип китеп тә бара.

Икенче көнне Илһам Шакиров Огарев урамына, үз чорында Сталин төзеткән манара-йортка кунакка килә. Ростроповичлар аны ачык йөз белән каршы алалар. Хатыны — Зур театрның опера җырчысы, атаклы

Галина Вишневская балга кия торган затлы күлмәктән була. Шунысы гаҗәп: өстәлдә — татарча пешерелгән бәлеш, пәрәмәчләр. Кызлары Оля белән Лена, диванга утырып, Илһам алып килгән шоколадларны бүлешә башлыйлар.

Ростроповичка мактану да килешә. Илһамга ул бай фатирын күрсәтеп йөри: «...Бусы — Америкадан. Бусы — Португалиядән ... Вилли Бранд минем якын дустым... Менә, кичә генә Жорж Помпидудан хат алдым... Ә син Казанда рәнҗетсәләр, туп-туры үземә шалтырат!».

Күпмедер вакыттан соң, мал иреге түгел, җан иреге даулап бу гаилә чит илгә китеп шау кузгатыр. Үз илендә каһәрләнсә дә, бүтән илләрнең мәртәбәле сәхнәләрендә дан казаныр, иң югары титулларга ирешер. Мстислав Леопольдович Ростропович татарның мәшһүр җырчысын тыңлап бәхетле мизгел кичерүен әле дә онытмаган, «Кара урман»ны ул болай дип искә ала: «Сүзләрен аңламасам да, гаҗәеп тирән мелодиясе аша җырның ни турында икәнен тойдым мин. Бөтен күнел дөньям актарылып ташланды. Гасырга бер генә туа торган искиткеч талант иясен котлавымны гына хәтерлим. Андый талантны сакларга кирәк! Ә җыры нинди! Кара урман... Мондый җырны бай тарихлы бөек халык кына тудыра ала. Андый халык алдында баш иярга була!..»

Әйе, татарның канлы да, шанлы да тарихы сүз белән түгел, күбрәк моң белән язылган. Илләр ава, китаплар яндырыла, тел бетә — иң актыктан моң кала... Үзен империя хуҗасы санаган, гамәлгә ашмас идея горурлыгын иңенә салган халыкларның җыр сүрүендә моң түгел, хәрби марш тантанасы өстенлек итә. Моң башка... Яуланган һәм яңа корылган күпме мәмләкәтләр нигезендә, төрле исем вә байрак астында татар каны тамган. Көчле дәүләтләр төзегән, шулар белән бергә дәһшәтле, таркалган, сибелгән халкым Олы язмыш, Олы хәсрәт кичергән — менә шул хис дигән илаһи тәэссоратны яраткан.

Җырла Син,

туган халкыңның күңел күгенә күтәрелгән Тургай, солтанатлы талант иясе!

Ходай тылсымыннан яратылган сәмәви тавышың белән уят газиз җаннарны! Актарылсын хәтер! Сүнгән учак урыннарында кузлар кабынсын, дәвер утларына салып, чайкап ал кыйбласын җуйган җаннарны!

Җырла Син,

сулкылдасын бәгырь, тетрәнсен рух, җылатып юат мәртәбәле татар дөньясын!

Син — кара урман Иясе, моң Иясе...

Кадереңне аңлата белмәсә, кичер безне, данлы, алкышлы елларыңны салават әйтеп озатыйк та, яңа чор капкаларын «мәрхәбә!» — диеп ачыйк әле!

Халыкның гасабилы язмышын йөрәгеңнән үткәреп, үз җырлары аша Син аңлаттың, яңа аһәңнәрең белән Син уяттың, өмет канатларын терелтеп, очар офыкларын Син киңәйттең.

Җырла Син, гасыр улы, мәшһүр талант иясе, моң галәмендә ни гамь бар, сөйлә безгә, күңелләрне сыгылдырып моңай бер, тарих пәрдәләре артында үткән зурлыкларның даны ачылсын...

* * *

**Татар җырында —**
*Биек Кытай дивары артындагы борынгы чин халыкларыннан күчкән ефәктәй нәфис көй борылмалары бар;*

**Татар җырында —**
*Алтай-Саян төбәгеннән кайнап чыгып, гасырлар аша килә-килә, Цезарьләр шәһәре — Римгә кадәрге ераклыкларны тояк тетрәүләре белән уяткан Атилла Һуннарының тантанасы бар!*

**Татар жырында —**
*ак чалмалы Һиндекуш, Һималай кыялары аша үтеп, Тадж-Мәхәллә кебек йөзек кашы төзеткән Бөек Могол төркиләренең җиңелү сагышы бар;*

**Татар жырында —**
*Хәрәзем оазисларында димәшекъ хәнҗәре белән кояш нурын кискәләп биегән гаярь егетләрнең атлас тирмә эчендәге җарияләрне гашыйк итү мутлыгы бар;*

**Татар жырында —**
*алтын бүре башы чигелгән байракларын җилфердәтеп, карабаир юргаларда кыйтгаларны биләп тә, төрле ил-исемнәргә таркалган төркләрнең Сак белән Сок язмышына тиң үкенечле хәсрәте бар;*

**Татар жырында —**
*Бөек Хәзәр каганаты биләгән ярларны тетрәткән диңгез дулкыннарының кылыч кыяларга бәрелеп кире чигенгәндәге яралы сызлануы бар;*


**Татар жырында —**
*Кубрат хан сараеның фирүзә гөмбәзләрендә җиңел шәүләләр уйнатып фонтан тирәли биегән болгариларның чулпы чыңнары бар;*

**Татар жырында —**
*Алтын Урданың җилгә изүен ачкан балбаллы япан далаларында Идегәйдән илсез калган мосафир-кыпчаклар яккан учакларның әрнүле күмер пышылдаулары бар;*

**Татар жырында —**
*пирамидалар иле — Мисыр тәхетен яулап алган мәмлүк Бибарыс яраннарының саз-кураена гарәп мәкаме кушылган сыктау аһәңе бар;*

**Татар жырында —**
*Идел карамаларыннан алып, малахит Урал сыртлары аша, Себер карагайларына кадәрге киңлектә дәрья булып шаулаган кара урманнарның гөнаһсыз-шомлы тирәнлеге бар!*

Татар жырындагы кодрәтле тылсымны, Күк катларыннан иелеп, Тәңре үзе тыңларлык...





## Рәдиф Гаташ

### БАРМЫ КӨЧЕМ — ЯШЬ МОҢНЫ ЮАТЫРЛЫК...

* * *

Пакь яшьлегең саклый алса ялгыштан,
Сакласын шагыйрь яшеннән — каргыштан:

Гомереңә житәр, төшсә, рәнжеше —
Язмышыңда эз булыр, тап рәвешле...

Чөнки, ихлас шагыйрь жаныннан аһлар —
Тәңресенә, шиксез, ирешер хатлар!

Шундый дога Кандалый хәзрәт кылды:
Ярга ялваруы — чын каргыш булды,—

Гыйбрәт өчен калдырды яманатын!
...Юк, шагыйрьләр, фаш итмәгез яр атын:

Бары сезне яклый — аклый гасырлар!
...Сөймәсәләр — гаепләме матурлар?!

Сөйсә, алар — чын «фәрештә валчыгы»,
«Гөнаһлы» ярның да — сез бит гашыйгы...

Аһ, саклый күр, күңелеңне шул каргыштан —
Мәңгелек үзе таш атар язмыштан!

* * *

Син — язмышым мәллә, монсу матурлык?
Гомерем синең юлда — кире кайту юк:

«Яр» дигәннең яралы йөрәгенә
Дәва эзләп, сүз кушам көннәремә.

Моң иясен терелтер рух табучы
Табиб бугай мин — бөек юатучы!

Юлыктым да җәрәхәтле җаннарга,
Яндым-көйдем — дару эзләп аларга...

Ә үз җаным дәвасын — наз чарасын
Кемнәр белде? Күрде кемнәр — ярасын?

Сөю! дип, бу — мәңгелек омтылышым
Юкка, бәлки? Кем бәһаләр очышым?

Бүген менә мин синең мәхәббәтнең
Зарын тыңлыйм — илаһи хикәятен:

Күк күзләрдә җанны өзәр матурлык...
Бармы көчем — яшь моңны юатырлык?!

* * *

Күңелем аңламыйсың, и Яр,
бәлки, балалык белән?
Телем алмыйсың — үртисең,
ахры, наянлык белән?!

Яшь ярга тиеш — үзгә наз,
кирәк сүз кушу аңа
«Ефәкләрдән нечкә хәйлә»,
шигъри чаялык белән.

Күпме акыл бирде дөнья —
сабак күп калдырдым ник?
Яшим хәзер мәхәббәттә
шактый наданлык белән.

Хис — карт шәкерт, урны һаман
мәдрәсә сәкесендә;
Сиңа пакь догам — ант итәм
ак җан — намазлык белән!

Хак бу сүзем, бел, Гөлбала:
чал башым синең алда
Иелгән — көл сипмә аңа,
берүк, хаталык белән!

* * *

*(Кышкы газәл)*

Йөзеңнеме өтә ут — ялкынлы хис? —
Йөрәгеңне! — тоймас ул салкынны һич:

Дөнья гүя бүген сиңа — эссе жәй!
Кышкы күк тә — ак хыял чатырың ич.

Бага шуннан ай, йолдызларның күзе:
Җирдә — гөлләр, пакь җаннар ачылыр кич!

Хис кичәсе... Ашкын уйлар зөфафы...—
Мәңгелектә ул язылып калыр ич?

Матурлык, син — әллә Вакыт гөлеме?
Галәмара утмы ул — яндырыр көч?!

* * *

Тәнеңнән яз тоташып минем тәнгә
Җаныңнан наз сарылды бүген җанга:

Күк һәм Җирнең: Амин! дигән сәгате!
Мәңгелекнең илаһи сәгадәте...

Тик, табынганга тәнеңә (мең кабат!),
Җаның белдерсә дәгъва бер, шикаять?

Икесе дә калдырмады битараф:
Җан, тән — тәңгәл, камил синдә бар тараф!

Аңлатырга табалмыйм бер матур сүз:
Телем бәйле — бәхетем итте һушсыз!

* * *

«Синдәйләргә — ихлас җанга авырдыр?
Раббым, шундый гашыйкларга сабыр бир!»

Сүзләреңнән яшәү эчте гариб рух —
Сеңлем, назла җанны шулай тагын бер?!

Мәҗнүннәрне якла — зурдыр савабы! —
Дога багышла — әрвахлар хакын бир!

Моң сарган ак башын сыйпа берәүнең —
Бәлки, Җирнең бер әүлия ярыдыр?!

Матурлык эчсен күзләрем яшьлектән! —
Байлыктан бит зякат алу ярыйдыр?

* * *

Борынгы җыр, әллә сиңа кайтасы,
Әллә әр-яңа сүз эзләп табасы?

— Апасыннан матур микән сеңлесе?
Сеңлесеннән матур мәллә — апасы?

Гел шул җырга, күңелем, әгәр кайтсаң син,
Ике матурның, әйт, кайсы тарта соң?
...Сер яшергән сихри караш иясе,
Исерткеч чәч исе — кайсы яктан син?!

Чишмә башын эзләп, хисләр кайтмасмы?
Әмма яшьлек көлеп каршыламасмы?
— Бу гөлләрем сиңа...— дисә сеңлесе,
— Акылыңа кил...— димәс микән апасы?

Борынгы җыр, килә сиңа кайтасы...

* * *

Чайпалыр да ташырдыр җанымнан Хис!
Чайкалыр да егылыр алдыңа Сүз!

Яшь матурлыктан исергән бу башым
Кулыңа ал — колак сал аһына, түз!

Яшерен дип белгән уйларым, сез күптән
Көнгә чыккансыз — зар-җырга тулгансыз!

Бәһа бирегез шул халәт-хәлемә,
Яр күзләре — иң биек йолдызлар, сез?!

Чайпалды да түгелде хис — гомеремдә
Фаш булды сүз — ышан: гөнаһсызлар сез!

## Гөнаһ-ут

### I

Күңелеңнең болганмас, бел, болагы:
Хисеңнең бит сак күзе һәм колагы;

Язык бер эш кермәс һәм сүз — яраусыз...
(Фәрештәләр! Бу — изге,— дип язарсыз!)

Ул — гөнаһтан өстен, биек калачак.
Шундый күреп, Сине күкләр алачак!

### II

Җир кызы син — җирдән аеры тән булмас! —
Тузанланыр — кайсы тәнгә кер кунмас?!

Чуар, кара җирдә үзең туфрак син.
(Яшәештә күктән шактый ерак син!)

Каралтса да мохит — рух, җан пакьлеге
Булыр сиңа азак — йөзең аклыгы!

Әһле оҗмах, шиксез, хәйран калачак:
Бер җанына җиде дөнья багачак!

III

Үткәннәрдән — нинди җанында эзләр?
Кабатлана ни гамь? — ядында сүзләр?!

Кан фетнәсе, дәрт үче булгандыр бит?
Гөнаһлы уй явы кагылгандыр бит?

Һәммәбезгә олуг сынау узасы...
Сират аша кичерер кем догасы?

Кемнең яше — яклап, Хакка барачак?
Тик пакьләнгәч җан, аны Күк алачак!

IV

Вәсвәсәле теләк, шәһвәт иблисе!
Кит ул Ярдан: ак күңел ул, гөл исле...

Ул сафлыкта сиңа табылмас урын,
Кит яныннан — хурлыкка калмас борын.

Йә күрсәтеп шөһрәттән тәти аңа,
Кызыктырма, пакь рух белән уйнама.

Бел, ялганнан чын динне аерачак:
Раббысына тугры юлдан барачак!

V

Каршылыклы бу уйларның тезгенен
Тоталмыйча, гаҗиз Гаташ-мескенең!

Сине уйлый: аргач, тәнең-җаныңны
Гөлсабыйлык сагындырыр чагыңны.

Үз халәтенә охшаш, дип, — үз тиңе:
Елап, хыял эзләр җирдә гел сине...

Әле гөнаһ-утта ул күп яначак!
...Ә Күктә аны Син аклап калачак!

* * *

Сыенсаң да бүген минем йөрәккә,
Сизәм: читтә миннән уең, еракта...

Уятса да ут-иреннәр канымны,
Беләм: яшькә — чын ялкыны җаныңның!

Шашкын хистән, аңлыйм бит, зәукың арган —
Шәүләм аша ул читкә карый һаман:

Омтыласың, сизәм, аның янына:
(Миннән көлеп сөйләрсеңме ярыңа?!)

«Камчысыннан бал тамар» — ул яратса,—
Гаҗәпмени — тиңең сине каратса?!

...Башым кочкан кулларыңда тере наз!
Тоям ләкин: түгел миңа — синең яз!

* * *

Ник, кабатлап, «Сөбханалла!» димәдем?
Күз тидергәнмен бит — шуны сизмәдем...

Ярамый шул яндырырлык соклану!
Ут көче бар караштa да — белмәдем...

Тынычланган күңел, бәлки, һәрдаим
Үзе саклар дип Хак — үзе биргәнен...

Кара көчләр, көнчел күзләр күп Җирдә,
Күрмәсен шулар гүзәллек сүнгәнен.

Юк, бу сырхау — түгел кырау (яз ләса!)
Китәр, ишетеп ул дога сүзләрен.

...Мең кабатла, Гаташ, «Сөбханалла»ңны —
Чын әдәпкә чакыр — гашыйк күзләрең!

* * *

Сиздекме без... сизмәдекме — ул узды:
Йөрәкләрне очраштырган Ел узды!

Бер мизгел ул бер ел Галәм каршында,
Ә бит җаннан гүя мең давыл узды!

Тузгыды чәч, елгадай — яшь... сөртер кем?
Маңгайга эз сызды — Язмыш-кул узды.

Йөрсәк тә без икәү тапкан сукмактан,
Рухта, бәлки, һәркем үзгә юл узды?

Әмма уртак тоташтырган уй юлы —
Яктырды җыр — илаһи нур гел узды...

Беренче бу — Җирдә бергә әйләнү;
Түгел нәүбәт-гомер, бер ел... шул узды!

* * *

Бирсә сиңа Сөю хакын бер Аллаһ! —
Рәхмәте, мәрхәмәте киң, бел, һаман!

Соңласын Яз, килсен салкын — барыбер
Атып чәчәк, тулышачак җан алмаң!

Табигатьнең илаһи канунынннан —
Сөюдәндер — җаннар сизгер яралган.

Яшьлек күгендә моң-болыт — тик кунак;
Гамь дөньясы да бер бездән калмаган!

... Үтмәдеме, читләп, зур Хис Гаташны?
Кабат Сөю хакым булса, бир, Аллам?!

* * *

Мин алданрак китәрмендер — тегендә;
Милли ярлар, сез булырсыз телемдә!

— Без — китәбез, — диярмен, сез — каласы...
Яңа гасырны иңләп Сез барасы.

Кайсыгыз соң — аннан сагынып дәшәр
(Исемем үк онытмас, димен яшьләр?!):

— Кабатланмас гашыйк Гаташ бар иде.
Сөелүне уйламый да яр сөйде...

Багышлыйкчы аңа бер яшьлек хисен?
Җан касәбез тулсын бер аның өчен! —

Кемнең шулай тибрәлермен телендә? —
Урын аңа, шиксез, оҗмах түрендә!

...Бәлки, әйтерсез исәндә — бүгендә?

*1997.*

Нурислам Хәсәнов

# ИҢРӘҮ

ПОВЕСТЬ

Тәрәзәләре кадакланган ялгыз йортта ут-нокта янып сүнде. Бу хәлгә кичке эңгердә болын мунчасыннан кайтып килгән өч хатынның берсе — үткер күзле, тәбәнәк буйлы, тулы гәүдәлесе беренче булып игътибар итте:

— Карагыз әле, малай!..— диде ул йортка таба ымлап.

— Нәрсә бар? — дип түземсезләнде озын кара чәчләрен иңенә таратып салганы.

— Фәйзулла абыйлар йортында ут янып сүнде.

— Чынмы? Булмас ла...— Моны башына сөлге урап бәйләгәне әйтте, ачык изүеннән ап-ак түше кичке инеш өстендәге көмеш айдай ялтырап китте.

Бер мәл тынып тордылар. Әлеге ут-ноктаның тагын кабынуын көттеләр. Хатыннарның кипшенеп тә өлгермәгән тәннәрен августның кичке йомшак җылы җиле сыйпап узды. Бу минутта аларның көн буе эшләп, арып-талчыгулары онытылган иде. Тынлыкны чәчләрен иңенә таратып салган хатын бозды:

— Берни юк ич!

— Билләһи менә, тәрәзә такталары арасыннан ап-ачык күреп калдым! — Хатын шактый мулдан киерелгән түшләрен әле берсенә, әле икенчесенә таба борды.

— Күзеңә күренгәндер әле, бу вакытта хуҗасыз йортта кем йөрсен? — диде кара чәчле хатын, култык астындагы табагына урын таба алмыйча.

— Юк инде...

Ул шулай диюгә, ут янә кабынып сүнде.

— Әнә, күрдегезме?

— Әйе шул...— дип килештеләр калган икесе.

— Кем булыр икән?

Башына сөлге ураган хатын, күңеле нидер сизенгәндәй, дәшмәде. Икенчесенең иңендәге кара чәчләре тибрәнеп алды.

— Кем булсын? Җәмит! Кайткан, тәмәкесен көйрәтә...

«Җәмит» сүзен ишеткәч, башына сөлге ураган хатынның озынча ябык чырае үзгәреп китте. Бу йортка килен булып төшәргә тиеш иде ул, ләкин насыйп булмады.

— Нишләп икән? — диде тегесе һаман кызыксына биреп.

Табаклы хатын буш кулы белән изүен төзәткәләп алды.

— Нишләп булсын, бәхетсезлектән... Бәхетле булса, Казандагы квартирын ташлап, монда кайтып утырыр идеме? Иллегә җиткән кеше. Өендә түзәр чамасы калмагандыр. Малае кешелектән чыгып, эшләмичә йөри, ди. Хатынын да әйтер идем... Карап торырга бер йолкыш кына нәрсәкәй, бөрчә кебек, тешләк. Бер бәхетең булмаса, юк инде ул, ю-ук!

— Әйе шул,— дип җөпләде зәңгәр табаклысы.

Тегесе, үзен хуҗабикәдәй сизеп, сөйли бирде:

— Авылның менә дигән егете иде. Буе-сыны дисеңме? Акылы-фигыле...— Ул култык астындагы табагын рәтли-рәтли башына сөлге ураган күршесенә таба борылды. Тегесенең ябык чырае нидәндер гаепле кешедәй үзгәреп куйды, шулай да иптәшенең карашына игътибар итмәскә тырышты.— Кешесенә туры килмәде, адәм рәтле кешесенә эләксә, мескен хәлгә кала торган ир-ат түгел иде ул...

Хатыннар, кузгалып киткәч тә, Җәмит исемен телдән төшермәделәр. Чатка җиткәч, башына сөлге ураган хатынның юлы уңга таба борылды. Йорты ерак та түгел, ике генә өй аша. Бу минутта аның йөрәген гүя ялкын ялмап алган, күңелен яшьлек хатирәләре әсир иткән, хәтере үзен беренче тапкыр озата килгән Җәмитне терелткән иде.

Ул аңа, менә шушы капка келәсен ачып керәм дигәндә, өзгәләнеп дәште:

— Зөлфия!..

Һәм ул артына борылып капкага сөялде.

— Җәмит!

— Мин шул, мин... Зөлфия, аз гына сөйләшеп торыйк әле!..

«Нәрсә турында?» — Зөлфия күңеленә шундый сорау килсә дә дәшмәде, Җәмитнең нидер әйтүен көтте.

— Ашыкма, зинһар!

— Ә мин ашыкмыйм.

Җәмит үзен уңайсыз сизде. Сүзен ничек башларга аптырады.

— Нинди матур кышкы кич.

— Матур кичләр күп була ул.

— Булсын. Матур кичләр...

— Нәрсә матур кичләр?

— Очрашып торырбыз.

— Нигә?

— Икәү күңеллерәк булыр.

Зөлфия рәхәтләнеп көләсе килүеннән тыелып калды да, башын артка ташлап елмайды.

— Белмим шул... Гармунчыга болай да күңелсез түгел, клубтагы кызларның күзләре синдә генә.

— Алай димә, мине беләсең ич...

— Юк, белмим...

Җәмит әйтергә теләгәнен аңлата алмый, башын тыйнак кына аска иде. Гүя аңа Зөлфиянең уттай янган зәңгәр күзләренә туры карап сөйләү ифрат авыр иде. Кызның сынаулы шаян карашы ниндидер тылсымга ия, телне көрмәкләндерә, салкынча айлы кич булуга карамастан, битләрне кызыштыра. Ул аяк астындагы карны шыгырдатып үкчәсе белән бораларга мәҗбүр. Бу — Зөлфиягә кызык кына, әйтерсең ул үзе өчен яңалык ачкан! Шулай да кыз бу тынлыкның озак дәвам итүен теләмәде.

— Бүген клубта кызларны әйбәт биеттең,— диде.

— Бәйрәмегез бит, сигезенче март. Сез биегәндә күңелле.

— Көлмә әле.

— Чын. Мин сине биетеп кенә торыр идем.

— Миңа кыенга туры килмәсме соң?

— Юктыр ла... Син биегәндә күңелгә рәхәт, гәүдәмне кош сыман очырам кебек.

— Булыр инде.

— Көмеш тәңкәләрең чың да чың кала. Уйнарга рәхәт, җинел. Зөлфия Җәмитнең купшырак яңгыраган сүзләре белән килешмәгәндәй итте.

— Бүтәннәр дә шулай бии инде.

— Юк, син бүтәнчә, син...

— Ничек?

— Аны әйтүе дә кыен... ул йөрәктә ялкын булып дөрли!..

Зөлфия капка келәсенә кулын куйды, үзе нидер тыңлагандай тынып торды. Келәне басып эчкә үтәргә базмады. Арттан таныш тавыш янә кабатланыр кебек тоелды: «Зөлфия! Тукта әле?!» Аны шул халәт камап алган: гомер кичкәндәге сагышлы борчулар, үкенү-рәнҗү хисләре барысы, барысы бергә җыйналып өскә калкып чыккан, йөрәге мәхәббәтен даулый сыман. Әйе, «Аны әйтүе кыен, ул йөрәктә ялкын булып дөрли». Ә тагын? «Бер генә минутка керми тор инде?» Хәзер дә аны шушы сорау туктатып калдырган төсле. Ул бер генә минутка түгел, сәгатьләп тә керми тора ала. Менә шушылай, электәгечә, капкага сөялеп, яшьлек хатирәләре тагын бер йөгереп узсын... «Җитәр, Җәмит, керим инде» — «Ашыкма...» Пышылдап дәшкән ягымлы тавышы җанга җылы өсти. Зөлфия ашыкмый. Җәмитнең зәңгәрсу күзләренә эчке дулкынлану белән сөенеп карый, башы, кояшка тартылган көнбагыштай, аңа таба үрелгән, егетнең уй-фикерләрен күзләренн ән белергә теләгәндәй, йотылып калган. Җаны, бөтен барлыгы чагылган төсмерләрне ул гүя мәңгегә хәтерендә сеңдереп калырга тели. Мондый минутларда Зөлфия өчен шат булган Җәмит, тыйнаклыгын саклап, ни дә булса әйтеп куя, ул исә аны ишетмәгәнгә сабышып, сокланып торуын дәвам итә. Егетнең күркәм битен, йөзләрендә чагылган төсмерләрне барлый. Алдан ук Җәмитнең нидер әйтергә җыенганын белеп тора. Чөнки Җәмит сүзен әйтер алдыннан, фикер сөрешенә бәйле рәвештә, алдан керфекләрен еш-еш каккалап ала. Аңа күзәтеп тору кызык. «Йә, ни уйладың, әйт инде?» — дип сорый, энҗедәй ак, тигез тешләрен ялтыратып көлә, куанычы эчтән балкып чыга, кулларын Җәмитнең киң, таза күкрәгенә куя, башын сала, шул хәлдә, бер онытылып, бәхетле мизгелләр кичерә. Аннан, Җәмитнең күкрәк читлегеннән яңгырап чыккан көр тавышыннан уянып киткәндәй, кинәт, башын горур калкытып, аңа сораулар бирә, аны тыңлый, йомшак кулларының егет учында кысыла баруын тоя.

Кинәт Җәмит сүзгә күчеп:

— Беләсеңме, Зөлфия,— ди,— мин сиңа багышлап бер җыр язмакчы булам. Көен дә, сүзләрен дә.

Зөлфия рәхәтләнеп көлә.

— Хыялый.

— Ә беләсеңме? Хыялсыз бер нәрсә дә тумый. Җирдә мәхәббәт тә яши алмый.

— Нинди җыр ул?

— Ул җырның инде исеме дә билгеле. «Көмеш тәңкә» дип аталачак. Ул җырда синең, биегәндәге кебек, елмаюлы йөзеңне көмеш тәңкәләр чыңы озата бара һәм, өзелгән бер көмеш тәңкәң, күктәге ялгыз ай булып йөзеп йөри. Болытларны аралап йөзгән көмеш тәңкәң, көзгедәй ялтырап, нурларын бар җиһанга, диңгез өсләренә сибә, диңгезләрдә тибрәлеп чагылган көмеш тәңкәле дулкыннар толымнарыңны хәтерләтеп тора.

— Шагыйрь буласың бар икән.

— Җыр үзеннән-үзе туа ул...

— Керик инде.

— Хуш, Зөлфия...

* * *

И-и гомерләр!.. Су сыман ага да ага. Яшьлектә булганнар, нигәдер, һаман да онытылмый, барсы да истә шул. Җәмитнең көмеш түгәрәккә охшаткан ае да. Кем генә айга багышлапҗыр чыгармаган, ялгыз айга карап моңаймаган, кемнәрдер ялгызлык читен булган-

га шушылай айга бакканнардыр. Бүген айга тыңгысыз сыман. Ул әллә каян гына чыгып, агылган болытларны аралый-аралый, үз юлыннан ашыга. Чыннан да, бер караганда болытларга ышкыла-ышкыла, югарып калган кебек. Гүя сафлыкка өндәгән җиһан сакчысы! Болытлар белән көрәштә җиңелергә теләми, барыбер, ялтырап, балкып чыгар да, көмеш нурларын үз-үзен чагылдырган инеш-елгалар, диңгезләр өстенә сибәр, караңгы тәрәзләрне үтеп керер, керер дә кайчандыр үзе турында җыр язарга хыялланган Җәмитне эзләп табар һәм көтмәгәндә аның да хәтерен яңартыр сыман...

* * *

Баганага сөялгән Зөлфия урыныннан кузгалмады, аны магниттай нәрсәдер тартып тотып торды. Әйтерсең ул, мунчадан кайтышлый, хәле китеп, бер сулу алырга гына тукталган һәм аның шушы кечкенә тынлыкта, әз генә булса да онытылып, үзенең толлыгын, җилкәсенә төшкән тормыш авырлыкларын, мәшәкатьләрен искәрми, уйларында бер ялгызы бушанып каласы килде. Шул тойгылар аны Җәмитләр йортына таба каратты. Заманында ул йорт бар урамны бизәп тора иде. Үзен Фәйзулла абый йорты, дип кенә йөртәләр иде. Балта остасы. Зәвык белән эшләнгән капкалары, тәрәзә йөзлекләре, өй кыеклары хозурланып көләп тора иде. Өй каршындагы рәшәткә такталарының тигезлеге тартылган кыл кебек. Ян бакчаларында берәүдә дә булмаган алмагачлар, җиләк-җимеш үсә. Май аенда алмагач чәчәкләренә узган-барган сокланып үтә. Тургай авылында Фәйзулла абый алмасыннан да тәмле алма юк. Шул агачлардан Җәмит өзеп биргән алсу сусыл алмалар тәмен Зөлфиянең һич кенә дә онытасы юк, алар һаман да истә, истә... Менә шул йорт, шул нигез бүген төсен шактый җуйган: нәкышьләп, бизәкләп ясалган такталарның буяулары кояш-яңгырлардан уңган, аннан да, моннан да калҗаеп калган. Башта Фәйзулла абый үзе, аннан аның карчыгы вафат булганнан инде унбиш-егерме еллап вакыт узган. Йортның тәрәзә капкачлары кадакланып тора. Өч баланың берсе-бер ата нигезенә кайтып төпләнергә уйламады, кызы читкә китеп кияүгә чыкты. Сәлимәсе Казанда тора, Җәмит акча эшләргә дип Донбасска киткән җиреннән шунда өйләнеп калды.

Әйе, кайчандыр тәрәзәләре «гөлт!» итеп янып торган шул йортка Зөлфия килен булып төшәрмен, шунда Җәмит белән бергәләп уртак гомер кичерермен, бәхетле булырмын дип уйлаган иде. Уй-хыяллары барысы, барысы бергә чәлпәрәмә килде. Бер-ике елга гына дип Донбасска киткән Җәмитне, әле мунчадан кайтып килгән Хәтимә апа әйтмешли, тешләк борчасы үз ягына оста бөтереп алган шул.

Зөлфиягә шушы төн караңгылыгында ниндидер боеклык кичергән йортта япа-ялгыз утырган Җәмит кызганыч булып китте. Аңа сызлануларын, йөрәк яраларын басарлык ниндидер җиңеллек кыласы килде, сорау артыннан сораулар тудырды. Беләсе иде: бу минутта ниләр уйлый икән ул? Ниләр кичерә?

Берсендә Җәмит аларның бәрәңге бакчасын ярышырга кергән иде. Көн кичкә авышкан чак. Алсу кояш офыкка тәгәри. Тып-тын. Шактый буй калкыткан яшел бәрәңге сабакларына, урыны-урыны белән, кара кучкыл шәмәхәлек иңгән. Кичке эңгерне көткәндәй, йокымсырап калганнар. Алар, буразна араларыннан сызганулы чалбар балаклары тиептиеп узганда, сискәнеп киткәндәй, итәкләрен җилпеп алалар да кабат башларын ияләр. Бил тиңентен чишенгән егетләрнең ялангач, тирләп пешкән тәннәре кояшта елкылдап-елкылдап кала. Сука, бакча башыннан борылып, эзгә генә туктап калган арада маңгай тирләрен сөртешеп алалар һәм янә сөрлегә төшеп, буразнаны ярып китәләр. Сулышлар кысылуга карамастан, егетләр бирешмиләр, шунысы куандыра: бер урам

егетләре бердәм, ярдәмчел. Алда — гәүдәгә барыннан да озынрагы, тазарагы Җәмит, командирдай, иптәшләрен үз артыннан иярткән. Зөлфия Җәмиттән күзләрен ала алмады, аны сокланып күзәтте. Ниндидер тойгылар аны якын иттерә, таза беләк мускулларының кояшта уйнап китүләре ни беләндер күңелне ымсындыра иде.

Менә алар соңгы буразнаны җиңеп, шаулаша-гөрләшә ишек алдына килеп керделәр. Зөлфия аларны, зур чүмечен алып, мичкәдәге чишмә суы белән юындырды.

Мичкә буендагы калку ак таш өстенә Җәмит килеп баскач, аның йөзе тагын да ачылып китә. Җәмит тәннәреннән көмеш тамчылар тәгәрәптәгәрәп киткәндә, куанычы арта, әйтерсең аңа бу минутта матур чәчәк бүләк иткәннәр. Ул:

— Салкынмы? — дип сорый.

— Шәп кенә... Кулың җиңел икән. Бөтен арыганнарны юып төшердең.

Зөлфия бер сөямгә үсеп көлә.

— Белмим шул.

— Мин белми әйтмим.

— Рәхмәт инде...

«Белмим, нигә болар күз алдына килә? Нәрсә булды? Моны Зөлфия үзе дә аңламый. Аның аякларын шушы багана төбе тартыштырган, йөрәген көтмәгәндә генә туган сихри моң — Җәмит моңы камап торткан! Мәхәббәт моңы! Ул чиксез кодрәткә ия, дәртле дә, сагышлы да, кабатланмас җыр җанга тансык кебек, күңелгә канат бирә, аның агышларына кушылып күңел тибрәнә, күптән көткәннәргә сусау, ярату арта. Бу — сүз белән аңлатып бирә алмаслык, үз артыннан әйдәп, чакырып торучы сихри тылсым, җанга, уянган тән күзәнәкләренә җылы дулкын өрүче хис. Колакта Җәмит тавышы яңгырый сыман: «Зөлфия! Әйдә, киттек, су буйларын әйләнеп кайтабыз...» Юк, ашкынулы яшь күңел карышуны белми, җанда күтәренкелек, ул Кояш сымак очына-калкына. Рәхәт. Ул аның янәшәсеннән атлап, әллә кайларга барырга риза. Сиңа юлларыңда очраган болын чәчкәләре елмая, син бәхет тантанасы кичерәсең, син аңа тартылып, бердәнбер терәк итеп, башыңны аның күкрәгенә куясың һәм серле тынлыкка колак салгандай тынып каласың да, ике йөрәк янәшә тибүен тоеп, гүзәл хисләр белән янасың. Шагыйрь әйтмешли, дөнья матур, дөнья киң! Без тиңдәшләр, без бергә булырга тиеш!..

Ә тагын? Тагын ни бар? Картыш тау итәкләрендә гөр килгән кечкенә уеннарның моңнары йөрәктән китми, Җәмит тарткан гармун моңнары! Салмак томан агышларыдай үзәннәргә тарала, кайчак бөтерелә-бөтерелә орчыктай төз, матур булып үскән чыршы агачлары очына килеп урала һәм сине тагын да югарырак — тургай итеп күкләргә күтәрә. Әйтерсең, болын, тау чәчәкләре яшьлекнең кайнар хисләреннән үсеп чыккан һәм син аларның хуш исләреннән тәмам исергәнсең. Син — бәхетле, син аны яратасың! Бу — мәхәббәт! Сөенеч чәчкәсе! Бәхет! Ә бәхетле булырга аның хакы бар, бар, бар!..

Әйтерсең, шушы әчке аваз, кинәт кенә пыр итеп, оясыннан очып чыккан коштай күктә талпына, җиһанны иңләп канат кагына, үзенә тиңдәш рухын эзли. Ишетсеннәр дип аваз сала: «Ул ярата...»

Күпме бәхетле минутлар! Аларны капка төбендәге ялгыз эскәмия көтеп ала. Урыннары бергә, янәшә. Җәмит аның учына гәрәбәдәй сапсары чикләвекләр сала. «Картыш тавыннан җыйдым, җиргә ятып торган иң аскы куак итәкләреннән, кәшәнкеләреннән менә-менә тып итеп төшәргә торганнарын»,— ди һәм кочагына ала... мин эреп сеңәм. Йөрәгемнең дөп-дөп тибүен генә сизәм. Аны бер дә читкә җибәрәсем килми, шахталарда ниләр булмас!.. Ягымлы сүзләре колак төбемнән яңгырап үтә: «Зөлфия! Син һичкайчан минем күз алдымнан китмәссең... Онытма, яме! Бер-ике ел озын гомер түгел, әйләнеп кайтырбыз...»

Һәм ул китте. Китте дә...

Зөлфия калганын искә төшерүне авыр тоеп, капкадан эчкә үтте. Әкрен генә атлап болдыр баскычына күтәрелде, гүя кулындагы кер сумкасы аска тартып авыраеп калган. Иң өске баскычны менгәч, тагын тукталды. Һәм теге көндәгечә, нәрсәсендер онытып калдыргандай, Җәмитләр йортына карап алды.

Ул көн кояшлы, матур иде. Көянтә-чиләкләрен асып, чишмәгә барырга чыккан иде. Җәмитләр капка төбенә аксыл «Волга» машинасы килеп туктавын күрүгә, шып итеп, баскан урынында калды, кинәт тыны кысылгандай булды, тәненнән кайнар дулкын йөгереп узды, яфрак өстеннән иртәнге чык калтырап тәгәрәгәндәй итте, битләре ут кебек янып кызышты. Ул бер мәлгә хушсыз-өнсез калды. Янәшә-тирә тып-тын. Ичмасам, ишек алдында җим чүпләгән тавык та тавыш бирми. Барысы, ни булырын көткәндәй, тынлыкка буйсынган диярсең. Зөлфиянең чиләк-көянтәсе әкрен генә иңеннән шуышты, шул хәлдә чиләкләренең болдыр идәненә төшеп утырганын гүя сизмәде. Ул күзләрен шул Җәмитләр капка төбенә килеп тукталган машинадан аера алмады. Түземсезлек белән көтте. Менә машина ишеге бер якка ачылып китте. Аннан өстенә аксыл костюм кигән, төз, озын гәүдәле кеше чыгып басуы булды, аның иреннәре тартышкандай калтыранып алды, башы чәчкәдәй сыгыла төште, тавышы сыкрап чыкты.

— Ул!.. Өйләнеп кайткан...

Йөрәк тибеше ешайды, күкрәк читлеген ниндидер ялкын ялмады. Ул, җәелә барып, бугазга таба үрмәләде, сулышны кысты. Шуңа да карамастан, ул сабырлыгын җыеп түзде, машинадан хатыны чыкканын көтте. Җәмит аны, министрны каршылагандай, ишекне ачып чыгарды. Гәүдәгә шактый чак күренгән хатын өстенә ялтыравыклы кызгылт күлмәк кигән, чәчләре кабарынкы, бөдрә. Бөдрә баш як-ягына каранды, күзәтеп бакты. Җәмит исә машинасындагы сумкаларын чыгарырга кереште. Бер кечерәк төенчекне хатынына тоттырды, аннан калганнарын үз кулына алып, капкага юнәлде. Яшь килен ире артыннан иярде.

Зөлфия сискәнеп китте. Үз-үзен нишләтергә белмәгәндәй тинтерәде. Яшь киленне җаны-тәне белән күрә алмау хисе баш калкытты, ярсыйсы, кычкырасы килде. Бугазындагы төер сулышын элмәктәй кысты һәм, ул чыдаша алмый, кырт борылып өенә атлады. Туп-туры ишектән узды да түр почмактагы пөхтәләп җыйган караватына барып капланды, иңнәре дерелдәп сулкылдады. «Үләм, нинди гарьлек!.. Кешеләр күзенә ничек күреним?! — Учлары мендәрен йомарлап кысты. — Ничек түзим? Мәхәббәтемне ятлар тартып алды...»

* * *

Кызы Айнур әнисенең мунчадан кайтуын көтеп, йокыга киткән иде. Өстәл өсләрен җыештырып, чәйләрен кайнатып куйган, бал-шикәрен әзерләгән. Ул кызын җәлләп тә куйды: «Көн буе бәрәңге чүпләп аруы җиткән балакаемның. Бу кадәр дә әтисенә тартыр икән, кара кашлары, тут йөзе барысы, барысы анык. Тач коеп куйган!»

Шушы чагыштыру аңа, ихтыярсыздан, моннан биш ел элек вафат булган ире Зәбирне хәтерләтте. Ул ашыгып-каударланып ишек катындагы чүәкләрен киде, сумкасын урындык өстенә куйды, башына ураган сөлгесен салып караватбашына элде, чәчләрен тиз генә киптерергә теләгәндәй, тузгытып алды да янә җыеп артка сыпырды. Аннан өстәл артына килеп утырды, башын уйлар сыкты. Гүя ул бәгырь авазына колак салгандай тынып калды.

Нигә син, тормыш, шулай мәрхәмәтсез икән? Кызгануны белмисең! Җәмиттән өмете өзелгәч, авырыксынып кына булса да Зәбиргә кияүгә

чыккан иде. Болай ук ярамас кеше кебек тә түгел иде. (Вакытың узып барганда бик сайлап торып та булмый!) Кулы эш белде, шөгыльгә җәптәш булды. Техниканы яратты, тракторчы һөнәрен үзләштерде. Авыл җирендә тормыш өчен анысы да ярады. Уртак кызлары Айнур туды. Бик җиңелдән үк булмаса да, тормышлары кешенекеннән калышмады. Үзе ферма юлын таптады, сыерлар сауды. Укырга туры килмәгәч, бүтән кая барасың?! Шул рәвешле тормыш ярыйсы гына барганда, Зәбир йомшаклык күрсәтеп, аракыга иялэшеп китте. Йомышын-гозерен тыңлагач, әле тегесе, әле монысы тракторчыга яртысын чыгарды. Әкренләп тыныч көннәр сирәгәя башлады. Эш сүгенү, җикеренүләргә барып җитте. Балкырга өметләнгән җан кояшы сүрелде, тоныкланды. Авыр сүзләр йөрәккә кылчык булып кадалды. Сүзләре йөрәккә яра булса да, ир хакы дип түзде. Түзми нишлисең, авыл җирендә утынын кискәч, печәнен әзерләгәч тә ярый дип уйлыйсың. Сабыр итәсең, бала атасы, хакы бар дип уйлыйсың.

Иң аянычы алдарак булган икән. Кем уйлаган, көтмәгәндә, аяз көндә баш очыннан яшен яшьнәп үтәр дип. Яман, зәхмәтле уй Зәбирнең башына суалчан кебек үрмәләп керер дә, көнләшү чире тамыр җәяр дип. Кем уйлаган, кем белә, шулай килеп чыгарын? Белгән булса, Бәкер санаториена барып та йөрмәгән булыр иде. Аяк буыннарына суык тидергәч, колхоз идарәсе бушка биргән путевка белән, бик кыстагач, дәваланып кайтырга ризалашкан иде бит ул. Юкса, Зәбире дә каршы килмәгән иде. Ул киткәч, кемдер аның күңеленә коткы салган. Янәсе, акыллы кеше хатынын санаторийга ялгызын җибәрәме? Санаторийга барган хатыннар бер-ике көннән үк чит-ят ирләр белән парлашып бетәләр, үзләренең авырганлыкларын да оныталар, никах антын бозалар, фәлән дә төгән. Шуннан китте, башына кергән шик үзенекен эшләде. Аралар соңгы чиккә җитеп киеренкеләнде. Нәрсә генә турында сөйләшеп китсәләр дә, сүзнең шуңа — булмаган хыянәткә барып терәлде, әче җәнҗал белән төгәлләнде. Тәмсез, нахак сүз җанны газаплады.

Аңа да читен иде. Ни сәбәптәндер ышанып җитә алмау уе аны корт сымак кимереп, әледән-әле җанын ялкынсындырып, иңрәтеп торды. Йокысыннан тирләп уянды, бусанды, битарафлыгы артты, арган кыяфәттә, исерек сымак, күзләре тоныкланып-тоныкланып китте, йә усал ялтырады. Аның, нидер күз алдына китереп, нидер уйлап, шикләнеп карап куюлары Зөлфия йөрәгенә уктай кадалды, утлы тимер сымак өтте. Нахакны кичерү җанга бик тә авыр, газаплы иде. Үзеңне мондый халәттә сизеп гомер кичерү бер җәза: кулдан эш төшә, йортның нуры кача, яме китә, кайчак эштән өйгә кайтып керәсе килми башлый. Берни белмисең: кайчангача дәвам итәр бу?

Ул да, кулыннан балтасы төшкән кешедәй, дәшми-нитми йөренә, кая барып бәрелергә белми, аннан, җанына урын таба алмагандай, чыгып китә. Китә дә барысын онытырга теләп, ярыймы, юкмы, аракы чөмереп кайта. Шул салулар ахыр чиктә башына җитте дә инде...

* * *

Урак өсте иде. Көн сүрелеп кичкә якынлашкач, урман полосасы буендагы арыш басуында, култыктарак, Басыйр комбайны туктап калган иде. Аның янәшәсендә, берничә метрлар арада Зәбирнең арба таккан «Белорусь» тракторы. Бар киеме, йөзе тузанга баткан Басыйр белән Зәбир әңгәмә кора.

— Юк инде синең, ә? — диде Зәбир тамак чылату ягын каерып.— Фляга төбендә дә калмадымы?

Басыйрның җәенке табак битендәге кабарынкы кашлары мөгез ясап, биешеп алды, йөзенә бераз ачыклык биреп киңчә сирәк тешләре ялтырап китте.

— Булса,— сүзен сеңдереп әйтергә теләгәндәй тыныш ясады,— үземә дә мишәйт итмәс иде ул үпкә тузаннарын юарга!.

Шуңа да карамастан Зәбир кабатлап сорагандай итте:
— Юк инде, алайса?..— диде.
— Юк шул,— диде Басыйр, аның хәлен чыннан да аңларга теләп.— Изгән балны бүген коргаксыттык. Аракыны күргән юкка биш былтыр. Талонына дигәнен дә кайтармыйлар бит, каһәр.
— Без кемгә кирәк?
— Шул-шул! Ат урынына җигеп эшләтергә булса гына.
— Начальство ансыз тормый, билгеле.
— Әлбәттә. Элек ничек булган, хәзер дә шулай. Сейф, холодильник эче буш тормый. Аерма шунда, хәзер ишекне эчке яктан бикләп кенә эчәләр. Кем ияләнгән тәмле нәрсәдән теләп бизсен? Не шутка!..
Тынып калган Зәбир, үз-үзенә дәшкәндәй, көрсенеп куйды.— һәм тагын бер үк сорауны бирде:
— Юк инде, алайса?..
Басыйр дәшмәде. Кузгалырга җыенгандай, читкә борылды. Зәбир ашыгып икенче соравын бирде.
— Бәлки, берәр әмәлен табарбыз?..
— Ничек? — Басыйрның акайган күзләре Зәбиргә текәлде. Зәбир сүзен күтәреп дәште.
— Бер җирдә бар инде ул. Шәп көмешкә! Чиста эшли, ипидән.
— Кемдә ул?
— Керәшен Настясында. Барып килсәң була инде, моннан ерак түгел.
— Рәтең бармы соң? Аңа бит бу,— Басыйр акчага ишарәләп, бармакларын уйнатты,— тити-мити кирәк.
Зәбир «һе» дип көрсенде.
— Рәт булса, сөйләшеп тә тормас идем мин, ни...
Басыйр аның нидер әйтергә теләгәнен тоеп туктап калды.
— Әллә ниме?
— Йә, турысын гына әйт инде?
— Настяга дим, арыш тондырабызмы? Миндә капчыклар бар!..
Басыйр җәенке иренен салындырып уйлана калды, түгәрәк чүмечтәй алгарак чыккан ияген кул аркасы белән сыпырып алды. Ни әйтергә белми икеләнде. Шул арада Зәбир өстәп куйды:
— Әйдә, чамаладык, чуртым да белмәячәк.
Ниһаять, Басыйр, килешеп, кулын селтәде:
— Әйдә, алайса...
Зәбирнең тракторы комбайн бункеры турына ук килеп басты. Алар, җәт-җәт, як-якка карана-карана, эшне тиз тотарга керештеләр. Арба өстенә менеп баскан Зәбир кулындагы капчыклар берсе артыннан берсе тулып, әрҗә төбенә тәгәрәде. Берничә минуттан трактор, кичке эңгер якынлашканда, полоса буйлап Керәшенкә авылына юл тотты...
Кырый йортта яшәүче ялгыз хатын Настя өйдә иде. Капка астыннан башта чәрелдек, йөнтәс эте өреп чыкты. Зәбир тавышына игътибар итмәгәч, эт өрүеннән туктап, койрыгын болгый башлады, үз кеше дип кабул итте булса кирәк. Бераздан алъяпкычына кулларын ышкый-ышкый Настя үзе дә килеп чыкты. Зәбир икәнен күргәч, кысыла төшкән күзләре ачылды, авызы ерылды. Ачык авызыннан сынык теш уртасында чыгып торган металл ялтырап күренде, төзәттергән тешнең яртысы янә кубып төшкән иде. Ул, үзенең шул ямьсез тешен күрсәтергә оялгандай, авызын каплап сыпырып алды. Бизәкле яулыгын әтәч койрыгыдай артка каерып бәйләгән иде. Кояшта җете каралган йөзе, табигый аксылланып торган муены колак тирәләреннән нык аерыла иде. Зәбирнең ник килгәнлеген шунда ук тоеп алды.
— Әйдә, түрдән уз,— диде ул, чуклы итәкләрен бөтереп һәм аяк астында буталган этенә типте:
— Бар, кит әле моннан, кит...
— Настя! — диде Зәбир, ишек алдына үткәч, тавышына аерым мәгънә салып.
Настя шунда ук игътибарын аңа юнәлтте.

— Көмешкәң бармы?
— Сиңа бераз табыла,— диде хатын тыйнаклык саклагандай итеп.
— Түлке акчам юк, мин сиңа бүтән «күчтәнәч» алып килдем, аны кая куясың? Өч капчык арыш.
— Ә-ә,— Настяның башы боргаланып алды. Аз гына уйланып торды һәм келәткә таба ымлады.— Давай менә бу келәткә!
Зәбир капчыкларны тиз генә келәткә кертеп салды. Аннан алар аннан-моннан гына җыештырылган өйгә керделәр. Идәндә әле мич акшарлаганда казаннан ташыган тамчы эзләре сузылып-сузылып ята иде. Борынга әчегән апара исен хәтерләтүче нинди-дер ят ис килеп бәрелде.
Настя өстәл янындагы урындыкка күрсәтте дә чоланга чыгып китте. Озакламый ике чирек шешәне түшенә бала сымак кысып килеп тә керде.
— Мин сиңа иң шәбен, беренче катын бирәм...— дип сөйләнде ул.— Түлке, Зәбир, ни, кеше-карага бик сиздермә инде...
— Нәрсә син, Настя? Мине белмисеңмени?— диде Зәбир һәм шешәләрне, кабаланып, таушалган сумкасына шудырды.
Шул арада Настя өстәлгә тиз генә ике стакан һәм ярты шешә чамасы көмешкә китереп куйды, тозлы кыяр чыгарды.
— Юлга бераз гына тотыйк инде.
Зәбир кире какмады...
...Көмешкә канны кыздырды, хисләргә ирек бирде. Әйтерсең, аларга гүләгән мотор көч, күәт бирә иде. Зәбир нервылар киеренкелегеннән тешләрен кысып-кысып куйгандай итте. Җан уйнаклады. Пычракта тәгәрмәч салулап үз эзенә төшкәндәй, кая гына барса да үзенә тынычлык бирмәгән уйлары кабат Зөлфиясенә кайтып калды, бер нәрсәне тукыды: «Вәт бит, ә? Хатыныңны санаторийга җибәреп, башыңа чир ал?.. Әгәр чыннан да... ул аны сиңа әйтеп торамы? Тинтәк мин, тинтәк... Көтмәгән җирдән... йортлар сал, көне-төне тырыш... Ә хәзер берсе дә күзгә күренмәсен, башыңны диванага салып яшә, эх...
Руль уңга да, сулга да боргаланды. Тоныкк күзләр фаралар яктырткан соры юлга — билгесезлек эченә — төбәлгән иде.— Үз өеңдә тынычлык калмасын, тамактан яз, наз тойма. Кичен хатының янына ятасың килмәсен. Бу — ни? Нишләргә? Аракы түгел, агу эчәрсең бит... Башларымны кая алып олагырга? Бәлки... Кызым кызганыч. Ул гөнаһсыз баланың ни гаебе бар?.. Юк, тормыш болай озак дәвам итсә, мин беттем...» — Зәбирнең күз алдында төрле төсләр пәйда булды, уктай аркылы-торкылы сызыклар сызылып узды, каршындагы юл бер яктырды, бер томаланды. Караса, ул Аю елгасына килеп җиткән иде. Башын суза төшеп, алга текәлде. Түбән таба руль тыңламый карышты. Кырын җиргә килеп җиткән трактор тәгәрмәченең дыңгырдап бер таш өстенә килеп менүе булды, рульне кырт борып куйды һәм ул фәкать тракторының янтаюын сизеп калды. Ни дә булса эшләргә соң иде инде. Җирдән аерылган тәгәрмәчләр, арбаны бер якка ычкындырып, кабиналарны изә-изә, дыңдың бәрелеп һәм туп сымак сикерә-сикерә үзәнгә таба очты — ахыр чиктә елга үзәнендә тынып калды. Тик Зәбир авазы гына ишетелмәде...
Иртән бу хәлне күргәч, тиешле кешеләр, исерек килеш елгага капланган, дип фараз кылдылар. Эчке фаҗигасен исәпләп торырлык аңлаучысы юк иде. Арыш сатуын Басыйрдан башка берәү дә белмәде. Чөнки алданрак өлгергән Басыйр ватылмыйча читкә атылган шешәләрне җыештырып куйган иде инде...

* * *

Зөлфия иелгән башын калкыта төшеп, самавырдан чәй ясады. Чәенә карлыган вареньесы салып болгатты-болгатты да туктап калды. Карашы стаканга түгел, нинди-дер билгесезлеккә төбәлде. Аннан ни беләндер килешми көрсенгәндәй авыз читен бөкте, үткәннәргә үкенгән-

дәй итте. Ире холкына бәйле күренешләр күңелендә яңарды. Уйлап кына кара! Җанны өшетеп, ике арадан салкын җил искәч (һич мәгънәсезгә), Зәбир тискәрелек тоеп, сөйләшми-нитми ялгыз ята башлады. Бу хәл аны үтә рәнҗетте, тинтерәтте, уйга салды: күпме дәвам итәргә мөмкин! Болай яшәү авыр. Сабыр итәргә тырышты, ничек тә булса сөйләшеп, аңлашып, җайлашып китеп булмасмы, дигән уй белән ире янына килеп ята, кулларын, сүзсез, уйларына бирелеп яткан Зәбир күкрәгенә куя, игътибарын үзенә җәлеп итәргә, якынаерга, араларында берни булмагандай хис итеп, аның үзенә карата булган ялгыш карашын төзәтмәкче, барысын-барысын онытмакчы була. Зәбир боларның барысын аңласа да, нигәдер, ихтыяр көчен җиңеп, элеккечә дәшә алмый. Бөтенләй белә, эчтән дулкынлануын яшерергә тырыша. Зөлфия аның бу халәтеннән ни кылырга белми аптырый, үзенчә тегеләй дә, болай да аңлатып карый:

— Йә, ничек инде үз хатыныңа ышанмаска кирәк?.. Гел болай яшәп буламыни? Нигә син минем җанымны рәнҗетәсең?

Зәбир дәшми. Аның дәшмәве Зөлфия өчен тагын авыр.

— Синең алда ни гаебем бар, әйт әле? Нишләп син минем турыда начар фикердә?

Зәбир дәшми, дәшә алмый. Булса да булыр кеше. Хатын-кыз җанын, кешелек хисләрен аңларлык дәрәҗәдә булмаган адәм генә шушындый үҗәтлекне эшли аладыр. Зөлфия түзми. Мөлдерәмә тулган күңеле ташуыннан дулкынланып, күз яшьләренә ирек биреп, китеп бара.

— Начар кеше син!

Ул иренең үзенә шикләнеп карауларын күрмәс өчен, почмакта, йә ишек алдында пышык-пышык еларга мәҗбүр. Үз-үзен тиргәп тә ала: «Нигә дип шул Бәкеренә бардым соң?..»

Ул вакыйгаларны искә алу да кыен, гәрчә йөрәк яраларын вакыт дигән нәрсә шактый юып узса да. Шуларны бүгенге карашыннан күз аллап, җүләр булганбыз дигәндәй, офтану кичерде һәм сусавын басарга һәм боларны онытырга теләп, чәен эчеп куйды. Аннары тагын чигәләрен тотып уйга калды. Көчлерәк хис, тойгылар өскә калыкты. Аптыратты. Бу минутта аның җанына нәрсәдер җитми иде. Шуңа гасабиланып урыныннан торып китте. Ишекле-түрле ары сугылды, бире сугылды. Барыбер күңеле үз урынында түгел иде. Көйсез, тынгысыз. Ни дә булса эшлисе, тынгысыз уйларыннан бушанып каласы, бер җаның теләгән кеше белән ачылып, чын күңелдән сөйләшәсе килә. Тик кем белән? Бармы соң аның үз хәлен, йөрәк серләрен аңлатып сөйләр якын кешесе? Җәмит! Аңлый алыр иде микән ул аны бүген? Кичәге Җәмитме ул? Әллә... һе, эч пошыргыч тынлык сиңа ни дип җавап бирсен? Ул синең ялгызлыгыңнан тырмашып изалануыңнан дәшми генә авыз ерып көлә дә кебек. Ялгызлык иң усал җәза икән, бәгырьне корт кебек кимерә.

«Бер әче нәрсә кабасы иде».

Шулай дип ул шкаф янына килде, аның аскы бүлеген ачты, кирәге чыга калса дип саклап торган аракыны алды, нишләргә дигән сымак бер тын карап торды һәм стакан алып өстәл янына басты. Шешәне ачты. Ярты стакан чамасы аракыны стаканга койды да күзен йома төшеп эчеп куйды, тиз генә су кабарга ашыкты, аннан өстәлдәге кызыл помидорга житеште. Бераздан самавырда чагылган йөзенә игътибар итте. Шулай тоелды: йөзендәге сагыш сөреме таралып юкка чыккан, алсулык иңгән. Аңа карап торган күзләрнең аңлатасы килде: кеше күңеле чәчәк кебек бит ул, җылылык, яктылыкны тиз тоя, үзе дә кояштай балкып янарга гына тора...

Ул тагын үзе өчен нәтиҗә ясый: «Яратканыңа, кадереңбелгәннәргә бар икән ул!». Торып тәрәзәгә килә, Җәмитләр ягына чыккан тәрәзәгә. Әйтерсең, кояшы шул як тәрәзәдән яктырак җылыта.

Тышта төн, тоташ караңгылык. Әмма Зөлфия аны искәрми дә. Тәрәзә-көзге аның йөзен баягыдан да матурайтып, чибәрләндереп җибәргән. Ул үзенә-үзе карап соклану кичерде. Гүя аның каршында унсигез яшьлек

Зөлфия басып тора. Озынчарак шома матур йөз, сызылып киткән кыйгач кашлар астындагы күзләрдән сүз әйтмәс борын ягымлы нурлар ташый. Куллары очар кош канатыдай җиңел, каз мамыгыдай җил ихтыярына бирелергә тора. Һәм ул кулларын җиңелчә генә күтәреп, артка салынган чәчләрен кабартырга теләп тибрәтеп алды, хисләренә бирелеп хыял итте: кем әйтер аны кырык яшен тутырган Зөлфия дип! Канатлар сымак һавада калкынган куллар аска төште. Тылсымлы бармаклары халат төймәләренә кагылып үтте, аксыл нәфис түше тыштагы диңгездәй караңгылыкта чагылып китте. Өзелеп-өзелеп, җан яратканы белән сөю рәхәтен тоясы килә иде аның.

Ул халатларын рәтләп, күңеленнән тәрәзәдән карап торган Зөлфиягә дәшә.

— Сәер кеше син, әйеме?

— Мәхәббәттә бар да сәер.

— Сиңа шушы тәрәз артындагы караңгы төн дә диңгез булып күренә башлады.

— Мәхәббәт — диңгез ул, шул диңгездә һәркем үзе теләгәнчә рәхәтләнеп йөзәргә тиеш.

— Инде соң түгелме?

— Юк, аның чикләре билгеләнмәгән.

— Ару түгел, килешмәс.

— Ару түгел дип, намусыңа хыянәт итү килешәме? Горурлыгыңны сакла, дисеңме? Аны аңлаучылар ничәү табылыр? Миңа бүгенге акылым яшьлектәге ялгышларны кабатламаска куша. Кемнең канаты каерылган кош хәлендә каласы килсен?! Кемгә кирәк рәнҗүле рух, җан сызып яшәү, әрнүләр?

— Читен хәл.

— Читен шул, җан яратканыңның янында булмавы, ялгызлык корбанына әверелү. Кем йолып алыр мине шушы газаплы бушлыктан? Кем? Җәмитме?

— Ул — кеше кешесе.

— Беләм, минеке түгел, минеке булырга тиеш булса да. И-и язмыш!..

Зөлфия кабат чәчләрен кабартып, җилпеп җибәрде. Колагындагы чирек ай сурәте төшерелгән алкалары нурланып чайкалды. Җәмит истәлеге! Кызына Айнур кушуы да көмеш тәңкәләрен айга тиңләүдән, хәтердә матур чагыштырулар калдыру нәтиҗәсе иде. Айлы кичләрне яратты, хыял диңгезендә йөзде. Бүген дә уйларына әллә ни булды. Аптырап чигәләрен тотып калды, бер уйларына ирек бирде, бер каршы төште: «Артка юл юк! Узганнар кире кайтмый. Гомер юлында бер ялгыш адым ясама икән».

Ялгыш адым! Юк, ул аны ясамады да кебек. Ә Җәмит?.. Ул аның газапларын ничек кичерә икән? Үз жаныңа посып, качып яшә. Туып-үскән ата-ана нигезендә ут алырга, кешегә күренергә курык. Куркып тәмәке көйрәт, кемгәдер рәнҗеш кичер... бәддога кыл. Ә мин нишли алам?

Зөлфия күңелендә Җәмиткә шушы минутта җиңеллек ясарга теләү, кызгану хисе калкып чыкты. Бәлки аңа Җәмит янына барырга да, күңелендәгеп барысын сөйләргә, аның зарын, уй-кичерешләрен тыңларгадыр. Ачыктан-ачык, берни дә яшерми? Нишләргә?

Күңелендә каршылыклы уйлар хакимлек итте. Кодрәтеннән килсә, Зөлфия каршындагы шушы караңгылык пәрдәсен алып ташлар иде. Аңа, гөнаһ шомлыгына каршы, нindидер куркыныч яный кебек. Бар матурлыкның дошманы булып күренә. Эченә күп кенә яманлыкларны йоткан, кемнәрнеңдер мәкерле йөзләрен, яманлык кылган гамәлләрен намуслы күзләрдән яшерә, көйсез тормышны көйсезли, җәза кыла.

Зөлфия хәрәкәтсез калды. Җанын уч төбенә кысып тоткан диярсең.

Тынлык. Тынлыкка игътибар белән колак салган, гүя нindидер тавышны ишетеп калырга тели һәм аның йөзләрендәге киеренкелек йомшарып язылa төшә. Колагына ерактан Җәмитнең әкрен генә тальян

моңы, таныш моң ишетелә сыман. Бар тарафны йокыга талдыргандай тын иткән. Ул аның гармун телләренә баскан бармакларын, чак кына бер якка авыштыра төшкән башын, йөрәк хисләрен кушып уйнаган моңсу йөзләрен бөгенгедәй күрә. Аның Донбасс шахталарына Зөлфиясен калдырып китәсе килми. Якын, бик тә якын таныш моңга йөрәк кага, күңелләр якты офыкларга талпына.

Зөлфия, шул моңны озата баргандай, урыныннан кузгалып китте. Тәрәзәдәге шәүлә тоныкланып юкка чыкса да, күңелдәге моң дәвам итте, аны ымсындырып еракларга дәште, җан пәрдәләрен җилкендерде, кызы Айнур караваты каршында шып туктап калды. Намусына киңәш итте: «Мин нишлим?..»

* * *

Бу вакыт Җәмит һаман да япа-ялгыз караңгы өйдә тәмәке тартуын белде. Ут-нокта бер янды, бер сүнде: әйтерсең җанында уйнаган фаҗигане кемгәдер ирештерергә теләп сигнал бирә, ул тозакка — магнит кырына эләккәнмени, утырган урыныннан кубып китә алмый. Уйлары иңенә баскан. Тәмәке уты ак кәгазьне көйдереп җәелгәндәй, эчтән янулары да аның күкрәк читлеген шулай камый бара, нервларын ялкынсындырып сулышын кыса, аны аптырашта калдыра: «Кемгә тап булдым мин? Кемне үстерәм? Үз малаең синә кул яксын инде?.. Барысына да мин гаепле, мин, минем мокытлык...»

Җәмит тәмәке кыстырган бармакларының калтырануын сизде, гаилә зилзиләләрен күңеленнән кичерде. Шушы шомлы тынлык аның эчен пошырды. Утны яндырырга теләде, аннары кире уйлады. Күрмәгәннәре, белмәгәннәре хәерлерәк. Ул автобустан төшкәч тә, урман буенда караңгы төшкәнне көтте. Аннары гына, иңенә плащын элеп, кулына күн сумкасын тотып бирегә кайтып керде. Төрмә качкынымыни? Юкса урламаган, бернинди хилафлык кылмаган. Гаепсез. Болай да ярты гомере кабер караңгылыгына тиң шахтада узган. Күпме сәламәтлеген югалтты ул анда? Шунда чак кына җан да тәслим кылмады.

...Ул көнне дә шахтада эш, гадәттәгечә, башланып киткән иде. Күмер чапкан машина үз көенә әйләнде дә әйләнде. Җәмит машина ваклап чыгарган күмерләрне чистартып вагоннарга төяп озата торды. Кинәт, көтелмәгән шартлау аны тетрәндереп җибәрде. Калганы секунд эчендә булды. Катлам куышында кысылып яшәгән метан, үзенә таба тешле машина пычагы якынлашуын көтте-көтте дә, кинәт күмер катламнарын як-якка ииште. Ул ниләр булганын абайларга да өлгермәде. Санаулы секундлар узгач кына, айнып киткәндәй, үз-үзенә дәште: «Исәнме мин?» Үтереп башы чатнады, куллары башына үрелде. Каска каядыр очкан. Чигә туры җылы юеш, аннан кан саркый. Нишләргә? Дөм караңгы. Дүрт як та бикле. Кабер тынлыгы җанны кыса. Күкрәк читлегендә йөрәк, нәни коштай үрсәләнеп, тибенә, ул тибеш чигәләрдә сизелә. Аны бүтәннәр ишетми... Олег исәнме икән? Ул аңа нибары: «Машинаны туктат!» — дип кенә кычкыра алды. Ул әллә ишетте, әллә юк...

Җәмитне авыр сызлану талпындырды һәм ул сыкранып телгә килде: «Бу ни? Уң аяк хәрәкәтләнми, кысылган. Нишләргә?... Үлемем шушы микәнни? Унсигез яшемнән тере килеш кабергә кереп ят инде...— Ул кысылган аягын ычкындырырга омтылып карады, эчтә кабыргасы чәнчешкәнен тойды.— Булганмын мин! Эх-ххх!..»

Баш чатнавына чыдар әмәл юк. Ничек түзәргә? Ахыр чиктә һуштан язмаска иде. Бәлки, ярдәмгә килеп өлгерә алырлар...

— Олег! Олег!

Җавап юк.

Җәмит артта тәрәүләр куеп мәш килгән икенче кул арадашына кычкырып карады.

— Иван! Иван!..— Әллә ишетмиләр...

«Белмим инде моннан исән-сау чыгуларны... сулыш кысыла. Ичмаса, противогазны да салган идем. Нигә, нигә дип килдем соң мин шушы Донбасска? Акчага кызыгыпмы? Хәзер ал күрәп! Янәсе, матур тормыш корам, Зөлфия белән бәхетле булабыз. Юраганым юш килде. Хәзер, үпкәңә күмер тузаны йотып, әҗәлеңне көт. Рәтләп дөнья яктысын да күрә алмый... Их, дөнья белән хушлашырга иртәрәк бит әле миңа, иртәрәк... Бу капкыннан ничек котылырга? Кем уйлаган?.. Бер айдан Сабан туйларына кайтам, дип йөргәндә...»

Баш, тартылган кылдай, чатнады. Ул авыртуга түзәргә тырышып, ихтыярсыздан, күзләрен йомды, һәм күнел түреннән иңгән ниндидер яктылыкта, әллә нинди сурәтләр чагылды, аннан туган йорт пәйдә булды. Ул, зәңгәр рәшәткәләр артында «Мин — Фәйзулла йорты!» — дип кукраеп утыра, чардаклары бизәк-бизәк. Ян бакчада алмагачлар, ботаклары алсу алмалары белән сыгылып төшкән, шунда Җәмит белән Зөлфия икәүдән-икәү калган. Ул, зур бер алманы өзеп алды да, Зөлфия кулына тоттырды. Зөлфия аңа энҗе тешләрен ялтыратып елмайды һәм алманы шыкырдатып тешләп алды. Алсу йөзләре алсу алмадай балкый. Каршында бер күбәләк туглана-туглана очынды. Ул, ниһаять, Зөлфиянең иң башына килеп кунды. Зөлфия: «Бәхетемә микән?» — дигәндәй, тынып калды. Шулчак күбәләк, күрше Гимайлар койма башыннан дөп итеп сикереп төшкән кара мәче тавышына сискәнеп киткәндәй, кабат канат җилпеде. Аны Зөлфия «Китмә!» дигәндәй, карашы белән озатып калды һәм борылып Җәмиткә карады, кулындагы алмасын Җәмиткә сузды.

— Мә, син дә кап!

— Монда күп ич алар.

Җәмит икенче алманы өзеп капты. Зөлфия, үпкә белдергәндәй, артка чигенде, зәңгәр рәшәткә артына узды һәм чиләк-көянтәләрен иңенә элде дә, су буена — чишмәгә төшеп китте. Һәм күздән югалды...

Җәмит күзләрен ачты. Шул ук караңгылык, шул ук тынлык, шушы сәер күренешкә гаҗәпсенде: әллә саташаммы? Нигә дип Зөлфия кулындагы алманы тешләмәдем? Очраша алмабыз микәнни?

Җәмит кабат күзләрен йомды. Тагын шул хәл: бу юлы күз алдында икенче күренеш пәйдә булды. Әтисе түр якта намаз укып утыра, әнисе аңа карый-карый бәрәңге әрчи. Менә әнисе бәрәңге әрчүеннән туктап калды, аптырап, намаз өстендә утырган ирен күзәтте. Аның сәҗдәгә иелергә әзерләнгән сул кулы колагына җитә алмый калтырана, әнисе аңа дәшәргә базмый, намазын бүлдерермен, ди бугай. Иренең мондый сәер халәте аны шиккә салган: нишләгән бу бүген? Әллә, Ходаем...

Шушы мәлдә әтисенең бөгелер-бөгелмәс кулы, колак турына җитә алмый, көчлерәк калтырана башлады. Һәм, кинәт, аның олы гәүдәсе, янтая-янтая, идәнгә гөрселдәп ауды. Моны күзәтеп торган әнисенең бөтен саны тетрәнеп китте, кулындагы пычагы чиләк эчендәге бәрәңгегә төшеп кадалды. Куркуыннан коелып төште, бер мәлгә, тораташ булып катты. Һәм ул, иләсләнеп, кабалана-кабалана ире өстенә килеп ябырылды. Аны нишләтергә белмәде: «Фәйзулла! Фәйзулла! Нишләвең бу? Нәрсә булды? И-и, Ходаем, әллә паралич сукты инде...— Ул аның кулларын тотып карады, җайлап утыртырга теләгән иде, уеннан кире кайтты. Фәйзулласының кара тут йөзе көлсуланып агарып чыкты, ирен читләренә күбекләр пәйдә булды.— Фәйзулла дим!..» Юк, ул аңа тел әйләндереп дәшә алмый, сораулы карашлары белән текәлеп калган. Ул карашларда аңа: «Бар, нигә көтәсең, фельдшер Гөлирамны чакырт»,— дип ишарә ясый сыман. Әнисе шуны гына көткәндәй, ишектән чыгып йөгерде...

Җәмит, хәрәкәтсез яткан әтисе янына якынаерга омтылып карый, булдыра алмый, «Әти, әти! Нишләдең син?» — дип кычкырырга тели.

Тавышы чыкмый. Әтисенең коңгырт күзләре бата төшкән, сагышланып калган, ялварып кемнәндер ярдәм көтәләр сыман. Аның кара-кучкылт йөзендә чак кына кырыслык чалымнары әле дә төсен җуймаган. Яңак сөякләре калку, кинчә ияк чокыры тирәнәя төшкән, керпе чәчләре арасында көмеш бөртекләр җемелди. Ул күпне күргән, тормышның ачы җилләрен күп татыган, авырлыкларны үз җилкәсендә күп күтәргән. Аңа әтисенең бу карашлары тау-кыяны хәтерләтә. Көмеш чәчләре шул тау башында яткан ап-ак карлар сыман ялтырый. Тырпаеп җыерылган калын кашлары гүя нәрсәгәдер ризасызлык белдерә. Ул бүген мине ияртеп чыгып алсу алмаларын сатмый, бакча сәдакасы өләшми. Ул бүген мине, каләмен колак артына кыстырып, ничек пычкы, ышкы тотарга да, сыерчык оясы ясарга да өйрәтми, үзе белән мунчага да алып керми. Балачакка тагын әйләнеп кайтып керсен иде. Мин аның тәнендәге батып торган түгәрәк ак тапларны күреп: «Әти! Синең тәнеңдә бу нинди аксыл эзләр»,— дип сорар идем. Ул көрәктәй киңчә ияген тибрәтеп алыр иде дә, сөйләп китәр иде: «Пуля эзләре ул, улым. Мине Алла үлемнән күп тапкырлар саклап калды. Ленинград фронтында, чәнечкеле чыбыкларны кисеп, пулемет өстенә дә бардым мин. Артта, «Бармасаң үзем атып үтерәм»,— дип әфисәр тора. Монда үтәм... Мин, син улымны күрәсе булганга, исән калганмындыр инде...»

Күз алдындагы яктылык тоныкланып китте. Җәмиттән әтисе бер ерагайды, бер якынайгандай итте. Өйгә кемнәрдер шәүлә сымак узды. Алар аның әтисе янына килделәр. Әнисе белән фельдшер Гөлирам апалары икән. Нидәрдер аңлаштылар. Гөлирам апа әтинең кулыннан тотты, йөрәк тибешен тикшерде, укол кадады, аннан юкка да чыкты.

...Чү! Кай арада бирегә Сәлимә апа белән Кәрим җизни килеп чыкканнар. Читкәрәк китеп икәүдән-икәү сөйләшәләр:

— Кәрим! Әтидән алып торган акчаларны бирик, ул Казанга шул бурычын сорап килгән иде. Суыткыч аласыбыз бар дигәч, дәшмәде, андый-мондый үлеп китә калса, аҗәтле булып калырбыз, дим.

— Үзеңә кара, бир соң...

Сәлимә апа күн сумкасына тыгылды, акчаларын тотып түргә узды да аларны әтисе кулына тоттырды.

— Әти! Без сиңа бурычыбызны алып кайткан идек, берүк рәнҗемә инде...

Әтисенең йөз җыерчыклары тирәнәйде, тоныкн күзләре ялтырап алды, нидер әйтергә теләгән иреннәре дерелдәп куйды һәм ул кулындагы акчаларын идәнгә чәчте.

Сәлимә аптырап калды.

— Әни! Нигә чәчте ул акчаларны? Син аңлыйсыңмы әтинең нәрсә әйтергә теләгәнен?

— Нәрсә дисең, миңа хәзер ул акчалар кирәк түгел, ди.— Һәм ул, яулык чите белән йөзен каплап, читкә борылды да караңгылык эченә кереп югалды.

Җәмит ыңгырашып күзен ачты, сурәтләр «эреп» юкка чыкты. Күмер астына кысылган аяк үзен сиздерде, аны кымшатырга теләде, юк, селкенмәде. Ул, кабат уянып киткәндәй, янә талпынды һәм куллары белән күмерләрне актарырга тотынды. Кырлы-кырлы күмерләргә бәрелгән куллары әчетеп-әчетеп китте. Һава җитмәүдән, тагын хәлсезләнеп, тынып калды. Күз алдында әллә нинди утлы шарлар бер сүнеп, бер янып биеште. Әйтерсең, вак-вак күмер тузаннары шулай җемелдәшеп яна, тәне кызыша, гасабиланган җаны бусана. Ул шушы авыр халәтеннән ничек котылырга белми тешләрен кысты, күзләрен чытырдатып йомды. Янә утлы шарчыклар, атылган йолдызлардай, як-якка сибелеп уйнаклады. Аннары... Аннары ул авыртуын сизмәде... Офыктан җиһанга таң яктылыгы иңгән, ул үзенең Картыш тау буйларына кайтып төшкән, гармунын сузып, моңнарын таныш болыннарга, чишмә буйларына тарата.

Ул моңнар Тургай авылының кечкенә урам, тыкрыкларына кадәр үтеп керә. Иртә-таңнарда гөлләр үскән тәрәзәләрнең ак пәрдә читләре күтәрелә. Ул узып киткәч тә, капкалар шыгырдап ачыла. Кемнәрдер: «Җәмит икән!» — дип аны озак вакыт капка төпләреннән өйләренә керми озатып кала. Эчке штаннан гына чыккан Хәнәфи абый исә арттан куып җитә дә: «Әйдә, энем, бер «Шахта көе»н уйна әле»,— дип үтенә. Җәмит кыстатмый, бүрәнә өстенә утырып, «Шахта көе»н суза. Гармунчыны гармунчы йөрәге ничек аңламасын, ди. Хәнәфи абый үзе дә өздереп уйнар иде, тик бармакларын сугышта өздергән...

Картыш тау итәкләреннән атлаган Җәмит, саф сулы чишмәгә килеп чыкты, тукталып, кулларын суга сузды. Нәкъ шул мәлдә, ул чишмәгә иелгән килеш, хәрәкәтсез тынып калды. Көмеш суда Зөлфиясе гәүдәләнде. Аның җыйнак, сылу гәүдәсе, ак балыктай ялтырап, әйләнәтулгалана йөзде дә йөзде. Камылдай алтынсу чәчләре агым суга ияреп таралды. Ул Җәмитне искәрми, үз дөньясына мөкиббән киткән дә, камыштай бөгелә-сыгыла тибрәнә. Кинәт, борылыш-хәрәкәтләр ясаганда, шикәрдәй аксыл, калку түшләрендә кисешкән нурлар, кояш ясап, күзләрне чагылдыра, җанга җылылык бөрки. Менә син гүзәл могҗиза икәнсең!.. Чү! Ни булды?.. Зөлфия, үз авырлыгын күтәрә алмый, тоныклана-тоныклана, су төбенә төшеп бара. Бу хәлгә Җәмит түзмәде, җан ачысы белән кычкырды.

— Зөлфия, китмә!..

Шул мәлдә Җәмит ыңгырашып күзләрен ачты. «Һаман да мине нәрсәдер саташтыра. Мин исән бит»,— диде. Куллары белән күмерләрне капшады. Нәрсә бу? Кабель! Машинаныкы. Димәк, күмер чапкыч уң якта. Ул кабат күмерләрне актара башлады. Мең газап белән, ниһаять, кысылган аягын ычкындырды. Һич туктап тормастан кабель юнәлешенә таба казынырга кереште. Әмма ялан кул белән бу кадәр күмер өемен күпме казыйсың? Куллары канга чиләнде, тыны кысылды, хәле тәмам китә баруын сизде, тукталып калды. Шунда ук үзен катгый кисәтте: «Тукталып калырга ярамый!..» Кабельгә ике куллап чытырдап ябышты. Әйтерсең, аның көче зур көчәнештәге токка каршы торырлык, өстеннән шушы күмер тауларын алып ташларлык кодрәте бар. Ул, бар мускулларын җыядәй киереп, кабельне үзенә таба тартты. Кабель аз гына тартылып куйды... Шушы минутта теге якта калган Иван, кабельнең тартылып куюыннан, Җәмитнең исән икәнлеген аңлап алды... Аннары, озак та үтмәстән, ярдәмгә килгән шахтерлар, чүкечләрен тыкылдататыкылдата, кабель сузылган якка юл ачарга керештеләр.

Җәмит иптәшләре белән очрашканда, машинист Олег дөнья куйган иде инде. Аның үлеме җанны тетрәтеп җибәрде...

* * *

Аннары инде — шифаханә палатасы... Күрше койкада ятучы Закир ага Казан татары булып чыкты. Аның янына алтын тешле кызы Сәкинә килеп йөрде. Җәмиткә якташлары белән танышу күңелле булып китте. Сәкинә кибеттә эшли икән. Ул әтисе янына еш килде, аңа тәмле-тәмле ризыклар ташыды. Үзе күрер күзгә үк үткән иде.

Бер көнне Сәкинә палата ишегеннән елмаеп килеп керде. Аның уттай янган күзләре Җәмит күңелен ничектер айкап алгандай итте. Өстәвенә: «Хәлең ничек, егет, бирешмисеңме?» — дип тә кызыксынды. Җәмит сер бирмәде: «Менә, күрәсез, әкренләп, сынган сөякләрне ялгап тазарталар»,— дип җавап кайтарды. Сәкинә алтын тешләрен ялтыратып елмайды, аңа күчтәнәчләреннән өлеш чыгарды, матур-матур алмалар сузды. Егет алыргамы, алмаскамы дигәндәй, кыенсынып калды. Сәкинәнең: «Мин бит аларны сезгә чын күңелемнән бирәм, алыгыз инде!» — дип текәлгән карашы аның кыюсызлыгын җиңде. Каршы килү уңайсыз иде.

Алсу алмалар Җәмит тумбочкасына менеп утырды. Бу хәлне читтән күзәтеп торган Закир абый кызның Җәмиткә булган игътибарыннан разый иде. Анычча, егет ярамаслык түгел. Күреп тора: тәскә-биткә дә шәп, эшчәнлеге йөзенә чыккан. Азып-тузып йөрмәгән, бозык түгел, тәртипле күренә. Тәвәккәл, кеше таный белү тәҗрибәсен узган Сәкинәсе дә сукыр түгел, кемнең кем икәнен күрә алды. Аның чак кына гәүдәсе егет алдында әле бер, әле икенче якка бөтерелде. Көдрә чәчле башын ялт кына бора да Җәмиткә елмайгандай итә һәм үз сорауларын бирә, аның белән якыннан танышырга, егет күңеленә сиздерми генә үтеп керергә тели. Җәмит рәхәтләнеп сөйли, ничектер, алгысынган күңеле аның сорауларына теләп җавап бирә. Хушлашканда да бер-беренә ачык карашлары игътибардан читтә калмый иде. Шуннан соң Сәкинәнең көдрә чәчләренә хушбуй исләрен мул сибеп, шифаханәгә ешрак килеп йөрүе дә, ачылып-ябылган ишекләрдән елмаеп керүләре дә юкка түгел иде. Ни гаҗәп, бу аның йомшаклык күрсәтүе булдымы, Җәмит Сәкинәгә каршы төшә алмады. Сәкинә аны үзе сайлады...

Шифаханәдән чыккач, Сәкинәләргә кунакка барды. Анда Җәмитне яхшы әзерлек белән, чын кияүне каршылагандай, көтеп алдылар, ике исәпне бер итеп, әйбәтләп кенә сыйладылар. Ул хуҗаларның эчке ниятләрен сизенмәде, эшнең кая табарак барганын чак кына тоемласа да, кире чигенергә аның ихтыяр көче җитмәде. Әтиләре Закир ага табында кыстата торганнардан түгел икән, салган берен «йомып» кына барды. Баксаң, Сәкинә дә, Җәмит көткәнчә, хәмергә авыз чылатып кына куймый, «әйдә, тотасыңмы?» дип кенә елмая да тора... Табында шактый утыра торгач, Сәкинә Җәмитне күзләре ару гына ялтыраган һәм ниләрдер вәгъдә иткән сихри карашлары артыннан ияртеп, веранда бүлмәсенә алып чыгып киткәндә, Закир аганың булуы җиткән иде. Ул, башын диванга кыңгыр салып, йокымсыравын белде. Хатыны иренә урын-җир хәстәрен күрә калды.

Пөхтә итеп җыештырылган, агач веранда эчендә икәүдән-икәү генә калгач, Сәкинә Җәмитнең кочагына бөтенләй кереп бетәрдәй булып сыланды. Аның карашларында чагылган хис-тойгылар баш әйләндергеч сихри, татлы да ләззәтле дә иде. Шушы сәер тынлык эчендә Сәкинәнең алсу иреннәре уттай кызышканнан кызыша барды һәм алар әкрен генә пышылдап тибрәнде:

— Үп мине!?..

Сәкинә, Җәмитнең муенына сарыла төшеп, аның кочагында үсте, көдрә чәчләре салмак кына егетнең әле уң, әле сул ягына авышты, аның шушы татлы мизгелне озак-озак дәвам итеп торасы килде. Җәмиткә дә рәхәт иде, тәненнән сәер дулкын йөгереп узды, һаман саен, кочагына кереп бетә язган Сәкинәне үзеннән җибәрәсе килмәде. Сәкинә шушы мәлдә артка чигенә-чигенә, тугарылып, йомшак мамыклы диванга авып төште. Чыланган иреннәр бер-береннән аерылмады.

Җәмит ул көнне төнен Сәкинә белән бергә уздырды. Ул аңа оҗмахтагы төш сыман гына тоелды. Иртән уянып киткәч кенә, ул берни аңламагандай, гаҗәпсенү кичерде. Менә шул вакытта Сәкинәнең көтелмәгән соравы аны ике ут арасында — аптырашта калдырды:

— Инде нишлибез?..

Томанлы пәрдә эчендә калган Җәмит үзендә бу сорауга каршы төшәрлек җавап таба алмады. Һәм ул Сәкинәгә өйләнергә ризалашты...

* * *

...Җәмит, караңгы өй эчендәге тынлыкны бозарга базмагандай, һаман да утырган урыныннан кузгалмады, тәмәкесен көйрәтте. Күмер тузаннары утырган силикозлы үпкәсен дә кызганмады. Тыны күбрәк тәмәке төтененнән түгел, үзен туктаусыз әзәрлекләгән

газаплы уйларыннан кысыла иде. Ул, жанына жиңеллек эзләп кайткан шушы әтисе нигезендә дә үзен тозакта кебек хис итте: әйтерсең аны, вакытлар узу белән, мең төрле җепләр белән чикләнеп чуалган, язмыш тозагы сагалап торган. Кирегә кайтып төенле җепләрен чишәрмен димә, алар Сәкинә куллары белән төйнәлгән... Аның шәүләсе ансат кына артыннан калырга да теләми. Аның еландай телләрен чыгарып, ут чәчкән сүзләре колактан китми. Барысына да Җәмит үзе гаепле, үзе. Нигә шулкадәр күзе ачылып җитмәгән авыл мокыты булырга кирәк иде. Хурлык бит, оят. Хәзер шул хурлыкны гомерең буе йөрәгеңдә сыкрана-сыкрана яшәт. Җитмәсә ул кыз, намуслы булып кыланган булды. Ә, чынлыкта ир белән хатын кебек типтереп яши биргән. Кем белән диген? Кибетендәге директоры белән. Без капчыкта озак ятмады шул, тишелде. Нәрсәгә акланып торырга иде. Янәсе, без Николай белән берничә тапкыр гына булдык. Нишлим, өстемнән җитмәүчелек чыкты. Кыен хәлдә калдым. «Фәлән сумың җитми, түлә, түләмәсәң эшең судка китәчәк»,— дигәч, утырып сыйланырга туры килде. Салган баштан булган ялгышлык бит ул. Булган, беткән... Беткәнме соң? Исереп алгач, өйгә кадәр килде бит Николае. Килде дә: «Где моя Сонечка?» — ди, күзен дә йоммый. «Пошел вон!», «Хәзер күрсәтәм мин сиңа Сонечкаңны»,— дигәч кенә, мыскыллы чырай белән көлеп китеп барды...

Бөтен ызгыш-гауга шуннан купты да инде. Ә Сәкинәнең соңлап кайтулары ешайганнан ешайды.

— Тагын соңгарып кайттыңмы?

— Әй, бәйләнмә әле...

— Мин бәйләнмим, сорыйм. Нигә соңгардың, дим? Тагын аның белән булдыгызмы?

— Җүләр сатмасаң иде. Эштә бераз гына утырып алдык. Ревизорны сыйладык.

— Синең ревизорларың бетә торган булмады инде. Тагын эчкәнсең, чак кына намусың бармы соң синең?

— Намус!..— ул, чыраен сытып, хихахайлап көлде.— Ул нинди бизмәндә үлчәнә соң? Бармы соң ул хәзер? Булса да бик дефициттыр инде ул. Аны сатып алып буламы икән? Ха-ха-ха!

— Син ул намусны бөтенләйгә җуйган инде, хәшәрәт...

— Ә син кем? Үзеңне бел, авыл сарыгы. Кем аркасында кеше булып йөрисең соң син? Кем тапкан, кем җүнәткән нәрсәләр бу? — Ул, кулларын җәеп өй эче җиһазларына ишарә ясады.— Боларның берсен дә блатсыз гына китереп бирмиләр.

— Ә кем акчасына?

— Әлбәттә, шахтер егет акчасына. Ха-ха-ха! Мин сине юкка гына сайладыммыни?

— Иблис җан...

— Ә син кем?

— Кеше хатыны бит син, кешедән калган.

— Артымнан кем ияреп килде? Иярмә идең...

— Җитәр!

— Кычкырма миңа.

— Бар чыгып кит хәзер.

— Минем үз өем, үзем сатып алган — аңладыңмы?

— Чыгып китәсеңме, дим?

— Кагылып кына кара! — Ул борча кебек чәчрәде.— Гомереңә дөнья яктысын күрә алмассың.

— Кабахәт! Үги җан син.

— Ирнең үгие юк аның...

— Ах, син, әле шулаймы? — Түземлек төкәнде, кул Сәкинә яңагына чалтыратып барып төште.

— Каравыл, үтерәләр!..

Аннары Җәмит, бәлале булганчы дип, өйдән үзе чыгып китәргә мәҗбүр булды, иптәш егетләренә барып кунды. Өч көн өенә кайтмады.

Дүртенче көндә Сәкинә үзе, әниләрендә калып торган кечкенә Альбертны житәкләп, янына килде. Җәмит малаен куенына күтәреп алмыйча булдыра алмады.

— Әти, кайтабызмы? — диде Альберт.

Аннан соң, карыша алмаган Җәмит, дәшми генә, Сәкинә янәшәсеннән атлады.

* * *

Караңгылык артынаниләр поскан? Уйламаганда шушы сорау Җәмит күңеленә үтеп керде. Аны кемнәрдер караңгы өйнең теге почмагыннан да, бу почмагыннан да күзәтеп торалар кебек тоелды һәм ул, ихтыярсыздан, сагая төшкәндәй итте. Тынды, тыңлады. Туып үскән шушы йортта, электәгечә, үзенә генә якын, таныш тавышларны ишетәсе килде. Бу минутта аңа кемдер үз итеп дәшәр төсле иде. Шуны көтте.

Юк, дәшүче булмады. Әйтерсең, бу йорттан бар да моннан кайтмаска киткәннәр. Исемен атап: «Улым! Кайттыңмы?» — дип тә каршы алмыйлар. Әле кайчан гына шулай иде. Кайчан гына әнисе орчык кебек бөтерелеп йөрде. Улының читтән өйләнеп кайтачагын ишеткәч, төн йокыларын качырып, тагын кабаланды, ары чапты, бире чапты. Вакытвакыт, аптырап, башын пошаманга да салды. Аннары, янә дә кубарылып, бөтен өй эчләрен гәрәбәдәй агартып юды, бар нәрсәне пөхтәләп җыештырды. Шәһәр нәмәстәкәе безнеңчә генә түгелдер, культурный була ул, дип бар җирен чистартты, урын-җир хәстәрләрен барлады. Кунаклар парлап «Волга» машинасында кайтып төшүгә, көткән киленен каршыларга капка төбенә кадәр атылып чыкты. Тик... Сәкинәне күрүгә, кулын сузар-сузмас, аптырап та калгандай булды. «И-и Ходаем, минем әзмәвердәй малаем янында бу нәмәстәкәй суга төшкән чебеш кенә ич!» — дип чак кына теленнән ычкындырмады. Шулай да аны-моны сиздермәскә тырышты. «Әйдә, кызым, исән-сау гына кайттыгызмы?» — дип алдан аның белән күреште, аны түрдән уздырды. Җәмитенә чират җиткәч, җаен китереп, читкәрәк борыла төшеп: «Җәһәннәмнән эзләп тапкан алтының шушымыни инде, улым?» — дип тә сорамый чыдамады. Аннары: «Үзеңә ошаса, ярар. Бәхетле, хәерле тормыш булсын...» — дип тә өстәде, изге теләкләр теләде. Базга каймакка дип төшкәч кенә, эченнән, күңелендәген түгеп, үз-үзенә сөйләнде: «Әй, Аллам, таный белмиләр шул кешене. Күрше Зөлфиягә ни җитми иде! Бу бит аның бер бармагына да тормый. Матурлыгы дисәң, матурлыгы бар. Буе-сыны коеп куйган. Ул булганлыгы дисеңме?.. Зурдан кубып, шушы ялтыравыкны көткәнмен икән. Әй, Аллам, иреннәре бик юка күренә, усал, тешләк нәрсәдер ахры. Бу баланың гомерләре заяга, җан газабы кичереп узмаса ярый инде. Өйдән бер чыгып киткәч, кемгә, кем кулына килеп эләгәсен бер Алла үзе генә беләдер шул...»

Җәмиткә караңгы түр почмактан әнисе карашы төбәлгән күк иде. Әйтерсең ул: «И-и улым, син дә шушы көннәргә калдыңмыни инде?» — дип гаҗәпкә калган да үз киңәшен бирә: «Кайт та тор атаң нигезенә. Илдә чыпчык үлми, син дә үлмәссең...»

Шулай ялгызы утыра торгач, Җәмит зиһенен моннан ун ел элек яңгыраган ата тавышы шакыды: «Әйдә, улым, бер ишек алларына чыгып керик әле...» Җәмит шул елны, әтисе авырып киткәч, ялга кайткан иде. Аның шахтада басылып калганда саташкан төше бер елдан соң рас килде. Чыннан да, әтисе йөрәк өянәге кичерде. Ул үлгәнче телендә, акылында булды.

Җәй урталары иде. Фәйзулла абый, көн җылы булса да, аягына киез итеген элде, иңенә җылы пиджәген салды, башына тезмәгә печән өйгән чагында, муенга чүп коелмасынга кия торган киез эшләпәсен киде.

Болдырга чыккач та, ул аркылы җепсәгә терсәкләре белән таянып, бер тын уйланып торды. Аның калын кашлары астындагы күз карашларында ниндидер сәер сүлпәнлек чагылды, күзләре өметсезлек упкынындай тирәнәйгән иде. Ул якты, зәңгәр күк астындагы бөтен тирә-ягын күзәтте, үз куллары белән өй-каралтыларын, үстергән алма агачларын, ян бакчада бал кортларына чактырырга дип, яннарында чүмәшеп утырган умарталарын — һәммәсен, һәммәсен күздән кичерде. Әмма күзләреннән, электәгечә, дәртле, куанычлы хисләр ташымады. Киресенчә, алардан сизелер-сизелмәс битарафлык, өметсезлек хисе саркыды. Шунда, үз карарына килеп, улы Җәмиткә дәшәр алдыннан аның сул кулы калтыранып китте.

— Улым! Балта-пычкыны ал әле. Метрны да онытма.

— Нишлибез?

— Бераз эшкәртәсе librariesакталар бар.

Җәмит сарайга кереп китте. Ата рәшәткә буендагы бүрәнә өстенә килеп утырды. Пычкы, балта алып чыккан Җәмит аның каршында туктап калды.

— Әти! Кайсы такталарны эшкәртәсе?

Фәйзулла абый ярдырып, абзар буена өеп куелган имән такталарга ишарәләде.

— Әнә теге имән такталарны.

— Аларны нишләтик?

— Өчесен менә мондагы бүкәнгә сузып сал әле. Такыл белән сызып, кырый кырыйларын балта белән читлә.

Җәмит әтисе кушканча такталарны юна башлады. Имән такталар таш булып кипкәннәр, балта агачка авырдан чаба иде.

— Ашыкмый эшлә, имән каты ул. Ботакларын ике яклап, каршыга чап! — дип өйрәтте ул.

Бер такта эшкәртелгәч, ул аңа тагын сүз катты.

— Ял ит бераз,— диде, үзе утырган бүрәнә кырыеннан Җәмиткә урын күрсәтте. Ике арада тынлык урнашты, аннары Фәйзулла уфтанып куйды.

— Балта күтәрерлек тә рәт калмады хәзер. Гомер буена кулдан балта төшмәгән иде. Ач килеш тә күпме чабылды. Ул Сослангер урманнарын тураганда куллардан балта төшеп-төшеп китә иде. Кешеләр ачтан шешенеп чебен кебек кырылдылар. Мин дә шунда үлеп каласы кеше идем. Ярый әле әниең килеп эзләп тапты. Мине эзләп урман эчләрендә адашып йөргән, «Фәйзулла Хәкимовны белмисезме?» — дип, әле бер, әле икенче артельгә барып чыккан. Урман эчләрендә адашкан каз кебек кычкырган. Аннары гына мине, хәлсезлектән алпан-тилпән килеп, үзебезнең «землянка»га барганда, артымнан йөрешемне чалымлап куып җитте дә: «Фәйзулла! Синме соң бу?» — диде һәм муеныма килеп сарылды...— Ул бүкәнгә чабылган балтага текәлеп калды, тамагын кырды һәм иркенрәк сулыш алып, сүзен дәвам итте.— Анагызны кадерләгез... Ул чагында мине сезнең авыздан өзеп алып килгән ризыклар исән калдырды. Бар да ач, ялангач иде. Ул кышкы салкыннарга чыдар әмәл юк. Тишек-тошык киемнәр, аяк үкчәләренә кадәр күренеп ялтырап тора. Барыбызны тезеп, автомат белән алып баралар, алып кайталар. Кайсы берсе, хәлсезлектән тора алмый, агач төбендә түнкәеп кала. Җитмәсә, бер бик әшәке әфисәр бар иде. Честь бирмәгән өчен минем дә яңакка китереп сукты. Безне шул арттан «чыбыркылап» йөрде. Бер көнне, көнлек нормагызны үтәмәдегез, дип бер олы чыршыны кисеп аударттырды да, аны артель кешеләренә өстерәттереп, җәфалый-җәфалый, биш чакрымлык станциягә кадәр кайтартты. Пистолет терәгән, бармый гына кара. Кайткач өлкән командир аптырап китте. Аны каршына чакырып алды да: «Нишлисең син?» — дип җикеренде һәм шунда ук үзен хөкем итте.

— Нишләтте?

— Атып үтерде, кабахәтне...

— Аннары нәрсә булды?

— Нәрсә булсын, шуның белән бетте. Анда кемнең кемлеге белән исәпләшеп тормадылар. Аннары мин, монда ачтан үлгәнче, дип фронтка киттем... Җитәрлек күрдек. Ничә тапкырлар үлемнән генә калдым, әмма...— Аның нигәдер соңгы сүзен әйтеп бетерәсе килмәде, авыр сулап ютәлләде һәм кабат имән такталарга ишарәләде.— Әйдә, юнып бетер боларны!..

Җәмит, такталарны читләп бетергәч, сорады:

— Хәзер нишләтик, әти?

— Туксан сантиметрга үлчәп, һәммәсен кисеп чык.

Җәмит, пычкы алып такталарны кисә башлады. Бирешергә теләмәгән имән такталар сулышны да кыса төште һәм ул, бераз хәл алырга туктады.

— Әти! Нәрсәгә соң болар?—диде.

— Ләхет тактасына.

— Кемгә?

— Үземә.

Җәмит сүзсез калды, аннары сорады.

— Әти, нигә алай эшлисең? Үләргә җыенгандай...

Ата тыныч калды.

— Кис, улым, кис! Ләхет буена җитәрлек булсын.

— Әти, дим!..— Җәмит рәнҗеде, сүзләре йөрәге түреннән тырмалып чыктымыни!—Кулларым бармый, исән бит әле син, исән килеш үзүзеңә... Юк, әти, кирәкми.— Кулыннан пычкысын ташлады.

Әтисе аның белән килешмәде.

— Үз эшемне чит кешегә калдырасым килми... Миңа инде, улым, бу үлемнән котылу юк...

Шул көннән соң ул озак та тормады. Китәсен күңеле сизенгән икән. Шуңа да, ахыр чиктә, аның гомер буе, саулыгы бәрабәренә тир түккән байлык-мөлкәтенә исе китмәде. Их, әти, әти! Хәзер әле дә авыр минутларымда, нигәдер, бала сымак, сиңа таянасым, киңәшләреңне ишетәсем килә... Ләхет такталарыңны, барыбер, син әйткәнчә юнып бетердем, барысын тәртипләп үзем урнаштырдым, сине соңгы юлга озаттым... Белмим, нигә дип син ул чагында Сослангерда урман кисүләреңне искә төшердең икән? Әллә «Анагызны кадерләгез!»—дип әйтер өченме? Яки кабат, инде бу юлы кичекмәс үлем белән очрашу—җан тартышудан туган хисләреңне яңартудамы? Мин әниемнең Мари урманнарына җыенып чыгып киткәнен ул көннәрдә бик ачык хәтерлим. Өйдә безне күрше Җәмилә апа карап торган иде. Әни юлга чыгар алдыннан, бер-ике көн, нәрсәгәдер, куана-куана йөрде, тәмле ризыклар да пешерде һәм бу турыда еллар үткәч кенә, сөйләргә батырчылык итте.

Бер көнне ул, шулай ялгызы гына эшкә барганда, колхозның икмәк турыннан узып бара икән. Аны шунда каравылчы аксак Гаптери абый туктата.

— Хәтимә! Тукта әле?—ди.

— Нәрсә, Гаптери абый?—ди ул, аптырап.

— Кил әле, кил!

— Нәрсә бар? Миңа йомышың юктыр ич?

— Юк та... кил инде, кил дигәч.

Әни килә. Шунда Гаптери абый әнинең алъяпкычына бодай сала. «Гаеп булса миндә булсын, ал, Хәтимә, сиңа җәл түгел, өч бала үстерәсең, шуның өстенә үзең ат кебек эшлисең дә!»—ди.

Әни дә нужаны күрмәде түгел, бик күрде, тик килен хезмәтен, килен хөрмәтен генә күрә алмады, шушы йортта бер ялгызы яшәп, соңгы көннәрен кичерде. Кунакка чакыргач та безгә аягы тартмады. Күңеле, кемнең кем икәнен сизде, нигезен ташлап чыкмады. «Алла саулыгымны бирсен, миңа үз өемдә рәхәтрәк»,— дия иде. Килештермәгәне шул булды: миңа сездә сыешып булмас, мин карт кеше, затлыдан затлы нәрсәләргә иялнмәгән, кая утырып торырга

кыймассың. Тегесенә, монысына кагылырга ярамас. Аннары, нинди йөз белән каршы алмаслар, анысын да белеп булмый. Бер эч серләреңне бушатып сөйләшерлек кешең дә булмагач, читен бит ул көн уздырулары. Киленнең һаман да үзенеке, бер сүз: акча да акча, дефицит товарлар. Фәлән дә төгән, ул үзе генә булган. Алга да, гөлгә дә манып мактану. Нишләтәсең, комсызлык чире кергән өйдә нур сүнә, комсызлыкка анның баласы да күнә, диләр...

Әнисенең шушы соңгы сүзләре Җәмитнең хәтер күгендә яшендәй яктырып алды һәм ул: «Безнең өйдә дә нур сүнәсен әни алдан тойган икән»,— дип килеште. Ихтыярсыздан, уйлары малае Альбертка барып тоташты. Янә йөрәк ярасы яңарды...

Альберты училищедан сугышып кайткан иде. Ул аңа аптырап, дәште:

— Сиңа бер акыл керәме инде?

Альберт аңа төксе генә, ачулы җавап кайтарды.

— Юк...

— Кире дә инде үзең.

— Ә син?

— Әти белән шулай сөйләшәләрме?— Ул сабырлык сакларга тырышты.

— Әти түгел син миңа.

— Ник?—Эчкә ачу йөгерде.

— Тик...

Альбертның кашлары усал җыерылган.

— Үзең әтиең өендә, әтиең хәстәрендә торып, шундый сүзләрне әйтергә ничек телең бара?

— Интернатка бир.

— Сиңа барыберме?

Альбертның карашлары кискенләште.

— Все равно...

— Болай әшәкеләнеп сугышып йөрсәң, төрмәгә дә килеп эләгүең бар бит. Сиңа анда да барыбер булырмы?

— Да, да...— Ул ярсып ук китте.— Нәрсә, мин төрмәгә эләксәм, репутацияң бозылыр дип куркасыңмы?

Җәмит шулчак аңа нигә дип сүз катуына үкенде. Ләкин соң иде инде. Сабыр түземлеге чигенә җиткәч, янә дә дәшми кала алмады.

— Минем репутациядән куркасы юк. Мин эшләп ашыйм. Миңа кайда да ике кулыма бер эш табылыр. Кирәк икән бүген үк теләсә кая китеп эшли алам.

— Кит.

— Мин китсәм, сиңа җиңелрәк булырмы?

— Не твое дело.

— Ничек син әтиең белән шулай сөйләшәсең, ә? Сине бит кеше булсын дип тапканнар.

— Тапмагыз иде...

Ярага учлап тоз сибелде.

— Наглец син!..— диде Җәмит ачуын баса алмый һәм Альбертның яңагына ямады. Шунда ук кулы, кызган мич капкачына тиеп киткәндәй, ярамаган эш кылганын аңлап алды, үкенде, ләкин соң иде инде. Бер аңламаганга усаллык белән генә аңлатып буламы соң? Аңа синең сүзләр син уйлаганча барып җитми. Ул инде, эшсезлектән урамда тырай тибеп йөреп, сиңа гына түгел, дөньясына каш җыерган... Юк инде, хатының ирен ир дип олылар дәрәҗәдә булмаса, малаең алдында кем син?

Менә шул «җимешләрнең» ачысын ул бүген дә татыды бит. Юкса, шушы караңгы өйгә кайтып утырыр идеме? Шахтерлык стажы белән пенсиягә чыккач та җан тынычлыгы таба алмый. Донбасстан Казанга күченеп кайткан чаклары иде. Гәзит-журнал караштырып утырганда, шул зимагур малае җилләнеп кайтып керде дә кухняга әнисе янына узды да сорады.

— Мам! Дай сто тысяч!
— Нәрсәгә тагы?
— На бензин.
— Кая барасыз?
— Съездить надо в одно место.
— Синнән аракы исе килә бит, ничек машинага утырасың?
— Мы с Володей... Ну дай, что ты?..

Кухня ягы бер мәлгә тынып калды. Димәк, Сәкинә тагын юмартланды. Аннары Альберт көзге тартмасында актарынды.

— А где ключи от машины?.. Пап! Тебе говорят.

Барысын ишетеп, тоеп торган Җәмит диваннан торып басты һәм малаена каршы төште.

— Юк! Улым, мин сиңа машина ачкычларын бирмим. Тагын берәр хәлгә эләгәсең киләме? Машинаны бер бәрдердең бит инде.
— Мы с Володей. Он будет за рулем, не я.
— Юк, бирмим.
— Некогда мне, дай говорят...

Ике арада тагын мәт купты. Күсәк кадәрле Альберт үзенә каршы килгән әтисен этеп җибәрде һәм кизәнеп кулын күтәрде. Ызгыш-талашка Сәкинә кухнядан чәчрәп чыкты.

— Нишлисез?.. Бирсәң бир инде ачкычын, чукынсын шунда. Ул машинаң белән җәһәннәмгә китмисеңдер бит...

Талаш, Альберт чыгып киткәч тә, дәвам итте. Сабырлыгы төкәнгән Җәмит кызды.

— Син боздың аны, син...
— Ә син кайда идең? Янымда шәүлә булып йөрдеңме?
— Малаең белән парлап аракы эчүгә кадәр барып җиткәч, шулай буласы билгеле инде аның.
— Ә син — бозау!..

Җәмит кизәнергә селтәнде.

— Кагылып кына кара, хәзер милиция чакыртам!..
— Бар кит моннан, күземә күренмә, дәҗҗал...
— Китәсең килсә, үзең кит, ялтырат табаныңны — минем үз өем...
— Оятың качкан инде...

Җәмит бүтән сүз көрәштерүне кирәк тапмады. Җанын рәнҗү сытты да сытты. Аңа бу квартира тәмуг оясы кебек тоелды. Һәм ул, уйланды-уйланды да, гарьлекне күтәрә алмый, җанына тынычлык эзләп чыгып китте һәм әтисе йортына кайтып егылды. Төн буе уйлар диңгезендә йөзде ул.

Кинәт, бер мизгелдә, Җәмитнең күңел түренә иңгән зәгыйфь кенә яктылыкта Зөлфия сурәте балкып алды...

* * *

Зөлфия бер тын, нишләргә белми икеләнеп, кызы Айнур караваты янында басып торды һәм, әкрен генә артка чигенеп аяк очларына баса-баса, ишек бусагасы янына килде. Стенага үрелеп ут сүндергечкә басты. Аннан, Айнур уянмадымы икән дип, янә чак кына көтте. Кызы йоклый иде. Ишек тавышсыз-тынсыз гына ачылып ябылды. Ул тышкы яктан ишеккә аркасын терәп тукталды. Өй эченнән тавыш ишетелмиме дигәндәй, сагаеп торды. Көне буе бәрәңге бакчасында эшләп арыган Айнуры рәхәтләнеп, изрәп йоклый иде. Тик аның бу төндә үз күзләренә генә йокы кермәде. Җәмит кайтканны белгәч, җанына ялкын элде, шушы көйдергеч ялкын тәннәрен, битләрен кызыштырды, нигәдер сулкылдый-сулкылдый типкән йөрәге аны тынгысыз уйларга этәрде. Аның Җәмит белән ике арада гомергә сер булып калган сорауларга җавап табасы, үз итеп сөйләшәсе, киңәшәсе килде, көтелмәгән шушы талпынудан кабынып киткән йөрәк ялкынын кем сүндерер соң? Кем?..

Тукта! Хәзер кирәкме соң ул Җәмиткә? Көмеш тәңкәдәй күктә йөзгән айга карап, тәңкә чыңнарын чишмә моңнарына кушып җыр язарга хыялланган элеккеге Җәмитме ул? Беләсе иде, кайчан да бер исенә төшерә микән ул аны?..

Зөлфия яшьлек мәхәббәтенә бәйле уйларына отыры биләнә барды. Үз-үзенә каршы төште: әйе, яратырга тиеш, аның да бүтәннәр кебек үк, бу дөньяда өзелеп-өзелеп сөяргә, бәхетле булырга хакы бар. Килдеме соң аңа үзе көткән бәхет? Нигә ул өйләнеп узды, аңардан читтә, еракта йөрде. Мәрхәмәтсез язмышына зарланды. Нигә дип ул шушы язмышка туры килгән үз бәхете өчен көрәшә алмады?.. Җаваплар көтелмәде.

Төн тын. Аны юатучы юк. Аның сыкранган күңеленә моң сарган. Караңгылык эченнән Зөлфиягә берәү дә дәшми, сыны тынып калган. Ул, йөрәген өтәләгән сорауларга җавап таба алмый, кул учлары белән чигәләрен тотты. Уч төпләренә кадәр кызышкан, куллары аска таба шуышып колак алкаларына кагылгач тукталып калды. «Болар — аның истәлеге»,— диде кабат. Әйе, ай сурәтендәге бу алкаларны аңа Җәмит сигезенче март көнне бүләк иткән иде. Вәгъдәләре дә колак төбеннән китми: «Зөлфия, онытма! Мин тиздән өйләнеп кайтырмын...»

Зөлфия һаман да, аягы тартышкандай, баскан урыныннан кузгала алмый ишеккә аркасын терәтеп торуын белде. Әйтерсең, ул шушы ишеккә мәңгегә берегеп ябышкан. Һәм аны ниндидер көч җибәрми тотып тора сымак. Гүя кемдер караңгылык эченнән дәшә: «Син нишлисең?» Ул килешми, аның белән бәхәскә керә: «Йә, әйт, ни рәхәтләр күрдем мин шушы йортта? Күпме рәнҗеш, кимсенүләр кичермәдем? Саф намусыма кара тап булып төшкән нинди генә нахак сүзләр ишетмәдем? Бер генә көн дә тынычлык күрмәдем, сөю-назлардан мәхрүм булдым. Кабынып ташыган хисләрем үз иркендә ага алмый, вакытсыз сулган гөлләр сымак, корый барды... Юк, ниләр генә язса да, мин ул тормышны инде кабат күрәсем килми. Һәммәсен онытасым килә...»

Зөлфия гүя шул тынгысыз, гаугалы тормышын онытырга, аннан бөтенләй котылырга теләгәндәй, ишеген аркасы белән терәткән. Инде Зәбире дөнья куйса да, үзегенә үткән аның тавышы, бозык пластинка тавышы сымак, колагында кабатлана: «Кая барасың, кая барасың?..» Абзарга чыкса да, кибеткә керсә дә, кая гына бармасын, аны артыннан күләгәдәй ияргән шушы сорау эзәрлекли. Сыер сауган җиреннән: «Түгәнәй, ал әле аягыңны?» — дип сыерга дәшсә дә, өйгә кергәч, аңардан Зәбире сорау ала: «Абзарда кем белән сөйләштең?» Телевизорны ачса, анда бер мәктәптә укыган күрше авыл егетенең җырлаганын күрә. «Кара, Сәйфи җырлый»,— дип тыңларга утыра. Зәбире аңа шикләнеп карап тора-тора да төксе генә сорый:

— Син аны каян беләсең?

— Алан мәктәбендә бергә укыган идек. Ә нигә?

Зәбир шулай дигәч дәшми тына. Шик корты, тирәнгәрәк үтеп, аның җанын кимерә, ул янә йөзен җимереп, кашларын җыера.

— Тыңлап утырасыңмы?

— Матур җырлый ич.

Зәбир тагын да өтәләнә, үзенә урын таба алмый:

— Һе, һе... Сине сагынып җыр җырлыймы?

— И-и, бетмәде инде синең. Сора үзеннән...

Ул тагын исереп кайткан.

Зөлфия, кинәт боларның һәммәсен онытырга теләп, өстенә ябырылган вак черкиләрне кугандай, кулын селекте дә, Җәмиткә тартылган уйлары артыннан иярде. Туп-туры ишек алдына чыкты, капкадан үтте, як-ягына каранды. Караңгы төн эчендәге Тургай авылы күләгәдәй җиргә ятып, тирән йокыга талган. Тып-тын, урам этләре дә аваз салмый. Кәнсәләр янындагы бердәнбер багана башында янган электр лампочкасының яктысы мәчет манарасын күккә суза төшкән сыман.

Зөлфия тынлыкны үзенә сердәш итте. Ул уңга да, сулга да карамый, салмак кына Фәйзулла абыйлар йортына таба атлды. Уенда — Җәмит! Ул хәзер нишли микән? Әллә йоклый микән? Юктыр, мөгаен. Бәлки, ул да мине уйлыйдыр. Бу хәлемдә ул мине ничек каршылар? Ярый ла, дөрес аңласа? Инде очрашмаганга күпме гомерләр үткән, күпме сулар аккан? Бәлки, бүген дә ул мине күргәч, «Зөлфия!» дип каршы алыр?.. Их, аның белән бер сөйләшеп утырулары ни тора иде бит! Яшьлек хатирәләрен бер искә алсаң, күңелгә дәва булыр иде. Кеше җаны үз тынычлыгын, үз кешесен табарга тиеш ләбаса. Ә без шушы омтылышыбызны үз акылыбыз белән чиклибез, миебезгә тукыйбыз: ярамый, ярамый! Нигә? Ни өчен кеше үз мәхәббәтенә табынмаска тиеш? Минем табыныр кешем — Җәмит, җаным аңа карышмый... Ә ул мине аңларга теләмәсә? Юк, алай булмас. Тәртипле егет ул, яхшы тәрбия алган. Холкы — Хәтимә апаныкы... Хәтимә апа мине якын итә иде. Юлыбыз чишмәгә суга барганда да, инеш болынына каз-үрдәк куа төшкәндә дә, көтү чыгарганда да, иртәләрен-кичләрен менә шушы урам чатларында да гел очраша идек. Апакаем, соңгы көненә кадәр, гөлләр үстергән тәрәзәләреннән күзләрен алмас иде. Тәрәзә төбенә менеп кунаклаган мәчесе дә шушы Тургай урамнарыннан узган-барганнарны күзәтә иде. Матур-матур парларга сокланып, оныкларын да тәрбияләп үстерәсе килгәндәй, аларны моңсу гына озатып калыр иде. «Нигә бераз киленнәреңә барып тормыйсың?» — дигәч, «Аларга барсам, саргаеп үләрмен шул», — дия иде. Ире Фәйзулла абый нигезен ташлыйсы килмәде, шулай ялгызы азапланып булса да түзде. Моңсулык сарган зәңгәр күзләрендәге жетелек, тыйнак кына көлемсерәп куйган чакларында йөзеннән җанының сафлыгы, пакьлеге бөркелеп торды. Риясыз, әйбәт кеше иде ул. Кайчак миңа: «Әй, киленем була алмадың», — дип тә куя иде. Кулындагы казлар куган чыбыгы, үз сүзен үзе раслагандай, тибрәлеп, җиргә тиеп-тиеп алды. Аннары офтану кичергәндәй: «Язмыштан узмыш юктыр шул», — дип чирәмле капка төбендәге үзе салган сукмагыннан борылып кереп китә иде.

Зөлфия шул нигезгә — Җәмит кайтып утырган йортка бара да бара. Әллә нинди чуалчык, таркау уйларының очына-кырыена чыга алмый. Менә ул, урам як рәшәткәләргә килеп сөялде. Йөрәге дөп тә дөп ярсып типкәнен сизде. Бер иркен сулыш алырга теләгәндәй, сагаеп тынып торды. Шулчак, өй эченнән килгән тавышны шәйләде. Чү! Бу бит — гармун тавышы. Ул уйный! Җәмит!.. Көйләрне онытмаган. Хәтимә апа сандыгыннан тальянын алган да ялгыз күңелен юата. Төн уртасы житкәч, кешеләр йокларга яткач. Тукта! Бу нинди көй соң? Таныш түгел, әмма йөрәккә якын. Читтән отып кайтты микән?

Зөлфия йөрәген талпындырып-талпындырып куйган моңлы көй, аны рәшәткә башларыннан үрелдерә-үрелдерә каратты, нindiдер тылсымлы көч эчкә әйдәде. Моң якыная барган саен күңеле, яшьлегенә әйләнеп кайткандай, аны әсәрләндерде, йөрәге урынын таба алмагандай итте. Җәмитне күрәсе килү теләге әле бер, әле икенче тәрәзә турында туктатты. Шулчак Җәмит үзе дә, салмак кына гармунына кушылып, җырлап җибәрде.

Сагыну, сагышка түзмичә,
Чыгамын аяз, тын кичләргә.
Ялгыз ай — тугрылык билгесе,
Ә синсез миңа соң нишләргә?
Анда да, анда да тулган ай
Йөзәдер ялгызы күкләрдә.
Сагынам, өзелеп сагынам,
Сөйгәнем, мин сине читләрдә.

Ай йөзә, ялгыз ай, армыйча,
Болытлар томанын аралап.
Нәкъ синдәй ул йөзен бер ача да,
Елмая йөрәкне яралап.
Ялтырап зур көмеш тәңкәдәй
Ялгыз ай чайкала диңгездә.
Очынып талпынган җанымда
Яшисең син генә, син генә!..

Йотлыгып тыңлаган Җәмит җыры, вакыт-вакыт, Зөлфиянең тәннәрен чемердәтеп җибәрде. Сыерчык бизгәге тоткандай калтыратып дулкынландырды. Әйтерсең, җырның һәр сүзе аңа аталган өзелеп-өзелеп сагы-

нуларны, тел белән генә аңлатып бирә алмаслык хис-кичерешләрне сөйли. Ул җыр көенә бер кушылды, бер тукталып калды. Тавышы үзгәрмәгән иде — һаман да шулай, көр, ягымлы яңгырый. Аның уйнавын Зөлфия әллә никадәр тыңларга да әзер. Әмма тальян моңы озак дәвам итмәде, кырт киселеп туктап калды. Аннары да җырның дәвамы гүя аның күңелендә яңгырады...

Ул баскыч төбенә килгәч, икеләнеп калды: ишекне шакыргамы, юкмы? Шакырга дип әзерләнгән куллары бер күтәрелде, бер төште. Көтте. Бер урында озак таптанып торды. Кинәт, ымсынып ялкынланган йөрәгенә әллә нәрсә булды: араларын бер стена гына бүлсә дә, нәрсәдер карыштырды. Әйтерсең, шушы ишекне үтеп керү аңа сират күпере кичүгә тиң. «Әйт, йөрәгем, нишлим?» — «Намусыңнан сора, ул ничек кушса, шулай эшлә», — «Мин бит тол хатын хәзер, кергәнемне сизеп, гаепкә санасалар?» Сорауга җавап көтелмәде. Зөлфиянең башы аска иелде.

...Таң сызылганда гына йокымсырап киткән Җәмит күрше әтәченең коймa башына менеп, гайрәт кагып кычкырган тавышына уянды. Тәрәзә капкачлары ярыгыннан сузылган озын бармаклы кояш нурлары мич авызына кереп нидер барлый иде. Өй эчендәге ярымйорты яктылык, сүрән тоныклык күңелне тырнады, рухны басты. Ул әлеге йортның, электәгечә, һәрвакыт матур гөлләре белән яктырып, нур сибеп торуын теләде — өйләренең бу төсе җанын рәнҗетте, бер мәлгә аптырашта калдырды. Йокысын качырып торып утыргач та, аның шушы халәте үз капкынында тотты. Һәм ул янә өй эчендәге бар нәрсәне күздән кичерә башлау белән үзен хәтер сандыгында кебек хис итте. Карашы әтиәнисенең стенада эленеп торган фотосурәтен капшады, аннан үзе тирбәлеп үскән бишекнең түшәмгә беркетелгән тимер ыргагына карап торды, шул кабык бишектән төшеп тәпи йөреп китүләрен күз аллагандай итте, мич арасына кысылып, моңаеп калган табагач та игътибарны үзенә җәлеп итте, әйтерсең, ул әнисе кулында уйный-уйный утлы күмерләрне таратты, өйдә, хуш исле ашлар, бәрәңгеләр пешкән, калфак сымак, нечкә билле тимер чуеннарны, табаларны ары-бире шудырды. Ә түр почмактарак аның тальян гармунын да шушы көнгә кадәр саклаган әнисенең бизәкле сандыгы — үзе үк бер гомерне эченә туплаган догалы, иманлы, шул ук вакытта, чәчәкле, чуклы киемнәре белән яшьлекнең саф мәхәббәтен саклаган хәзинә, хәтер байлыгы, чын тарих. Анда әнисе куллары белән тасланып куелган һәммә нәрсә күңел иләге аша үтеп, аңа, нидер сөйли, уйландыра. Шул уйлары аны житәкли-житәкли, өй эченнән өй алдына — әтисенең эш кораллары янына да алып чыкты, баскычтан очырмага кадәр алып менде, үзе үскән бишеккә юлыктырды, кадакларга эленгән чалгы, табагач, толып, иске чикмән белән очраштырды. Түбә тактасы ярыгына ялгыз урак та кыстырылган. Ул, үзен музейда хис иткәндәй, барын күзәтеп түргәрәк узды, өй кыегында айлы тишектән урам якка — авыл йортларына күз салды. Карашы Зөлфияләр йорты турында тукталып калды. Күңеле, ишектән баскыч төбенә үзе килеп чыкмасмы, дип көтте. Әмма Зөлфия күренмәде. Шулчак, бер карарга килендe: Җәмит кырт борылды да, кабалана-кабалана кире аска төшеп китте. Кулына балта, кадак суыргыч алды, урам якка чыкты, кадакланган тәрәзә капкачларын каерып ачты һәм өйгә керде. Ул, үзенә һава җитмәгәндәй, яктырып киткән өйнең тәрәзәләрен дә барып ачты. «Нигә миңа тәрәзәләре кадакланган өйдә качып яшәргә?» — дип, иркенләп, урам якка карады.


Ни күзләре белән күрсен, анда, каршыга таба, чиләк-көянтәләрен асып Зөлфия килә иде. Бу минутта алар икесе дә бер-берсен күрделәр, икесе дә эчке дулкынлану кичерделәр. Җәмит, Зөлфия чаттан борылып, түбән оч чишмәсенә таба төшеп киткәч тә, аны артыннан назлы күз карашы белән озатып калды...

# ДУСЛЫК ИЛЧЕСЕ, ТУГАНЛЫК ҖЫРЧЫСЫ

Татар әдәбиятының якын, сыналган дусты, Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге абруйлы премиясе лауреаты, «Казан утлары»ның редколлегия әгъзасы олуг шагыйрь Нажар ага Нәҗмигә 80 яшь тулды.

Әйе, башкорт әдәбиятының аксакалы, узаманы булган, Башкортстанның халык шагыйре, Салават Юлаев исемендәге премиясе лауреаты Нажар ага — татар укучысы, татар халкы өчен дә кадерле, үз исем. Бу — аның үзе язганча, әтисе башкорт, әнисе татар булып, татар телендә укып, Тукайлар, Такташлар рухында тәрбияләнүе өчен генә дә түгел. Юк, бөтен иҗади үсеше белән башкорт халкына, аның кодрәтле авыз иҗатына, шигъриятенә бурычлы булган Башкортстан улы Нажар Нәҗми гомер буе татар халкына да, әдәбиятына, асыл шагыйрьләренә дә тугры дус, замандаш булды, татар халкы, татар теле өчен янып-көйде, авыр чакта, яклап, атаклы шигырьләрен язды, матбугатта чыгышлар ясады. Шагыйрьнең татар каләмдәшләренә багышлап язган «Дим буеннан хатлар»ы гына да бик күпне сөйли. Шулай ук Г. Тукай, Һ. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил, С. Хәким, К. Нәҗми һ. б. классик шагыйрьләребез, әдипләребез турында саллы мәкаләләрен, шигырьләрен искә төшерик. Соңгы елларда аның мондый характердагы истәлек-мәкалә, шигырьләреннән Н. Дәүли, М. Хөсәен, Г. Зәйнашева, Р. Фәйзуллин, Зөлфәт, Р. Миңнуллин һ. б. турындагылары безнең





журнал битләрендә басылды. Ә шигъри шәлкемнәре? Менә кырык ел инде ул, Мостай Кәрим, Сәйфи Кудаш кебек асыл исемнәр белән бергә, даими авторыбыз — шагыйребез булып санала һәм без моңа бик шатбыз. Мондый язмыш — тугандаш халыклар, әдәбиятлар, шигъриятләрнең уртак улы, сөекле әдибе булу — бик сирәкләргә генә эләгә торган бәхет ул...

Олуг гомер агышын күзаллау өчен без бу санда шагыйрьнең Казан, татар шагыйрьләре белән бәйле фоторәсемнәреннән берничәсен укучыларыбызга тәкъдим итәргә булдык.

Менә ул 1980 елның декабрендә — Хәсән ага Туфанның сиксән еллык юбилее көннәрендә, Нәкый ага Исәнбәтләрдә кунакта. Алар бу бәйрәмгә Сәйфи ага Кудаш белән килгәннәр иде. Мәҗлестә — Бакый Урманче, Әмирхан Еники кебек ил агалары, асыл кешеләребез һәм аларның хәләл җефетләре... Хәзер күбесе арабызда юк (иң әүвәл — юбилееннан соң ярты ел узгач — Хәсән ага китте... җәсәденә дә Уфадан Нажар ага килгән иде...).





Икенче сурәттә ул — 1986 елда, Тукаебызның 100 еллыгы көннәрендә, махсус телевизион тапшыруга, ул вакыттагы баш редактор Р. Миңнуллин чакыруы буенча килгәнендә. Бу тапшыруда алар — Сибгат ага Хәким белән икесе — шигърият, Тукай һәм халык язмышы турында озаклап сөйләделәр. Очрашу-тапшыруны редакциябездән мөхәррир — шагыйрь Р. Гаташ алып барды. Сурәт — шул кичәнең ядкаре..

Өченчесендә — Нажар ага үзебездә — редакциябездә кунакта. «Татар каны» исемле яңа поэмасын укып фикер алышабыз (1987 ел, апрель.)

Поэмасы бездә басылмады, ә сурәт калды. Анда төшкәннәрнең дә кайберләре арабызда юк инде... Гомер ага...

Дүртенче сурәт — чагыштырмача яңарак (1993 ел, май) төшелгән; ул — Төркия истәлеге. Бурса шәһәрендә узган төрки халыклар шигърияте фестивале көннәре. Нажар ага белән янәшә «Агыйдел» журналы (Уфа) мөхәррире шагыйрь Булат Рәфыйков, ә уңда — кырыйда — «Казан утлары»ның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин...

Гомер агышлары... Аның һәр мизгеле иҗат белән, халыклар һәм әдәбиятлар дуслыгы белән бәйләнгән. Һич арттырусыз, йөрәкләрне, шигъриятләрне ялгаучы асыл күпер бу иҗат! Шагыйрьнең, «соңгылар», дип безгә юллаган шигырьләре дә моны раслардыр, мөгаен...

# Нажар Нәҗми

## Сиксән тулганда

*...Нәрсә ул тән!*
М. Җәлил.

Ә бит нинди яшь булганмын икән
Илле, алтмыш тулган елларда.
Илледә ил гиздем, алтмышта да
Гашыйк идем әле кызларга.
Син,— диделәр,— һаман йөгереп бит
Йөрисең гел... Яшең җитмештә.
Тик, каһәрең, йөгерелми икән
Сиксәнеңне куып җитмештә...
Ә барыбер җан дигәнең йөгерек,
Җан — җан икән, һич тә тән түгел.
Нәрсә ул тән! Йөрәктәге утлар
Унсигезнекеннән ким түгел!
Яшьлек дигәнең дә кемгә кайчан
Ничек килеп, ничек китәдер.
Кем өчендер хәтта унсигездә
Яшьлек дигән мизгел үтәдер.
Бөекләргә генә хас микән ул
Иртә янып, иртә сүнүләр?
Озын гомер!.. Нигә кирәк икән
(Шигырь генә моңа сәбәп микән)
Шулай озак газап чигүләр?..

*1997*

* * *

Шагыйрьләргә хәзер илле, алтмыш...
Илһамлана җитмеш яшьле дә.
Күпме яшәп, җитә алсаң икән,
Җитсәң икән... Тукай яшенә!

*1996*

* * *

Үтәр... Үтәр... Барысы да үтәр...
Фани дөнья түгел мәңгелек.
Өметне бит иң соң үлә, диләр,
Нәрсә үлә икән иң элек?

*1997*

## Гаяз Исхакый

# ИКЕ ХИКӘЯ



*Гаяз Исхакый иҗаты хәзерге татар укучысына аз таныш. Моның сәбәбе аның әсәрләренең җитмеш еллап вакытта кат-кат бастырылмавында гына да түгел, бәлки, моңа өстәп, язучының элек тә үзебездә һәм соңрак чит илләрдә нәшер ителгән китапларның хәтта укудан тыелуында. Ниһаять, 1991 елда Татарстан китап нәшрияты олы әдипнең сайланма чәчмә һәм сәхнә әсәрләрен «Зиндан» исемле калын ук җыентык итеп чыгарды. Һәм шуның белән Г. Исхакый китапларын укучыга кайтару мөмкин булды, диярлек. Югыйсә әдәбиятыбыз корифееның гаҗәеп бай иҗатын укучыларга тулысынча җиткерү моңарчы сузылмас иде. Ә аның иҗаты чын мәгънәсендә киң колачлы һәм күпкырлы. Бу Г. Исхакыйның 1951 елда үзе төзегән библиографик исемлегеннән (галимнәр искәртүенчә, бу озын исемлек тулы түгел) ачык күренә.*

*Түбәндә без татар әдәбияты баһадиры Гаяз Исхакыйның ике хикәясен, аның туусына 120 ел тулу уңаеннан, журнал укучыларына тәкъдим итәбез. «Шәкерт абый» хикәясе Истанбулда 1911 елның 11—12 июнендә язылган, 1912 елда әдипнең сигез томлыгында басылган «Зиндан» җыентыгына да кертелгән. «Хәлимә туташ» хикәясе исә, галим Ибраһим абый Нуруллин язуынча, беренче тапкыр Г. Исхакыйның 1909 елгы «Җыентык» китабында дөнья күргән. Шуннан соң бу әсәр 1993 елда гына «Ватаным Татарстан» газетасында (23 февраль) басыла.*

*Шушы ике хикәя үк әдипнең әсәрләренең тематикасына һәм язылыш рәвешенә (өслүбенә, манерасына) бик игътибарлы булуын раслый, безнеңчә. Беренче хикәя ике кешенең әңгәмәсе рәвешендә язылса, татар хатын-кызларының хокуксызлыгы турындагы икенче хикәя, гәрчә Г. Исхакый вакыйганы тасвир итү рәвешен сайласа да, аның герое Хәлимә туташның монологына, бу очракта үз хәлен үзенә сөйләвенә тартым. Шунысын да искәртик, икенче алым дөнья әдәбиятында күптән кулланыла (соңгырак чорда без мондый алымны күренекле язучы Владимир Набоковның кайбер хикәяләрендә очраттык), әмма язучының яңалыгы тасвирны эчке монолог белән оста ук үрә белүендәдер.*

*«Шәкерт абый» хикәясе югарыда аталган «Зиндан» җыентыгыннан, «Хәлимә туташ» хикәясе «Ватаным Татарстан» газетасыннан үзгәртелмичә (кечкенә орфографик төзәтүләрдән тыш) алынды.*

Әсәрләрне журналда бастыру өчен **Мәгъсүм ХУҖИН** әзерләде.

— Сафа мөәззинне, ахирәт, куып чыгаргансың дип сөйлиләр. Кыз сорарга килгән кешене шулай итәргә ярыймыни?— дип, Гөлҗамал абыстай үзенең ахирәте Гайнижамалга сөальле иттереп карады да чәйне ясарга тотынды.

Самавыр чыжлавы астында Гайнижамал абыстай, уйга калган кеби:

— Шулай иттем шул, ахирәт,— диде дә туктады.

Гөлҗамал абыстай, ишек төбендә борынын пышкылдатып, әбисенең бер нәрсә биргәнене көтеп тора торган килененең угылына күмәч кисәге илтергә бара-бара:

— Ник алай иттең, ахирәт, яхшы җирдән килгәндер бит? Кызыңның бит, әлхәмделилла, яше җиткән. Кызлар бит бу елда егермедән үтсә картка исәпләнә башлый,— диде дә борылып кайтып:— Чын, ник куып чыгардың?— диде.

Гайнижамал абыстай:

— Мин шул мәхәббәтсез мөәззинне яратмыйм!— диде дә тагын туктады. Гөлҗамал абыстай ахирәт дустының күзенә керергә теләгән кеби вә, кереп, шуның эчендә серне күрергә теләгән кеби иттереп карады. Шул күз карау астында Гайнижамал абыстай бераз кызарып та китте. Ул, ахирәт дустының шул сүзсез сөаленә җавап биргән кеби:

— Була бит шундый, кайсы кешене пәриең сөйми,— диде дә, алдаганыны үзе дә белгән кеби, тагын кызарды.

Гөлҗамал абыстай:

— Бу бит кеше аңларлык түгел. Үзе сезнең шактый якын карендәш тә түгелме соң? Андый-мондый эш булган дияргә, ул — бала-чага атасы, син — тагын, Әлхәмделилла, угыл-кыз җиткергән кеше. Юк, ахирәтем, син миннән әллә нәрсә яшерәсең. Ахирәт шулай буламыни? Ахирәттән серенне яшерергә китап та кушмаган, диләр. Бир чынаягыңны, чәй тәмсез түгелдер бит? Әле карт моны яңа чәй дип алып кайтты,— диде.

Гайнижамал абыстай:

— Юк, ахирәт, юк, синнән нәрсә яшерим! Яшерерлек эш юк...— диде.

Аның сүзе тәмам итәргә бирмәенчә, Гөлҗамал абыстай:

— Югын юк та, куып чыгаргансың. Баш коданы куып чыгарыр өчен, ахирәтем, миннән яшерәсең яшерүен дә, бик зур сәбәпләр булырга кирәк, бик зур сәбәпләр,— диде.

Гайнижамал, чәене бераз эчкәннең соңында:

— Мин шул, шул мөәззинне күрәсем килми. Яшьтән күңелем җәрәхәтләнеп калган! Шуның өчен, шул, чыдый алмадым.

— Ни булды соң, ахирәт?

— Юк, булуын бер нәрсә дә булмады... Ничек сөйләргә дә белмим инде, сөйләрлеге дә юк... Ярар инде, ахирәтем, шулай калсын, сөйләтмә инде.

— Сөйләргә теләмәсәң сөйләмә, ахирәтем. Мин ахирәтеңнән яшерерлек зур эш бардыр дип белми идем.

Шул сүзнең артының шөбһәле бетүе Гайнижамал абыстайны бераз кызартып, уйга калдырды. Ахирәтенең шөбһәсе аның бер яктан ачуыны китерде, бер яктан хурландырды. Ярты ачуланган тавыш берлән ул:

— Ярый, алай булса, сөйлим, ахирәт, дәртең почмаклансын,— диде.— Югары оч янмас борын, безнең әтинең йорты хәзерге Галәү тегермәненә чыга торган тыкрык буенда иде. Артымыз суга төшкәнгә, су буенда әни мәрхүмә, әллә никадәр түтәлләр ясап, кыяр, кишер, чөгендер, кәбестә утырта иде. Тыкрыкка каршы ягында, әнә хәзер таллар бармы, шулар урынында, безнең әтиләрнең мал-туар йорты иде. Былтыр Әхмәтсафаның кәҗәсе төшеп үлгәч күмелгән кое — ул безнең бабайдан калган кое иде. Ул вакытта бөтен авылда суының тәмлелеге, суыклыгы берлән дан тоткан иде. Урак өстендә уракка китүчеләр, су алыр өчен, юлаучылар кеби тезелеп көтеп торалар иде.

Безнең әтиләр, бай булмаса да, таза иде: чиләк-чиләк балымыз үзелми, он-тоз өсәгенең[1] түбе күренми иде; мал-туар күп, ашлык мул иде. Заманасымы башка иде, ахирәт, җиреме башка иде, һәр елны ашлык җимерелеп үсә иде. Һәр елны кар төшәр алдыннан гына көчкә-көчкә генә кырдан керәләр иде. Кыш буе хатын-кыз киндер, алача[2] суга; кызлар тугый[3], челтәрле иде. Мәдрәсә ул вакытта да бар иде. Ләкин хәзерге кеби калай башлы түгел; әнә хәзер Миңлевәлиләрнең мунчасы бармы, әнә шуның урынында!.. Хәзрәт үзе дә укыта, хәлфә дә китертә иде. Ләкин, хәзерге кеби, кызлар сабакка йөрү юк иде. Әллә күрше авылларда булгандыр да, ләкин безнең хәзрәтнең остазбикәсе андый түгел иде. Мәрхүмә, Алла разый булсын, китап сөйләгәндә дә хәзрәтеннән өйрәнеп чыга, диләр иде.

Менә мин сигез-тугызга җиткәндә беркөнне безгә бер егет килде. Мин әле ул вакыт — яланаяк чабып йөри торган бала! Аңардан әни дә качмады, җиңгиләр дә качмады. Ул вакытларда бит әле муллалардан, каенаталардан гына качалар иде. Безнең җиңгиләр аңар «Шәкертҗан агай» дип тә йөри башладылар. Менә, ни булгандыр, ул егет мәдрәсәгә күчте. Кайдандыр, хәтеремдә калган, ул безнең әтиләрнең якын карендәшләренең угылы икән дә безнең авылның мәдрәсәсенә хәлфә булып килгән икән. Егет һәр көнне кеби безгә килә башлады. Таба ашы пешерелдеме — ансыз ашалмады; кунак-төшем булдымы — ул чакырылмыйча калмады. Әни аңар «Шәкерт» дип йөргәнгә, җиңгиләр «Шәкертҗан агай» дип йөргәнгә, мин: «Шәкерт абый» дип йөри башладым.

Безнең әти ашлы-сулы кеше булганга, безнең әнинең кабартмасы, коймагы, кыстыбые, бәлеше, кулламасы данлыклы булганга, кунактан өзелеп тормый идек: шәһәргә бара торган мулла бездә кич кунып китә, базарга бара торган мөәззин бездә ат ашата иде. Ил-көн дә бай булганга, туйлар да хәзерге кеби түгел иде: коданы бер атна сыйлыйлар, кода булып бер атнага баралар иде; туйга куелган бал, сыра бөтен авылга эчерелә иде. Дөньясы ук ул вакыт, ахирәт, башка иде. Безнең җиңгиләрнең әнигә ләм-мим дип әйткәннәрене ишетмәдем. Хәзер безнең киленнәр берлән сөйләшеп кара! Бер сүзеңә ун җавап табарлар.

— Шулай, ахирәт, шулай. Әле бит яшь киленем каен сеңлесе берлән орышышырга тотынган. Кайчан төшкән, кайчан килгән бит, орышышырга өлгергән. Бу ел, ахирәт, аналарының сөте берлән үк явызлыкка өйрәнәләр.

— Шулай, ахирәтем. Менә, шулай итеп, бу шәкерт абый безгә ияләште. Аны һәммәмез яраттык. Мунча яккан көнне аны мунчага чакыра идек тә мунчадан соң ул имам торып әтигә намаз укыта иде. Намаздан соң сузып кына Коръән укый иде. Без һәммәмез бик ихлас берлә тыңлап тора идек; бергә дога кыла идек. Күп вакытта әти шуннан соң аңа сәдака бирә иде; әни һәйбәт май берлән чәй эчертә иде. Мин берδәнбер кыз булганга, билгеле, иркә идем; самавырның янына гына килеп утыра идем дә чәй эчә идем. Шәкерт абый миңа май бирә, күмәч бирә, мине сыйлый иде. Ул мине сөя, мине ярата иде. Беркөнне ул минем курчакларга аллы-гөлле, алтынлы-көмешле кәгазь берлән бик матур, кызыллы-аллы, кош төсле пәрәннек тә китерде. Аның пәрәннегe әллә ничә айга кадәр курчак кунагы уйнарга җитте. Мин аны һәрвакыт курчак уйнаганда, кыз биргәндә генә бирә торган аш иттереп йөртә идем. Менә беркөнне карт җиңгиләрнең агалары кунакка килде. Анларның миннән бер-ике яшьлек кечкенә генә угыллары бар иде. Ул, малай булса да, кызлар арасында үскәнгә, курчак уйный белә иде. Менә без аның берлән курчак уйнадык, кунакка чакыры-

---

[1] Өсәк — келәттә ашлык, он һ. б. ш. саклау өчен бүлеп ясалган урын яки зур әрҗә; ашлык бурасы.

[2] Алача — төрле төстән буй-буй сугылган киндер (күбесенчә актан һәм кызылдан сугыла); буй-буй итеп сугылган палас, келәм.

[3] Тугый — тугу, туку.

штык, кыз бирештек. Иртә берлән мин торсам, перәннек юк. Мин жыларга тотындым. Әни килде, жиңги килде; теге малайны кыйнадылар; ләкин перәннек кайтмады. Мин балавыз сыгып утырганда, менә теге Шәкерт абый килеп керде. Ул, минем ни өчен жылаганымны белгәч тә, элгәре перәннекнең шулкадәр озакка баруына исе китте. Аннан соң ул чыгып китеп, бераз торып, миңа тегенәрдән дә матур бер перәннек китерде. Шуннан соң мин аны сөя башладым; аңар ияләштем, үзләштем. Ул да, шуны сизепме, килгән саен курчакларның хәлләреннән сораша, перәннекнең нишләвене белешә башлады.

Мин перәннекне ашамый килсәм дә, беркөнне әллә нигә бик тәмле төсле күренгәнгә, кырыеннан, тычкан кимергән кеби генә, каптым. Авызыма әллә нинди хуш ис керде; тел өстемдә перәннек эреде. Авызымнан шул тәмне бетермәс өчен, тагын аз гына каптым. Авызым тагын тәмләнеп китте. Никадәр авызымнан шул тәмне бетермәс өчен тырышсам да, тагын теге тәм бетте; тагын кабарга туры килде. Шулай аз-аз гына каба-каба, карасам, перәннек яртыга калган. «Моның берлән нишлим?» — дидем дә ашап бетердем. Үзе егылган бала егъламый, диләр, перәннек кызганыч булса да, әни орышыр, дип егъламадым.

Менә берәр атна вакыт үтмәде — Шәкерт абый минем перәннек беткәнне белде. Ул:

— Кая китте, кая? — диде.

Мин кызардым. Ул, аңлады булырга кирәк, миннән сорап тормады, тагын перәннек китерде. Безнең дустлык тагын ныгыды. Мин курчак уйнаганда, үксез балаларны ашата торган, орышышкан кешеләрне килештерә торган «Шәкерт абый» атлы тагын бер курчак керттем. Туйларда, мәҗлесләрдә аннан яхшылыклар кылдырдым.

Менә беркөнне әти хәзрәтләрне чакырды. Ул вакытта хәзрәт, мәрхүм, Аллаһе Тәгалә разый булсын, Шакир хәзрәт иде. Мин дә шунда булганмын ахры, ансыны рәтләп белмим, ахырдан гына хәзрәт: «Шәкерт абыйсыннан сабак укырга ярый, язу гына өйрәнмәсен»,— дип әйтә, диделәр. Мине: «Сабак укый, Шәкерт абыйсыннан сабак укый»,— дип сөйли башладылар. Һәммә кешенең кызыгып сөйләгән шул сабак уку мине бераз һаваландырды. Сабак укуның нәрсә икәнене белмәенчә генә, мин шул көнне көтә башладым. Ул вакытларда хәзерге кеби түгел, сабак чын сабак иде. Хәзерге безнең киленнең балалары кеби: «Арба, чана, сука, тырма» укымыйлар иде, китап укыйлар иде. Шуның өчен, хәзерге кеби, авыл сатучысында, мәктәптә ул китап юк иде; шәһәргә барырга кирәк, аннан алырга кирәк иде. Менә китап та булды. Мин сабак башладым. Курчак дәрте бөтенләй сабакка күчте. Мин көне-төне укый башладым. Белмәгәннәремне сорап, әни-жиңгиләрнең башыны әйләндерергә тотындым. Минем сабак бик алга китте: өч-дүрт айда иҗекне сукалый башладым. Икенче елны Коръән укып «Йосыф китабы»на кердем. Өченче ел укысам, бәлки, хәзерге мулла хатыннарыннан ким булмас идем, Шәкерт абый, укырга, дип шәһәр мәдрәсәсенә китте. Мин, житешлегем аркасында язу танып калсам да, мәгънәле китапка керә алмадым. Тагын мин курчакка кайттым, тагын курчак уенына баттым.

Ләкин Шәкерт абыйны һичбер вакыт онытмадым: көтүдә кызлар берлән сугышсак, бәпкә каравыллаганда карга бәпкәне урласа, әни кыйнаса, һәрвакыт мин Шәкерт абыйны хәтерли идем; аңар сыгына идем. Миңа, ул булса, кызлар кыйный алмас, карга бәпкәне урлый алмас кеби тоела иде.

Менә, шулай итеп, бер-ике ел үтеп китте. Мин унбер-уникегә җиттем. Беркөнне (көз иде) бөтен авыл Дөбрән[1] Хәяты әкиятене сөйли башлады. Дөбрән Хәятыны син белмисең. Әнә, Жиһанша бармы, тимерче Жиһанша? Шуның сеңелесе, шул кыз диләр иде. Әниләр, жиңгиләр миңа нәрсә булганыны әйтмәсәләр дә, кызлар берлән үзем барып карадым: аның

[1] Дөбрән — саңгырау. *(Г. Исхакый искәрмәсе.)*

капкасыны буяганнар иде. Без барганда бөтен урам бала-чага белән тулган иде, мин нәрсә икәнене, ни өчен буялганыны белмәсәм дә, шундагы кызлар: «Уйнаш иткән!» — диделәр. Берсе:

— Уйнаштан бала тудырган! — диде.

Шул арада булмады — авылның ул вакыттагы куштаны Хәмид карт, әллә кемнәр берлән килеп:

— Ул нинди оятсызлык! Урамда йөртергә кирәк! Бөтен кырлар кипте, мал-туар өшәнде; бар да шуларның гөнаһ шомлыгы! — диде.

Кызлар:

— Менә урам буе йөртәләр, Дөбрән Хәятыны кара корымга буйыйлар да: «Уйнаш итмә, уйнаш итмә!» — дип урам буенда йөртәләр; бөтен ир, хатын аның йөзенә төкерә. Аннан ары мәсҗед алдына китереп суктыралар; мулла абзый үзе суктыра, — диделәр.

Җиңги берлән суга барганда күргән Дөбрән Хәяты минем күз алдыма килеп басты: зур, таза, матур, ачык, бербуйдан көлә торган Хәят хәзер, кара корымга буянгач, коточкыч күренде; дөнья анасы кеби тоелды. Җылыйсы килү куәте никадәр көчле булса да, мин куркуымнан җылый алмадым.

Өйгә кайттым. Әни, мине күргәч, ни өчендер:

— Алла Тәгалә тәүфикъ бирсен, — диде.

Бөтен көн шуның куркусы берлән үтте. Көтүдә бөтен кызлар шуны сөйләделәр; малайлар Дөбрән Хәятының бәетене җырладылар. Көтү керер алдыннан гына ягъмур ява башлады. Көтә-көтә арып беткәннең соңында берсе: «Көтү түбән очтан керде», — диде. Барымыз да җылаша-җылаша киттек. Барымызга да менә Дөбрән Хәяты корымга буялган көенчә чыгар да алдымызга басар кеби тоелды. Курка-курка, бер-беремезгә тотынышып, сарылышып чабыштык. Кояш баеп, күзге төн караңгылана башлаганда гына мин, ике сыерны табып, өйгә кайттым. Өйдә абзыйлар, җиңгиләр шалкан кисеп кайткан булганга, шалкан ашарга утырдык: элгәре чи шалкан ашадык, аннан ары әни пешкән шалкан кертте. Мин һәрвакыт пешкән шалканны яратам. Ул көнне бигрәк сөеп ашадым.

Күзге вак ягъмур бөтен дөньяны каплап алды. Мин җиңги берлән тышка чыкканда күзгә төртсәң күренмәс төндә тагын котым очты. Җиңгинең кулына тотынып кына, кычкыра-кычкыра, көчкә өйгә кердем. Миңа шул караңгы төн тагын Дөбрән Хәятыны исемә төшерде. Менә ятарга вакыт җитте. Әни миңа үзләре берлән берочтан түргә урын салды. Мин чәчемне сүтәргә өлгермәдем, урамнан тәрәзә кактылар. Мин куркынып киттем. Күз алдыма тагын Дөбрән Хәяты килеп басты. Ул да булмады, капка ачылды, йортның шул дөм караңгысыны көчкә генә ерып-ерып, фонарь йөри башлады. Озак үтмәде, минем алдыма өстеннән су ага торган Шәкерт абый килеп басты.

Самавыр куелды, яңа шәмнәр ягылды. Өй яктырып, җылынып китте. Минем күңелемнән дә Дөбрән Хәятының хикәясе чыкты.

Әти-әни аны бик кадерләп каршы алдылар:

— Өшегәнсең, туңгансың. Явымы да бит үзегенә үтәрлек, тизрәк тишен, тизрәк, — дип чишендерделәр, юындырып чәй янына утырттылар.

Минем йокым качты. Шкаф артына сөялеп кенә Шәкерт абыйны карарга тотындым. Аның күзләре үзгәрмәгән булса да, һаман әле көлгәндә күзләре югалып китә торган булса да, аның йөзе шактый үзгәргән иде. Бездән киткәндә кечкенә генә чыгып килә торган мыегы зурайган, сирәк кенә сары йоннар аның сакалыны бөтенләй каплый язган, битенә дә әллә нинди, мин танымый торган яңа төс чыккан иде. Кечкенә чакта, беләсең бит, ахирәт, балалар бик тиз үпкәләүчән булалар, мин дә шулкадәр сөйгән Шәкерт абыемның миңа илтифат итмәвенә үпкәли башладым. Аны эчемнән генә: «Нинди мәхәббәтсез, бу минем Шәкерт абыем түгел, бу башка», — дип уйлый башладым. Ни өчендер, җылыйсым килде.

Җил берлән тәрәзә шакылдап китте. Минем күз алдыма тагын Дөбрән Хәяты килеп басты. Мин дерелдәп, каушап киттем. Шуны күрепме, әти берлән бик тәмле сөйли торган Шәкерт абый:

— Син дә мондамыни, Гайниҗамал? Кил әле монда, кил! — диде.

Минем ачуым бердән язылды. Шәкерт абый, минем баштан сыйпап, күземә карап торганның соңында: «Зур булган инде»,— диде. Әни дә:

— Утыр, кызым, чәй эчәмсең? — диде.

Мин әнигә «ию» дигән күз берлән карадым. Безнең әни, мәрхүмә, үзе каймаксыз чәй эчмәгәнгә, һәр кешегә каймак салып ясый иде. Шуның аркасында әти: «Чәйнең тәмене бозасың, затсыз!» — дип, үзене һәрвакыт тирги дә иде. Чит кунак-фәлән булса, әти, әнине чакырып алып:

— Каймак салып ясама! — дип әйтеп тә куя иде.

Ләкин, нидәндер, әни әти мәрхүмнең сүзене тутыра алмый иде — һаман каймаклы ясый иде.

Бүген дә шулай булды. Ул вакытлар, беләсең бит, ахирәт, хәзерге кеби, әллә нинди канәфер тәмнәре килә торган чәй юк иде: кара, ак койрыклы чәй иде. Аңа каймак салу, билгеле, шуның нечкә тәмене боза иде. Менә әни миңа да каймаклап ясап бирде. Алдыма зур кашык бал куйды. Мин Шәкерт абыйның сүзләрене тыңлый-тыңлый эчкәнемне дә сизмичә калдым. Ул үзенең хәзер әллә кайдан ерактан кайтуыны сөйли, әллә нинди мөфти хәзрәт берлән күрешүне аңлата иде. Әти шуларның һәммәсенә дә: «Шулай диең, шулай диең!» — дип авызыны ачып тыңлый иде. Ул вакытта мин нәрсә икәнене, кайдан кайтканыны аңламасам да, ул — Шәкерт абыйның мөәззин булыр өчен имтиханнан кайткан вакыты икән! Бердән соң әни миңа тагын берне ясап бирде. Беләсең, балаларга кич чәйне күп эчерү файдалы түгел: йокылары кача, төрле эшләргә сәбәп була. Әни шуны оныттымы, ул миңа өченче чынаяк та ясады. Мин, боларның мәҗлесләреннән калмас өчен, әнидән, «Бар инде, кызым, ят!» дидертмәс өчен, һаман эчтем. Менә чәй бетте. Шәкерт абый мине тагын чакырып алып, башымнан сыйпап:

— Йә, сабак кар астында калдымы? Онытылып беттеме? — диде.

Мин бер сүз әйтмәдем. Әни: «Юк, юк, онытылмаган»,— дип өлгермәде, әти:

— Бар әле, кызым, китапларыңны китер әле, Шәкерт абыең тыңласын әле,— диде.

Мин китеп, Коръәнемне алып килдем. Ачып, кычкырып, әгузе бисмилла әйтеп укыдым. Үземнең Коръән укый торган тавышым үземә ишетелеп, үземнең элгәреге хәлләремне исемә төшерде. Минем күз алдыма Шәкерт абыйның биргән перәннеге күренә башлады, аның тәме авызымда уйный башлады. Мине әллә нинди шатлык биләде. Шәкерт абый: «Онытмаган, онытмаган»,— дип мине бик мактады. «Менә, шәһәрдән кайтсам, үзеңә перәннек алып кайткан булыр идем»,— диде дә кесәсеннән әллә нинди акча савыты чыгарып: «Менә, шуңар сатучыдан перәннек алырсың»,— дип зур бер тиен ярымлык бирде. Мин, сөенә-сөенә алып, курчак сандыгыма салып куйдым. Шуннан соң мине яткырдылар. Мин йокы арамда гына Шәкерт абыйның Коръән укыганыны ишетеп күземне ачсам, әти берлән анларның намаз укуларыны, әнинең түргә әтигә бер урын, Шәкерт абыйга бер урын салганыны күрдем. Тагын йокыга киттем.

Менә, төшемдәме, көнемдәме, Дөбрән Хәятыны күрә башладым. Ул ялан өс басып тора. Судан мунчала алып чыккан кеше кеби, аның бөтен битене, тәннәрене кара бака яулыгы каплаган, йөзләреннән кара, куе, сазлы су ага; үзе авызыны ачкан да тешене ыржайтып көлеп тора. Мин аңардан куркам: «Әни! Әни!» — дип кычкырам, бакырам, качмакчы булам: ләкин аягыма тимер таккан кеби, атлый алмыйм; атласам, алга бара алмыйм. Ул миңа таба килә; минем котым оча; ул мине кочакламакчы була. Кочаклый! Аның кулы берлән минем бөтен тәнем кысыла... Аның тәненнән ага торган кара су миңа тама башлый. Аның өстенә

ябышкан кара бака яулыгы миңа ябышмакчы була, җанлы кеби, миңа таба сузыла. Мена ул минем корсагыма килеп ябышты... Аның суыклыгы минем ботларыма кадәр агып китте... Минем йөрәгем ярылды... Тагын кычкырмакчы булдым. Кычкырдым да, ләкин минем тавышыма беркем дә килмәде. Ул салкын бака яулыгы әле минем корсагыма, әле минем бот араларыма кереп йөри башлады. Тагын икенче берсе муеныма ябышмакчы булды... Мин куркуымнан тагын бик каты кычкырып җибәрдем. Үз тавышымнан үзем куркынып уянып киттем.

Уяну берлән, корсагымнан түбәннән сәнәк тармакларыны араландырып ята торган авыр, зур бер нәрсә бар икәнене сизендем. Куркуымнан күз ачып күз йомганчы йокым ачылды. Күзге айның нуры берлән яктырган өйдә, күршемдә сузылып ятып, миңа таба борылган Шәкерт абыйны, аңардан ерак түгел генә «мыш-мыш» йоклый торган әтине күрдем. Шуларны күрү берлән, шул минем корсагыма, бот арама салынган япьле нәрсә Шәкерт абыйның кулы икәнлегене күңелемә төшерде. Мин аның авыр кулыны алып ташладым. Ул «лап!» итеп идәнгә барып төште. Шуның тавышы берлән минем башым эшләргә тотынды, «уйнаш» дигән сүз колагыма килеп керде... Мин, алай булгач, уйнаш иттем, Дөбрән Хәяты кеби уйнаш иттем; иртәгә безнең дә капканы буярлар, миңа да «бәет» әйтә башларлар...

Шул уйлар мине куркытканнан куркытты... Хәзер мин үземне кара корым ягылган көенчә урамда йөретәләр кеби күрә башладым. Үземне кара бака яфраклары берлән ялан тән өстенә сыланган кеби сизә башладым. Шул хурлыкка ничек чыдарга?.. Мин бер минутта тирләдем, пештем; шабыр суга баттым. Мена гомеремдә күрмәгән рәвештә эчем борып-борып авыртырга тотынды. Минем күңелемә: «Уйнаштан бала табам икән»,— дигән уй керде... Шул уй шулкадәр башыма утырды — мин, җиңги бала тапкандагы кеби, көчәнеп-көчәнеп кычкырасым килә башлады. Кычкырырга дигәндә генә әти-әни исемә төште. Мин җир ярылса җиргә керерлек булып оялдым. Шул хурлыкны күрмәс өчен үләсем килә башлады. Алладан, бөтен белгән догаларымны укып, үләргә тели башладым... Эчем басылмады. Дога кабул булмады. Минем ачуым килде: «Үлим, әнә күрше Әхмәтҗанның чәчәктән үлгән кызы кеби үлим!» — дип уйларга тотындым. Ләкин һаман үлмәдем — үләргә юл таба алмадым. Әнә, былтыр, безнең бер сарык кизләүгә төшеп үлгән иде... Мин дә төшсәм үлерменмени?.. Мин үземне үзем кизләүгә төшкәндә битенә, тәненә әллә никадәр кара бака яфрагы ябышкан иттереп күрдем. Минем эчем «жу-у-у!» итеп китте, тәнем калтырарга тотынды; эчем тагын борып-борып авырта башлады. Мин: «Хәзер менә кечкенә генә бала тудырам, уйнаштан бала тудырам»,— дип тагын котым очты. Акыртын гына торып, әти-әнигә белдермәенчә генә, чыгып китмәкче булдым. Тордым. Идәннәр шылтырады, тәрәзәгә бәрелә торган җил моңлап сызгырды. Әллә кая әтәч кычкырды; аның артыннан тагын берсе, тагын берсе! Мине тагын курку биләде... Аяк атлый алмадым. Барып урыныма ятарга теләдем. Анда Дөбрән Хәяты ята кеби тоелды. Мин аның тәннәрене, кулларыны — һәммәсене күрдем. Мена тагын эчем борырга тотынды. Миңа бала — уйнаш баласы хәзер чыга кеби күренде. Мин баланың ничек туганыны белмәгәнгә, баланы тудырмас өчен, ике кулым берлән корсагымны басып тордым. Тәнем дер-дер калтырап, суыклык сизгәнгә, шундагы түшәккә сөялдем, ышкындым.

Уянып киткәндә көндез булган иде. Самавыр чыж-чыж кайный, кунакка дип коймак пешә иде. Өйдә беркем дә юк иде. Менә әллә кайдан Шәкерт абый тавышы колагыма чагылды. Шул тавыш башымдагы буаны ерып җибәргән кеби булды. Күз алдыма берсе артлы берсе төнге эшләр килә башлады. Мин, бала табып-тапмаганымны белер өчен, корсагымны капшадым. Ярылган җире юкка, тапмаган икәнмен, дип аллага шөкерләр әйтергә өлгермәдем, «бәлки торгач табармын» дигән фикер

башыма килде. Тагын оят мине каплап алды. Әти-әни белән Дөбрән Хәяты күз алдыма килеп басты...

Менә Шәкерт абый белән әти килеп керде. Мин, йоклаганга салынып, керфек арасыннан гына карадым. Ул хәзер бөтенләй үзгәргән, элгәреге Шәкерт абыйга аз гына да охшамый. Әнә быелтыргы ат урлап тотылып урам буенда йөртелгән карак төсенә кергән. Мин аның борылганыны гына күттем дә, чабып торып чыгып киттем. Әти дә, борылып карап:

— Кызым, ни булды? — диде.

Теге өйгә дә кермәенчә абзарга чыктым. Бик озак эчемне карадым. Бала туу галәмәте күренмәгәч, бәлки, әти-әни белмәс, дип, азрак нығыдым. Ләкин өйгә таба борылгач та, тагын менә әни күрер дә, уйнаш иткәнемне белер кеби тоелды. Мин тагын кизләүгә төшмәкче булдым. Ләкин аның суы бик суыктыр кеби күренгәнчә, арт капкадан җиңгинең сәнәкләр, тырмалар, көрәкләр күтәреп ындырга киткәнене күреп, аның артыннан киттем. Анда да, анлар янына бармаенча гына, саламда яттым. Кибәннәр арасына барып, берничә мәртәбә эчемне карадым.

Ашыйсы килгәнгә, абзыйлар белән ашарга кайттым. Йортка якынлашкан саен, теге качкынны күрмим, дип курка башладым. Менә капкадан керсәм, ул атка утырып маташа...

— Ә, Гайниҗамал, кил монда, кил! Хуш, сау бул! — диде.

Мин куркып киттем. Аннан ары ачуым килде. Аңар күземне акайтып карадым; ул кызарды.

Шуннан чабып кереп киттем. Әнинең: «Ник Шәкерт абыең белән күрешмәдең-фәлән»,— дигәнене тыңламаенча, мин, курчак сандыгындагы бер тиен ярымны алып, кизләүгә илтеп ташладым. Ул су төбендәге имләп салган җиде төенле чүпрәк янына барып төште. Ул тоньк суда ялтырап киткәнгә, мин итәгем белән бик күп туфрак җыеп килеп, суга ташладым. Анлар сөйләшә-сөйләшә суга төшеп киттеләр. Су болганды, акча югалды. Ләкин болганган су тагын Дөбрән Хәятыны исемә төшерде...

Мин артыма карый-карый өйгә кайттым. Шәкерт абыйны күрүдән курыкмаганга, өйгә батыррак кердем. Ашарга утырдым. Ләкин эчем тагын авырта башлады. Әни: «Көне-төне шалкан ашыйсыз да...» — дип тышка чыгарды.

Көннәр, еллар үткән саен шул вакыйга хәтердән югалды. Зурая төшкәч, үзем дә шуннан көлә башладым. Ләкин мөәззингә дошманлыгым һаман кимемәде. Аны төшләремдә күреп куркып уянуым әлегә кадәр бетмәде.

Аннан, шунсы кызык, ахирәт, менә шул бер тиен ярымлык та һаман мине ташламады; әллә теге имле чүпрәк янына төшкәнгәме, бер-бер кайгы булырга булса, бер-бер кәефсезлек булса, гел шул бер тиен ярымны төшемдә күрмичә калмадым: йортымыз янганда да шуны күрдем; картым үлгәндә дә күрдем; караклар йортымызны басканда да күрдем,— диде дә туктады.

Гөлҗамал абыстай сузып кына:

— Алай икән, ахирәт! — диде.

*1911.*

## Хәлимә туташ

Хәлимә туташ уянып киткәндә көн бик иртә иде. Камыш пәрдә аша үтә торган кояш нуры да, әле көнгә өйрәнмәгән кебек, көннән оялган кебек кенә, зәгыйфь кенә яктылык берлә бүлмәне яктырта иде. Пәрдә аша синдин салкынчарак чык исе керә иде.

Бер тәрәзәдән ерак кына чишмәләрнең чакырулары ишетелә иде. Тирә-яктагы тынычлыкны сирәк-сирәк кенә мөгри торган сыер тавышы да бераз боза иде.

Хәлимә туташ, акрын гына торып, тәрәзә янына килде, тавышсыз гына иттереп камыш пәрдәне күтәрде. Тыштагы салкынрак кына бакча һавасы, ашыга-ашыга, Хәлимә туташның бүлмәсенә ага башлады.

Ул тәрәзә төбенә утырып, тирә-якны карарга тотынды. Зур каен агачы үзенең ярты шар кебек түгәрәк яфраклары-ботаклары берлә генерал алдында басып тора торган Никольский солдат кебек селкенмәенчә-нитмәенчә тора иде. Өске яфраклардагы энже бөртекләре кебек чык тамчылары яңа иртәнге кояшта ялтыр-йолтыр итеп каенның матурлыгын арттыралар иде.

Аннан ары гына шомырт агачы үзенең зимруд кебек яшел яфраклары берлә үзенең түм-түгәрәк, ямь-яшел ачылган шомыртлары берлә, үзенең өстенә тезелгән энже бөртеге чыклары берлә каеннан да матуррак күренә иде. Ул туйга зиннәтләнгән хатын кебек киенеп-бизәнеп, үзенең сөйгәнен көтә торган кыз кебек, селкенмичә-нитмәенчә тора иде. Аның янындагы акация агачы да үзенең башыннан-аягына кадәр сары чәчәкләргә буялып, янындагы һичбер агачка илтифат итмәенчә, үзенең матурлыгы, үзенең сафлыгы берлә ләззәтләнгән кебек була иде. Аның артында тагын шундый агачлар, тагын шундый чыкка буялган яфраклар, тагын төрле төстәге чәчәкләр күренә иде. Алар артындин көзге кебек тип-тигез тора торган күл дә гүя йоклаган кебек, аз гына да селкенмәенчә үзенең бар буена сузылып яткан иде. Аның теге ягында алалы-сорылы бар да тып-тын гына тора иде. Йирдәге үләннәр дә, өсләренә төшкән чыкларны күтәрә алмаенча, бер якка сыгылып кына, берсе өстенә берсе сөялеп йоклаган кебек, тик торалар иде. Һәммә йир тыныч, һәммә йир моң, һәммә нәрсә хәл җыя, һәммә нәрсә киләчәк озын көндә эссе кояш берлә тартышырга хәл хәзерлиләр кебек күренә иде.

Менә акрын гына җил исте. Күлнең көзге кебек шома өсте шадраланып китте, агачларның тик тора торган һавалы яфраклары да бер-берсенә җырлашып, үзенә бер төсле матур гына тавыш чыгара башладылар. Энже бөртеге кебек чык бөртекләре берәм-берәм йиргә коела башладылар. Үләннәр дә аз гына урыннарыннан кузгалдылар. Алар да бер-ике мәртәбә башларын селкеп, авыррак чыкларын төшереп, кояшка каршы башларын күтәрделәр. Бу җил Хәлимә туташның күңеленә дә тәэсир итте, аның йоклаган уйларын уятты. Ул да үзенең хәлен уйларга, үз тугрысында фараз кылырга тотынды. Үзен-үзе белмәенчә генә, үзен-үзе сизмәенчә генә, зур авыр чәчен алдына алып салып, аның берлә уйный-уйный, үзенең үткән гомерләрен тикшерә башлады. Әнисенең үлеп, моның үги әни кулына калуыннан башлап, бүгенгә кадәр килеп җитте. Үзенең рәхәтләнеп тордым диярлек бер минут та гомерен таба алмады. Үзенең укыган нәрсәләрен уйларга, үзенең театрларда күргән манзараларын күз алдына китерергә тотынды, анда да искитәрлек бернәрсә дә таба алмады. Күңеле киләчәкне уйларга тотынды, киләчәк өчен планнар корырга башлады. Үзенең кыз булуы, үзенең татар кызы булуы, үзенең үз тормышы эшләргә түгел, уйларга да правасы юклыгы хәтеренә төште. Тагын киләчәк планнары җимерелде. Тагын озын-озын уйларга чумды. Тагын, үзен-үзе онытып, иркен дөньяда, иркен аланнарда, иркен шәһәрләрдә, өйләрдә, иректе бер кеше булып, кешенең кәефен китерер өчен ясалган бер курчак кына булмаенча торуларын уйлый башлады. Аның бу өйдән, бу үги ана идарәсеннән чыгасы, бу зинданнан котыласы килә башлады. Аның чын кеше булып, беркемнән ризалык алмаенча киенәсе, йөрисе, торасы килә башлады. Ул, башка халык кызлары кебек, үзе сөйгәнен генә сөясе, үзе яратканын гына яратасы, үзе теләгән тормыш берлә генә торасы килә башлады. Ул анасының кушуы берлә йөри торган, анасының әсәре берлә сөя торган машиналыктан чыгасы, ул дөньядан әллә кая, еракка-еракка китәсе, ул дөньяны бөтенләй ташлыйсы, мәңгегә шул зиндан өйләрдән китәсе, гомерлеккә шул «ярамый», «килешми»

богауларын өзәсе килде. Матур, киң дөньяда, шундый матур бакчада, шундый тигез күлләрдә, шундый томанлы гына урманнарда үзенә үзе хуҗа булып, үзе теләгәнчә йөрисе килде. Тагын үзенең кыз идеге, татар кызы идеге, үзенең болай уйларга, үзенең тәрәзә төбенә утырырга да правасы юклыгы хәтеренә төште.

Хәзер анасы уянып, кыяметләр чыгарачагы, хәзер анасы моның шул фикерләрен белсә, моны «дөнья вә ахирәт рәхәтенә ирешдерер өчен», бу бозык фикерләрдән коткарыр өчен, хәзер үк, кем очраса, шуңарга кияүгә бирәчәге хәтеренә килде.

Күз алдына караңгы өйләр, ямьсез тормышлар килә башлады. Әллә нинди: «Мин — ирең, мин — падишаһ»,— дигән тавышны ишеткән кебек була башлады. Хәлимә туташ калтырый башлады. Тагын җил исте, тагын күл шадраланды, тагын агачлар акыртын гына бер-берсе илә бәрелешделәр, сөйләштеләр, тагын чыклар коелыштылар, тагын Хәлимә туташ үзен үз бүлмәсендә, үги ана ихтыярында кыз идегенә хәтеренә китерде.

Андый иркенле-иркле тормышлар моның кебек мең-мең татар кызлары өчен харам идеге, кеше булып дөньяда торулар аның өчен гөнаһ идеге күңеленә килде дә күзләреннән мөлдер-мөлдер энҗе бөртек яшьләр ага башлады.

Шул яшьләр берлә бергә аның өметләре, киләчәк өчен корган матур планнары да бергә китте. Ул тагын үзен-үзе шул үз өендә, үзенең тормышының колы итеп күрә башлады.

Үзенең шул тормышыннан котылырга хәле юклыгыны уйлап, тагын пәрдәсен төшерде. Тагын бүлмә караңгыланды. Тагын Хәлимә туташка караңгы уйлар килә башлады. Тагын Хәлимә туташ үзен-үзе правасыз татар кызы итеп хис итте.

# ӘДИПНЕҢ ТОРМЫШ МИЗГЕЛЛӘРЕ

## (ОКТЯБРЬГӘ КАДӘРГЕ ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТ ХӘБӘРЛӘРЕННӘН)

Мин «Г. Исхакыйның тормышы һәм иҗаты турында замандашлары» дип исемләнгән җыентык төзегән идем. Ул мәшһүр язучыбыз турында октябрьгә кадәрге газета-журналларда басылган мәкаләләрдән һәм хәбәрләрдән гыйбарәт. Биредә шул җыентыкның хәбәрләр өлеше укучыга тәкъдим ителә.

Тупланган мәгълүматлар язучының тормыш һәм иҗат елъязмасы түгел. Ул Исхакый биографиясендәге вакыйгаларны, елъязмадагыча, көндәлек төгәллек белән вак-төягенә кадәр теркәп бармый — эрерәк вакыйгалардан тора, ике хәбәр арасында вакыт ераклыгы да шактый булырга мөмкин.

Мондагы хәбәрләр 1900 елдан башлап 1917 елга кадәр булган вакытны үз эченә ала һәм аларда бигрәк тә ике нәрсәгә басым ясала: Г. Исхакый — күренекле язучы-драматург, актив җәмәгать эшлеклесе, шуның өстенә журналист, газетчы да.

Г. Исхакый турында беренче мәгълүмат 1900 елның 22 июль санында «Тәрҗеман» газетасында басыла. Әнә шул вакыттан алып Октябрь революциясенә кадәр аның исеме матбугат битләреннән төшми.

Ул XIX йөзнең ахыры XX йөзнең башында әдәбият мәйданына килә, әллә ни өйрәнчеклек чоры да үтеп тормый, тиз арада талантлы язучы буларак танылa.

Г. Исхакый — 1907 елның 24 октябреннән 1913 елның 4 февраленә кадәр сөргендә. Аның актив җәмагать эшлеклесе булып танылуы исә сөргеннән кайтканнан соңгы елларга туры килә, аңа вакытлы матбугатның игътибары тагын да арта. Ул XX йөз башы татар әдәбиятының иң популяр язучысы гына түгел, татар халкы аны үзенең мөстәкыйль дәүләтчелеге өчен көрәшүче милли каһарманы дәрәҗәсенә күтәрә.

Кайбер талант ялтырап ала да тиз сүнә, Г. Исхакый исә сүнми, шушы абруен совет хакимияте чорына кадәр төшермичә саклап килә. Әсәрләре басылып чыгу белән рекламалар бирелә. Пьесалары 1906 елдан башлап татарлар күп яши торган Казан, Мәскәү, Уфа, Оренбург, Уральск, Әстерхан, Ташкент, Мәкәрҗә шәһәрләрендә профессиональ театр труппалары, һәвәскәрләр тарафыннан еш уйнала, татар театры репертуарының зур өлешен алып тора. Пьесаларның уңышлы һәм уңышсыз куелу очраклары да була. Әйтергә кирәк, прозасына караганда әдипнең драматургиясе матбугатны ныграк җәлеп иткән. Исхакый пьесаларын иң күп уйнаучы — «Сәйяр». Әдип белән «Сәйяр» труппасы арасындагы җылы мөнәсәбәтләр дә, әдип әсәрләренең рус теленә, халыкара эсперанто теленә тәрҗемә ителүе дә газета битләрендә теркәлеп калган.

Февраль һәм Октябрь революцияләре арасы — Г. Исхакыйның иҗтимагый эшчәнлеге аеруча активлашкан чор, шуңа бәйле хәлдә, хәбәрләр дә элекке еллар белән чагыштырганда күбрәк басылган, иҗтимагый эшчәнлеге алгы плангарак чыккан. Бу ике революция арасында татар халкының милли аңы үсә, милли хәрәкәте моңа кадәр күрелмәгәнчә җанлана, күп төрле җәмгыятьләр төзелә, корылтайлар булып үтә.

Г. Исхакый Мәскәү «Мөселман комитеты» рәисе итеп сайлана. Бөтен Русия мөселманнарының Беренче корылтаенда (Мәскәү, 1917, 1—11 май), Мәскәү «Мөселман комитеты» утырышларында, Бөтен Русия мөселманнарының икенче корылтаенда (Казан, 1917, 20 июль — 31 июль) катнашып чыгышлар ясый. Үзенең «Ил» газетасында шушы чор турында озын-озын мәкаләләр урнаштыра. Кайда иҗтимагый вакыйга — Г. Исхакый шунда: Мәскәүдә дә, Казанда да.

1911 елда тәмамланып та сәхнәдә куярга цензура рөхсәт итмәгән атаклы «Зөләйха» пьесасын да ул сәхнәгә чыгара. «Сәйяр» труппасы бу пьесаны Мәскәүгә барып, Беренче корылтай делегатларына күрсәтә.

Һәрхәлдә, әдипнең биографиясенә кагылышлы хәбәрләр матбугат битләрендә күп басылган. Ләкин монда аларның барысы да кереп бетмәде, әһәмияте азрак булганнарын төшереп калдырдым. Текстка төзүченең кулы бераз керде, гарәп сүзләре тәрҗемә итеп алынды. Күләмле кайбер хәбәрләрнең эчтәлекләре генә бирелде. Аерым урыннарда аңлатмалар таләп ителә. Сынык җәяләр эченә куелган аңлатмалар да төзүче тарафыннан эшләнде.

**Фатыйма ИБРАҺИМОВА.**

**1900**

*Яңа китаплар*

Казанда борадәран Кәримовлар табгыханәсендә басылмыш «Кәләпүшче кыз» исемендәге бер китапта, мөселман кызының алданып, гонаһда булдыкыннан соң, фахишханәгә керүе турында сөйләнә.

*«Тәрҗеман», 1900, 22 июль (26)*

**1902**

*Казан*

Казан думасы Пушкин шәрәфенә аның әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү өчен 500 сум акча тәгаен итә. Г. Исхакый әдипнең «Капитан кызы» хикәясен

татарчалаштыра һәм мәгълүм акчадан эш хакы бирүне сорый. Тәрҗемә мәгъкуль күрелсә, акча аңа биреләчәктер.

*«Тәрҗеман», 1902, 8 январь (5)*

*(«Капитан кызы» 1902 елда Казанда аерым китап булып басылып чыга).*

**1903**

*Таза китаплар*

Оренбургта Г. Исхакыйның биш пәрдәдән, алты мәнзарәдән торган «Ике гыйшык» исемле комедиясе басылып чыкты. Хәбәрдә комедиягә уңай бәя бирелә.

*«Шәркы рус», 1903, 14 май (19)*

**1906**

*Игълан*

«Әлгасрел-җәдит» журналының 1 нче санында әдип Гаяз әфәндене «Борынгы алпавытлар» исемле тәрҗемә әсәре басылып чыгачак.

*«Фикер», 1906, 1 январь*

(I) (Н. В. Гогольдән тәрҗемә ителгән бу «Борынгы алпавытлар» хикәясе «Әлгасрел-җәдит»нең 1906 елгы 1, 2 нче саннарында басылып чыга.)

Кичә «Чыңгыз» әфәндене (Г. Исхакыйның) өенә тентү булды. Үзе өйдә юк иде.

*«Таң йолдызы», 1906, 28 июль (22)*

*Кулга алу*

30 октябрьдә «Таң йолдызы» гәзитәсе мөхәррире Сәгыйть Рәмиев өендә тентү булып, кунакка килгәндә генә кунып калган мәшһүр татар мөхәррирләреннән Гаяз әфәнде илә икесен арестовать иткәннәр иде. Сәгыйть әфәндене суды булгангача чыгарып торганнар.

*«Казан мөхбире», 1906, 1 ноябрь (171) «Таң йолдызы», 1906, 1 ноябрь (60)*

*Чыгарылу*

Кулга алынган мәшһүр мөхәррир Гаяз әфәнде Исхакый 2 ноябрьдә, кичке сәгать уннарда төрмәдән чыгарылды, ләкин 24 сәгать эчендә Казаннан китәргә шарт иткәннәр. Авылына (Яуширмәгә) кайтып китте.

*«Казан мөхбире», 1906, 5 ноябрь (179)*

*Хөрмәтле укучыларым!*

Бу көн, 2 ноябрьдә, кич сәгать уннарда 24 сәгать эчендә Казаннан китү шарты белән мине азат иттеләр.

*«Чыңгыз», «Япанчы» — Мөхәммәтгаяз Исхаков «Таң йолдызы», 1906, 5 ноябрь (61)*

*Төрле хәбәрләр*

Казан татарларының иң беренче мөхәррире Гаяз әл-Исхакый әфәнде хәзрәтләрене 2 ноябрьдә төрмәдән чыгарсалар да, Казаннан 24 сәгать эчендә чыгып китәргә фәрман ителгән. Шул сәбәптән Гаяз әфәнде ватанына кайтып китте. Гаяз әфәндене тоткын иткәнгә чын күңелдән кайгырсак та, каләме сынмый, авызы печәтләнми калганга бик шатландык.

*«Фикер», 1906, 12 ноябрь (42)*

Гаяз әфәнде Исхаков, Казанда тормау шарты белән, төрмәдән чыгарылгач, Яуширмәдә янә кулга алынып, Чистай төрмәсендә бер тәүлек ятып чыкмыштыр.

*«Вакыт», 1906, 18 ноябрь (100)*

Гаяз әфәнде Исхаковны янә арестовать иткәннәр. Чистай өязе крестьяннәре аны думага сайларга ният иткәннәр иде.

*«Казан мөхбире», 1906, 25 декабрь (193)*

**1907**

### *Отчет*

Мәшһүр мөхәррирләрдән Гаяз әфәнде Исхакый җәнабләренең «Өч хатын берлән тормыш» драмасы ушбу 1907 елның 13 январенда Новый клуб залында Казанның Императорский университет һәм Ветеринарный институтның фәкыйрь мөселман студентлары файдасына куелды.

*Н. Ф. Юшков «Казан мөхбире», 1907, 18 февраль (220)*

### *Хәбәр*

11 апрельдә Казанда махсус хатын-кызларга багышланган спектакль куела. Моның өчен Г. Исхакыйның «Өч хатын берлән тормыш» драмасы сайлап алына. Шунысы кызык, театрда уйнаучылар да, тамашачылар да хатын-кызлардан гына гыйбарәт була.

*«Тавыш», 1907, 23 апрель (1)*

### *Хәбәр*

Гаяз әфәнденең «Зиндан», исемле әсәре басылып чыкты. Китапка әдипнең фото-рәсеме һәм тәрҗемәи хәле урнаштырылган.

*«Тавыш», 1907, 25 май (6)*

### *Казан хәбәрләре*

Кичәге көнгә каршы төндә полиция, Гаяз әфәнде Исхакыйның фатирына тенту ясап, үзене кулга алмыштыр. Әйтүләренә караганда, Гаяз әфәнде фатирыннан һичбер гаепле нәрсә табылмамыштыр.

*«Йолдыз», 1907, 6 июль (128)*

Бу хәбәр Г. Исхакыйның Казанда 1907 елның 4 июнендә кулга алынуы уңае белән басылган. Шул кулга алынудан ул 1907 елның 24 октябрендә Архангель губернасы Пинега шәһәренә сөргенгә җибәрелә, 1913 елның 4 апрелендә сөргеннән азат ителә.

### *Дахили хәбәрләр*

Гаяз әфәнде Исхаков Архангельга барып җиткән. Шәһәр мөселманнары каршы алырга вокзалга төшкән булганнар һәм дә губернатордан аны шәһәрдә калдыруны үтенгәннәр. Губернатор Гаяз әфәндедән сәяси эшләр белән шөгыльләнмәскә вәгъдә сораган һәм шул шарт белән генә калдырачагыны сөйләгән. Мәгәр Гаяз әфәнде андый вәгъдәләр бирә алмаганга, Архангельдан ике йөз чакрымнарда ераграк Пинегага, бер кечкенә шәһәргә җибәрелмештер.

*«Әхбар», 1907, 12 декабрь (2)*

**1908**

### *Театр*

13 нче январь, пәнҗешәмбе көнне, Городской театрда Уральскийда улан «Мөсафир артистлар җәмгыяте» (соңыннан «Сәйяр») тарафыннан әл-Исхакый җәнабләренең «Алдым-бирдем» исемле әсәре сәхнәгә куелды.

Бу «Алдым-бирдем» әсәренең Русиядә беренче мәртәбә уйналуы булса да, артистлар үз рольләрен яхшы чыгардылар. Хосусән, бу кичәдә бенефис иясе Сәхипҗамал ханым Гыйззәтуллина гаять гайрәт белән тырышты. Пәрдә төшерелгән саен кул чабулар тавышы театрханәне селкетерлек дәрәҗәдә булды.

Гыйззэтуллина җәнабләренә җәмәгать тарафыннан бер һәдия тәкъдим кылынды. Спектакль сәгать сигездән башланып, сәгать бергә кадәр сузылып, озаграк булды. Бундан соң дәхи концерт башланды.

...Уральскида театр эше тәрәккъый итмәктә булып, җәмәгать тә гадәтләнеп бара. Бу көндә театрханә тәмам тулган иде.

*«Яңа тормыш», 1908, 2 февраль (13)*

## *Казан хәбәрләре*

16 мартта Новый клуб залында «Ике гыйшык» исемле әсәр уйналды. Тамашага килүчеләр байтак күп иде. Театр уйналып беткәч, «Таң йолдызы» газетасында мөхәррир булып торган Сәгыйть әфәнде белән әңгәмәдәше Йосыф әфәнде Акчура татар милләтенең бүгенге хәле турында чыгыш ясадылар.

*«Йолдыз», 1908, 20 март (99)*

## *Гаяз Исхаковның адресы*

Бик күп җирләрдән Гаяз әфәнде Исхаковның адресын сорап хатлар килә. Берәмләп җаваплар язып тору минем өчен бик мәшәкать булганга, гәзитәләр аша Гаяз әфәнде Исхаковның адресын игълан кыламын:

г. Пинега Архангельской губернии Гаязу Исхакову

Моннан соң Гаяз әфәндене үзенә шул адрес белән мөрәҗәгать кылуыгызны үтенәм.

*Хөсәен Әбүзәров. «Казан мөхбире», 1908, 24 март (272)*

## *Мәкәрҗәдә татарча театр*

31 августта Фоли-Биржер бакчасында шәһәрдән-шәһәргә күчеп йөри торган труппа тарафыннан Гаяз Исхакыйның «Алдым-бирдем» исемле пьесасы тамашага куелды. Бу пьесада Гаяз әфәнде карагруһ байларның, бигрәк тә Чаллы ягындагы... фамилияле байлардагы вакыйгаларны бөтен дөньяга күрсәткәнгә күрә, күп татарлар, хосусән, Казан татарлары пьесаны уйнатмаска йөреп, ахундка барып, әллә нинди донослар ясап, рөхсәт бирдертми йөрсәләр дә, яшьләр ягыннан да кешеләр чыгып рөхсәт алынды һәм тамашага куелды. Бәлки, бу кешеләрнең болай каршы торулары бигрәк тә бу пьесага халыкның дикъкатен җәлеп кылып, күбрәк килүләренә сәбәп буладыр.

Бу пьеса Сәхипҗамал ханым Гыйззэтуллинаның бенефисына куелды. Безнең халык та хәзер бенефисның нәрсә икәнен аңлый башлаганнар икән. Күп кешеләр тарафыннан һәдияләр тәкъдим ителде. Уйнаучылар да һәркаюсы, бер төрле гайрәт берлә уйнап, рольләрен гүзәл үтәделәр.

Халык бик күп иде. Уйнаучылардан да һәм пьесадан да бик разый иделәр. Ахыргы пәрдәдә, Галия берлә Ибраһимның монологыннан соң, халык пәрдә төшкәнне көтә алмыйча, бик озак кул чабулар дәвам итеп, «Яшәсен яшьләр!» дигән вакытта музыка уйнап, пәрдә тәмам ителде.

Ишетүемә күрә, бу труппа Казанда да ике спектакль куймакчы икән.

*«Мөхбирең». «Әл-ислах», 1908, 8 сентябрь (44)*

**1909**

## *Татарча спектакль (Театр һәм музыка)*

5 июньдә Казанда, Зур күргәзмә театры залында һәвәскәрләр тарафыннан Г. Исхакыйның «Алдым-бирдем» драмасы сәхнәгә куелды. Спектакль ярыйсы җанлы үтте. Һәвәскәрләрдән Мирсалимбекова Гафифә ролен аеруча уңышлы башкарды.

*Гассан. «Волжско-Камская речь», 1909, 7 июнь (195)*

## *Яңа әсәрләр*

«Җыентык» дигән китап мәшһүр мөхәррирләремездән Гаяз әфәнде Исхаков тарафыннан язылмыш. Бу әсәрдә иң башта Русиядәге мөселман гәзитәләренең

бәгъзеләре тәнкыйть ителмеш. Аларның фикер вә мәсләктә аерымлыклары нәтиҗәсе уларак, татар галәменең һәр эше искечә калуы, янармага торганнарының җимерелүе тасвир ителмеш. Нашире Хөсәен Әбүзәров.

*«Идел», 1909, 19 декабрь (219)*

**1910**

### *Басылып чыкты «Кыямәт» Гаяз Исхакый әсәре*

«Кыямәт» моннан унөч еллар элек Казанда вакыйг улмыш язулы йомырка мәсьәләсе һәм шул хакта бөтен Казан халкының шаулавы хакында әдипләремездән Гаяз әфәнденең оста һәм матур каләме берлә тасвир ителмеш бик мәгънәле һәм көлке комедиядер.

*«Йолдыз», 1910, 23 февраль (508)*

(Пьеса түбәндәге вакыйгага нигезләнгән дип фараз ителә: Казандагы матбага хуҗасы Мөхәммәтҗан Кәримовның Яңа Бистәдәге йортында асраулар беркөнне тавык кетәгеннән язулы тавык йомыркасы табып алалар. Йомыркага «тиздән ахырзаман булачак» дип язылган була. Хатын-кызлар арасында елаш, тәүбә итешүләр куба.

Моны Кәримовларның табгыханәсендә эшләүче шагыйрь һәм типограф Мәхмүт Алмаев уйнап язган була.)

### *Татарча театр*

7 мартта Народный домда (Оренбург) «Сәйяр труппасы» тарафыннан Гаяз әфәнде Исхаковның «Мөгаллим»е куелды. Уенны яхшы уйнадылар. Баш пәрдәләре халыкның күңеленә бик охшады, соңгысы тирәнрәк мәгънәле булганлыктан, бераз авыр тоелды. Зал халык илә тулы булып, мөселман хатынкызлар да күп иде.

*«Вакыт», 1910, 9 март (589)*

**1911**

### *Татарча театр*

Җомга көн, 14 гыйнварда Новый клуб залында һәвәскәрләр Гаяз Исхаковның «Мөгалим»ен сәхнәгә куйдылар. Уйнаучылар һәвәскәрләр булгангамы, халык бармак илә генә санарлык иде. Уен тәнкыйтьтән түбән булды.

*«Йолдыз», 1911, 16 январь (633)*

### *«Кыямәт»*

«Сәйяр» труппасы Гаяз әфәнде Исхаковның «Кыямәт» пьесасын сәхнәгә куйды. Тамашачылар уенчыларны түгел, гүя ки мәгыйшәтебездәге чын каһарманнарны үз әхвальләрендә күреп тордылар. Хәтта пьесаның үзендә булган кимчелекләр бик күп тутырылып, тәмам төзәтелмеш иде. «Сәйяр» труппасының бу соңгы уены халыкта гүзәл тәэсир калдырды.

*Оренбруг. «Вакыт», 1911, 27 январь (724)*

### *«Алдым-бирдем» яхуд татарча театр*

Якшәмбе көн, 8 майда Плотников варисларының Зимний театрында Хаҗитарханның һәвәскәр яшьләре Гаяз әфәнденең «Алдым-бирдем» исемле биш пәрдәле драмасын сәхнәгә куйдылар. Спектакль матбугатта уңай бәя ала.

*«Идел», 1911, 10 май (351)*

### *Хаҗитархан хәбәрләре*

Гаяз әфәнде Исхаковның «Җәмгыять» комедиясе үз хәятымыздан алып язылган. Ул, һич шик юк, яхшы әсәр. Шуңа булса кирәк, Хаҗитархан яшьләре бәйрәм спектакеле өчен шушы комедияне сайлаганнар. Ләкин ул безнең бу заман артистлары өчен уйнарлык комедия түгел икән. Карап торучы җәмәгать бик ялыкты.

Бер пәрдәдә бетәргә тиеш булган картинаны ике пәрдәгә сузып, Гаяз әфәнде бик ялгышкан. «Җәмгыять»не үзе укып чыкмаган кеше сценадан күреп, бернәрсә дә аңлый алмады.

*«Идел», 1911, 25 ноябрь (404)*

**1912**

### *Театр һәм музыка (мөселман спектакле)*

20 февральдә Ташкентның һәвәскәр мөселман яшьләре җәмәгать җыелышы залында ачлар файдасына Г. Исхакыйның «Алдым-бирдем» пьесасын сәхнәдә уйнадылар. Сәхнәгә куюу өчен шактый авыр булган бу пьесаны һәвәскәрләр, күп көч түгеп, уңышлы башкарып чыктылар. Уен тамашачылар тарафыннан алкышлар белән кабул ителде.

*«Туркестанский курьер» (Ташкент), 25 февраль (45)*

### *Шәрекъ клубында бенефис*

5 мартта Шәрекъ клубында Габдулла әфәнде Кариевның бенефисы булып, сәхнәгә Гаяз Исхакыйның «Өч хатын берлән тормыш»ыннан ахыргы бер пәрдәсе, Г. Камалның соңгы әсәрләреннән «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясенең соңгы ике пәрдәсе куелды.

Пәрдә ачылу белән бенефис иясе Кариевны халык самими рәвештә алкышлады. Кариев алган рольләрен гадәттән тыш бер осталык белән башкарды.

*«Йолдыз», 1912, 8 март (803)*

### *Шәрекъ клубында бенефис*

Җомга көн, кич белән Шәрекъ клубында Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның бенефисы булып, тамашага Г. Исхакыйның «Алдым-бирдем» әсәре илә «Кызлар шулай кызык итәләр» (Г. Атави) исемле бер пәрдәлек водевиль тамашага куелды. Бенефис иясе ике пьесаны да осталык белән уйнады. Халык аның осталыгын тәкъдир итеп, бик күп һәдияләр бирделәр. Һәдияләр баштанаяк алтын-көмеш зиннәт әсбаплары белән пакетлы акчалардан гыйбарәт иде.

*«Йолдыз», 1912, 11 март (804)*

### *Шәрекъ клубында бенефис*

Җомга көн, 16 мартта Шәрекъ клубы залында «Сәйяр» труппа артистларыннан Мортазин Иманскийның бенефисы ясалды. Тамашага Гаяз әфәнде Исхаковның «Мөгаллим» исемле әсәре куелды. Бенефис иясе Мөгаллим ролен шактый зур осталык белән башкарды. Тамашачылар уеннан разый булып, Мортазин әфәндене тәбрик иттеләр. Шәрекъ клубы әгъзалары һәдияләр бирделәр.

*«Йолдыз», 1912, 18 март (807)*

### *Татарча театр*

Татар театры шимбә көн, 1 сентябрь Городской театрда (Оренбург) татарча театр уйнады. Сәнгатьчә ул хәтле үк булмаса да, идеягә бай «Алдым-бирдем» пьесасы уйнаучыларның шактый хәзерлек вә тырышлыкларына да карамый сыеграк чыкты. Сыек чыгуына да шул идея вә акыл сатуларның күбрәк булуы сәбәп булгандыр ахырысы. Халык күп, музыка юк иде. Сәгать икенче яртыларга кадәр сузылган бу уенны карау шактый авыр вә күңелсез булды.

*«Вакыт», 1912, 4 сентябрь (1030)*

**1913**

### *«Мулла бабай»*

«Мулла бабай» Г. Исхакый әфәнденең иң беренче язылган бөек романнарыннан. Бу әсәрнең ике китабы чыкты. Әсәр руханиларыбыз тормышыннан алып

язылгандыр. Хәзерге көндә беренче кисәгенең өченче китабы басылмакта улып, март башларында чыгачактыр. Китап «Гасыр китапханәсе» тарафыннан Харитонов матбагасында басыла.

*«Аң», 1913, 5 нче сан (1 март)*

18 февральдә Стәрлетамак мөгаллимнәре Гаяз әфәндене «Ике гыйшык» комедиясен сәхнәгә куйдылар.

*«Сибирия», 1913, 6 март (83)*

## *Дахили хәбәрләр*

«Кояш» идарәсе тарафыннан сөргендәге мөхәрриремез Гаяз әфәнде Исхаковка 25 февральдә ушбу эчтәлекле телеграмм бирелгән икән: «Сөргеннән азат ителдегезме? Мезеньнән кайчан вә кайда китәсез?»

26 февральдә Гаяз әфәндедән шушы җавапны алганнар: «Амнистия (Гафу гомуми) миңа тимәде. Сөргендә тору срогымнан бераз киметелү ихтималы бар» Гаяз.

*«Сибирия», 1913, 6 март (83)*

## *Манифест һәм мөхәррирләремез*

Романовлар нәселенең Русиядә тәхеткә утыруына 300 ел тулу юбилее уңае белән чыгарылган амнистия (21 февраль, 1913) нәтиҗәсендә Гаяз Исхаков, Йосыф Акчура, Рәшит казый (Ибраһимов) гафу ителәләр. Теләсәләр Русиягә кайтырга мөмкин.

*«Кояш», 1913, 6 март (64)*

(Г. Исхакый сөргенлек чорында ике мәртәбә качып китеп, Төркиядә торып кайта. Соңгы кайтуында Петербургта яңадан кулга алына һәм Архангель губернасының Мезень шәһәренә озатыла. Сөргеннән 1913 елның 4 апрелендә шунда азат ителә.)

## *Гаяз Исхаков*

Әдип вә мөхәрриремез Гаяз әфәнде Исхаков Архангель губернасына сөргенгә җибәрелгән иде. Авыр тормыш, шималь җилләре аның гайрәтен киметә алмады. Берсеннән берсе кыйммәтле әсәрләре матбугат галәмендә чыга гына барды.

Гаяз әфәндедән үзеннән килгән телеграммга караганда, сөргенлек срогы бер ел киметелеп, 4 нче апрельдә азат кылыначак икән. Гаяз әфәндене иркенлек дөньясына чыгуын бөтен миллләт исеменнән тәбрик итәмез, кайтып шул хезмәтендә дәвам итүен чын күңелдән телимез.

*«Хокук вә хәят», 1913, 4 нче сан (март)*

Мәшһүр мөхәррирләремездән мөхтәрәм Гаяз әфәнде 7 апрельдә сөргеннән Петербургка кайткан.

*«Сибирия», 1913, 21 апрель (99)*

## *Дахили хәбәрләр*

Гаяз әфәнде күптән түгел Чистайдан Казанга килгән иде. Падишаһ хәзрәтләренең манифесты илә ирекә җибәрелүенә карамый, үз артыннан һәркөн эзәрләкләп йөргәннәрен күргәч, Казаннан китәргә мәҗбүр булган. Хаҗитарханга төшүе дә көтеләдер.

*«Вакыт», 1913, 21 май (1205)*

## *Дахили хәбәрләр*

Мөхәррирләремездән Гаяз әфәнде Исхаков, Уфа шәһәрендә мөсафир булып, аннан Самара якларына ялга китәчәк икән.

*«Вакыт», 1913, 30 май (1212)*

## *Дахили хәбәрләр*

Мөхәррирләремез Г. Тукаев белән Г. Исхакый бер-берсенә дусларча якын һәм мәсләктәш булсалар да, икесе бергә туры килеп, күрешә алмаганнар икән.

Г. Тукаев Уральскидан Казанга күчеп килгәндә, Г. Исхакый сөргенгә чыгып киткән. Г. Исхакыйның сөргеннән кайтырга чыккан көн Г. Тукаевның дәфен көненә туры килгән.

*«Вакыт», 1913, 2 июнь (1215)*

### *Гаяз әфәнде хөрмәтенә театр*

Бөек мөхәрриремез Гаяз әфәнденең Мәкәрҗәдә булуыннан файдаланып, Мәкәрҗәдәге зыялы яшьләремез, бәгъзе артистларымызның катнашы белән, Гаяз әфәнде шәрәфенә кечкенә генә кунак мәҗлесе сыман бернәрсә ясадылар. Соңра артистларымыз бәйрәмнең әүвәлге көнендәге спектакльне бөек мөхәрриремез шәрәфенә дия атап куйдылар. Шушы мөнәсәбәт илә бу кичне бөек мөхәрриремезнең «Мөгаллим» исемле әсәренең өч пәрдәсене һәм дә «Өч хатын берлән тормыш»ның ахыр пәрдәсен уйнадылар.

Спектакль тәмамында Гаяз әфәндегә «Сәйяр» труппасы исеменнән һәдия уларак, алтын чылбыры илә алтын сәгать тәкъдим улынды. Театрда халык күп булып, Мәкәрҗәдәге татар аристакратларынын күбесе килгәннәр иде.

Спектакльдән соң Гаяз әфәнде бөтен «Сәйяр труппасы»н чакырып, кунак итте.

Татар театрының мөдире сыйфаты илә Габдулла әфәнде Кариев вә Мортазин җәнабләренә әдип үзенең ихтирамын белдерде.

*«Мөхбир», «Кояш», 1913, 26 август (200)*

### *«Ил» гәзитәсе*

Петербургта «Ил» гәзитәсен чыгарырга хөкүмәттән рөхсәт алынган икән. Мөхәррире Гаяз әфәнде Исхакый җәнабләре булып, 15 октябрьдә гәзитә чыга башлыячактыр. Соратыр өчен адрес: С. Петербургская сторона, Мало Пушкарская, д. 22, кв. 14.

*«Идел», 1913, 27 сентябрь (591)*

*(«Ил»нең беренче саны 1913 елның 22 октябрендә чыга)*

### *Дахили хәбәрләр*

Мөхәррирләремездән Гаяз әфәнде Исхаков «Мөгаллимә» исемле яңа пьеса тәмам иткән. Пьеса өч пәрдәле булып, тиз көндә басылырга биреләчәктер.

*«Кояш», 1913, 23 декабрь (294)*

(«Мөгаллимә», өч пәрдәле драма, 1914 елда Петербургта басылып чыга.)

**1914**

### *Дахили хәбәрләр*

1913 елның 23 декабрендә Петроградта Русия мөселманнарының Беренче съезды ачыла. 1914 елның 2 январена кадәр дәвам иткән, уку-укыту мәсьәләләрен караган бу съездда Г. Исхакый чыгыш ясый.

*«Ил», 1914, 2 январь (10)*

### *Эсперанточада татар әдәбияты нәмүнәсе*

Мәскәү эсперанточылары тарафыннан нәшер ителә торган Лаонде де Есперанто мәҗмугасының (гәзитәсенең) 1913 елдагы мөштәриләренә һәдия итәр өчен Шәрекъ халкының әдәбият нәмүнәләреннән гыйбарәт улан «Шәркы альманах» (Ориента Алманако) исемле әсәр нәшер ителеп, югарыдагы гәзитәнең мөштәриләренә таратылды.

Һәдия ителә торган әсәргә бастыру өчен гәзитәнең мөхәррире Захаров җәнабләре, хосусый уларак, вакыт илә миңа мөрәҗәгать итеп, яшь татар әдәбиятының нинди дә булса әсәреннән берәр нәмүнә эсперанточага тәрҗемә кылуымны сораган иде. Мин аның шул мөрәҗәгатенә бинаән Гаяз әфәнде Исхаков җәнабләренең «Галош» исемле кечкенә әсәрене сайлап алып, эсперанточага тәрҗемә итмеш идем. Шушы «Галош» исемле кечкенә хикәя исә, татар әдәбиятыннан бер нәмүнә уларак, югарыды әйткән «Шәркы альманах» исемле әсәрдә эсперанточа басылып чыкты.

Моннан соң тагы Гаяз әфәнде җәнабләренең әсәрләреннән ничә бер кисәкләрен эсперанто әдәбиятына кертмәк әмәлендәмен.

*Йосыф Казаков. «Ил», 1914, 2 январь (10)*

(Хикәянең эсперанточага тәрҗемәсе табылмады.)

### *Гаяз әфәнденең сырхавы*

Гәзитәмезнең мөхәррире Гаяз әфәнде Исхакый бу көндә сырхаулап тора. Баш авыртуы, кәефсезлек һәм хәлсезлектән зарлана.

Докторлар сырхавы күп эшләп баш арыганнан, диләр һәм берникадәр вакыт ял өчен санаторийга барырга мәслихәт итәләр.

Гаяз әфәнде бу көннәрдә Финляндиядә торачактыр. Шуның өчен әлегә кадәр һәм моннан соң үзенә махсус мөрәҗәгать итеп килгән мәктүбләрне Гаяз әфәнде берникадәр вакыт җавапсыз калдырырга мәҗбүрдер.

*«Ил», 1914, 27 апрель (25)*

### *«Ил»нең суды*

Гәзитәмезнең 7 нче номерында (6 декабрь, 1913 ел) «Татарга» дигән шигырь басылган һәм шул номер конфисковать ителеп, мөхәрриремез Гаяз әфәнде судка бирелгән иде.

Судебный следователь Гаяз әфәндедән шигырьнең язучысы Мәннаф әфәнденең кем вә кайда торганнарын сораган да, Гаяз әфәнде шигырь өчен бөтен җаваплыкны үз өстенә алам, Мәннафның кем икәнен әйтә алмыйм, дигәч, Гаяз әфәнденең үзен генә җавапка тартканнар иде.

12 майда судебная палатада шул эш каралды. Судебная палата шигырьдә законга каршы бернәрсә тапмады һәм эшне бетереп, 7 нче номер «Ил»дән конфискацияне алырга вә Гаяз әфәндене хөкем итмәскә карар бирде.

*«Ил», 1914, 17 июнь (31)*

### *«Алдым-бирдем» тәрҗемәсе*

Гаяз әфәнде Исхакыйның «Алдым-бирдем» исемле драмасы Петербургта һәр ай саен чыга торган «Заветы» журналының июнь нөсхәсе 6 нчы номерында «Брачный договор» исеме белән тәрҗемә ителеп басылып чыкты. Тәрҗемә итүчесе Г. С. дыр.

Гаяз әфәнденең «Шәкерт абый» хикәясе Италиядә Максим Горький тарафыннан чыгарылган «Современник» журналында тәрҗемә итеп басылган иде.

«Алдым-бирдем» Гаяз әфәнденең русчага тәрҗемә ителгән икенче әсәре.

*«Ил», 1914, 23 июнь (32)*

(«Шәкерт абый» «Современник» журналының 1913 елгы 4 нче китабында «Шакирд аби», рассказ Мухамеда Гаяза Исхакова исеме белән тәрҗемә итеп басылган. Тәрҗемәчесе Г. Свердлова.)

### *«Ил» матбагасы*

«Ил» гәзитәсе әлегә кадәр кеше матбагасында басыла иде. Петербургта татар матбагаларының кямил куелган булмавы «Ил»нең нәшерен байтак читенләштерә иде.

Шуңар күрә «Ил», яңа гына аякка басып килә торган бер гәзитә булса да, үзенә махсус матбага куярга мәҗбүр булды.

Бу номерымыз берлә «Ил» матбагасы эшли башлаган саннардыр. Ләкин хәрефләремез урнаштырып бетмәгәнлектән, «Ил»нең бу номеры нәфасәт җәһәтеннән кямил була алмады.

Моннан соң «Ил» матбагасы үз гәзитә вә нәшриятыннан башка читтән заказлар да кабул итәчәктер.

Гаяз әфәнденең «Мәҗмугаи асар»ыннан «Гасыр китапханәсе»ндә басылмый калган әсәрләре шул ук формада һәм том саннары «Гасыр» дагасының дәвамы итеп «Ил» матбагасында басылачактыр.

*«Ил», 1914, 23 июнь (32)*

### *Дахили хәбәрләр*

Гаяз әфәнде тарафыннан язылган өч пәрдәлек «Мөгаллимә» пьесасының сәхнәдә уйналуына цензордан рөхсәт алынды. Бу әсәр якында «Ил»нең үз матбагасында басылачактыр.

*«Йолдыз», 1914, 29 июнь (1217)*

### *«Зөләйха» («Отпавший»)*

Гаяз әфәнденең соңгы әсәрләреннән «Зөләйха» исемле биш пәрдәлек драмасы бу көннәрдә «Ил» матбагасында басыла башлады.

*«Ил», 1914, 21 август (38)*

### *Мөхәммәтгаяз Әл-Исхакыйның «Мәҗмугаи асар»е*

3 нче томның 3 нче китабы булган «Мөгаллимә» исемле өч пәрдәлек драмасы, «Ил» матбагасында басылып чыгып, сатылырга куелды.

*«Ил», 1914, 21 август (38)*

### *«Мөгаллимә» пьесасы уйналу*

Бәйрәм мөнәсәбәте белән Шәрекъ клубында Г. Исхакыйның яңа гына матбугатымызда чыккан «Мөгаллимә» исемле пьесасын куйганнар иде. «Мөгаллимә»не карарга килүчеләрдән яртыдан артыгы ханым һәм туташлар иде.

Театр бик күңелле үтте. Уйнаучылар да яхшы уйнадылар. Ханым һәм туташлар да бик шат булып таралдылар.

*«Сөембикә», 1914, 1 нче сан (1 ноябрь)*

## 1915

### *«Остазбикә» романы*

Гаяз әфәнденең яңа вә соңгы әсәрләреннән булган «Остазбикә» исемле әсәренең язылып, тәмам булып, матбагага бирелгәнлеген ишеттек. «Остазбикә» Гаяз әфәнденең башка әсәрләре шикелле үк тормыштан алып язылган зур бер әсәре булачак икән. Әсәрнең берәр ай эчендә матбугат мәйданына чыгу ихтималы бар, ди.

*«Тайфун» (Мәскәү), «Йолдыз», 1915, 16 апрель (1412)*

### *Мөхәрриремез Гаяз әфәнде*

Бөек әдибемез Гаяз әфәнде Исхакый җәнабләре яз башында, «Ил» гәзитәсе тукталгач, җәй көне хәл җыяр өчен, Уфага килгән иде. Гаяз әфәнде Уфа тирәсендә, Караидел буенда дачада да торды. Монда бик тазарды. Киләчәк эшләр өчен бик күп көч җыйды. Шуның белән бәрабәр язуын да дәвам итеп, берничә башлаган әсәрләрен тәмам итте. Шундый әсәрләрнең берсе «Ил»дә «Ул икеләнә иде» исеме белән фельетон рәвешендә басыла башлаган иде. Башкалары да шул мәүзугъларак булып, берничә хикәя бер мәҗмуга булып чыгачак икән.

Гаяз әфәнде Уфада җәмәгать эшләренә дә ялкаулык итмәенчә катнашып торды. Аның дачасы да яшьләрнең, җәмәгать хадимнәренең, мөгаллим вә мөгаллимәләрнең җыен урыны иде. Көз башлану белән Гаяз әфәнде, дачаны ташлап, 10 августта пароход белән Казанга кайтып китте. Аннан Мәскәүгә барып, «Ил» гәзитәсен чыгарырга тырышачак.

*«Тормыш», 1915, 12 август (298)*

(«Ил»нең соңгы саны 1915 елның 27 мартында чыга. Г. Исхакыйның «Ул икеләнә иде» хикәясе «Ил»нең 1914 елгы 20 декабрь саныннан башлап 1915 елгы 18 январь санына кадәр дәвам итә. Соңгы санында «Бетмәде» дип куелган, ләкин дәвамы очрамады. Әсәр 1917 елда китап булып чыга.)

## *Хәбәр*

27 ноябрьдә, җомга көн Уфа һәвәскәрләре русча-татарча кызлар мәктәбе файдасына ике бүлектән торган кичә ясадылар. Беренче бүлектә Г. Исхакыйның «Мөгаллимә» пьесасы куелды.

*«Тормыш», 1915, 13 декабрь (376)*

### 1916

## *Гаяз әфәнде шәрәфенә зыяфәт. Оренбург*

Мөхтәрәм әдибемез Гаяз әфәнде Исхакыйның шәһәремездә мөсафир булыну мөнәсәбәте илә дуслары тарафыннан аның шәрәфенә Биржевая гостиница залында 8 мартта, якшәмбе көн кунак мәҗлесе үткәрелде.

Мәҗлестә утыз-кырык кеше бар иде. Нотыклар сөйләнеп вә фикер алышып мәҗлес бик гүзәл үтте.

*«Вакыт», 1916, 11 май (2030)*

Бүген көн, иртә белән Гаяз әфәнде Оренбург, Казан сәфәреннән Мәскәүгә кайтып китте.

*«Сүз», 1916, 25 май (58)*

## *Большой театр*

Большой театрда 9 декабрьдә Кариев җитәкчелегендә «Сәйяр» труппа артистлары Г. Исхакыйның «Алдым-бирдем» пьесасын яңа постановка белән куячаклар. Пьеса биш пәрдәдә. Уйнаучылар: Болгарская, Ильская, Таждарова, Әмирова, Гомәрова, Шамилева, Арсланова, Кариев, Тинчурин, Камал I, Камал II, Әбүбәкеров, Колмәмәт, Искәндәрев, Уралов вә гайреләр.

*«Йолдыз», 1916, 7 декабрь (1726)*

### 1917

## *Большой театр*

Большой театрда 17 мартта «Сәйяр» труппасы мөдире Габдулла Кариевның бенефисы була. Тамашага беренче мәртәбә Гаяз Исхакыйның мәшһүр әсәре «Зөләйха» куелачак. Гыймади карт һәм Габдулла мөрит рольләрен бенефис иясе Кариев башкарачак. Уенга иллегә якын кеше катнаша. Беренче пәрдәдә туй күренешендә һәм дүртенче пәрдәдә Зөләйханың утлы мәнзарәсендә Солтанәхмәт Габәши тарафыннан пьесага язылган музыка композиторның үз җитәкчелегендә уйналачак.

Фаҗига дүрт пәрдәдә, биш мәнзарәдә.

*«Йолдыз», 1917, 13 март (1769).*

## *Музыкага салынган пьеса*

Гаяз әфәнде Исхакыйның үткән елларда язылып, тәмам ителеп тә, мөхәррирнең теләве белән хәзергә кадәр басылмый тотыла торган бер пьесасының («Зөләйха»ның) бернечә күренешләре яшь музыка белгечләребездән Солтанәхмәт әфәнде Габәши тарафыннан музыкага салынып, тәмам ителгән.

Татар галәмендәге әүвәлге тәҗрибә булган бу яңа эшнең көтелгәннән артык уңышлы чыкканлыгы хәбәр ителә.

Пьесадагы туй күренеше һәм хыялый күренеш булган үлем алдыннан фәрештәләр күренеше хосусый уңыш белән музыкага салынганлыгы ишетелә.

Фәкать пьеса өчен махсус декорацияләр, махсус әсбап вә зур уйнаучы көч кирәк булачактыр.

*«Аң», 1917, 2 нче сан, (15 март)*

## *Телеграмма*

Милли театрның мөстәкыйльлеге һәм алга китүе өчен тырышучы армас хадимебезне ялкынлы күңелебездән тәбрик итәбез. Монда 17 мартта беренче кат

сәхнәгә куелган вә тамашачыларның күңелләрендә гасырларча изелүдән котылган халыкның бөек теләкләрен вә өмидләрен уйгаткан бөек «Зөләйха»ның авторы бөек әдипне котлыйбыз. Милли театр вә туган халкыбыз файдасына алдагы хезмәтләр өчен Алла сезнең көчегезне ныгытсын.

*Габдулла Кариев. «Ил», 1917, 23 март (1)*

## *Телеграмма*

Туган халкыбызның ирке вә хокуклары өчен армас көрәшче һәм шөһрәтле хадимебезне ялкынлы күңелебездән тәбрик итәбез. Киләчәктә нәтиҗәле хезмәтләрегез өчен Алла сезнең озак елларга көчегезне ныгытсын.

Казанлы курсисткалар һәм студентлар

*«Ил», 1917, 23 март (1)*

(Бөтен Русия мөселманнарының Мәскәүдә булачак Беренче съездына хәзерлек уңае белән Мәскәү «Мөселман комитеты»ның җыены була. Комитет рәисе Г. Исхакый җыенда съездны ничек оештыру турында чыгыш ясый. Бу телеграммалар әдипнең әлеге чыгышы һәм «Зөләйха»ның уңышлы куелышы уңае белән җибәрелгән.)

## *Гаяз әфәнде Казанда*

Казан халкы Гаяз Исхаковны бик сагынганлыгын эштә күрсәтте. Аның Казанга килү мөнәсәбәте белән төрле җирләрдә митинглар җыелды, Театрлар уйналды, банкет ясалды. Бу җөмләдән пәнҗешәмбе көн «Свет» кинематографиясендә иртә белән яшьләр митингысы, «Электро» кинематографиясендә көндез хатын-кызлар митингсы ясалды. Шул ук көндә, кич белән Никитин цыркында митинг ясалды. Җомга көн Гаяз Исхаковның «Зөләйха»сы үзе килү мөнәсәбәте белән өченче тапкыр уйналды. Монда кунаклар гадәттән тыш күп иде. Шул ук җомга көн, кич Новый клуб залында Гаяз Исхаковны ихтирам итүчеләр тарафыннан аның шәрәфенә банкет бирелде. Моннан башка күп урыннарда, Гаяз әфәндене Казанда булуыннан файдаланып, нәүбәттәге эшләнеп бетмәгән мәсьәләләрне ашыктырып, хәзерләнеп, ул булган чакта мәҗлескә тәкъдим итүләр булды. Халыкның Гаяз әфәндене сагынуы вә ихтирамы гадәттән тыш бер дәрәҗәгә ирешкәнлеге аңланды.

Җомга көн «Сәйяр» труппасы артистлары тарафыннан «Зөләйха» өченче тапкыр тамашага куелды. Бу мәртәбәсендә электә төшерелә килгән туй пәрдәсе дә уйналды. Артистлар элекке мәртәбәләреннән күп яхшы вә оешканлык белән уенны алып бардылар. Уен беткәч, әсәрнең авторы Гаяз әфәнде Исхаковны, үтенеп, сәхнәгә чыгардылар. Гаяз әфәндегә, аның әдәби вә иҗтимагый-сәяси хезмәтләрен тәкъдир итеп, артистлар тарафыннан адрес тәкъдим ителде. Зур вә кыйммәтле һәдияләр тәкъдим ителде. Гаяз әфәнде адреска каршы чыгышында артистларның мөхәррир идеясен гәүдәләндерүче булганлыкларыннан тәкъдиргә иң лаек затлар икәнлекләрен бәян итте. Казанга икенче килгәндә татар театры бинасын күрергә теләгәнлеген белдереп, чыгышын тәмам итте.

*«Кояш», 1917, 9 апрель (1103)*

(Бу вакытта татар зыялылары арасында татар театры өчен «Ирек йорты» исемле махсус бина төзү мәсьәләсе күтәрелә. Г. Исхакый шуны искә ала.)

## *Гаяз әфәнденең кайтуы*

Пасха көннәрендә Гаяз әфәнде Казанга киткән иде. 13 апрельдә Мәскәүгә кайтты. Су ташуы сәбәпле, Мәскәү-Казан тимер юлы бозылып, поезд йөрешләре тукталып калганга, Гаяз әфәнде пароход юлы ачылганга кадәр Казанда торырга мәҗбүр булды. Су юлы ачылгач, ул пароход белән Мәскәүгә кайтты.

*«Ил», 1917, 16 апрель (10)*

## *Сарытау мөселман гаскәрләренең комитетыннан Гаяз әфәндегә тәбрик телеграмы*

Сезне милләтебез вә илебез файдасына армый-талмый эшләвегез өчен җәмәгать хадиме итеп тәбрик итүне үзебезгә бурыч саныйбыз. Бу кыен, изге эштә сезгә уңыш телибез.

Сарытау мөселман гаскәрләренең комитеты

*«Ил», 1917, 16 апрель (10)*

### *Театр вә музыка*

14 апрельдә Гаяз әфәнденең тыелган пьесаларыннан беренче мәртәбә «Тартышу» исемле әсәре уйналды.

«Тартышу» 1905 ел инкыйлабының кечкенә генә бер ядкяре булып, ул вакытлардагы бер төркем яшьләремезнең фикер вә хәрәкәтләрен гәүдәләндергән тарихи бер сәхифәдер. «Тартышу»ның эчтәлеге бик садә булып, мөхәррирнең иң зәгыйфь әсәрләреннән булса да, ләкин хәзерге вакытына күрә азмы-күпме бер әһәмияткә иядер. Бу уеннан килгән керемнең бер микъдары, мөхәррирнең теләве буенча, Казанда төзеләчәк «Ирек йорты»на багышланды. Халык күп иде.

«Сәйяр» труппасыннан Казанда беренче куелуыннан ике йөз сум гонорар «Ирек йорты» фондына бирелсә кирәк, бу әсәрне чит шәһәр труппалары да сәхнәгә куеп, «Ирек йорты»на ярдәмләшүләре көтеләдер.

*Г. Кәрам. «Аң», 1917, 3—4 нче сан (20 апрель)*

### *Вәкилләр шәрәфенә театр*

Мәскәүдә 4 майда, кич «Сәйяр» труппасы тарафыннан Бөтен Русия мөселманнарының Беренче съездына килгән вәкилләр шәрәфенә Г. Исхакыйның «Зөләйха» драмасы уйнала. Спектакль бик тантаналы үтә. Г. Болгарская башкаруында Зөләйха зур җанлы, көчле иманлы татар хатыны булып күз алдына килә. Г. Кариев бу кичтә Гыймади, Габдулла, доносчы кебек өч рольне уңышлы башкара.

Спектакль ахырында мөхәррирне бөтен вәкилләр тарафыннан тәбрикләү һәм аңа һәдияләр тәкъдим итү тантанасы була.

*«У. Р.» («Уралбай») «Вакыт», 1917, 10 май (2220)*

(Бөтен Русия мөселманнарының Беренче съезды 1917 елның 1-11 майларында Мәскәүдә була).

### *Гомуми Русия мөселманнарының Беренче съезды*

Беренче көнне Гаяз әфәнде Исхаков Мәскәү «Мөселман комитеты»ның рәисе сыйфаты илә Беренче хөр мөселман съездын котлагач, үзенең элек бу көннәр киләчәгенә иманы булганлыкны бик әсәрле итеп сөйли: «Мин чит илләрдә сөргендә йөргәндә түгел бундай олуг җыелышлар күрә, хәтта татарча бер җыр ишетергә дә гаҗиз булып тилмереп йөргән вакытларымда, караңгы зиндан бүлмәләрендә киләчәгем ничек булачакны белми яткан чакларымда шушы көннәр киләчәккә өмидем кямил иде. Мин төрек-татар халкының беркөн шулай хөр булып үз эшләрен үзләре башкара алачакларына, үзенә хас мәдәниятле олуг бер төрек-татар милләте мәйданга чыгачакка ышана идем, бу көн һәрберемез хосусый вә сыйнфый мәнфәгатьләрдән вә карашлардан ваз кичеп, олуг бер милләтнең шанына лаек бер берлек күрсәтик»,— ди.

Гаяз әфәнде рус хөкүмәтенең дә, хәтта рус җәмәгатенең дә мөселманнар хакында гел ялгыш фикердә булдыкларын, аларны танымыйча түбән күргәнлекләрен бәян итә. Без, кямил гражданнар булып, үз эшләремезне үземез башкара алырмыз, дигән фикер әйтте.

*«Вакыт», 1917, 10 май (2220)*

### *Театр вә музыка*

24 апрельдә Новый клуб сәхнәсендә «Сәйяр» труппасы тарафыннан «Мөслимәләр җәмгыяте» файдасына Г. Исхакыйның «Алдым-бирдем» пьесасы уйналды. Моны исә сезонның иң уңышсыз уеннарыннан хисапларга ярый. «Сәйяр» труппасы бу көнге уенга гадәттән тыш бер дикъкатьсезлек күрсәтеп, ул гүзәл пьесаны уйнаучылар тәмамә боздылар. Шундый әһәмиятле бер вакытта Русиянең һәрбер почмагыннан килгән мөслимәләрне игътибарга алып, татар сәхнәсен, аның бу көнге куелышын мөмкин кадәр яхшы сурәттә күрсәтергә тырышырга кирәк иде.

Бәлки мөхтәрәм кунаклар арасында татар театрын гомерендә беренче мәртәбә күрергә тугры килгәннәре булгандыр. Татар театрын гәзитәләрдә укып белгән ханымнар безнең милли театрымыздан нинди тәэсир алып киткәннәрдер, анысы безгә караңгы, шулай да күп ханымнарның уеннан, гомумән,

уйнаучылардан разый булмадыкларын ишетергә тугры килде. Халык күп иде. Җәмгыятькә шактый файда калса кирәк.

*Г. Кәрам. «Аң», 1917, 5 нче сан (31 май)*

(Бу спектакль Казанда, Новый клуб залында Бөтен Русия мөслимәләренең (хатын-кызларының) 24 апрельдә булган җыелышы вәкилләренә күрсәтелгән.)

### *«Зөләйха»ны сәхнәгә кую хакы*

«Зөләйха»ны сәхнәгә кую хакын Гаяз әфәнде өч елга «Сәйяр» труппа мөдире Габдулла Кариевка тапшырды. Шул өч ел эчендә пьесаны сәхнәгә кую хакы фәкать Г. Кариев кул астындагы труппада гына булып, Гаяз әфәнде «Зөләйха»ны сәхнәгә куярга һичкемгә рөхсәт итә алмаячак. Кариев «Зөләйха»ны куярга 1918 елның җәендә Идел буе, Кавказ, Төркестанга гастрольләргә чыгарга бурычлы булып, бу пьесаны иң азыннан егерме мәртәбә куячактыр. Шулай ук Кариев бу көчле пьесаны мөмкин кадәр тулырак, гүзәлрәк, тиешле әсбапларын җитештеребрәк куярга иҗтиһад сарыф итәчәктер. Бундан соң «Зөләйха»ны кую хакы Габдулла Кариевның хокукый милкедер.

*«Ил», 1917, 28 май (25)*

### *Съезд бетү мөнәсәбәте белән вәкилләргә зыяфәт бирелү*

Мәскәү «Мөселман комитеты» 12 майда, кич Әсәдуллаев мәктәбендә съезд вәкилләрен кунак итә. Мәҗлескә дүрт йөздән артык вәкил килә. Төрле уеннар, котлаулар була. Г. Исхакыйга хатын-кыз галәменең хөррияте өчен тырышканлыгы, шул юлда беренче сафтагы көрәшче булганы өчен рәхмәт йөзеннән адрес һәм язу әсбабыннан гыйбарәт бүләк тәкъдим ителә.

*«Ш. Ә.» «Ил», 1917, 28 май (25)*

### *Белдерү*

Мәскәүдә булган Бөтен Русия мөселманнарының Беренче съездында «Милли шура» оештыру хакында олуг мөхәрриремез Гаяз әфәнде Исхакый тарафыннан укылган вә съезд кабул иткән доклад китап итеп басылып чыгып сатыла башлады.

Москва, контора газеты «Ил», Пятницкая, 13

*«Ил», 1917, 4 август (47)*

(Доклад «Мәскәүдәге Беренче мөселман съездында «Милли шура» тәэсис итү хакында Гаяз әфәнде Исхакый тарафыннан укылган вә съезд кабул иткән мәгърүзә. Нашире «Мөселман халык комитеты», М. Шәрекъ басмасы, 1917 ел, исеме белән басылып чыга.)

### *Уфа хәбәрләре*

Уфада Гыйззәтуллина-Волжская җитәкчелегендәге «Нур труппасы» артистлары тарафыннан Г. Исхакыйның «Кыямәт» исемле ике пәрдәлек комедиясе беренче мәртәбә тамашага куела.

*«Тормыш», 1917, 25 октябрь (740)*

## ПУБЛИЦИСТИКА

**Әхмәт**
**Галиев**

# БЕР ҺӘЙКӘЛНЕҢ ТАРИХЫ



**Редакциядән:** *Әлеге гыйбрәтле хикәятне сөйләүче — Әхмәт Мөхетдин улы Галиев — 1931 елны Арча районының Сеҗе авылында ишле гаиләдә 8 нче бала булып дөньяга килә. Туган авылыннан 4 чакрым ераклыктагы Чуриле җидееллык (рус) мәктәбендә укый. Аннан соң, Казандагы авиация техникумын тәмамлагач, башкалабыздагы моторлар төзү заводына эшкә җибәрелә һәм, бер үк вакытта производстводан аерылмыйча, авиация институтында һөнәрен камилләштерә. Белемгә сусаган бу егет аспирантура һәм Мәскәүдә Халык хуҗалыгы академиясен тәмамлый.*

*Ә. М. Галиев — хезмәт юлын, гомерен, нигездә, Куәтле компрессорлар һәм уникаль суыткыч машиналар төзүгә багышлаган шәхес. Ул 7 ел дәвамында махсус компрессорлар төзү бюросының баш инженеры, 24 ел буе Казан компрессорлар төзү заводының директоры һәм генераль директоры булып эшли.*

*Әхмәт Мөхетдин улы — техник фәннәр докторы, академик, СССР Министрлар Советы премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының атказанган машиналар төзүчесе. Ул — Хезмәт Кызыл Байрагы, «Халыклар дуслыгы» һәм «Почет билгесе» орденнары кавалеры. Галим новатор, рационализатор буларак, Әхмәт әфәнде илледән артык фәнни-техник хезмәтләр авторы.*

*Ә. М. Галиев — компрессорлар төзү заводында эшләүчеләрнең социаль яшәү шартларын яхшыртуда, торак йортлар төзүдә, азык-төлек мәсьәләләрен һәм матди проблемаларны хәл итүдә, Татарстанның дәүләтчелеген торгызуда һәм мәгариф, сәламәтлек саклау, әдәбият-сәнгать өлкәләрендә эшләүчеләргә һәртөрле ярдәм күрсәткән мөхтәрәм асыл затларның, зыялыларыбызның берсе.*

*Хәзер сезнең игътибарга аның бер хатирәсен тәкъдим итәбез. Ул аның җәмәгате — мөгаллимә* ***Гөлчәчәк ханым Галиева*** *хикәяләвендә бирелә.*

...Бөек рәссам Бакый ага Урманче белән күрешеп, якыннан танышуым 1981 елның көзендә булды.

«Менә бүген дә эш көне үзенең мең төрле мәшәкатьләре, борчулары белән узып китте»,— дип торганда, кинәт кенә, кабинетыма нык борчылган һәм нидәндер коты алынган хәлдә заводның партком секретаре Воротынов белән ярдәмчем килеп керде. Воротынов ашыга-ашыга:

— Безне иртәгә сәгать икегә райком бюросына чакыралар. Көн тәртибе: «Беркутовский» совхозында кишер алуның барышы. Һәм Сездән аңлатма чыгыш таләп ителә»,— дип белдерде. Әйе, ул вакытларда без һәр көнне өчәр йөз кешене совхозга эшкә җибәрергә тиеш идек. Мин аларга:

— Алайса, мине башка мәсьәләләр белән борчымагыз, телефоннан шылтыратучылар булса да, тоташтырмагыз. Баш инженерга әйтегез, безнең заводның соңгы вакытта Советлар Союзында беренче тапкыр эшләнә торган уникаль машиналар төзүе турындагы плакатларны һәм таблицаларны хәзер үк миңа кертсен. Иртәгә бюро өчен алар миңа бик кирәк булачак. Бюрога ныклабрак әзерләнергә туры килер,— дидем.

Воротынов белән ярдәмчем, бик гаҗәпләнеп, бер-берсенә карашып куйдылар. «Бу плакатларның кишер алуда ни катнашлары бар икән?» — дип уйлап алдылар, ахрысы. Шулай да ачыктан-ачык сорарга кыюлыклары җитмәде булса кирәк, ашыгып чыгып киттеләр...

Әйе, ул заманнарда партия органнары барлык эшләребезгә кысыла иде: язгы чәчүләр, көзге урып-җыюлар башланды исә, заводның нинди продукция чыгаруын да онытып җибәрәләр. Үзебезнең төп эшебезнең барлыгын шушы плакатлар һәм таблицалар аша югарыдагыларның исләренә төшереп алу иде ниятем.

Күп тә үтмәде, ярдәмчем, гаепле кеше сыман, ишекне яңадан ачып:

— Гафу итегез, сезгә йомышым бар, дип рәссам Бакый Урманче шалтырата, аңа нәрсә дип әйтим икән? — диде. Мин, шунда ук бөтен эшемне читкә куеп, телефон трубкасын алдым:

— Бакый ага, Сезне Әхмәт Галиев ихлас күңел белән тыңлый!..

— Рәхмәт, туганкай, озак көттермәдең,— дип сөйләп китте рәссам, илаһи гөрләп торган матур, ягымлы тавышы белән. Искиткеч итагатьле мөрәҗәгате белән ул мине бик тиз әсир итте:

— Әхмәт әфәнде, минем Сезгә булган гозеремне телефон аша гына хәл итеп булмаячак. Үзегез белән очрашып сөйләшү бик тә кирәк иде. Кайчан кабул итә алырсыз икән?

— Бакый ага, Сезнең үзегез өчен кайсы вакыт уңайлы — үзегез билгеләгез,— дидем.— Сезнең белән очрашуга мин бик шат!.. Туктагыз, алайса болай хәл итик: мин Сезгә иртән сәгать тугызга машина җибәрермен. Адресыгызны әйтегез, ә көндезге икегә минем үземне райком бюросына чакыралар. Иртәнге якта очрашу мәслихәтрәк булыр!..

Бакый ага шатланып риза булды, ә үзем уйга калдым. Мәгърифәт, әдәбият, сәнгать өлкәсендә эшләүче шәхесләрнең һәрвакыт ярдәмгә мохтаҗ булулары минем өчен яңалык түгел иде инде. Аларга көчемнән һәм кулымнан килгәннең барын да эшләргә тырыша идем. «Халкыбызның бөек рәссаме Бакый ага кадәр Бакый ага да минем ярдәмгә мохтаҗмы әллә?! Ни өчен әле ул минем белән очрашырга тели икән?» — дигән сорау кич буе миңа тынычлык бирмәде. Хәтта минем өчен күп вакытта җәза бирү урынына әйләнгән райком бюросына барачагым да мине бу уйлардан арындыра алмады...

Ниһаять, иртәгесен Бакый ага белән очраштык. Сул кулына таяк тоткан, бераз аксабрак, әмма аякларына нык басып, гаҗәеп мөлаем йөзле, ап-ак чәчле, пәһлевандай таза, төз гәүдәле мәһабәт ир-зат — Бакый ага — ишектән килеп кергәч мин аның каршысына ашыктым. Телефоннан сөйләшкәндә үк күңелемә үтә дә хуш килгән олпат рәссам-сынчы бу юлы үзенең бөтен торышы, күргән һәр кешене сокландырырлык матур саклануы белән йөрәгемне яулады. Йа, Хода! Кем генә теләмәс икән үзенә шундый матур-сәламәт картлык килүен! Бөтен гомерен газиз халкы өчен армый-талмый иҗат утында дөрләп үткәргән һәм хәзер инде тугызынчы дистәсен ваклап баручы бу бөек шәхес алдында «картлык» сүзен телгә алу да килешмәс кебек...

Күрешкәч, Бакый ага күрсәтелгән урынга салмак кына килеп утырды да, гарәпчәниләрдер әйтте. Бәлки, бу аның ниятләгән эшенең уңышлы барып чыгуын теләве булгандыр... Бәлки, бу эшне башкаручыларның күңелләренә миһербан сал, дип Аллаһы Тәгаләгә догасын юллагандыр... Ни генә булмасын, үзен ул күптән күрешкән-белешкән танышлардай иркен тотты һәм ашыкмый-кабаланмый гына сүз башлады:

— Әхмәт туган! Минем гозерем бик зур бит. Сезне тапканчы, кемнәргә генә мөрәҗәгать итеп карамадым. Хәтта Казаннан тыш, кою цехлары булган Зеленодол, Чаллы, Бөгелмә шәһәрләрендәге предприятиеләргә дә барып чыктым. Тик берсе дә миңа ярдәм итә алмадылар, әллә инде — теләмәделәр... Соңгы өмидем — Сез калдыгыз. Инде Сез дә гозеремне кире каксагыз, белмим, кая барып бәрелермен... Эш менә нәрсәдә, Әхмәт туган: мин халкыбызның күренекле шагыйре Шәйхи Маннурга туган ягы Мамадышта һәйкәл куйдыру теләге белән йөри идем. Бу — минем изге бер теләгем. Менә шул һәйкәлне Сезнең заводта бронзадан коеп булмасмы икән?

Ул шулай диде дә, башын бераз кыңгыр салып, эчкерсез бер елмаю белән күзләремә текәлде.

Һич көтелмәгән бу сораудanмы, Бакый аганың үтенечле ачык зәңгәр күзләре тәэсиреннәнме, мин югалыбрак калдым булса кирәк. Күпмедер вакытка кабинетта тынлык урнашты. Заводта хәл бик киеренке, кою цехында аерата. Көнне төнгә бәйләп эшләгән вакыт. Заводка нефтьчеләр өчен («Газлифт ысулы» белән — нефтьне җир өстенә чыгару өчен!) куәтле компрессорлар төзергә зур заказ килгән чак. Аның өстенә, әле безнең илдә беркайчан да эшләнмәгән, тәүлегенә 1360 тонна күләмендә сыек аммиак эшләп чыгару өчен кирәк булган компрессорлар төзү заказы да бар. Тагын илдә төзелә торган су асты көймәләре һәм крейсерлар өчен кирәкле искиткеч җегәрле суыткыч машиналарның да заводта — җирдәге сынаулары барган чак иде. Бу эшләрнең берсен дә калдырып торырга — ярамый иде...

Шулай да Бакый абыйга да бик ярдәм итәсе килә иде. Милләтебезнең горурлыгы, халкыбызның йөз аклыгы саналган шушы мөгътәбәр кеше, олы башын кече итеп сиңа килгән икән инде — бирәр чарасын тапмыйча ярамый. Министрлыктан рөхсәт алудан башларга кирәктер, мөгаен. Юк, рөхсәт бирмәячәкләр. Заказлар күп, һәйкәл кою өчен акча тапмаячаклары көн кебек ачык. Хәер, акчасын ничек тә юллар идек әле. Безнең заводта бит бронза кою технологиясе һәйкәл кою өчен көйләнмәгән. Ничек бу хәлдән чыгарга соң? Күп күләмдәге бронза бик кыйммәткә төшәчәк. Бу эретмәне алу өчен Госснаб заводларга аның һәр килограммын төгәл үлчәп кенә бирә. Әгәр югары даирәләрне «алдап», бу бронза күләмен югарыда санаган заказлар хисабына керткәндә, иртәме-соңмы бу хәлләр турында анонимкаларның төрле тарафларга очасына минем шигем юк иде. Чөнки ул елларда заводка кергән һәр яңалыкны мөмкин кадәр каралтырга теләп, югары даирәләргә аноним хатлар еш ява иде. Мондый «язмалар»дан соң, гадәттә, заводта айларга сузылган тикшерү эшләре бара иде. Кайчакта предприятиебездә берьюлы 10—12 шәр тикшерү комиссиясе эшли иде. Әгәр һәйкәлне эшли калсак, шундый тикшерүләр вакытында бу шөгыльнең минем «яңа җинаятем» итеп билгеләнәсе дә көн кебек ачык. Моңарчы әдәбият-сәнгать әһелләренә, мәктәпләргә, сырхауханәләргә кылган кайбер игелекләрем дә шундый ук «җинаятьләр» дип бәяләнеп, хәләл акчамнан кайбер айларда шактый гына хезмәт хакымны тотып калулар белән төгәлләнә иде. (Бу матди җәзаның «фәнни» исеме — «начет ясау» дип атала иде. Ул, 1 айлыктан алып, 3 айлык хезмәт хакы күләмендә билгеләнеп, шул сумманы тутырганчы, ай саен 20—25% акчаны тотып калалар иде). Министрлыктан һәм партия органнарыннан шелтә, каты шелтәләр бирүләр гадәти бер күренешкә әйләнде. Боларның барын да Бакый абзыйга сөйләп утырып булмый бит инде...

Бераз алгарак китеп, шуны да әйтим әле: чыннан да, һәйкәлне булдырып чыгабыз бит, дип куанып кына йөргән бер көнне Мәскәүдән Главка начальнигы П. Г. Деев шылтыратып: «Сез нәрсә анда, хөкүмәт куйган бурычларны үтәү урынына, завод номенклатурасына бөтенләй туры килмәгән һәйкәлләр кою эшенә күчтегезмени? Безгә шундый хәбәр килде», — диде. Бу сөйләшүдән соң заводка яңа тикшерү киләчәге көн кебек ачык иде. Шуңа күрә үзебезнең Мәдәният министрлыгыннан һәйкәлне коярга рөхсәт сорап язган хат соратып алырга туры килде. Ярый әле, Бакый ага бу хәлләрне белмәде. Бу турыда сөйләп, аның сабыйларча шатланып та, дәртләнеп тә йөргән көннәренә күләгә төшерәсем килмәде. (Соңрак заводтан, эшчеләр исеменнән, тугыз ел буена төрле тарафларга киткән дистәләгән анонимкаларның тугыз ел партком секретаре булып эшләгән Воротынов тарафыннан язылган булуы ачыкланды. Һәм ул, коллективта үзенә карата туган нәфрәткә чыдый алмыйча, тиз арада заводтан гына түгел, Казаннан ук чыгып китәргә мәҗбүр булды).

Аннан соң бу эшне фәкать сменадан соң калып кына эшләп булачак. Андый очракларда эшчеләргә дә, белгечләргә дә эш хакы артык түләнелә... Әгәр дә бу «киртәләр»нең барын да тезеп-санап утырсам, Бакый ага моны үз үтенечен кире

кагу дип аңлар иде. Нишләргә??? Бу чорда мондый заказ югары оешмалардан булса да, бездән җавап шунда ук: «Бу эш — мөмкин түгел!» — дип тәмамланыр иде. Ә бит каршымда сынлы сәнгатебезгә нигез салган, халкына турылыклы фидакарь хезмәте өчен күпме фаҗигалар кичергән бөек рәссам Бакый ага үзе утыра. Бу бит аның милләтебез өчен — шәхси үтенече. Һәм бу гозерне ничек кенә булса да үтәргә кирәк! Ләкин моны нинди юллар белән хәл итеп булыр икән? Әнә шундый сораулар чигәмне бораулый башлады. Шагыйрь Шәйхи абый Маннурны да шигырьләре буенча яхшы беләм. Аның Муса Җәлил эзләре буенча язылган романын да яратып кабул иткән идем.



*Язучы Шәйхи Маннурга Татарстан Югары Советы Президиумы Рәисе С. Батыев хөкүмәт бүләген тапшыра.*

Әйе, Шәйхи абый — һәйкәлгә бик лаек зат. Татар әдәбиятында үзе исән чагында ук классигыбыз булып санала башлаган, япь-яшь килеш орден алган, һәр бала күңеленә «Гайҗан бабай» поэмасы белән кергән олуг шәхесебез бит ул безнең! Хәтта, вафаты алдыннан, бар булган байлыгын туган авылында (Тулбайда) китапханә салдырырга васыять итеп калдыруы гына да бу шәхеснең олы җанлылыгын раслап тормыймыни?! Юкка гына Бакый ага әлеге шагыйрьнең скульптурасын койдыру өчен җан атып йөрмидер...

Эшләргә, ничек кенә булса да эшләргә! Шәхси карточкага язып, шелтәнең «майлысын» чәпәсәләр чәпәрләр. Бер кисәтү артык яки ким булудан гына тормышым да әлләни үзгәрмәс. Куркып калырга ярамый. Әнә бит Бакый ага, нинди авырлыклар күрсә дә, йөрәгенә ачу ташы җыя бармаган. Аның кешеләргә йөрәге ачык. Һаман матурлыкны, гүзәллекне мәңгеләштерү турында кайгырта. Башкалар турында кайгыртудан тәм таба. Төрмәләрдә, Соловкиларда утырганда да үзенең көчле рухын, эшкә сәләтен, тормышны ярата белүен саклап кала алган. Динебезнең фарыз кануннарын үти барырга да, үзенең мәңгелек түгеллеген белеп, 17—18 әр сәгать эшләргә дә, иленә һәм намусына тугры калырга да көч тапкан ул үзендә. Мөгаен, аңа бу көчне халкыбызны чиксез ярату, үз эшенә фанатикларча табыну, тормышка куш куллап ябышып яту һәм киләчәккә өмет белән карау биргәндер.

Һәм мин ныклы карарга килдем. Бакый ага әйтмешли, җан биргәнгә җүнен дә бирер Ходай! Шундый фикергә килгәч, ничектер, җинел булып китте. Хәзер инде мин бу мөхтәрәм затның күзләренә туры карап сөйләшә алам.

Мин сүземне аның ниятен хуплаудан башладым.

— Ләкин, — дидем мин, — Сезнең изге теләкне тормышка ашыру юлларын бергәләп эзләргә туры килер!..

Безнең заводта ел саен 7000 тоннадан артык чуен коелганын һәм цехта берничә төр маркалы чуеннар белән эш иткәнебезне сөйләдем. Бәлкем, бу һәйкәлне бергәләп чуеннан коеп булмас микән, дигән фикеремне дә әйттем. Бу тәкъдимемне көчәйтү һәм дәлилләү өчен чуенның кайбер төрләренең атмосфера үзгәрешләренә бирешмәгәнлеген һәм күгәрмичә мең елларга түзә алуын белдердем. Аннан соң, моңарчы бронзадан коелган һәйкәлләрнең тора-тора яшел төскә кереп, өстәвенә, тузан белән аралашып, ямьсезләнгәннәрен дә искәртеп үттем. Һәм бездәге тәҗрибәле белгечләр белән сөйләшеп карарга кирәклеген әйттем.

Алар, бәлкем, безгә яңа берәр сер ачарлар, дигән фикеремне дә өстәдем. Бакый ага мине бүлдермичә, үзенә генә хас сабырлык белән тыңлады. Әмма, мин аның йөзеннән һәйкәлнең тууына ышанып бетмәү, шикләнү кебек чалымнарны күреп алдым. Җитмәсә, безнең сөйләшү барышында Мәскәү министрлыгыннан, райкомнан шылтыратулар һәм аларның шактый усал сөйләшүләре дә Бакый абыйга авыр тәэсир итми калмагандыр. (бик тә сизгер кеше иде бит ул!)

— Мин кузгалыйм инде, Әхмәт туган. Белгечләрегез белән фикер алышкач, яңадан бәгланышка керербез әле. Ничек кенә булмасын, бу һәйкәлне ясарга кирәк иде,— дип торып басты да җитди генә саубуллашты. Мин дә, үз чиратымда, бөтенләй өмет өзмәскә киңәш итеп, мөмкин кадәр игътибарлы һәм ихтирамлы булырга тырышып, Бакый аганы озатып калдым. Аннары шунда ук үземнең гадәти-көндәлек эшләремә чумдым...

Һәйкәлне эшләү өчен кирәк булган чаралар белән шөгыльләнүне икенче көнгә калдырырга туры килде. Көндәгечә цехларга йөрү графигын бозып, иртәгесен сәгать сигезгә чуен коюю начальнигы В. К. Каменскийны һәм коюю эшләренең барлык нечкәлекләрен яхшы белгән баш металлург урынбасары Н. Т. Сафроновны үз яныма чакырдым. Каралачак мәсьәләнең темасын алдан әйтеп тормадым.

Иртәгесен бу белгечләр әйтелгән вакытка, кыяр-кыймас кына, кабинетыма килеп керделәр. Баһадир гәүдәле, төскә бик тә чибәр, гомумән, хатын-кызларны бер күрүдә гашыйк иттерә алырлык, Гомәр Хәйямның шигырьләрен яттан белгән Владимир Константинович Каменский ул көнне аеруча борчулы күренде.

Бу чорда коюю цехының эше бик тыгыз иде. Бер яктан, заказларның күп булуы һәм югары чыдамлыктагы чуеннан «Газлифт» компрессоры өчен эшләнә торган кайбер детальләрнең коюю технологиясе җайланып җитә алмавы эчне пошырса, икенче яктан, төрле маркалы кайбер төсле металларның кирәкле дәрәҗәдә җитмәве сәбәпле, графикны үти алмавыбыз тынычлыкны ала иде. Җитмәсә, бу очрашуның райком бюросы утырышыннан соң икенче көнне үк булуы егетләрнең икесен дә, безнең өчен бу инде бюроның дәвамы булса кирәк, дип нык шүрләткән булып чыкты. Әле ни өчен чакырылуларын да белмәстән:

— Сез безгә 75 кешене кишер алырга җибәрмәскә рөхсәт итеп, үзегезне яңадан уңайсыз хәлдә калдырдыгыз. Сезгә бирелгән шелтәдә безнең дә өлешебез бар, дип саныйбыз,— диештеләр.

— Хәзер Сезгә графикны үти алмавыбызның сәбәпләрен аңлатырга җыенабыз,— дип янә сүз башлады Каменский. Мин аның сүзләрен бөтенләй игътибарсыз калдырып, ике тонна тирәсендәге чуеннан зур бер шәхескә һәйкәл коярга кирәклекне белдердем. Алар, һич тә көтелмәгән бу белдерүдән аптырап, күзләрен зур итеп ачып, шаккатып калдылар. Шул ук вакытта җилкәләрендәге тау кадәр йөктән котылгандай, йөзләрендә шатлыклы елмаю да күреп алганым хәтеремдә. Бераздан үзләрен кулга алып, төп эшләрендәге кайбер кыенлыкларны да җайлап бетерә алмаган бервакытта, бездә һәйкәлләр коюю технологиясенең бөтенләй эшләнмәвен, бу заказны берничек тә үтәп булмаячагын әйтеп салдылар. Ә баш металлургның ярдәмчесе Сафронов, форсаттан файдаланып:

— Әхмәт Мөхетдинович, әле Сез, цехның авыр хәлен аңлап, безгә ярдәм итәргә уйлыйсыз ахыры, дип өмет иткәндә, чуен коюю технологиясенә бөтенләй аңа хас булмаган бурычлар куясыз икән! — дип, һөҗүмгә үк күчте. Каменский исә, Сафроновның үз-үзен шулай тотышы сөйләшүне ямьсезли күрмәсен тагы, дигәндәй, йомшак кына, хәйләле бер елмаю белән:

— Әхмәт Мөхетдинович, мөмкин булса, турысын гына әйтегез әле, бу һәйкәлнең коелуы Сезнең үзегез өчен дә кирәкме? Заказ югары оешмаларданмы? Чыгымнарны, эш хакын түләүне үз өсләренә алалармы? Һәм ул кемгә коелачак һәйкәл? — дип, сорауларын тезеп китте.

Мин аларга бу заказның, халкыбыз горурлыгы булган бөек рәссам Б. Урманче соравы буенча, шагыйрь Ш. Маннурның туган җире Мамадышта куелырга тиеш һәйкәл икәнлеген аңлаттым. Үземнең дә бу һәйкәлгә карата теләктәш булуымны белдердем. Әлеге мөһим эшне коюю цехының ширпотреб планы хисабына үтәп булыр, дигән фикеремне дә әйттем. Чөнки ул елларда халык өчен киң куллану товарлары эшләү планы зурдан иде.

Әгәр дә эшне Бакый ага теләгәнчә һәм бик озакка да сузмыйча башкарып чыга алсалар, бу хезмәттә катнашкан һәрбер кеше бер айлык хезмәт хакы күләмендә премия алачакларын да әйтергә онытмадым.

Зыялыларыбыз турында сөйләгәндә, күрәсең, шәхсән үзем дә дулкынланыбрак киткәнмендер. Дулкынлануым егетләргә дә күчте. Егетләрнең күзләре дә очкынланып китте, үз-үзләрен тотышлары да бөтенләй башка юнәлеш алды. Булачак һәйкәлнең макетын кайда, кайчан күрергә мөмкин булуын ачыкларга


куштылар. Мин шунда ук Бакый абыйга шылтыратып, егетләрнең теләгән әйттем. Ул моңа бик шатланып, иртәгә үк остаханәсендә очрашу билгеләде.

Безнең белгечләр Бакый ага белән очрашып, Ш. Маннур һәйкәле өчен эшләнгән макет белән танышып кайтканнан соң, кою цехында эшләүче мастерлар һәм эшчеләр белән үземә очрашырга кирәк булыр, дигән фикергә килдем. Чөнки форма ясаучыларга да, чуенны эретүчеләргә дә, коючыларга да һәм коелачак һәйкәлне саклык белән генә эшкәртүчеләргә дә бу эшнең бик әһәмиятле икәнен аңлатырга кирәк иде. Һәм бу очрашу вакытында мастер Мәгъдүт Тимерханов, форма ясаучылардан Иван Коломин, Александр Булавинко, Владимир Кулагин, чуенны эретүче һәм аны коючы Михаил Сухорский, коелган һәйкәлне эшкәртүче (обрубчик) Фидаил (фамилиясен хәтерләмим) сварщик (эретеп ябыштыручы) Мәсгут Хисамовларның сүз сөрешләрендә, кыяфәтләрендә, бу заказны эшләп булмас, дигән шикнең булмавы мине бик сөендерде. Мактап та алдым үзләрен.

Билгеле булганча, һәр хезмәтнең үзенә генә хас серләре була. Эшчеләр аларның барысын да ачып салырга яратмыйлар да. Үз һөнәрләрендәге башкалар белмәс серләрнең хуҗалары булу аларга эчке бер горурлык хисләре бирә. Осталарның бу хисләренә ихтирам белән карасаң, синә да шундый ук эчке бер җылылык белән җавап бирәләр. Бу юлы да шулай булды. Алар, әлеге һәйкәлне эшләп чыгу өчен кимендә ярты ел вакыт кирәк булачагын белдереп, Бакый аганың үзен дә күреп-сөйләшәсе килүләрен әйттеләр. Мин исә үз нәүбәтемдә:

— Мөмкин кадәр вакытны кыскартырга тырышыгыз инде, егетләр! — дип, зур бер җиңүгә ирешкәндәй сөенеп, цехтан күтәренке күңел белән чыгып киттем.

Берничә көннән соң Бакый ага белән киңәшеп, һөнәр осталары теләгән бу очрашуны да оештырдык. Бөек рәссам заводта күп кешеләрне кызыксындырып өлгергән иде инде. Минем барлык ярдәмчеләрем һәм күп кенә белгечләр, утырышлар бүлмәсендәге зур өстәл янында (25 ләп кеше), дулкынланып, Бакый аганы көтә башладылар. Күп тә үтмәде, хәләл җефете Флора ханым белән, мөләем елмаеп, Бакый ага үзе дә күренде. Безнекеләр аларны, класста мөхтәрәм мөгаллимнәрне көткән укучы балалар кебек, дәррәү күтәрелеп — аягүрә басып каршы алдылар һәм барысы да бик җылы итеп исәнләштеләр. Безнең хезмәткәрләр күрсәткән тирән хөрмәттәнме Флора ханымның күңеле тулып киткәне әле дә хәтеремдә. (Чын татар хатыны буларак, ул Бакый агага — гали затка — тиешле дәрәҗәдә ихтирам, күтәренкеюгары караш булдыру өчен җан атып йөри иде.— Ә. Г.) Сөйләшүләр барышында һәйкәл өчен СЧ — 20 маркалы көрән чуен кирәклеге һәм эшнең барышы 5—6 айларга сузылачагы ачыкланды. Бакый аганы кайсы хезмәтнең кемнәр тарафыннан башкарылачагы белән дә таныштырдык. Иртәгә үк һәйкәлнең макетын заводка алып килү өчен, Б. Урманче остаханәсенә машина җибәрергә дә килешендек. Бу минутларда Бакый ага шат, бик шат иде. Хәтта зәп-зәңгәр күзләре дымланып та алган кебек булды. Һәйкәлнең туачагына ул инде тәмам ышанып җитте булса кирәк!..



*Б. Урманче Ш. Маннур һәйкәлен иҗат итә.*

Егетләр дә — әллә инде бу бөек зат белән очрашуданмы, рәссамның бу изге эшләренә ихтирамнары, сокланулары арта баруданмы — бик теләп, эш сәгатьләрен дә санап тормыйча, үзләре өчен өр-яңа иҗатка чумдылар. Эшне ярты елга да сузмадылар — Бакый аганы таң калдырып, дүрт айда төгәлләп тә чыктылар. Һәйкәлне карарга янә Бакый ага Флора ханым белән бергәләп, бу юлы инде кою цехына килделәр. Һәйкәл коелып беткәч, аны тәмам хәзер хәлгә керткәннән соң мине цехка, Бакый ага белән бергә, эшне кабул итәргә дәштеләр. Егетләрнең эшеннән бик тә канәгать

булып, шатланып, аларга үз вакытында вәгъдә иткән премияне шушы көннәрдә бирәчәкләрен ышандырдым. Ә бөек рәссамның йөзендәге илаһи балкышны күрү — минем өчен иң югары бүләк — бәя иде!.. Хәзер, еллар узгач, уйланып утырам: менә шул вакытта һәйкәл янына Бакый аганың үзен һәм аның заказын үтәүдә бик теләп катнашкан егетләрне бергә бастырып, фоторәсем ясалган булса, нинди тарихи истәлек буласы булган, югыйсә. Юк шул, минем ул вакытта алда санап үтелгән машиналарны тапшыру вакыты иде. Шул ук көнне, хәтта Бакый аганы заводта калдырып, үзебезнең министрның кушуы һәм Украина Политбюросының чакыруы буенча, Ровно шәһәренә очарга туры килде...

Бакый ага, әйткәнемчә, безнең заводта башкарылган эштән ифрат канәгать иде.

— Әхмәт туган, һәйкәл нәкъ үзем теләгәнчә килеп чыкты бит! — диде ул, сабый балаларча ихластан сөенеп. — Дөресен әйтим: Сез һәйкәлне, бронза урынына, чуеннан коярга тәкъдим иткәч, ул болай ук уңышлы чыгар, дип һич өмет итмәгән идем. Сезгә, сезнең оста куллы егетләрегезгә Алланың рәхмәтләре яусын! Шушы эш барышында, дүрт ай вакыт эчендә, сезнең заводның хәтта алдынгы капиталистик илләр өчен дә катлаулы уникаль машиналар эшли алуы, аннары бик тә күркәм, акыллы, бай тәҗрибәле эшчеләрегез һәм белгечләрегезнең күп булуы мине сөендерде. Сезнең заводта, үземнең яраткан эш процессымда шатлыклы көннәр кичердем. Һәр тарафтан үземә карата тирән хөрмәт күрү дә җаныма рәхәтлек биреп торды. Барысы өчен тагын бер мәртәбә олы рәхмәтемне белдерәм! Әгәр, вакытыгызны бүлеп, миңа килә алсагыз, мин бик тә теләп сезнең портретыгызны язар идем...

Аннары тагын Сезнең белән бүлешәсе кайбер уй-фикерләрем дә бар. Шәйхи Маннур һәйкәленең куелу урыны турында да ризасызлыгымны әйтәсем килә. Дөрес, төп урыны әйбәт, Мамадышның нәкъ үзәгендә, матур паркта. Сүз биредә постаментның күңелемә хуш килмәве турында бара. Ленин һәйкәлен аннан алып куялар да, шагыйрьнең һәйкәлен шул биеклеккә менгереп урнаштыралар. Ул постамент һич кенә дә шагыйрь өчен түгел. Югыйсә, Маннур һәйкәле өчен үзенә генә хас постамент эшләп кую — нинди катлаулы шартларда һәйкәлне тудыруга караганда — күпкә җиңелрәк иде бит. Нишлисең инде, Әхмәт туган, бу дөньяда күп нәрсәләр без теләгәнчә генә бармый шул...

Аның бу сүзләре мине дә тирәнтен уйландырды. (Шәт, якын киләчәктә бу «ялгыш» төзәтелер дип, ихластан ышанам!)

Ә инде Ш. Маннур һәйкәленә килсәк, чыннан да ул һәркемне сокландырырлык дәрәҗәдә, гаҗәеп матур килеп чыкты. Дөресен генә әйткәндә, үзем дә бу кадәр үк булыр дип уйламаган идем. Күрәсең, бу ифрат та изге эшкә Хак Тәгалә үзе дә бик теләп ярдәм иткәндер, миңа да бу өлкәдә бернинди тикшерү һәм җәзалар булмады.



*Мамадыш шәһәрендә шагыйрьгә куелган һәйкәл бүгенге көндә.*

Һәйкәлнең уңышлы чыгуы тагын бер мәртәбә безнең заводта алтын куллы, зур талантка ия булган чын осталар эшләгәнлекне раслады. Тик менә — ни үкенеч! — ул вакытта үземнең өйдә булмавым сәбәпле, шундый зур, изге эшне ахырына кадәр җиткереп, ягъни һәйкәлне төп урынына матур итеп куюны оештыра алмадык. Гомумән, һәйкәлнең авторы Бакый ага да, Казан компрессорлар заводы тарихында беренче мәртәбә һәйкәл коюны башкаручы инженерлар һәм эшчеләр дә тиешле бәяләмәне ала алмадылар-ишетмәделәр. Бу олы вакыйга, ничектер, матбугатта да, җәмәгатьчелектә дә эзсез генә, тавышсыз-тынсыз гына узды. Фәкать халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев кенә (рәхмәт төшкере!) үзенең «Ачы тәҗрибә» дигән китабында (Ка-

зан, Татарстан китап нәшрияты, 1993 ел) Мамадышка укучылар белән очрашу кичәләренә бер төркем язучылар белән килгән вакытында, һич тә көтмәгәндә шагыйрь Шәйхи Маннурның һәйкәлен очратуы турында болай дип язган иде:

«...Беренче көнебездә Мамадыш мәдәният йортына барабыз, карасак — куаклар, чәчәкләр арасында бер һәйкәл. Мин тынсыз калдым. Шәйхи Маннурга һәйкәл. Бюст. Туктале, туктале, Татарстанда безнең чорда яшәгән кайсы язучының туган ягында һәйкәл куелганы бар? Һәйкәлгә чәчәкләр куябыз. Әйбәт эшләнгән. Шул ук киң бит, шул ук кечкенә күзләр, шул ук кысык иреннәр. Гипстыр инде ул?..»

Безнең тыйнак татар акылы шуннан да ерак китә алмыйдыр, күрәсең. Янарак кына арабыздан киткән һәм әле ниндидер легендалар серенә төрелергә өлгермәгән гади татар язучысына зур бер заводта чуеннан һәйкәл коелып, шәһәр уртасына утыртылыр, дип хәтта мәшһүр язучыбыз М. Мәһдиев та башына китерә алмагандыр, күрәсең. Тагын шунысы да бар: Ш. Маннур һәйкәле бик зур ярымгәүдәдән (полифигура) гыйбарәт, ә Мөхәммәт аны «бюст» дип яза. Татар язучыларына карата кечерәйтелгән караш күңелләребезгә шулкадәр сеңгән ки, хәтта күз алдыбыздагы чуен скульптураны да карага буялган гипс дип кенә кабул итәбез. Бу сүзләр белән хөрмәтле язучыбыз Мөхәммәт Мәһдиевны һич кенә дә кечерәйтергә теләмим. Киресенчә, үз бөеклегебезне озак вакытлар күрми йөрүебез, үзаңыбызны йокымсыраган хәленнән чыгара алмыйча, безнең дә, башка халыклар кебек, зур эшләргә көчебез дә, сәләтебез дә барлыгын күрсәтә алмавыбыз өчен йөрәк әрни.

Җитмәсә, безнең артык тыйнаклыктанмы, әллә кул җитмәүдәнме, һәйкәлнең авторын һәм аның кайда, кайчан, нинди металлдан коелуын һәм кайсы елны урынына урнаштырылуын язган табличка да куя белмәгәнбез. Хәзер, үземнең мөмкинлегем булмаса да, бу эшне завод аркылы эшләтүне сорарга кирәк булыр. Һәм аның эчтәлеген мин болай күз алдына китерәм:

*«Шагыйрь Шәйхи Маннурга һәйкәл.*
*Авторы: Бакый Урманче.*
*СЧ-20 маркалы көрән чуеннан*
*Казан компрессорлар заводында*
*коелды. 1982 елда куелды».*

Кеше гомере, аеруча олыгая башлагач, бигрәк тә тиз уза икән. Әле бит күптән түгел генә иде шикелле Бакый аганың чуен кою цехында эшчеләр белән ихлас әңгәмә алып барулары! Бөек рәссам-сынчының осталар белән уртак тел табып, юк-юк та аларны көлдереп тә алулары сагынып сөйләргә генә калды...

1997 елда Бакый ага Урманченың 100 еллыгына багышлап үткәрелгән юбилей вакыйгалары миндә бу бөек шәхеснең тормыш юлын, иҗатын тагын да тирәнрәк белү ихтыяҗын тудырды. Чаллы шәһәрендә аның бер гасырлык бәйрәменә багышланган шәхси күргәзмәсенең ябылу тантанасында (июнь) катнашу мөмкинлеге тугач, без җәмәгатем белән моңа бик шатланып риза булдык.

Әйе, бу бөек рәссамның бәяләп бетергесез күп төрле иҗади эшләре белән янадан очрашу, анда җыйналган халыкның һәр чыгыш ясаучыны йотлыгып тыңлаулары, Бакый аганың олуг хезмәтләрен аңлап, аларга югары бәя бирүләре бик матур тәэсир калдырды. Анда бигрәк тә мөгаллимнәрнең күп булуы һәм аларның дулкынландыргыч-самими чыгышлары Бакый аганың киләчәк буыннар өчен дә илаһи шәхес-пәйгамбәр булып калачагын күрсәтте. Бу очрашуда Чаллы халкының һәм аның хакимиятенең, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Флора ханым Әхмәтова-Урманчега — Бакый аганы соңгы 25 еллык гомере дәвамында, ягъни 93 яшькә кадәр иҗат көчендә саклый алган газиз хатынына булган тирән ихтирамы безне сокландырды. Аларның безне дә кадерле кунак итеп кабул итүләре күңелләрдә мәңге онытылмаслык хатирәләр калдырды. Чаллының гаҗәеп бер матур, мәгъруր тауларга барып тоташа торган урамына Бакый Урманче исемен бирүләре, янә зур күргәзмәләр сарае төзеп, анда бөек рәссам өчен махсус зал булдырырга тырышулары турындагы хәбәр бирәүне дә битараф калдыра алмады. Флора ханымны чәчәкләргә күмделәр һәм җилкәләренә кәҗә мамыгыннан бәйләнгән зур ак шарф салдылар. Нинди гүзәл мизгелләр!!! Ә бит бу мизгелләрнең тууына төп сәбәпче — Бакый аганың тиңсез иҗади хезмәтләре һәм шәхес буларак та бөеклеге иде...

Шул ук елның 22 июнендә Мамадышта, Шәйхи Маннур һәйкәле янында, Бакый ага Урманче белән янадан очрашкан кебек булдык. Бу көнне биредә район хакимияте (җитәкчесе — Татарстанның халык депутаты Әгъзәм Самат улы Габәйдуллин) һәм тынгысыз язучы-эзтабар, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Шаһинур Мостафинның тырышлыгы-кайгыртучанлыгы белән тагын

бер бик тә кирәкле — мөһим чара тормышка ашырылды. Яу кырында 8 улын югалткан Анага — тыл батыры Фатыйха түти Әхмәдиевага (Урта Кирмән авылы) һәм аның кебек башка милләт аналарына ап-ак һәйкәл куелды. (Һәйкәл-мемориалны әтиле-уллы скульпторлардан Альфрет, Альберт, Гадел Абдрашитовлар иҗат иткән иде. Архитекторы — Рамил Миннеханов...)

Һәйкәлне ачканда миңа да сүз бирделәр. Форсаттан файдаланып, мин, һәйкәлдә сурәтләнгән Ананың бөеклеге — рухи батырлыгы турында һәм бер үк вакытта шушы ук «Хәтер паркы»нда Ш. Маннурга һәйкәл куйган тылсым иясе Бакый ага, аның тиңдәшсез хезмәтләре турында сөйләүне дә кирәк дип таптым. Соңыннан хакимият башлыгы Әгъзәм әфәнде Гобәйдуллин һәм аның урынбасары Шамил әфәнде Хәсәнов безне Шагыйрь һәйкәле янына алып киттеләр. Анда, зур ихтирам белән, Флора ханымга сүз бирделәр. Ул, әңгәмә барышында, Бакый аганың һәйкәл постаментыннан бик үк риза булмаганын да искә төшереп үтте. Һәйкәлдән читтәрәк берничә эскәмия куелса, анда шигъри митинглар, кичәләр уздырыла торган булса, гомумән, бу урын «Шигърият бакчасы»на әверелеп, бик күпләрнең күңелләренә бетмәс-төкәнмәс илһам өстәр, яшь иҗатчыларның тууына ярдәм итәр иде. Үзе бөек рәссам да, шагыйрь дә, җырчы да булган Бакый ага моннан бик канәгать калыр, рухы сөенер иде. Амин, бер үк шулай була күрсен!..

Хәер, бу эшнең үтәләчәгенә без тирәнтен ышанабыз. Чөнки хакимият башлыгы Әгъзәм әфәнде Гобәйдуллинның соңгы вакытларда Мамадыш халкы өчен башкарган күп кенә игелекле эшләре һәркемнең күңеленә хуш килерлек. Ятим балалар өчен бөтен уңайлыклары булган, бик зәвыкле итеп эшләнгән ике катлы мәһабәт йорт үзе генә дә ни тора! Эчендәге җиһазларының, тормыш өчен кирәкле барлык әйберләренең затлы, заманча булуы безне таң калдырды... Яңа төзелгән бинаһая гүзәл мәчет тә әллә кайдан күңелләрне үзенә тартып тора. Без барыбыз да бу мәчеттә Бакый ага рухына багышлап сәдака калдыра алуыбызга шатландык...

Инде бу очрашулардан соң Бакый аганың остаханәсен һәм анда саклана торган хезмәтләрен дә күрәсе килү теләге уянды. Флора ханымның чакыруы белән анысын да күрү бәхетенә ирештек. Биредә булганда, атаклы Останың мәшһүр шәхесләребезгә һәйкәл кояр өчен ясаган сыннары, төрле эскизлары, картиналары, графика эшләренең бихисап күплеге безне гаҗәпләндерде. Ә монда булмаганнарын, ягъни музейларда түрдә урын алганнарын да өстәсәк, берничә кешенең дә гомере җитмәслек эшләр бит бу!.. Юбилей көннәренә ачылып өлгермәгән музей бинасы да бөек рәссам-сынчының барлык хезмәтләрен һич сыйдырып бетерә алмаячак...

Гипс сыннарның вакытлар узу белән бозыла баруларын күрү мине тагын ирексездән 1981—82 елларга кайтарды. Теге вакытта Бакый ага портретымны ясарга дип үзенең остаханәсенә чакырганда, бармыйча калып, нинди хата ясаганымны аңладым да, үкенечләр дәрьясына чумдым. Әгәр шул вакытта һәйкәлләргә әйләнә алмый яткан бу гүзәл сыннарны күргән булсам, барысын булмаса да, кайберләрен, әйтик, якташым, бөек Шиһабетдин Мәрҗанине, Шәехзадә Бабичны, Шамил Усмановны заводта койдыра алган булыр идем бит. Ә мин, имеш, шундый олуг шәхес алдында кукыраеп утырып, портретымны ясдырырга тиеш, кем әле мин ул кадәр, дигән уйлар белән Бакый ага янына бармадым. Эш портрет язудамыни, бәлки аның минем белән иркенрәк шартларда сөйләшергә, киңәшергә теләгән сүзләре булгандыр. Кайбер мәгълүматлар да аласы килгәндер. Ул бит бик киңкырлы шәхес иде!..

Җитмәсә, юбилей көннәрендә К. Миңлебаевның «Бакый» исемле (роман дип исемләнгән) күләмле әсәрен укыгач та, Бакый ага өчен күңел әрнеде. Киләчәктә оста каләмле, киң фикерле, зур тәҗрибәле язучыларыбыз бу темага кабат алынырлар әле. Халкыбызның горурлыгы булган бу бөек зат турында тагын язарлар. Аның фаҗигале язмышын, бөтен тормышын яктырткан һәм шәхес буларак көчле, уңай якларын, көнкүрешендәге матур гадәтләрен ачкан һәм барлык иҗади хыялларын, аларның тормышка ашканнарын һәм ашмый калганнарын да күрсәтә алган әсәрләр туар, дигән өметтә яшим.

Татар рәсеме, сынлы сәнгате өлкәсендә һич кабатланмас искиткеч бай мирас калдырган Бакый аганың исемен мәңгеләштерүдә иң зур эшләрнең берсе — 100 еллык юбилеена Зур Кызыл урамы бакчасында үзенә бик тә ошаган һәйкәлен ачу булды. Әлеге тантана күңелләрдә мәңге сакланырлык чын тарихи вакыйгага әйләнде. Безгә дә анда катнаша алу, һәйкәленә чәчәк бәйләмнәре салу насыйп булды.

Бәлкем, бу урам үзе дә, тора-бара, ошбу җиһанны изге гамәлләре, тиңдәшсез хезмәтләре белән данлаган, күңелләрдә гомер бакый яшәячәк Бакый ага Урманче исемен алыр әле!..

# МУЛЛА ШАГЫЙРЬ



Әлегәчә дин галиме буларак кына танылган Яңа бистә имамы Садыйк хәзрәт Иманколыйның 1923 елның октябрь аенда төзелә башланган (ул 60 биттән тора) «Диван мулла Садыйк Иманколый» дигән һәм 1927 елда башланган 14 битле «Әсрари дил» («Күңел серләре») исемле кульязма җыентыклары табылды. Җыентыктагы әсәрләр арасында гасыр башы әдәбиятыбызның истәлекле күренеше саналырлык шигырьләр шактый; алар сан ягыннан да саллы гына,—бу мираста 200 ләп шигырь теркәлгән. Күпчелек—шактый күләмле. Һичшиксез, ул көннәр кәйфиятен чагылдырган, үзенчәлекле осталык белән иҗат ителгән әлеге шигырьләр әдәбиятыбызда үз урыннарын ияләргә тиешләр.

Садыйк Шаһиәхмәт улы Иманколый 1870 елда Казанда мулла гаиләсендә дөньяга килә. Аның әтисе Казанның сигезенче мәчете (Яңа бистәдәге «Кечкенә мәчет»нең) имамы, китапка гашыйк кеше була. Ш. Мәрҗани аның хаҗ сәфәреннән бик күп китаплар алып кайтуына махсус тукталып үтә[1]. Шаһиәхмәт үзе дә каләм иясе булган. Ул—Ш. Мәрҗанинең «Нәзурәтел хак» исемле китабына каршы зур тавыш тудырган «Җәрүдә» китабын бастырган кеше. Садыйк хәзрәт аның яшь хатыныннан туган, күрәсең—малае туганда аңа 67 яшь була. Улына сигез яшь тулганда, ягъни 1878 елда карт мулла дөнья куя. Вафатыннан соң, әҗәт-бурычларын түләү өчен, җыйган акчалары гына җитми, гаилә әгъзалары мулланың бөртекләп җыелган өй җиһазларын, хәтта китапханәсен дә сатарга мәҗбүр булалар. Атасыз һәм милексез калган малай матди яктан авыр тормышта үскән булырга тиеш. Шуңа күрә, бар ышаныч—уку, белем алуда. Ул үсмер чагында ук башка сыймаслык мөстәкыйль карарга килә—кесәсендә бер тиен булмаган хәлендә Бохарага белем эстәргә юл тота. «Үз әхвалем» дигән шигырендә язуына караганда, бу вакытта аңа 14 яшь тула. (Ләкин хакыйкать өчен искәртик, бу хәл һиҗри белән 1303 елда, 1886 елның җәендә, Садыйкка 16 яшь тулган көннәрдә була.)

Казаннан кузгалып, ул ике көндә пароход белән Самарага, аннан поезд белән Оренбурга килеп җитә. Анда ике атналап мәдрәсәдә яшәп, байлар иганәсе ярдәмендә дөя кәрванында Казалы шәһәренә юнәләләр. Утыз өч көн дигәндә анда да барып җитәләр, тагын егерме ике көннән Бохарага да барып ирешәләр. Шул рәвешле, мәдрәсәгә урнашып, гаять авыр шартларда укый башлый. Бу хакта ул болай дип искә ала:

Агыр булды миңа бик анда хәл:
Үзем бик яшь идем һәм кулда юк мал;
Миңа ул хинда дөнья бик тар иде,
Ашарга тапмаган көннәр бар иде.

[1] Ш. Мәрҗани. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан, 1989.—347 б.

Шул шартларда ул Бохарада сигез ел белем ала. 1894 елда Бохарадан хәзерге Красноводский шәһәренә поездда килеп, аннары Каспий һәм Идел буйлап пароходта Казанга кайтып төшә һәм Яңа бистәнең алтынчы мәчетенә, Зариф Әмирхан белән берлектә, шәрик мулла булып урнаша. Соңрак ул гади мулла гына булмыйча, каләм иясе һәм галим буларак та таныла. Ул «Тәрҗемәи руси, фарси вә төрки» дигән сүзлек төзеп, аны 1909, 1913, 1917 елларда кат-кат бастыра. 1910 елда 744 битле «Коръән тәфсире»н әзерләп бастырып чыгара. Башка хезмәтләре дә билгеле (кара: «Мирас», 1995, № 9, 78 б.). Әмма, башка муллалардан аермалы буларак, Садыйк хәзрәт байлык та, зур шөһрәт тә казана алмаган. Шуны искә алып, «Зарлану» шигырендә ул туган халкына киная дә белдерә:

Булса да фазлым, минем кадеремне халкым белмәде,
Хәлемне тәэмин итәргә кулларымнан килмәде.
Үтте гомерем. Бер дә мин мәгыйшәт күрмәдем.
Үтсә дә яшь илледән, һич ат белән мин йөрмәдем.
Безнең өчен һәр вакытта булды авыр көнкүреш—
Ике бистә арасында сумка күтәреп йөреш...

Илдә марксизм-ленинизм тәгълиматына нигезләнгән тоталитар режим тернәкләнеп килгән елларда, руханиларны Иблистән хәтәррәк бер көч санап, аларны тоташ эзәрлекләү башланган бер чорда, шагыйрь Садыйк Иманколый, үз тормышы мисалында, татар халкының көнкүреше хакында ачынып яза. Әйтергә кирәк, татар руханилары көнкүрештә киң катлау крәстиәннәрдән әллә ни аерылмаганнар — алар да иген иккәннәр, мал асраганнар. Әмма рухани катламыннан булган әһли голамә, тулаем алганда, тормыш турында тирәнрәк уй-фикер йөртергә сәләтле булулары белән башкалардан аерылып та торганнар. Шул яктан алар крәстиәннәрнең аң-фикер үсешенә сизелерлек йогынты ясаганнар. Садыйк Иманколыйның иҗаты исә шул тормышны күзәтү, шул хакта уйлану үрнәге ул. Ул илдә барган хәлләр хакында милләт, халык язмышы югарылыгына күтәреп уйлана. Аның иҗатына конкрет бер чорның, нәкъ менә 20 нче елларның моң-зарын чагылдыру хас. Шул ук вакытта бу зарларның бер шәхеснең — Яңа бистә мулласы Садыйк Иманколыйның аһ-зары икәне дә төсмерләнә. Алар хәтта, вакыйганамә чикләренә кертелеп, аерым шигырь темасы да булып киткәннәр («Үз әхвалем», «Шикаят» һ. б.). Бу — Садыйк Иманколый шигъриятенең натурализмга якын бер хасиятен билгеләүче төсмер. Икенче төр шигырьләрендә ул зур гомумиләштерүләргә ирешә, андый әсәрләрдә гүяки вакыт, чор төшенчәсе бөтенләй югала. Шуның нәтиҗәсендә аларда Әхмәт Ясәви һәм Сөләйман Бакыргани кебек борынгы шагыйрьләр иҗатына аваздаш фикерләр дә очрап куя, әйтерсең лә гасырлар да узмаган, тормыш-көнкүреш тә үзгәрмәгән, вакыт бер урында «катып» калган. Әмма бу борынгылык, шагыйрьне дулкынландырган дәрт әсәрдәге моңны төссезләндерми; хәтта, киресенчә, мондый рухи-лирик герой авызыннан әйтелгән ул хисләр үтемлерәк һәм хисләр үткенрәк яңгыраш та таба кебек әле. Шул рәвешле яңа чор шигъриятендә, бай мирасыбызга килеп тоташкан күпер рәвешендә, Садыйк Иманколыйның традицион нигездәге иҗаты туа.

Садыйк Иманколый шигъри мирасының яртысын диярлек дини эчтәлектәге шигырьләр тәшкил итә. Әмма аның, рухани кешенең, иҗади уңышы, югары уңышларга ирешүе дини эчтәлекле әсәрләрендә чагылыш тапмаган. Бу төр шигырьләрендә ул Һибәтулла Салихов кебек шагыйрьләребез казанышларын гына яңа чорларга яраклаштыра кебек. Ә менә дөньяви темаларга язылган кайбер әсәрләрендә ул, безнеңчә, шул чор татар милли аңы үсешендә яңа бер сәхифә ача. Аның бу казанышының мәгънәсен дөнья мәдәни хәрәкәтенең шул юнәлештәге казаныш-табышларына бәйләп, шуңа нисбәтән рәвештә аңлап һәм аңлатып булыр иде. XIX йөздә, капиталистик мөнәсәбәтләр тәмам урнашып житкәч, түбән социаль катлаулар (масса-гавам) иҗтимагый-сәяси тормышта активрак катнаша башлыйлар. Шушы җирлектә шәхеснең вакланыуы, юкка чыгуы кебек хәвеф мәйданга чыга. Бу хәтәр хәвефкә каршы Ауропада фәнни-фәлсәфи фикер баш күтәрә. (Маркс, Ницше һ. б.) Шушындый борчылуларга юлыгып, Садыйк Иманколый укымышлы татар голамәсе активлыгына каршы кизәнүләрне «голам»аларны бөтенләй юк итәргә тырышу, дип бәяли, моңа протест белдерә. Аның иҗатының әһәмияте менә шуннан гыйбарәт. 1990—1995 еллардан соң кайчандыр әдәбиятта Садыйк хәзрәт бер үзе генә диярлек

игътибар иткән әлеге мәсьәләне аңлау-бәяләү зарурлыгы татар җәмәгатьчелеге алдына кабаттан килеп басты. Шушы җәһәттән дә аның әсәрләре бүген дә актуальлеген югалтмаганнар.

**Мәсгуть ГАЙНЕТДИН,**
филология фәннәре кандидаты.

# Мөхәммәтсадыйк Иманколый

## Газәл

Ни тәэссеф кем: фазыйләт әһеленә тәкъдир юк;
Фәһем итүче гыйлем-ү гыйрфан кадерене — бер ир юк.

Кем җәһаләттә фәрид, улдыр газиз вә мөхтәрәм;
Мәгърифәт әһеленә зәррә ихтирам, тәүкыйрь юк.

Чәрхе дәүран, ни гаҗәп, һәр дәм кире дүнмәктәдер;
Әһле фазыйл ирер хакыйрь-ү, җаһилә тәхкыйрь юк.

Әһле гыйльмә хәким ирер җаһиләне би тәмиз,—
Эчләрендә боларның бер сәхиб тәдбир юк.

Таш күңелледер гавам: һич кабил ислах түгел;
Ни кадәр кыйлдым нәсихәт, зәррәчә тәэсир юк.

Әһле гыйлемнең хаҗәте үтәлмидер меңнән бере;
Талигы мәсгуд сәфиһ җитешмәгән бер җир юк.

Бер итекче, йә кәвешче — галиме тәхкыйрь итә;
Һич тарафтан аңа каршы аз гына тәгъбир юк.

Аңламыйлар тугъры сүзне, ничә кат әйтсәң дә син;
Эчләрендә һушлы булган бер егет, йә пир юк.

Бу сәфиһлар мәҗмагында заигъ итмә сүзеңне,—
Чөнки сүз аңлаучы — дөньяда хомар, хинзир юк.

Итмә, Садыйк, җәһһаль сөхбәтеннән бер өмид,—
Болар эчрә, әһле фазыйле таныган бер ир юк.

---

**Сүзлекчә:** тәэссеф — үкенү. Фазыйләт әһеле — белем, гыйлем иясе. Гыйрфан — аң. Фәрид — тиңсез. Зәррә — тузан (атом). Тәүкыйрь — хөрмәт. Чәрхе дәүран — язмыш бөтерчеге. Хакыйрь — хур. Тәхкыйрь — хурлау. Җаһиләне би тәмиз — ахмак, наданнар. Сәхиб тәдбир — фикер иясе. Кабил ислах — үзгәрүгә сәләтле. Талигы мәсгуд сәфиһ — бәхетле язмышлы ахмак. Тәхкыйрь итә — хакарәтли, хурлый. Пир — карт. Мәҗмагында — җыелышында, төркемендә. Хомар — ишәк. Хинзир — дуңгыз. Җәһһаль сөхбәтеннән — наданнар белән сөйләшүдән.

## Зарлану

Ничә җәһед әйләсәм дә, һич мәрамем булмады мәүҗүд;
Дога кыйлсам да ни хәтле, иҗабәт итмәде мәгъбүд.
Гомернең күбе үтте — көткәнемчә булмады бер эш;
Мияссәр булмады дөньяда безгә талигы мәсгуд.
Мәгариф әйләдем тәхсил, ләкин булмады тәкәммил,
Һаман юк җирдә каль-у кыйль белән үтте гомер. Ни сүд?! —
Шикаят әйләрәм һәр дәм: минем хәлемдә юк бер ямь.
Эчемдә тулы дәрт-ү гамь, йөрәк янса да чыкмый дүд.
Читендер бик минем хәлем: мияссәр булмый әмалем;
Юк икән бер дә икъбалем, фазыйләт миндәдер мәфкуд.
Ирермен гасый бер бәндә гөнаһым илә шәрмәндә;
Фазыйләт бер дә юк мәндә — һәммә юллар ирер мәсдүд.
Бу дөнья ләззәте арзандыр әсхабе сәфаһәткә;
Гаҗәптер: мәгърифәт әһленең ирер һәр таләбе мәрдүд.
Хакарәт итеlә әһле дианәт гасыр-и мәшъүмдә,—
Бәхетсез бер горуһ ирер ки: хәлвәсе дә зәһәр алүд;
Дәрига, нинди мәнхус бер замана әһле без булдык,
Хәерле бу кавемнәндер Сәмүд-у Гад-у кауме һүд.
Дианәт сахибе галимгә һич тә кадер вә хөрмәт юк;
Әгәрчә булса да анда фазыйләт көн кеби мәшһүд.
Дәрига, көн ба көн сүнмәктәдер әнваре дин хак,
Югалмакта ирер әсар-и шәргъ-и Әхмәд-и мәхмүд —
Әмәл күп иде, ләкин һичберенә булмадым васыйль,
Үтеп китте гомерләр, бер дә кабул булмады максуд.
Дәлилдер фазлыңа: хасидләрең булса, тәшәккер ит,—
Мәсәлдер чөнки мәшһүр: көлле зи-нигъмәт — ирер мәхсуд.
Тәмыг итмә халыктан — никадәр мохтаҗ булсаң да,
Өмид әйлә Ходадан — башкадан булмас сиңа һич сүд.
Ходавәндәи кәрим ихсан безгә кыйлды бераз гыйрфан,
Вә ләкин юк аңа мәйдан, танучы аны бик мәхдүд.
Гаҗәбтер бивафа гәрдүн: берәүне итмәде мәмнүн.
Ирер фетнә илә мәшхун һәмишә афәти мәждүд,
Һәмишә әйлә истигъна, халыктан хаҗәтең сорма,
Рижүг ит Раббеңә: һәр хәлдә улдыр — зөлкәрәм вәл җүд.
Бу бабта сүз язып бетмәс, ничә язсаң да — сүд итмәс,
Бетер, Садыйк, бу җирдә, бәс, сүзеңне әйләмә нәбүд.

---

**Сүзлекчә:** Җәһед — тырышлык. Мәрамем — теләгем. Мәүҗүд булмады — бар булмады. Иҗабәт итмәде — кабул итмәде. Мәгъбүд — Алла. Мияссәр булмады — мөмкин булмады. Талигы мәсгуд — бәхетле язмыш. Тәкәмил — камиллек. Каль-у кыйль — юк-бар сүз. Сүд — файда. Дүд — төтен. Икъбалем — бәхетем. Мәфхүд — югалтылган. Гасый — гөнаһлы. Шәрмәндә — оятлы. Мәсдүд — ябылган. Әсхабе сәфаһәткә — әшәке кешеләргә. Мәрдүд — кире кагылган. Хәкарәт итеlә — хурлана. Әһле дианәт — дин әһеле. Гасыр-и мәшъүмдә — шомлы гасырда. Горуһ — төркем. Алуд — таплаган. Мәнхус — явыз язмышлы. Сәмүд, Гад, һүд кавеме — Коръәндә телгә алынган азгын халыклар. Сахибе — иясе. Мәшһүд — ачык. Әнваре дин хак — хак дин нуры. Әсар-и шәргъ-и Әхмәд-и мәхмүд — олы, мактаулы шәригать әсәре. Васыйл — ирешкән. Көлле зи-нигъмәт ирер мәхсүд — барлык мал иясенең көнчеләре була. Гыйфран — аң, белем. Мәхдүд — чикләнгән. Бивафа гәрдүн — тотрыксыз язмыш. Мәмнүн — канәгать. Рижуг ит — кайт. Зөлкарәм вәл җүд — иң ярдәмлекле һәм юмарт. Нәбуд — әрәм.

## Газәл

Җәмалең нурыны күрсәм, миңа Галәм мөнәүвәрдер,
Күзең — аһу, тешең — энҗү, ләбең — якут-и әхмәрдер.
Һилалдик кашларың — җәя ирер, керфекләрең — уклар,
Һәдәф аңа минем мәҗрух күңлем, мөкаррәрдер,
Синең хөснеңне тәфсыйль илә тәүзыйф түгел мөмкин,
Лисаны җөмлә Галәмнең аны тәкъдирдә әбтәрдер.
Синең ядыңнан үзгә, юк тереклек ләззәте миндә,
Адашкан гаклыма васлың хыялы, яр, рәһбәрдер.
Синең фикереңдә җанымдыр һәмишә зар-ү сәргәрдан,
Хыялың илә гакылым һәр заман хайран мозыйттәрдер.
Төшеп гыйшкың уты күңлемә көйдере вөҗүдемне,
Бу утка нисбәт илә, башка кайгы — әмре әхкардер.
Каләмнән чөн бу әшгарем синең шаныңда түгелде,
Минем диваным эчрә бу газәл чын таҗ бәр сәрдер.
Мәхәббәт илә һәр дәм Садыйк әйләр исмеңне тәкърар,
Синең зикереңанең шигырендә һәр юлда мөкаррәрдер.

---

**Сүзлекчә:** Җамалең — йөзең. Мөнәүвәрдер — нурлыдыр. Аһу — җәйран (киек). Ләбең — иренең. Әхмәрдер — кызылдыр. Һилалдик — яңа туган Ай кебек. Һәдәф — мишень. Мөкаррәрдер — анык, бәхәссез. Хөснеңне — гүзәллегеңне. Тәүзыйфь — бәяләү. Лисане — теле. Тәкъдирдә — әйтеп бирүдә. Әбтәрдер — көчсездер. Васлың — күрешү, кавышу. Рәһбәрдер — җитәкчедер, юллаучыдыр. Сәргәрдан — интегүле. Мозыйттәрдер — борчулы. Әмр әхкардер — бик вак нәрсә. Таҗ бәр сәрдер — баштагы таҗ. Дәм — вакыт. Зикереңe — исемең атау.

## «Бостан Сәгъди»дән

Белмим, кай китапта күрдем аны:
Төшендә күрде Иблисне җәвани,—
Гаҗәп гүзәл икән Иблис, чын — хур,
Йөзендә балкый аның, Ай кебек, нур;
Назыйре юк аның хөсне җәмале
Гүзәллектә — булыр Йосыф мисале.
Аны күргәч бу хәлдә, калды хәйран,
Диде аңа: «Син — ул Иблисме, чыннан?
Гаҗәп күркәм икән синең җәмалең;
Гүзәллектә ирер хури — мисалең.
Ничек илләрдә моннан һич хәбәр юк,—
Синең хөсне җәмалеңнән әсәр юк?
Җәмалең бар икән бу хәтле күркәм,
Сине ямьсез диләр ник барча Адәм?
Ни өчен әйвани шаһта һәм дә такда,
Дәхи хаммам эчендә — һәммә якта
Болай ямьсез сине тәсвир итәләр?—
Караучыны ничек нәфир итәләр?
Сине ничен кара йөзле ясыйлар,
Акайган куркыныч күзле ясыйлар?»
Диде Иблис, ишеткәч мәҗараны:
«Минем рәсемем диеп син белмә аны! —
Минем рәсемем түгел ул рәсме чиркин;
Каләм — дошман кулындадыр вә ләкин.
Каләм дошман кулында, һәр ни язар!
Ничек истәрсә, рәсемем шуйлә ясар.
Мин Адәмне чыгардым җәннәтеннән,—

Ерак иттем шул аны нигъмәтеннән.
Миңа инде итә анлар гадәвәт.
Итәләр сурәтемне дә кабахәт.
Гүзәл сурәтле булсам да шулай мин,
Годуләр күрсәтәләр мине чиркин!»

---

**Сүзлекчә:** «Бостан» — мәшһүр Иран шагыйре М. Сәгъдинең (1208—1292) шигырь китабы исеме — гөлбакча. Җәвани — яшь ир. Назыйры — охшашы, тиңе. Хөсни җәмале — йөзе күркәмлеге. Әйвани шаһта — шаһ сараенда. Такта — түбәндә. Дәхи — шулай ук. Хаммам — мунча. Нәфир — нәфрәтләнүче. Чиркин — җирәнеч. Гадәвәт — дошманлык. Гадүләр — дошманнар.

## Гыйбрәт

Олугланса да көчле ни кадәр, урынын зәгыйфь алыр.
Күтәрелсә дә ялкын, гакыйбәт, урнында көл калыр.
Кулыңда дәүләтең булса, ышанма, — ул китәр синнән:
Бүген синдәге акча иртәгә (чит) кулларда саналыр.
Кулыңда дәүләтең булганда, әхбабың булыр бик күп,
Әгәр төшсәң фәкыйрьлеккә, китәр барчасы, таралыр.
Мөнафикъның ышанма дуслыгына, иҗтинаб әйлә,
Тышыннан дус күренсә дә, сиңа һәр дәм аяк чалыр.
Тышыннан ак күренгәннәргә дә артык инабәт юк,
Кием ни кадәр ак булса, шулай тизлектә каралыр.
Әгәр дошман үзен бичара күрсәтсә, хәзар әйлә,—
Чаян — тик торса да, аннан курык: ул — зәһәрен салыр.
Урынсызга үзеңне тотма түбән, сакла гарызыңны,
Чамадан тыш иелгәннәр аяк астында тапталыр.
Сәбәп булыр кеше гафеллегеннән үз һәлакенә,
Утын ярырга — балтаның сабы утыннан ясалыр.
Үзеңдә бар фазыйләтне син изһар итмә һәр җирдә,
Хасәдтән күп вакытта зур гадәвәтләр дә яралыр.
Җәдәлдән саклана күр, булмасын зур фетнәгә бәгыйсь,
Күрерсең, аз гына сүздән ничек зур фетнә кузгалыр.
Әгәр дә байлыгың булса, фазыйләт азы — күп булыр,
Фәкыйрь булсаң, үзең дә бар фазыйләтләр дә югалыр.
Сабырсызлык белән һичбер вакытта башкарылмас эш,
Тәхәммел һәм чыдамлылык илә күп мөшкелләр уңалыр.
Эшеңне, Садыйк, уйлап эшлә, булма бер заман гафил,
Килер бер көн — синең кылганнарың хакында соралыр.

---

**Сүзлекчә:** Гакыйбәт — нәтиҗәдә. Әхбабың — дусларың. Мөнафикъның — ике йөзленең. Иҗтинаб әйлә — читләш, саклан. Дәм — вакыт. Инабәт — ышанып карау. Хәвар әйлә — саклык күрсәт. Гарызыңны — биредә, үз дәрәҗәңне сиздерү, белдерүне. Гафеллегеңнән — аңкаулыгн сәбәпле. Фазыйләтне — белемне, өстенлекне. Изһар итмә — күрсәтмә, искәртмә. Хасәдтән — кешедән көнләшүдән. Гадәвәтләр — дошманлыклар. Җәдәлдән — ызгыштан, шаулашудан. Бәгыйсь — сәбәпче. Гафил — надан, аңсыз.



Харис Әшрәфҗанов

# ТАМЫРЫБЫЗ — ТАРИХТА

## Кереш

Төрле тайпылышлар булуга да карамастан, кешелек җәмгыяте үзенең үсеш тарихында ахыр чиктә барыбер эволюция кичерә. Революцияләр һәм сугышлар, еш кына фаҗигале нәтиҗәләр белән тәмамлансалар да, алар әлеге олы процессның билгеле бер буынын гына тәшкил итәләр.

Ә әдәбият һәм әдәби хәрәкәт исә җәмгыятьнең үзгәреш юлларын чагылдыра, үзе дә эчтәлек һәм форма җәһәтендә сәнгати, методологик һәм әхлакый-рухи үсеш кичерә.

Аннан соң әдәбият нинди дә булса сыйныф вәкилләренең иҗатына гына түгел, ә гомуммилли мираска нигезләнә, таяна. Аның үзәгендә кеше тора — әсәрләрдә күтәрелгән мәсьәләләр бөтенлегенең асылы да шуннан гыйбарәт. Алардагы төп проблематиканың эволюциясе исә җәмгыятьнең үсеш-үзгәреш кануннарына бәйле хәлдә, горизонталь һәм вертикаль юнәлешләрдә бара.

Горизонталь юнәлештәге үзгәрешнең төп күрсәткече — әдәбиятның революцияләрне сурәтләүдән милли тарихка йөз белән борылуы булды. Шул ук вакытта, иң борынгы дәверләрдә булып узган кардиналь вакыйгаларның гына түгел, ә якын үткәндәге сәяси революцияләрнең сәбәпләрен дә милли-тарихи факторларның үзара кисешкән уртак нокталарын ачыклау нигезендә аңлату, шул рәвешчә халык язмышын бәян итү процессы бара. Соңгысы шәхесләр, аерым кешеләр язмышы мисалында уңышлы башкарыла.

Тарихи әсәрләрдәге төп проблематиканың вертикаль юнәлештәге эволюциясе хакында сүз күтәргәндә иң әүвәл без геройның сыйнфый-социаль язмышыннан аның әхлакый язмышына күчүне күздә тотабыз. Хәзер безнең тарихи әсәрләрдә даими сыйфатлы гомумкешелек кыйммәтләре, кешенең әхлакый язмышы өстенлек ала бара. Алар тотрыклы характерга, гомумтарихи әһәмияткә ия.

Тарихи романнарда күтәрелгән төп проблематика эволюциясенең юнәлешләрен ачыклау өчен безгә «Җәмгыять һәм шәхес», «Сыйнфый көрәш һәм милли-азатлык хәрәкәте» мәсьәләләрен карап узарга туры киләчәк. Тарихи роман жанры үсешендә, аның сыйфаты үзгәрешендә 70 нче һәм 80—90 нчы еллар мөһим чор булу сәбәпле, без башлыча шул елларда язылган әсәрләргә мөрәҗәгать итәчәкбез.

## Җәмгыять һәм шәхес

Тарихны кешеләр ясый. Аерым шәхесләрнең тарихи ролен инкярь итеп булмый. Әмма алар, мәгълүм ки, үзләре генә тарих тудыра алмыйлар. Шәхесләр халык эчендә формалашалар, җитлегәләр. Биредә тарихи зару-

рият, тоташтыручы фактлар булып кына калмыйча, иҗтимагый таләпкә хәлиткеч йогынты ясаучы шарт, үсеш-үзгәрешнең үзенчәлекле локомотивы булып тора. Ул аерым кешеләрнең, төркемнәрнең, халыкларның һәм хәтта илләрнең генә түгел, ә тулы цивилизацияләрнең дә язмыш кысаларын билгели, кануни рәвештә җәмгыятьнең барлыкка килүе һәм үсеше процессының нигезендә ята.

Җәмгыять һәм шәхес — безнең тарихи романнарыбызда күтәрелгән төп мәсьәләләрнең берсе. Әмма әлеге мәсьәлә тарихи-революцион романнарның күпчелегендә башлыча сыйнфый-сәяси төсмерләре белән күзгә ташлана. Борынгы үткәнебез тасвирланган әсәрләрдә, шулай ук тарихи-биографик романнарның күпчелегендә исә милли-тарихи билгеләргә өстенлек бирелә.

Әйтелгәнчә, кеше — физик-биологик тереклек берәмлеге булудан бигрәк, җәмгыятьнең аерылгысыз һәм актив органик өлеше, аны тәзүче. Аның тормышы, эшчәнлеге, конкрет гамәлләре табигый һәм тарихи зарурият кануннары буенча бара. Кеше җәмгыятьтә шәхес булып җитлегә.

Әдәбият үзенең тарихи әсәрләрендә геройларны реаль чынбарлыкның актив субъектлары буларак сурәтләргә омтыла, аларның шәхси һәм иҗтимагый мәнфәгатьләре мөнәсәбәтен тарихи зарурият яктылыгында карый, кешенең биосоциаль ихтыяҗларын да күрсәтергә тырыша. Кешене бары тик җәмгыять идеологиясен, глобаль-иҗтимагый мәнфәгатьләрне генә алга сөрүче сыйфатында гына күзаллау зур хата булыр иде. Кеше, социаль организм буларак, үзенең тормышында, эшчәнлегендә нинди күркәм генә гамәлләр кылмасын, бу гамәлләр билгеле бер дәрәҗәдә аның шәхси ихтыяҗларыннан, мәнфәгатьләреннән чыгып эшләнә. Моны үз вакытында марксизм башлангычы да инкарь итмәде. (Кара: Маркс К., Энгельс Ф. Фейербах. Противоположность материалистического и идеалистического воззрений. — М., 1966. — С. 83.) Россия большевиклары исә бу фактны башкачарак аңладылар, «шәхси эгоизм-милекчелеккә» каршы сугышчан сәясәт алып бардылар. Крестьяннарга вәгъдә ителгән җир дә, эшчеләргә кайтарылачак завод-фабрикалар да телдә-шигарьдә генә аларга бирелде. Бу исә җавапсызлыкның үсүенә, «минеке түгел — дәүләтнеке (колхозныкы)» карашының өстенлек итүенә китерде. Нәтиҗәсе — бөлгән, ярымҗимерек икътисад. Урысча әйтмешли «Нет худа без добра» дигәндәй, империя үзе дә таркалды. Кыскасы, җәмгыять үз алдына һәм кеше алдына нинди генә олуг максатлар куймасын, тарихи үсеш-үзгәреш юлында шәхес барыбер үзенең био-социаль һәм иҗтимагый асылы булган мәнфәгатьләре белән катнаша, чыгыш ясый. Бу — бик табигый хәл. Мәсәлән, К. Нәҗминең «Язгы җилләр»ендәге Мостафага, И. Газиның атаклы трилогиясе «Онытылмас еллар»ындагы Галиуллага күз салыйк. Алар үзләренең тормыш-көнкүреш дәрәҗәсенә, язмышларына, әлбәттә, канәгать түгелләр. Икесе дә яшәү рәвешләрен яхшырту турында уйланалар. Алар бәхетле киләчәккә ирешү юлын байларга тырышып эшләүдә күрәләр. Хәер, романның ахырында Мостафа үз кулына кызыл байрак ала. Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» романының төп герое Сәфәргали дә башта (большевик Фәсхи белән очрашканчы) шундыйрак фикердә була. Тормыш шартлары кискенләшкәндә кешенең шәхси позициясе, мәнфәгатьләре конкретрак һәм ачыграк чагыла. Соңгыларын канәгатьләндерүгә омтылу, милекчелек сыйфаты — кеше өчен табигый күренеш (совет режимы бу сыйфатны юкка чыгару өчен бар куәтен җикте һәм шул рәвештә үз тамырына үзе балта чапты). Сәфәргалинең баштагы фикерләренә (әгәр дә тегүчелек белән шөгыльләнмәсәләр — аларның акчалары булмаячак. Акча булмаса — ат сатып алып булмаячак. Атсыз иген игү мөмкин түгел. Икмәк чәчмәсәң — кабартмакөлчәләр булмаячак), «Онытылмас еллар»дагы кечкенә Хәлимнең әтисе Галиуллага биргән соравына («Әти, без кайчан баербыз икән соң?») яки авылга килгән икмәк отрядына булышып йөргән, Маликның яшерен базын табып биргән һәм моның өчен үзенә тигән икмәктән баш тарткан, советның актив әгъзасы булган Берьярым Миңнулланың алпавыт утарыннан үзе алып кайткан өч атның икесен алырга теләүче көрәштәшләренә арба кендеге тотып каршы торуына игътибар итик. Миңнулланың әлеге гамәлен И. Нуруллин болай аңлата: «Хикмәт, күрәсең, хосусый милекчелектә генә түгел. Кәҗә бәтие чаклы аты белән бөтен авыл каршында адәм көлкесе булып йөри торган Миңнулла гомер буе яхшы атка тиенү хыялы белән яшәгән икән, аңардан ни көтәсең! Сөлек кебек өч ат киртәнә килеп кергәч, сыйнфый сыйфатың да бер мәлгә читенеп тора икән шул». (Нуруллин И. Тормыш һәм сәнгать чынлыгы, 30 б.)

Эш нәкъ менә шунда, милекчелектә! Һәм моны бер дә оялмыйча әйтергә кирәк. Милекле булу — кешенең табигый хокукы. Коммунистик режим исә сыйнфый сыйфатларны саклау хакына кешене бөлдерү, җәмгыятьне рухи һәм матди хәерчелектә тоту сәясәтен сайлады. Әлеге сәясәткә мөнәсәбәт тарихи

романнарыбызда да чагылыш тапты. Әлбәттә, яшерен-батырын түгел, социаль заказ факторы да игътибарсыз калдырылмады. Әмма бу мөнәсәбәт тә бертөрле генә түгел иде. Әдипләрнең бер өлешенең берсүзсез коммунистик идеалларга табынуы ачыктан-ачык сизелсә дә, икенче берәүләр үз әсәрләрендә бу идеалларга карата сак кына шикләрен белдерә башладылар, өченчеләре исә тоталитар системаның киләчәге юклыгына ишарә иттеләр, гомумкешелек кыйммәтләренә өстенлек бирделәр — тарихи роман жанрында төп проблематиканың эволюциясе шул юнәлештә барды.

Большевистик режим хакимияткә килү белән шәхес мәнфәгатьләрен җәмгыять мәнфәгатьләре белән алыштыру юлына басты. Ул җәмгыятьне кешене ашатучы да, киендерүче дә, «корбан тәкәләре» бирергә тиешле көтү дә итәргә омтылды. (Нәрсәгә ирешкәнен кабатлап тормыйк, әлеге системаның миллионнарча корбаннарын тынлык белән искә генә алыйк.)

Шәхесләрнең, һәм хәтта буыннарның да, фаҗигасе шушы җирлектә башланды. Сату-сатылу, ялагайлану гадәти нормага әверелгән гарип җәмгыять төзелде. Табигый рәвештә үсәргә тиешле шәхес мәнфәгатьләре көчләү-кысу басымына дучар булды, тар күңеллелек, эгоистик тойгылар көчәя барды. Шундый даирәдә, мохиттә намуслы кешеләргә, шул ук Габбас хәзрәтләргә, Иргалиләргә тормыш рәхимле түгел иде. Шәхси тормышын, киләчәген җайлы кору өчен әти-әниләреннән ваз кичкән Нурияләр бездә күп үрчеде. Ф. Галимуллин «Идел кызы» героен шул заман шартларыннан чыгып аңларга мөмкин, ди. (Галимуллин Ф. Инешләр Иделгә кушыла.— Казан, 1985.— 20 б.) Габбас мулланың фаҗигасендә, аның (мулла булган кешенең!) үз куллары белән гомерен чикләвендә кызы Нурия Уразаева хәлиткеч роль уйный. Әйе, кеше реаль тормыш тәкъдим иткән мөмкинлекләр арасыннан иң кулаен сайлый шул.

Җәмгыять — кешенең шәхес булып җитлегү процессында, аның рухи дөньясы формалашуда мөһим фактор. Җәмгыять кешене үстерә, үзгәртә, тәрбияли, биосоциаль мәнфәгатьләргә иҗтимагый эчтәлектә һәм характерда йогынты ясый, эстетик карашларның һәм патриотик хисләрнең ныгуында зур роль уйный. Демократик җәмгыятьтә шәхеснең иреге: азатлыгы, аның хокуклары һәм мәнфәгатьләре, сыйнфый билгеләре һәм милли сыйфатлары ихтирам ителә. Киресенчә булганда исә шәхес күңелендә хөкем сөргән тәртипләргә карата ризасызлык өлгерә. Соңгысы зурая-үсә барып каршылыкларга, ә аерым бер очракларда ачыктан-ачык конфликтларга китерә. Алар гомуммилли масштаблар яки социаль катлаулар арасындагы кискен каршылыклар дәрәҗәсенә җиткәндә, ягъни революцион ситуация шартларында, конфликтлар шәхес файдасына хәл ителергә дә мөмкин. Әмма бу ихтималлык һәрвакытта да гамәлгә ашырылмый. 1905—1907 еллардагы революция чорында, мәсәлән, демократик көчләр шактый гына күтәрелешкә ирешсәләр дә, бер йодрык булып туплана алмадылар, җиңелделәр. 1917 елның Февраль революциясе дә демократик бурычларны тулысынча тормышка ашыра алмады. Большевиклар инициативаны үз кулларына алдылар, Октябрь революциясе җиңде, әмма ул демократик стройга китермәде. Демократик үсеш юлы шул вакытлардан алып бүгенгәчә актуаль булып кала бирә.

Татар халкы әлеге өч революциядән дә читтә калмады. Аның революцияләргә килүе, аларда катнашуы тарихи зарурият иде. Тарихи-революцион романнарда бу раслана да. Әмма ул әсәрләрнең нигезенә сыйнфый-сәяси фактор гына алынды. Ә бит мәсьәләнең милли-тарихи ягы да бар иде. Татарлар революцияләр белән билгеле бер дәрәҗәдә үзләренең дәүләтчелекләрен торгызу өметләрен дә бәйләделәр ич. Совет дәверенең беренче елларында ук күпләп агылган хатлар, мөрәҗәгатьләр шул хакта сөйли.

Шәхеснең революциягә кушылуын да, мәсьәлә буларак, берьяклы гына карарга кирәкми. Игътибар итсәк, тарихи-революцион романнардагы геройларның, персонажларның революциягә төрле сукмаклар белән килүләрен күрербез. Аларның сәяси яктан җитлегүләре дә бер үк дәрәҗәдә түгел. Бу процесс төрле тизлек белән бара, аларның төзеләчәк яңа җәмгыятькә баглаган өметләре дә берберсеннән беркадәр аерыла, гәрчә күбесе «якты киләчәк» хакына кузгалса да. Берәүләр үзләренең максатларын, аларга ирешү юнәлешләрен тәгаен ачык аңлыйлар. Икенчеләр исә бу юлны озаграк узалар. Шулай: әдәби герой — индивидуаль һәм типик сыйфатларның уңышлы җыелмасы ул. Әмма ике очракта да иҗтимагый тирәлекнең йогынтысы мөһим фактор булып кала. Әйтик, матрос Федюшкин әсәргә давыл кебек килеп керә, дәртләнеп-ялкынланып керешә, яшь Якуб Саттаров та революциягә җиң сызганып хезмәт итә, ул революцияне үзенең сәяси-сыйнфый карашлары җитлегеп җиткән, ныгыган шәхес буларак каршылый («Онытылмас еллар»). Шәяхмәт Айдаров та революция эшенә баштанаяк чума

(«Идел кызы»). Галиулланың исә үз гомере азагында гына карашлары тормышны көч кулланып, көрәш нәтиҗәсендә үзгәртү ягына борыла башлый. Аның яллы хезмәт белән баю турындагы татлы хыяллары шахтадагы күмер белән бергә җимерелә («Онытылмас еллар»). Тәгъзимәләргә, Фәхретдиннәргә («Ямашев»), Сәфәргалиләргә («Җәяүле кеше сукмагы») һәм Мостафаларга да («Язгы җилләр») революцияне кабул иткәнче тормыш тегерменендә шактый иләнергә туры килә. Геройларның кайберләре туры, кайсысы әйләнеч юл үтәләр. Берәүләре исә бу юлны берничә тапкыр кабатлыйлар. Госман Габдрәшитов («Имәннәр тамыр җәйгәндә»), мәсәлән, сыйнфый көрәш баррикадасының ике ягында да була.

Сәяси көчләрнең дәүләт хакимиятенә килү юлында массалар, кешеләр ышанычын, аларның аңнарын яулау өчен көрәш төп урынны алып тора. Чөнки җиңү-җиңмәү шуңа бәйле. Әлеге көрәш тарихи романнарның зур күпчелегендә төп геройның сыйнфый-сәяси позициясенең үзгәрүендә сәяси көчләр тәэсиренең зур роль уйнавын, аларның йогынтысының көчәюен сурәтләү аша чагылдырыла. Әйтик, Мостафаның көрәш юлына басуында — Андрей Петрович һәм Алексей Халявин («Язгы җилләр»), Садыйк Сәгыевнең («Ямашев») һәм Гафур Колахмәтовның («Гафур гаиләсе») сәяси-сыйнфый карашлары формалашуда — Х. Ямашев (һәм Андрей — икенче очракта), Шәрифҗанның революциягә килүендә Якубның йогынтысы зур роль уйный. Соңгысының сыйнфый-сәяси яктан җитлегүе Столяров белән бәйле («Онытылмас еллар»). Госман Габдрәшитов исә Сабир Шәрипов, Дмитрий Ушаков һәм Валериан Куйбышев кебек революционерлар белән таныш була («Имәннәр тамыр җәйгәндә»). Мисалларны дәвам итәргә мөмкин. Геройлар бер үк революция каһарманнары булсалар да, революцияне аңлау тирәнлеге буенча бер-берсеннән шактый аерылалар. Менә Якуб («Онытылмас еллар»). Ул салкын канлы, тирән фикерле, үзенең гамәлләре өчен җавап тотарлык төпле, таләпчән, эшлекле, оештыру сәләтенә ия булган шәхес буларак сурәтләнә. Кирәк булганда ачуын тыеп тора, сыгылмалы сәясәт үткәрә, мөмкинлек туганда сыйнфый дошманнарының икътисади тәҗрибәсен дә революция эшенә хезмәт иттерергә омтыла. Матрос Федюшкин исә холкы, гамәлләре белән күпкә аерылып тора. Баш имәс холыклы, үз-үзенә нык ышанган, энергиясе кайнап-ташып торган бу герой революция юлында үз-үзен аямый, хәвеф-хәтәр янаган җирләргә барып чыга. Еш кына «мөгез» дә чыгарып куйгалый (әйтик, төрмәгә хөкем ителгән кунакларны һәм мулланы үз куллары белән атып үтерә). Сыйнфый дошманны кыру дәрте кызган Федюшкинның барлык гамәлләрен дә хуплап бетереп булмый, әлбәттә. Яки, ары китеп, Шәяхмәт Айдаровның («Идел кызы») революцияне аңлавын ачыклау өчен, үлем баржасында аның белән штабс-капитан Динислам Бохараев арасында булган диалогка мөрәҗәгать итик.

«Муллануp Вахитовның гомере кыл өстендә булу Шәяхмәтнең җанын тетрәтте. Ләкин бу минутта, сәяси дошманы алдында утырганда, ул йомшаклык күрсәтә алмый иде. Үҗәт бер ныклык белән соравын кабатлады:

— Ни өчен Вахитовны атарга тиешләр?

— Ни өченме? Өч гасыр буена хакимлек итеп килгән Романовлар тарихи хата ясады, без ул хатаны кабатларга теләмибез. Ышетәсеңме, Айдаров, теләмибез.

— Нинди хата ул?

— Николай Романов монархия дошманнарын үтереп бетермәде. Ул аларны каторгага җибәрде, төрмәләргә тыкты, Себергә сөрде. Кыскасы, Россияне сәяси тоткыннар белән тутырды. Акылы бар аңларга тиеш: янып торган учакны кая гына куйсаң да, нинди генә йозак белән бикләсәң дә, ул учак булудан туктамый. Сүндерергә кирәк учакны, томаларга кирәк. Шул чагында гына тыныч йоклый аласың, пожар чыгудан курыкмыйсың. Рус монархиясенең иң зур хатасы шундадыр ки, ул бик озак ут белән уйнады, уйнап бетергәч, утны сүндерергә онытты.

— Сез... сүндерәсезме?

Штабс-капитан урыныннан торды, киң сары каешлы портупеясын төзәтәтөзәтә, Шәяхмәткә якын ук килеп басты; Айдаров аның саргылт авыру чыраена нур биреп торган яшькелт күзләрендә усал очкыннар биешүен күрде.

— Сүндерәчәкбез. Идел белән Камада — үлем баржалары, тимер юлда — үлем эшелоннары. Син тузгыткан Таминдар байлар, Шакир хаҗилар үз имениеләренә кайтып утырдылар. Зартугай белән Салагышта син урнаштырган советларның көле күккә очты. Патша вакытында нинди тәртип булган — илдә шундый тәртип. Шулай булгач, большевик Айдаров, син гомер буе юкка көчәнгәнсең булып чыга түгелме?

Шәяхмәт диванга ничек килеп утырган булса, шул хәлендә, гаять тыныч чырай белән, җиргә береккән имән кебек утыра бирде.

— Штабс-капитан, сез яралы аюның нәрсәгә сәләтле икәнен беләсезме?

— Аюның монда ни катнашы бар?

— Сез ирекле илне яраладыгыз. Ил моның үчен алачак. Сез үзегезнең төзүче түгел, җимерүче икәнегезне ачып салдыгыз. Причем, оятсыз рәвештә. Тарих шаһит — халыкның беркайчан да җимерүче артыннан, палачлар артыннан барганы юк, жандарм Бохараев!

Штабс-капитанның чигә тамырлары сулкылдап тибә башлады.

— Солдатлар! — дип кычкырды ул. — Бу мерзавецны җан исәбенә кертегез».

Шәяхмәт Айдаровның әлеге диалогта китерелгән соңгы сүзләре нигездә большевикларның сәяси позициясен, аларның 1917 елгы Октябрь революциясенә һәм күпмедер дәрәҗәдә «якты киләчәк»кә карата мөнәсәбәтен чагылдыра. Хәер, Шәяхмәт Айдаров шушы «ирекле илнең» бераздан ГУЛАГ челтәре белән капланачагын, лагерьларның һәм төрмәләрнең йөзләрчә мең-миллионнарча «халык дошманнары» белән шыплап тулачагын, бик күпләрнең кара төннәрдә чыгып китеп кире кайтмаячагын, гарипләнгән җәмгыятьнең, «палачлар артыннан иярмәячәк» халыкның тыныч тормышта миллионнарча корбаннар биреп тә сугыш кырларында «Ватан өчен! Сталин өчен!» дип утка-суга ташланачагын бәлки башына да китермәгәндер. Әмма моңа карап кына большевикларның җинаяте кичерелә алмый. «Тамырыннан йолкып атып...» шигарен күтәреп, кан-сөякләр өстендә корылган «яңа» җәмгыятьнең «якты киләчәге» буламы соң? Юк, әлбәттә! «Революция үз балаларын ашый», диләр. Меңнәрчә Айдаровлар, Саттаровлар, Гәрәйләр, Шәрифҗаннар һ. б. үзләре дә сәяси дошманнары язмышына дучар булды. Җәмгыять үз геройларын күпләп корбан итте. Кызганыч та, гыйбрәтле дә.

Мәңгелек тарихи хакыйкать: шәхес беркайчан да, берничек тә җәмгыятьтән азат була алмый. Хәтта хакимияттә утырса да! Җәмгыятьтә шәхес үзенең этник-милли, матди һәм рухи ихтыяҗлары белән яши. Соңгыларының хәл ителүе, гамәлгә ашырылуы җәмгыятьнең мәдәни-рухи, икътисади үсешенә, сәяси халәтенә бәйле. Әйтик, «Әтил суы ака торур» романында (Н. Фәттах) Утташ кам белән конфликтта Күрән би җиңсә дә аның өстенлегенең хокукый чикләре Акбүре ыруында хөкем сөргән реаль чынбарлык, иҗтимагый таләпләр белән билгеләнер иде. Тотыш угланның гамәлләренә карата туган мөнәсәбәтне генә искә төшерик. Монда, әлбәттә, халыкның рухи-дини асылы бәяләү-ярлыкау механизмын хәрәкәткә китерә. Әйе, дини-мәҗүсилек — иң әһәмиятле, көчле фактор. Шулай да мәсьәләне соңгысы белән генә аңлату берьяклылык булыр иде. Игътибар итик, Тотышны бит асмыйлар да, кисмиләр дә. Тотыш — хисләр кешесе. Тормышның иң хәлиткеч мизгелләрендә дә ул акыл көченә түгел, йөрәк кушканга буйсына, нинди дер карарга килгәндә дә ул үзенең эмоцияләре белән эш итә. Бер үк вакытта бу аның бөеклеге дә, фаҗигасе дә. Характерының әнә шул үзенчәлеге ягыннан Ф. Хатипов аны Ф. Хөсни геройлары — Айдар һәм Сәфәргалигә охшата. (Хатипов Ф. Духовный мир героя, 85 б.) Әмма шул ук үзенчәлеге белән Тотыш икенче бер мәхәббәт корбаны, озак вакыт икеләнүле уйлар һәм кичерешләр дөньясында чәбәләнгән Сәеттән («Хыянәт». Ф. Латыйфи) күпкә аерылып тора. Хикмәт монда зуррак нәрсәдә: халыкның менталитетында, үзенчәлекле дәүләтчелек традицияләрендә һәм тарихи зарурияттә. Әйтик, әтисен һәлак иткәндә Албуга да руханиларны җыеп киңәшми («Сызгыра торган уклар». Н. Фәттах). Әмма аның бу гамәле Сөн җәмгыятендә чагыштырмача тыныч кабул ителә. Албуга шундый мәрхәмәтсез адымга реаль чынбарлыкны белеп бара. Туман каган җәмгыятьтә инде өлгереп җиткән таләпләрне, ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек сәясәт алып бара алмый. Сөнне көчәя барган күршеләренең һөҗүмнәреннән саклау аның хәленнән килми, җиңелүләр ешая. Сөнгә барысы да кирәк: иминлек тә, азатлык та, сәүдә дә, иркен көтүлек җирләр дә... Романда күренгәнчә, Албуга тәхеткә утыргач та, ул бер-бер артлы боларга ия була. Шәхеснең гамәле җәмгыятьнең ихтыяҗлары һәм таләпләре канәгатьләндерелү хисабына аклана. Ә Совет дәүләте хакимиятендә утырган Сталинның һәм аның варисларының гамәлләре исә акланмый. Чөнки репрессияләр, рухи һәм матди бөлгенлек җәмгыять ихтыяҗы булмаган кебек, империячел-тоталитар богауларда җан асрау да милләтләрнең мәнфәгатенә, аларның менталитетына бөтенләе белән каршы килә иде.

## Сыйнфый көрәштән — милли-азатлык хәрәкәтенә

Татарлар революцияләр белән билгеле бер дәрәҗәдә үзләренең дәүләтчелекләрен торгызу, аны аякка бастыру өметләрен дә бәйләделәр, дидек. Әмма билгеле бер дәрәҗәдә генә. Чөнки реаль чынбарлыкта туган шартлар халкыбызның сыйнфый-көрәш урынына милли азатлык юлын тулаем сай-

лавы файдасына түгел иде. Татар милләте сыйныфларга һәм сәяси фиркаләргә таркалды, ә бу исә милли хәрәкәтнең тукталып калуга йөз тотуы иде. (Биредә кайбер атаклы шәхесләребезнең мөһаҗирлеккә китеп, чит илләрдә азатлык идеологиясен дәвам итүләре түгел, ә милли-массачыл масштаблардагы хәрәкәт күздә тотыла.

Ни өчен шулай дибез? Чөнки бу хәрәкәт гасырлар дәвамында барды, ул милли-массачыл характерда иде. Татарлар гасырлар дәвамында царизмның рәхимсез изүенә каршы көрәштеләр. Россиянең гомер бакый аграр империя булуын да истән чыгармыйк. Тарихта 1861 елга кадәр мәгълүм булган күтәрелешләрдә, сугышларда башлыча алпавыт белән крепостной крестьян арасында булган сыйнфый каршылыклар чагылыш тапты. Әмма татарлар арасында, галимнәребезнең күпчелеге тануынча, крепостной бәйлелек булмаган. (Бер Тәфкилевләр мисалы гына барлык халыкта да таралыш алган күренеш сыйфатында бәяләнә алмый.) Шул ук вакытта безнең милли феодаль катлау юкка чыгарылды, чөнки царизм аның милли-азатлык хәрәкәтен яңа талпыныш белән дөрләтүеннән, бу хәрәкәтне җитәкләвеннән курка иде. Кыскасы, татарлар арасында озак дәверләр буена сыйныфлар булмады, татар кешесе туры мәгънәдә Россия феодаль системасы коллыгында интекте, халкыбыз империянең милли изүенә дучар ителде. Шулай булгач, татарлар өчен милли таләпләр, сыйнфый таләпләргә караганда, табигыйрәк иде. Халкыбыз әлеге изүгә каршы дин-иман азатлыгы, дәүләтчелек өчен көрәш байрагы астында күтәрелде. Соңгы еллардагы сәяси үзгәрешләр, халкыбызның мөстәкыйль дәүләтчелегебезне кабат торгызу юлына аяк басуы нәтиҗәсендә туган «Батырша» романыннан (Җ. Рәхимов) өзек китереп, батыршаның уй-фикерләренә күз салыйк.

«Анысы тәзкирнамәне язу рәвеше әллә ни куркытмады Батыршаны. Шөкер, каурый каләмне тәүге тотуы түгел. Моңа хәтле язган хатларын, рисаләләрен вә башка язуларын укыган бәндәләр аларны бик тә камил һәм хиссиятле дип таба торганнар иде. Аны шикләндергәне вә гаҗизләндергәне башка нәрсә. Халаекларның күпчелеге алда торган яуны ислам дине өчен җиһад дип саный һәм Мөхәммәт пәйгамбәрнең яшел байрагы астына тупланырга ниятләнә. Батырша үзе һәм аның тарафдарлары исә, мөэмин-мөселманнарны төрлечә кысу-изү, мыскыл итүләргә бөтен вөҗүдләре белән каршы булган хәлдә, боларның дин хакына гына кубуы белән чикләнәселәре килми. Аларча, ачулы гавам иң әүвәл теге Шәрыкъка ыргый торган явыз Каракошның юлына манигъ булып басарга, ул гынамы, шул аждаһаны имгәтеп-изеп, юк итәргә тиеш. Шунда гына Идел-Урал төбәгендә тереклек итүче халаекларга азатлык вә асабалык килер, төрле хурлык-тарлыклар, изү-кысулар, зольмәт-җәбер гаип улыр. Шуңа ирешкән тәкъдирдә генә мәчет-мәдрәсәләр ачу үзеннән-үзе хәл кылыныр, ислам дине хөррә улып, кимсетелүләрдән котылыр. Тик шунысы бар: әлеге комсыз Каракош канатын канат иткән ныклы каурыйлар арасында бер кяферләр генә түгел, мөселман түрәләре дә байтак. Дини кануннар исә мөэмин-мөселманнар бердәм кавем дип өйрәтә, алар арасында кыерсытучылар да, кыерсытылучылар да юк, ди. Бер-беренә кул күтәрмәскә куша. Димәк ки, халаекларны зәхмәтле Каракошка каршы көрәшкә чакыру ислам дине өйрәтүләренә капма-каршы булып чыга. Бу исә берәүләрне икеләндерәчәк, хәтта өркетәчәк. Шуннан инде мәгълүм буладыр ки, төп максатны шәрәләндермәскә, аны дин пәрдәсенә төрергә, шулай итеп халаекларның хәерхаһлыгына ирешергә кирәк. Ие, ие, тәзкирнамәнең һәр сүзе, һәр фикере пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам вә хак тәгаләнең исемнәре белән ныгытылсын».

Батырша үзенең мөрәҗәгать хатына түбәндәге юлларны да өсти: «Сез, бер аллага ихластан инанучы чын дусларым минем, тырышыгыз, тырышыгыз, тырышыгыз! Чирү атлары вә корал хәзерләгез, кылыч-сөңге, җәя-ук вә шуңа охшаш кирәк-яракны мөмкинлегегез барынча әзерләгез һәм алла боерыгына буйсыныгыз: хак тәгаләдән мәдәт сорап, аңа өмет вә ышаныч баглап һәм дә аның катына пәйгамбәребез Мөхәммәт рәсүлуллаһны юллап, теге кяферләрне кыйрата башлыйбыз. Ул зобаниларны җиребездән куып, йорт-илебездә мәчет-мәдрәсәләр гыймарәт кылырбыз, хак динебезне кайгыртырбыз...» «Ышанабыз ки, барысыннан да бөек вә кодрәтле алланың рәхиме вә рәхмәте белән ул мөселман халаеклары өстеннән түрәләр вә имамнар итеп мәҗлес кешеләре, хак динне тәрәккый иттерүчеләр куелыр». «Сез, динебезнең башлыгы Мөхәммәт пәйгамбәрне дошман күрүче кяферләр безгә дуслык кулы сузарлар дисезме?! Аң булыгыз, алар Болгар калаларын вәйран иттеләр, хак дин юлындагыларны кырып бетерделәр, мәчетләрне җимерделәр, алар урынына чиркәүләрен гыймарәт кылдылар: үзләренең сафсата диннәрен тарату өчен. Ниһаять, безнең авылларыбызны да

болай гына калдырмаслар. Болгар иле хәленә төшерерләр». «Бер аллага ышанучылар күңелләрендә тотсыннар: йомышлы урыслар төрле хәйлә, кушханлык вә бүләкләр белән кыр казакъларын алдадылар. Әбелхәер ханның улын Оренбур каласына аманәт итеп алдылар. Әнә шул әшәке әмәлләре белән кыргыз кайсакларны Рәсәй канаты астына кертмәкчеләр. Уфа өязендәге сыман, аларның җирләренә дә кала вә кальгалар салып, Ташкент, Бохара һәм башка аймакларны кулга төшермәкчеләр, ул җирләрдәге бәндәләрне буйсындырып, чукындырмакчылар. Шунысы да бар, урыс түрәләре Уфа өязендәге һәм дүрт юл халкының кыргыз-кайсаклар белән дуслашуыннан, аларның бергәләп баш күтәрүеннән куркалар...»

Тарих дәвам итте, 1861 елда мәгълүм реформа булды, әмма аңа карап Россия кисәк кенә аграр-феодаль империя булудан туктамады. Промышленность һәм капиталистик мөнәсәбәтләр бик акрын, авырлык белән үсте. Бу хәл исә XX гасыр башындагы революцияләргә китерде. Большевиклар инициативаны үз кулларына алырга омтылдылар. Милләт капма-каршы мәнфәгатьле, максатлы төркемнәргә, фиркаларгә бүленде — милли хәрәкәт шул рәвешле тукталу чорына керде. Әмма милли омтылыш бөтенләе белән сүнмәде. Бу омтылыш сыйныфый азатлыкка ирешүгә талпыну гына түгел иде, әлбәттә. Әлеге юлда милләт мәнфәгатьләрен чын күңелдән кайгыртучы зыялыларыбыз бар иде әле. Заманында җәмәгатьчелек И. Гаспралы, М. Бигиев, Й. Акчура кебек шәхесләребезне тискәре яктан гына бәяләде, (Галимуллин Ф. Национальное и интернациональное в характере. Татар совет прозасында образлар һәм характерлар.— Казан: КДПИ, 1981. 71 б.) милли идеяне күтәреп чыгучыларны Мөбарәкша, Гайфи, Идрисләргә («Язгы җилләр») яки Дәүләтьяровларга («Онытылмас еллар») тиңләде. Әмма халкыбызның әле Гаяз Исхакыйлары, сыйнфый көрәш богауларыннан ахыргача аерылып бетмәсә дә, тоталитар режим шартларында беренчеләрдән булып милли дәүләтчелек идеяләрен күтәргән Мирсәет Солтангалиевләре бар иде.

Милли-азатлык хәрәкәтенең нигезендә милли үзаң үсеше ята. Революция шартларында соңгысы сыйнфый мәнфәгатьләрнең көчле басымына дучар була. Менә алдыбызда «Язгы җилләр» герое Мостафа. Аңарда сыйнфый мәнфәгатьләр милли сыйфатлардан көчлерәк. Әмма ара-тирә аның милли асылы да үзен сиздереп куя. Ф. Галимуллин Мостафаны милли яктан да һәм сыйнфый яктан да типик герой дип исәпли. Ул аны А. Гудайтис-Гузявичюсның «Тимерче Игнотас хакыйкате» романы герое Игнотас белән чагыштыра һәм аларның (ягъни татар Мостафаның һәм литвалы Игнотасның) язмышларында уртаклыклар күп, шул ук вакытта алар икесе дә милли характерлар, аларда күп кенә милли үзенчәлекләр чагыла дигән нәтиҗә ясый. Әлеге милли үзенчәлекләргә Ф. Галимуллин Мостафада салкын канлылык белән кызып китүчәнлек чиратлашуын, Игнотасның иң кискен ситуациядә дә үзен кулга алуын конкрет хәлгә һәм үзенең гамәлләренә бәя бирү сәләтен кертә.

Безгә калса, әлеге сыйфатлар гына милли характерларның үзенчәлекләрен ачып бетерә алмыйлар. Чөнки аларны һәр грузин белән немецтә дә, йә булмаса, кубалы белән шведта да, үзебезнең милләттә дә һәм тагын әллә кемнәрдә, һәр халыкта да күпләп табарга була. Болар иң мөһиме түгел. Милли характер ул милли үзаң һәм милли психология җирлегендә, менталитетлы нигездә формалаша.

Сыйнфый көрәштән милли-азатлык хәрәкәтенә күчеш, бер яктан караганда, соңгы елларда иҗат ителгән тарихи романнарның төп проблематикасы эволюциясендә тоемланса һәм бу эволюциянең юнәлешен күрсәтсә, икенче яктан, бу күчеш конкрет планда — аерым геройлар, бигрәк тә тарихи шәхесләр язмышында чагылыш таба. Мисал өчен Р. Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» романын алыйк. Әсәрнең беренче җөмләсе үк аның идея-эстетик юнәлешенә ишарәле сыман. Кечкенә Мирсәет әтисенә сорау бирә: «Әти, әйт әле, татарларга да патшага каршы баш күтәрергә ярыймы ул?» Сорау беренче бүлектә генә дә берничә тапкыр кабатлана, бер очракта «татарлар кайчан баш күтәрә инде?» дип төзәтелә. Шулай итеп, романның башында ук күтәреләчәк мәсьәләдә сыйнфый һәм милли факторлар урын алачагы чалымлана. Әйтергә кирәк, Мирсәетнең әтисе Хәйдаргали агай белән Нуриәхмәт хәзрәт арасындагы диалогның да хикмәте бар. Шуннан бер өзек китерик: «Нуриәхмәт хәзрәт бирәсе җавабы хакында бик җентекләп уйланды. Дәшми калу ярамый, мәсьәлә кабыргасы белән куелган. Янә бер кабат йөткеренеп алгач, ниһаять, тамагын кырып куйды.

— Шәригатьме? — дип башлады әүвәл һәм ипле генә сеңдереп дәвам итте.— Юк, Хәйдәргали, шәригать бу эшне тыймый. Коръән Кәримнең шундый-шундый хәдисендә халкының, үзен рәнҗеткән хакимнәргә буйсынмыйча, баш күтәрү хокукы да бар диелгән. Хәтта аны бәреп төшерү дә хәрам эш саналмас. Әйе!..

Канәгать кенә сакалын сыпырып куйды хәзрәт. Мирсәетнең дә җанына җылы инде. Димәк, ул да ярамас, хәрам эш белән шөгыльләнми икән бит!
Әмма Хәйдәргали агайның бирешергә түгел иде исәбе.
— Хуш, Нуриәхмәт абзый, бәхәсләшмим. Коръәнне вә шәригать эшләрен син миңа караганда яхшырак беләсең, әлбәттә. Анысы шулай. Тик менә тагын бер нәрсә бар бит әле: изге китапта «хакимнәр» диелгән, патша турында әйтелмәгән. Моңа ни диярсең?..
Мирсәетнең күңеленә янә шом йөгерде. Нигә шулай төпченә, нигә шулай үҗәтләнә инде аның әтисе, хәзрәтнең әйткәннәре белән генә килешсә ни була торгандыр...
Картның әллә ни исе китмәде бугай бу юлы. Әллә сер бирергә теләмәве иде, өздереп әйтте дә куйды:
— Хакиме ни дә, патшасы ни, шул бер үк нәрсә, ике чабата — бер кием инде ул, Хәйдәргали. Патша да хакимлек итә. Үз халкын рәнҗетә икән, аны төшерү мөмкин диелгән. Китап каршы килми моңарга.
— Анда бит «явыз булса, халыкны рәнҗетсә» диелгән, Нуриәхмәт абзый. Әле аның явыз булу-булмавын, рәнҗеткәнме-түгелме икәнлеген ачыкларга кирәктер бит әүвәл?..
— Ул кадәресен инде, китап түгел, халык үзе ачыкларга тиеш,— диде хәзрәт, ике уйлап тормый гына. Үзенең шундый сорауларга җавап табып, Хәйдәргалине тынычландыруына куанып та алды бугай ул. Ә бераздан, уйлана төшеп, дәвам итте.— Аннан, шунысы да бар бит әле, Хәйдәргали, патша — мөселман түгел, артык хафаланма. Гөнаһысы зур булмас!... Нәрсә, урыс патшасы безне бөтенләй дә рәнҗетми дип әйтергә җыенмый торгансыңдыр бит?!
Мирсәетнең әтисе шунда бөтенләй үзгәреп, ачылып китте.
— Анысы шулай, Нуриәхмәт абзый, безнең татарга көн күрсәтмиләр инде. Хак анысы... Елга янында яшәргә ярамасын, олы юлга якын яшәргә ярамасын, үз ана телендә гәҗит чыгарырга ярамасын — нинди тормыш була инде ул...
— Хак сөйлисең, Хәйдәргали, хак сүз сөйлисең. Хак сүз — дип җөпләп утырырга гына калды хәзрәткә.— Безләр өчен гомер кичерү — сират күпере кичүгә тиң бит ул».
«Сират күпере» романында Мирсәет Солтангалиевнең катлаулы язмышы бәян ителә. Аның язмышы, тоткан юлы, чыннан да, катлаулы иде. Большевик, татар дәүләтчелеген аякка бастыруны үзенчә аңлаган, үз кыйбласы булган атаклы, әмма фаҗигале шәхес. 1917 елның сентябре. М. Солтангалиев Крестовников заводы каршында татар эшчеләре белән очрашып, алдагы бурычлар һәм дөнья хәлләре турында тыныч кына әңгәмә корып тора. Шулчак завод капкасыннан күсәкләр, тимер-томыр белән коралланган рус эшчеләре килеп чыга. Ярсыган төркем Мирсәетләрне стенага китереп тери. Чак кына бәрелеш чигенә килеп җитмәгән аңлашудан соң, М. Солтангалиев төркемгә болай мөрәҗәгать итә: «Туганнар, сез миңа юкка кизәнәсез,— дип тыныч кына сөйләргә керешә Мирсәет.— Мин кешеләрне христиан белән мөселманга, рус белән татарга аермыйм. Сезнең, рус һәм татар эшчеләренең, дошман бер, ул — дөнья капиталистлары һәм буржуйлар. Күрәсез,— дип үзенең өс-башына игътибар юнәлтте ул,— мин үзем дә сездән ары китмәгән, крестьян улы, хезмәт иясе вәкиле. Баш очымда түбә, ашарга икмәк булса, шуңа ризалашып яшим. Ләкин мәңге шул хәлемдә торып каласым килми. Сез күргәннәрне, үзем күргәннәрне балаларым күрмәсен, алар бәхетле булсын дим».
М. Солтангалиев пролетар революциягә җаны-тәне белән хезмәт итә. Большевик Солтангалиев күздә тоткан республика чын мәгънәсендә татар дәүләтчелеге (яки милли дәүләтчелек) характеристикасы кысаларына туры килә ала идеме соң? Янә бер тарихи фактка игътибар итик. Ул романда бик җанлы күренешләрдән торган вакыйга рәвешендә бирелгән. 1918 елның 28 февраленә каршы төндә Казанда мөселман хәрбиләренең II Бөтенроссия корылтае җитәкчеләре Ильяс һәм Җиһан Алкиннар, Госман Токымбетов һәм Йосыф Мозаффаров кулга алыналар. (Тулырак мәгълүмат: Вәлиев Р. Фаҗига.— Казан, 1996.— 18 б.). Операция Солтангалиев тәкъдим иткән план буенча тормышка ашырыла. Аның алдыннан булган киңәшмәдә Грасис белән М. Солтангалиев арасында шундый сөйләшү була:
«— Сорауга җавап бирмәдең, иптәш Солтангалиев...
— Бүген төнлә... Таңга таба өйләренә наряд белән барырга кирәк, әмма шау-шу чыгармаска.
— Адресларын табу өчен генә дә күпме вакыт кирәк булачак. Булмас эш сөйли... Хыял гына. Ул махсус шулай буташтыра...

— Адреслар бар,— дип, кесәсеннән кызыл тышлы куен дәфтәрен чыгарып күрсәтте Мирсәет.

— Кемнәр алырга бара?

— Үзебез. Һәр наряд башында бер татар большевигы торырга тиеш. Табарбыз, кешеләр бар». Романда, Ильяс Алкин белән сөйләшкән вакытта, әлеге адымга баруның сәбәпләрен болай дип белдерә: «Әгәр дә мәгәр сез ният иткән Идел-Урал штаты тормышка ашар булса, ике уйламас, бүген үк янәшәңә тән сакчың булып басар идем... Тик син аңла, аңларга тырыш, бу — тормышка ашмас хыял гына. Һәм шул хыялның, синең белән минем генә түгел, бөтен бер милләтнең башын һәлакәткә юлыктыруы ихтимал. Кайда гына һәм нинди мохиттә булуны онытмаска иде бит, менә нәрсә!.. Урыс-татар сугышы чыкса, ни белән бетәчәген уйларга кирәк! Аннары милли хис — әйбәт нәрсә ул. Әмма милләтне коллыктан азат итүнең бердәнбер чарасы сугыш түгел. Большевиклар, Советларга тартылуым әнә шуның өчен... Укыганың бармы икән, узган ел ук инде Совет хөкүмәте Россия халыкларының хокуклары турында декларация кабул итте. Ул документка иптәш Ленин үзе кул куйган. Һәр халыкның үзбилгеләнү хокукы таныла анда...

Әдәби версия шулай. Ә чынлыкта исә М. Солтангалиев Советларның бу гамәлен түбәндәгечә аңлата: «а) Татар дәүләтен игълан итүнең милләтчеләр файдасына кискен борылыш ясавы мөмкин; б) Без бу вакытта кораллы конфликт юлына баса алмый идек: беренчедән, безнең (ягъни Советларның) Казанда кораллы көчләребез юк иде диярлек, ә Хәрби Шура татар солдатларының санын Казанда гына да 60—80 меңгә кадәр житкерә ала иде» (Султангалиев Мирсаид: статьи, выступления, документы.— Казан, 1992.— 421—422 б.б.).

Күренә ки, большевиклар житәкчелегендәге Совет хакимияте четерекле милли-сәяси мәсьәләләрне көч куллану юлы белән хәл итүне кулайрак күргән. Кызганычка каршы, Солтангалиев кебек «милли большевиклар»да үз халыкларына карата башлыча шундыйрак чаралар күрүне хуплаганнар (Вәлиев Р. Фажига, 21 б.). Кыскасы, М. Солтангалиев күздә тоткан республика чын мәгънәсендә милли дәүләтчелек кысаларына ятышып бетми иде. Чөнки әлеге республиканы оештыру юллары һәм нигезе үк тарихи үсеш-үзгәреш кануннары белән капма-каршы килә иде. Милли дәүләтчелек бервакытта да милләтне дошман фиркаләргә бүлү, аларны бер-берсе белән сугыштыру, милләтнең бер өлешен аның икенче өлешеннән кырдыру юлы белән төзелми. М. Солтангалиев күзлегендә исә милли-азатлык хәрәкәте беркадәр сыйнфыйлаштырылган иде.

## Тарихи романның төрләре

Тарихи роман жанрының безнең әдәбияттагы «иң борынгы» төре — тарихи-революцион роман. Тарихи тематиканы яктырткан әсәрләрнең иң зур күпчелеге әлеге төргә керә. Менә алар: «Г. Ибраһимов — «Безнең көннәр», «Тирән тамырлар», М. Галәү — «Болганчык еллар», «Мөһәжирләр», Ш. Камал — «Таң атканда», К. Нәжми — «Язгы жилләр», И. Туктар — «Ике егет», Г. Әпсәләмов — «Күк күкрәр», Г. Ахунов — «Идел кызы», И. Салахов — «Иманнәр тамыр жәйгәндә», Ә. Гаффар — «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы», М. Хәсәнов — «Язгы ажаган» һ. б.

Тарихи-революцион романда реаль чынбарлыкта булып узган тарихи-сәяси вакыйгалар геройларның кылган гамәлләре, уй-фикерләре аша бирелә. Әлеге төрнең асылы турында сүз барганда, әлбәттә, беренче чиратта күз алдына 1905—1907 еллардагы Беренче рус революциясе, 1917 елдагы Февраль һәм Октябрь революцияләре, алар белән бәйле вакыйгалар килә. Әмма әдәбият фәне әлеге төрнең колачын бу фактлар белән генә чикләми, аңа 1917 елгы Октябрь революциясе нәтижәләрен дә кертә. Соңгыларын исә ачыктан-ачык кораллы бәрелешләр (әйтик, гражданнар сугышы, авыллардагы чуалышлар) буларак кына аңларга кирәкми. Көчләп күмәкләштерү, «кулакларны сыйныф буларак юк итү» сәясәте, ил халкы өчен кыйммәткә төшкән индустрияләштерү һ. б.— болар барысы да соңгы революциянең нәтижәләре иде. Хәер, «соңгы» сүзе үзе дә абсолют мәгънәгә дәгъва кыла алмый. Чөнки нәрсәнең соңгы булуын тарих үзе генә билгели.

Кешелек тарихында революцияләр күп булган. Ара-тирә алар контрреволюцияләр белән чиратлашканнар. Бер Франция генә дә, мәсәлән, XVIII гасыр ахырында — XIX гасырда: 1789—1794, 1830, 1848, 1871 елларда берничә тапкыр революцияләр давылларын кичергән. 1848—1849 елларда шулай ук Германиядә,

Италиядә һәм Австрия империясендә революцияләр булып узган. 1775—1783 һәм 1861—1865 елларда революцияләр ялкыны АКШта дөрләгән. Мәгълүм ки, Россия тарихы да бу җәһәттән ярлы түгел.

Кыскасы, вакыйгаларны колачлавы буенча тарихи роман жанрының тарихи-революцион төренең бирге чиге билгеле бер дәрәҗәдә тәгаенләнде дияргә мөмкин. Әмма аның аргы (башлану) чиге дә югарыда искә алынган революцияләр белән генә билгеләнми. Чөнки революциягә китерүче революцион ситуация үзенең барлык кискенлеге белән, чагыштырмача кыска вакыт эчендә туса да, аның өлгерү процессы дистәләрчә елларга сузыла. Россиядә XX гасырның беренче-икенче дистә еллыкларында булып узган революцияләр дә бу очракта искәрмә була алмыйлар. Шул сәбәпле, аерым алганда, М. Галәүнең XIX гасырның соңгы чирегендә булып узган вакыйгалар тасвирланган әсәрләрен тарихи роман жанрының тарихи-революцион төренә кертәбез. Һич шикләнмичә аларда искә алынган революцияләрне (аерым алганда, 1905 елгы революцияне) тудырган ситуациянең өлгерү процессының кайсы этаплары бирелгәнен әйтә алабыз. «Болганчык еллар» һәм «Мөһәҗирләр» романнарының дәвамы буларак планлаштырылган әсәрләрнең (мәгълүм булганча алар язылмый калалар) 1917 елгы Октябрь революциясе вакыйгаларын колачларга тиеш булуы безнең фикеребез файдасына җавап бирә.

Ә инде тарихи-революцион романның барлыкка килү вакыты буенча, иҗат ителү хронологиясендә беренчелекне Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романының беренче варианты тота.

Тарихи роман жанрының үсеш баскычлары хронологиясендә аның төрләренең барлыкка килү вакыты буенча икенче төре — тарихи-психологик роман. Әлеге төр үзенең күләме, зурлыгы буенча югарыда карап үтелгән төрдән күпкә кечкенә. М. Галәүне без хаклы рәвештә аңа нигез салучы дип атый алабыз. Бу очракта әдипнең «Кабылсай» исемле романы күздә тотыла. кызганычка каршы, ул әсәр дә, «Болганчык еллар» һәм «Мөһажирләр» романнары кебек үк төп оригиналда басылмыйча, русча тәрҗемәдә генә дөнья күрде. (Галяу Махмуд. Кабулсай (С татар. пер. автора. Лит. обработка С. Сапожниковой).— М.: Москв. т-во писателей, 1934). Романда революциядән соңгы авылдагы тормыш, кешеләр арасындагы сыйнфый каршылыклар психологик планда сурәтләнә.

Тарихи-психологик әсәрләрдә тарихи вакыйгалар, тормыш агышы төп геройның, персонажларның кичерешләре, күңел тетрәнүләре, фикер агышы, каршылыклары, икеләнүләре, психологик бәяләмәләре аша тасвирлана. Аларга катлаулы һәм киң планлы коллизияләр — сурәтләнгән характерларда чагылган теләк-омтылышларның, мәнфәгатьләрнең бәрелеше, шәхес белән аны чолгап алган тирәлек арасында яисә геройның үз күңелендә туган каршылыклар хас. Психологик характердагы әсәрләрдә тормыш-чынбарлык кеше күңеле аркылы үткәрелеп, аның сиземләве, тоюы аркылы гәүдәләндерелә. Әдәбият фәне психологизмның (психологик анализның) махсус билгеләре итеп түбәндәгеләрне таный: «Сурәтләү объекты (өлкәсе) — хис-кичерешләр дөньясы; кешенең халәте җентекләп өйрәнелә, күзәтелә; катлаулы, каршылыклы хис-кичерешләр бербөтен процесс буларак тасвирлана; нинди дер бер нәтиҗәгә, халәткә, хис-фикергә алып килгән хәрәкәтнең сәбәбе эзләп табыла, ачыклана һәм шул кичереш, мөнәсәбәтләр хәрәкәтнең һәр күчеше, борылышы җентекләп сурәтләнә». (Әдәбият белеме сүзлеге (Төз. Әхмәдуллин А. Г.— Казан, 1990.— 144—145 бб.).

Тарихи-психологик романнарда психологик тирәнлек эпик масштаблык, күп планлылык һәм тарихилык (җөмләдән авторның тарихилык хисе) белән тыгыз бәйләнештә тора, сюжет сызыкларының үзара үрелүендә әлеге бәйләнеш конкрет рәвештә чагыла.

Психологизм әсәрнең сюжет төзелешенә җитди үзгәрешләр кертә. Бу хакта татар прозасындагы психологик процессны махсус өйрәнгән Ф. Хатипов болай дип язды: «Бу инде чиста вакыйгалар агышыннан гына торган сюжет түгел, вакыйган-психологик сюжет. Тышкы эпизодлар һәм рухи тормыш процессы аңа чиратлашып динамика бирәләр. Бу исә автомобиль-амфибияне хәтерләтә — ул коры җирдә тәгәрмәчләр, ә суда винт ярдәмендә хәрәкәткә килә, әмма һәрвакытта да хәрәкәтнең чыганагы бер — двигатель. Бу мәгънәдә психологик әсәрнең сюжеты кеше тормышының тышкы һәм эчке процессын берләштерә... Күңел хәрәкәтенең эпизодлар белән хокукый дәрәҗәсе тигезләшә, ул игътибар объекты була». (Хатипов Ф. Духовный мир героя, 121 б.)

Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» романы — тарихи роман жанрының тарихи-психологик төренең оригиналда нәшер ителгән классик үрнәге. Әдип үзенең әсәрендә төп героеның рухи дөньясын яктыртуга зур игътибар бирә. Ул

күңелнең, уй-кичерешләрнең каршылыклардан торган катлаулы халәтен төрле яклап ачарга омтыла. Төп герой булган Сәфәргалинең һәм кайбер персонажларның нинди дә булса фикергә килүе, алдагы тормышка мөнәсәбәте киеренке характердагы психологик процессның нәтиҗәсе буларак бирелә. Авторның геройлары (Сәфәргали, Зәйтүнә) уй-фикерләр дөньясында бөтереләләр, хисләр-кичерешләр казанында кайныйлар, хыял дәрьясына да кереп чыккалыйлар, кырыс чынбарлыкта чыныгалар. Зәйтүнәнең Сәфәргали белән очрашу мизгелләре, Сәфәргалинең кичерешләре, Фәсхигә мөнәсәбәте, реаль тормышны һәм киләчәкне күзаллавы мисалларында без психологизмның классик чагылышы белән очрашабыз.

Соңгы елларда иҗат ителгән тарихи романнар арасында тирән психологизм өстенлек иткән әсәр — Ф. Латыйфиның «Хыянәт» романы. Без аны шикләнмичә тарихи-психологик төргә кертәбез. Әсәр, милли тарихыбызның гаять катлаулы һәм фаҗигале дәверен (Казан ханлыгы дәверен) чагылдыру белән бергә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең сафлыгын, мәхәббәт һәм дуслыкның тирәнлеген, хыянәтнең ачылыгын тасвирлаудагы тормышчанлыгы белән игътибарны җәлеп итә. Санька-Сәетнең динен алыштыру вакытындагы уйлары, аның милләте һәм кабул иткән мөселманлыгы арасындагы каршылыклар гаять оста сурәтләнгән. Казан өчен барган сугышлар вакытындагы икеләнүләре, мәхәббәте һәм гаилә факторы тәэсирендә Сәетнең катгый карарга килеп, Казанны саклаучылар арасына басуы, Саньканың исламга күчеп, Сәет исемен алуы шартларында Кол Шәрифнең кичерешләре һ. б. романдагы психологизмны тагын да тирәнәйтә төшә. Мисал итеп, әсәрдән берничә өзек китерик. Менә Саньканың мөселманлыкка чыгуы эпизодыннан бер мизгел:

«...Күңелендә урнашып өлгергән тынычлану хисен кул белән йолкып алдылармыни: тагын шикләр өермәсе кузгалды, күңелендә курку, бу тыелгысыз ташкын сытып-изеп үтәчәк кан-кардәшләрен кызгану дулкыны күтәрелде. Сугышның котылгысыз икәнен белгән хәлдә дә ул аны булдырмас өчен җанын-тәнен кызганмаска әзер иде. Әмма хисләрен авызлыклап тыя алмаган кебек, үзенең чарасыз икәнен, вакыйгалар колы икәнен дә яхшы аңлый. Яннарына сыендырып кеше иткән, ил-көн арасында дәрәҗә, мал-мөлкәт биргән, нан һәм дан уртаклашкан казанлылар газиз һәм якын булган кебек, урыс кавеме дә аңа дошман түгел, якын һәм газиз иде, һәр ике якка миһербан, шәфкать һәм мәрхәмәт, бер-берен аяуны теләп кемнәргә генә баш орырга!!!

Әгәренки шушы мизгелдә «Син — дөньялыкта Сәет Сәлим углы, ә тумышың, чыгышың илә Александр Савельевич Булгаков, җаныңнан ваз кичсәң, барысы да үз урынына кайтыр, урыс явы кубарылып кайтып китәр, казанлылар тынычланып элеккечә көн күрә башлар. Ризамы шушыңа?» — дисәләр, ул ике дә уйлап тормыйча каланың иң биек манарасына менеп йөз, мең мәртәбә:

— Риза, риза, мең кәррә риза! Тик хәләлем Гөлйөзем сау булсын, газизләрем Җәгъфәр илә Галия генә ачылып җитмәгән чәчәк көйгә харап булмасыннар.

Кешеләр! Сез — адәми зат, аллаһы тәгаләнең сөекле коллары, табынуыгыз төрлечә булса да, бер кодрәт иясенең балалары, туктагыз, акылыгызга килегез, җир йөзендә урын җитмиме әллә,— дип сөрән салыр иде.

Аһ, ни аяныч! Бу аның кулыннан килми. Күзләрен кан баскан, җан һәм кан даулап, гөнаһлы дөньялыкта үзләренә җәннәт кора алган казанлылардан җир-су яуларга килгән явыз урыс Иванны айнытыр көч юктыр, күрәсең. Мондаен дәһшәт каршында казанлыларга бер генә юл: канга — кан, үлемгә үлем белән җавап бирү, изге каланы яклап соңгы сулышкача дошманны кыру, юк итү, җир өстендә эзе калмаслык итеп себереп түгү.

Гаскәр үткән арада Сәет шуларны уйлап өлгерде».

Әйе, Сәет озак икеләнүләрдән газаплана һәм бу табигый кабул ителә. Казанны саклаучылар сафына басканчы аңа күп уйларга, күрергә, кичерергә туры килә. Автор аның уй-кичерешләрен тасвирлаганда кабатлау алымын да читләтеп узмый. Безнеңчә, ул бирердә билгеле бер дәрәҗәдә әсәрнең эчке тәэсир көче артуга исәп тота һәм ялгышмый. Әйтергә кирәк, Ф. Латыйфиның бу мәсьәләдә ирешкән уңышы кечкенә түгел.

Тарихи роман жанрының тарихи-психологик төре, хәзергә, югарыда күрсәтелгән өч роман белән чикләнә.

Бездәге тарихи роман жанрының барлыкка килү вакыты буенча өченче төре — тарихи-биографик роман. Бер караганда, төрләрнең хронологиясендә өченче урынны И. Газиның «Онытылмас еллар»ына бирергә кирәктер кебек тоела. Әмма тоела гына. Чөнки Ә. Фәйзинең «Тукай» романы дөнья күргәнче тарихи роман жанрының башка мөстәкыйль төре — роман-эпопея буларак бәяләнгән

«Онытылмас еллар»ның беренче китабы гына нәшер ителергә өлгерә, әдип трилогиянең икенче һәм аннан соң өченче кисәге өстендә эшләвен дәвам итә. Әсәрне тулы канлы, классик мәгънәдәге эпопея иткән соңгы кисәк — «Канатланыр чак», югарыда әйтелгәнчә, 1973 елда гына басылып чыга. Әгәр дә И. Гази трилогия урынына аның беренче кисәге белән генә чикләнгән булса, без бу очракта әсәрне тарихи роман жанрының иң «борынгы», беренче төренә — тарихи-революцион роман төренә кертер идек. Әлбәттә, трилогиядә революцион ситуация, революциянең алшартлары, үзе һәм нәтиҗәләре урын алган чорлар — тарихи-революцион тематика яктыртыла. Әмма, әйткәнебезчә, трилогия үзенең эчке төзелеше, анда бирелгән вакыйгаларның динамикасы, сюжет сызыкларының бер үзәккә тартылу рәвеше, композиция һәм сюжет үзенчәлекләре буенча гадәти тарихи-революцион романнан күпкә аерыла һәм роман-эпопея буларак бәяләүне таләп итә. Бу төр турында без түбәндәрәк сүз алып барырбыз. Җыеп әйткәндә, барлыкка килү вакыты буенча тарихи-биографик роман тарихи роман жанрының өченче төре иде.

Тарихи-биографик романга нигез салынуны Ә. Фәйзи исеме белән бәйләсәк, без, ихтимал, ялгышмабыз. Әлеге төргә түбәндәге әсәрләр керә: Ә. Фәйзи — «Тукай», Г. Шәрипова — «Гафур гаиләсе», А. Расих — «Ямашев», Ш. Маннур — «Муса», Җ. Тәрҗеманов — «Көмеш дага», Р. Мөхәммәдиев — «Сират күпере» һ. б.

Тарихи-биографик романда документальлекнең роле үсә, әһәмияте арта. Шул ук вакытта, икенче яктан караганда, еш кына фабуланың катгый хронологиягә буйсындырылуы, ара-тирә биографизмнар белән артык мавыгулар да сизелә. Публицистик стиль алымнарын чаманы белми куллану да соңгылары өчен уңай җирлек тууга булышлык итә.

Тарихи-биографик роман тарихи шәхеснең тормышын һәм эшчәнлеген тирәнрәк аңлау, күзаллау, аның кичерешләре һәм гамәлләре аша үткәннәрне танып-белү юлында зур әһәмияткә ия. Чөнки, әйткәнебезчә, аның үзәк герое — конкрет тарихи вакыт аралыгында яшәгән реаль шәхес. Соңгысының тирәлеккә мөнәсәбәте һәм чорның вакыйгаларына бәяләмәләре, актив позициясе һәм кылган гамәлләренең тарихи-фактик яктан төгәл бәян ителүе, җанлы картиналар аша күрсәтелүе әсәрнең информатив сыйфатын баета, тәэсир-ышандыру көчен арттыра. Тарихи-биографик романда, гадәттә, башка тарихи шәхесләр дә катнаша. Аларның образлар буларак роле үзәк геройга фон тудыру, яисә аның аралашу һәм эшчәнлек даирәсен билгеләү, күрсәтү белән генә чикләнми. Әлбәттә, тарихи-биографик роман өстендә эшләгәндә, реаль шәхесне сурәтләгәндә дә автор үз фантазиясен эшкә җигә. Ул тарихи шәхеснең берәр сыйфатын, хәл-әхвәлен калкурак итү теләге белән вакыйгаларны сюжет үсеше логикасына буйсындыра, ягъни чынында ул кичермәгән хәлгә куя яки эшләмәгән берәр эшне эшләтә (Хәйри Х. Язучы һәм тормыш, 207 б.), әсәргә хыял нигезендә туган образларны да кертә. Бу исә биографизм шаукымына бирелеп китмәү өчен беркадәр уңай йогынты ясый. Әмма монда да чаманы белергә, тарихи шәхесне реаль чынбарлыктан ераклаштырудан сак булырга кирәк.

Югарыда күрсәтелгән тарихи-биографик романнар сюжет һәм композиция төзелеше, стиль мәсьәләләре буенча бер-берсеннән билгеле бер дәрәҗәдә аерылалар. Бу табигый күренеш. Әйтик, Г. Шәрипованың «Гафур гаиләсе» романында тормыш-көнкүреш факторына зур урын бирелсә, Ә. Фәйзинең «Тукай» романында хронология басымы, төп геройның тормыш юлын җентекләп хикәяләү алымы күзгә ташлана. А. Расихның «Ямашев» трилогиясендә (аерым алганда, соңгы китапларда, бигрәк тә өченче китапта) һәм шулай ук Ш. Маннурның «Муса» романында психологик анализга игътибарның арта баруы сизелә, ә Җ. Тәрҗемановның «Көмеш дага» һәм Р. Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» романнарында исә тарихи-биографик хрониканың кайбер аермачык билгеләрен табарга мөмкин.

Тарихи роман жанрының дүртенче төре — тарихи-романтик роман. Бу мәсьәләдә Х. Хәйри һәм Ф. Хатипов бәяләмәләре белән килешкән хәлдә, без һич икеләнмичә әлеге төргә Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» романын да кертә алабыз. Әсәрнең сюжеты романтик стильдә корылган. Анда төп геройлар — Тотыш углан һәм Аппак — романтик геройлар. Аларның мәхәббәте, кичерешләре, тирәлеккә мөнәсәбәте, Тотышның кылган гамәлләре ыруларның тормышы-көнкүреше, вакыйгалар романтик рухта сурәтләнгән.

Н. Фәттахның романтизмы турында әдәби тәнкыйтьтә күп тапкырлар әйтелде, язылды. Әмма аны «Әтил суы ака торур»ның кимчелеге итеп карарга ярамый. Чөнки мәгълүм: тарих, кешелек җәмгыяте үсешен өйрәнүче фән буларак һәм

сәнгать әсәре булган тарихи роман һәрберсе үзләренә генә хас булган үзенчәлекләргә ия. Моны Н. Фәттах яхшы аңлап иҗат итә. Алай гына да түгел, әйтелгәнчә, әсәре өстендә эшләгәндә аңа тулы һәм туры мәгънәдә фәнни-тикшеренү эшләре алып барырга туры килгән. Әсәрнең сюжет сызыклары бергә үрелеп бара, аның геройлары кискен, идеологик социаль һәм психологик каршылыкларга, конфликтларга керәләр. Нәтиҗәдә романда сурәтләнгән тарихи чор үзенең бөтен яклары: халык көнкүреше, аның рухи мәдәнияте, көрәш-сугыш күренешләре, фольклор, образлар, авторның лирик һәм фәлсәфи-публицистик чигенешләре белән күз алдына килеп баса.

Тарихи роман жанрының тарихи-романтик төренә якын торган тагын бер төре — тарихи-маҗаралы роман.

Маҗаралы әсәрләрдәге вакыйгалар еш кына гадәттән тыш шартларда, кискен үзгәрешләр белән бара. Герой көтелмәгән хәлләргә дучар була, кызыклы, серле, куркыныч, дәһшәтле ситуацияләргә эләгә. Мавыктыргыч, динамик, үткен сюжет кискен үзгәрешләргә бай, урлап качу, эзәрлекләү, куркыныч хәл һәм аннан котылулар белән тулы була.

Безнең әдәбиятта тарихи-маҗаралы романның соңгы дистә ел эчендә барлыкка килүе һәм алга таба перспективалы үсеш алуы башлыча М. Хәбибуллин иҗаты, төгәлрәк әйткәндә, аның тарихыбызның борынгы дәверләре яктыртылган әсәрләре белән бәйле. Әдипнең «Кубрат хан», «Илчегә үлем юк», «Шайтан каласы», «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» романнары кайбер кимчелекләренә карамастан, тарихи роман жанрының тарихи-маҗаралы төренең уңышлы үрнәкләре булып исәпләнергә хаклы. Әлеге әсәрләр фабуласына хәрәкәт динамикасын үстерү ысулы буларак интрига хас. Вакыйгада катнашучыларның характерларын ачуда аларның роле зур. М. Хәбибуллин югарыда күрсәтелгән романнарында интригаларның гадәттәге ике төре дә очрый: аларны йә башлыча вакыйгалар тудыра («Кубрат хан») яки алар бәрелештә катнашучыларның берсе (бер ягы) тарафыннан оештырыла («Илчегә үлем юк», «Шайтан каласы», «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный»). Әсәрләрдә вакыйгаларның үзгәрүчәнлеге, сарай интригалары, мәхәббәт маҗаралары (Дәүран-Назлыгөл, Бачман-Акбикә), Кубрат хан болгарларының хазарлар белән бәрелеше, Казанга нигез салыну, болгарларның монголларны 1223 елда тар-мар итүләре һ. б. — болар барысы да мавыктыргыч итеп күрсәтелә, бәян ителә.

Тарихи роман-хроника исә — тарихи роман жанрының вакыйгаларны тормышта булган вакыт эзлеклегендә сурәтләүгә өстенлек бирелгән гаять үзенчәлекле төре.

Мөстәкыйль жанр буларак хроника сирәк кулланыла. Әдәбиятчылар, гадәттә, хроникага А. Гыйләҗев һәм А. Литвинның «Августның алтысына кадәр» дигән романын кертәләр. (Әдәбият белеме сүзлеге, 205 б.) Югарыда карап үтелгән әсәрләрдән без И. Салаховның «Колыма хикәяләре»н жанрның роман-хроника төренең ачык мисалы дип исәплибез. «Колыма хикәяләре»нең жанр таныкнамәсе турындагы мәсьәләгә кагылып, А. Гыйләҗев та әсәрне роман-хроника дип таныды. Аерым алганда, ул болай дип язды: «Эчтәлеге белән гаять үзенчәлекле, документаль төгәллек белән язылган бу әсәр — Сталин чорының роман-хроникасы да, илебез халыкларының тирән фаҗигасе дә ул. Шуның белән бергә, бик күп миллионнар арасыннан могҗиза белән генә исән калган Ибраһим ага Салаховның җан авазы да.

Бу китап сез моңарчы укыганнарның берсенә дә охшамаган. Ибраһим Салахов шактый гомерен шушы әсәрне язуга багышлаган. Автор үзе бу әсәрен бер сүз белән генә «Фаҗига» дип атау ягында тора. Болай дип атау гадел, дөрес бәя. Мәгәр бу шомлы сүз генә әсәрнең бөтен тукымасын, бәян ителгән гадәттән тыш вакыйгаларны үзенә сыйдырып бетерә алмый. Әсәр формасы белән дә, эчтәлеге белән дә моңарчы без белгән әдәби калыпларга сыймый, аңа үзгә бәя, яңа үлчәү кирәк»... (Гыйләҗев Аяз. Җан авазы. Салахов Ибраһим. Колыма хикәяләре.— Казан, 1989.— 5 б).

Әсәргә югары дәрәҗәдәге тәэсир көче, хикәяләүгә җанлылык, катгый хронологик эзлеклелек хас. Шәхес культы елларында кулга алынып, гаепсез хөкем ителгән кешеләрнең авыр тормышы, фаҗигале язмышы барлык яклары белән ачылган. Без төрле катлау, төрле милләт вәкилләре, фән һәм мәдәният эшлеклеләре, төрле профессия ияләре, зыялылар, татар халкының асыл уллары — реаль яшәгән шәхесләр белән очрашабыз. Аларның иң авыр елларда, иң кыен юлларда да горур, намуслы, чиста күңелле булып калулары бездә соклану, тирән ихтирам уята. А. Гыйләҗев сүзләре белән әйткәндә, әсәрнең һәр сәхифәсеннән, һәр юлыннан батырлык, кыюлык, гаделлек бөркелә.

Тарихи роман жанрының соңгы елллардагы кардиналь сәяси үзгәрешләр нәтиҗәсендә һәм халкыбызның милли дәүләтчелеген торгызу юлына аяк басуы белән турыдан-туры бәйле рәвештә туган төре — тарихи-сәяси роман. Ж. Рәхимовның «Батырша» романы — аның ачык мисалы. Әлеге төргә кергән әсәрнең үзәгендә милли-азатлык көрәше тора, барлык сюжет сызыклары да әлеге көрәш проблемасына буйсындырыла. Төп конфликт — тарихи конфликт: самодержавиеле хакимиятнең милли-дини изү сәясәте, һәм, моңа җавап рәвешендә халыкларның (аерым алганда, татарларның) баш күтәрүе, милли-азатлык көрәше җәелдерүләре. Хәер, югарыда карап үтелгән әсәрләрдә дә сәяси фактор (әйтик, революцияләрнең асылы) зур урын ала. Әмма аңа карап кына без аларны сәяси-тарихи роман дип бәяли алмыйбыз. Чөнки соңгысында мәгънә ягыннан күпкә үзгә мәсьәлә — милли дәүләтчелек өчен көрәш мәсьәләсе күтәрелә. Югарыда күрсәтелгән жанр үзенчәлекләре, сюжет сызыкларының төп проблематикага мөнәсәбәте, конфликтның чишелү юллары буенча «Хыянәт», «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» романнары да тарихи-сәяси романнар рәтенә кертелә алмыйлар. В. Имамовның «Сәет батыр» повестен исә без шикләнмичә тарихи-сәяси проза исәбенә кертә алабыз. Киләчәктә бу төрнең хронологик колачы киңәюе бик ихтимал.

Тарихи роман-эпопея — сюжет-композиция, фабула-структура, тарихи вакыйгаларны тасвирлау һәм хронологик вакыт аралыгын колачлау җәһәтендә, геройларның тарихи үсеш-үзгәреш процессындагы үтә әһәмиятле вакыйгаларда урынын билгеләү, аларның шәхес буларак эволюциясен күрсәтү мәсьәләләре буенча тарихи роман жанрының югарыда карап үтелгән төрләре белән чагыштырганда күпкә мөстәкыйльрәк, гаять үзенчәлекле төре. Тарихи роман-эпопеяда, Х. Хәйри сүзләре белән әйтсәк, тарихи хәрәкәт, халыкның тарихтагы хәлиткеч роле ачыла, тарихи вакыйгалары, шәхесләр халык массасы күзлегеннән карап сурәтләнә. (Хәйри Х. Иҗат чишмәләре, 97 б.)

Эпопеяның бүгенге әдәбият фәнендә кабул ителгән билгеләмәсе түбәндәгечә: «Эпопея — эпик төргә кергән әсәрләрнең иң зур, эре формасы; халыклар тарихына, милләтләр язмышына караган проблемаларга, иҗтимагый вакыйгаларга нигезләнә; халык образы, зур шәхесләрнең язмышы, тарих бәйләнеше гәүдәләнә» (Әдәбият белеме сүзлеге, 219 б.).

Сугыштан соңгы татар әдәбиятында зур күренеш, олы казаныш, И. Гази иҗатының иң югары ноктасы, иҗат таҗы буларак бәяләнгән «Онытылмас еллар» трилогиясе — хаклы рәвештә М. Шолохов, А. Толстой, К. Федин, К. Седых, М. Стельмах әсәрләре рәтендә лаеклы урын алган татар тарихи роман-эпопеясы.

Роман-эпопея безнең әдәбият өчен чагыштырмача сирәк күренеш булса да, аның үсеше әлеге атаклы трилогия белән генә чикләнеп калмады. Вакыт татар роман-эпопеясының перспективалы булуын күрсәтте. Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар» дилогиясе моның ачык мисалы. Безнең эрага кадәр III—II гасырлар арасында булган тарихи вакыйгалар урын алган, әлеге дәвердә Сөн җәмгыятенең эволюциясе, төрле катлауларның (аксөякләрнең; хәрбиләрнең, гади халыкның) дәүләтчелек мәсьәләсенә карата карашлары һәм актив позицияләре, аларның еш кына каршылыклардан тора торган үзара мөнәсәбәтләре, Сөн-Кытай мөнәсәбәтләре; әсәрдәге төп конфликт булган алар арасындагы дошманлык, сөннәрнең тышкы сәясәте, эчке хәләте һәм тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре һәм йолалары, сөннәрнең тарихи вакыйгаларга мөнәсәбәте, бәяләмәләре күрсәтелгән әлеге киң күләмле, күп планлы, күп персонажлы, ике китаптан торган әсәр үзенең сюжет-композиция үзенчәлекләре, эчке төзелеше, колачлаган тарихи вакыт аралыгының зурлыгы, вакыйгаларның һәм характерларның бирелеше һәм күп кенә башка сыйфатлар буенча тулы мәгънәдә тарихи роман-эпопея таныкнамәсенә лаек.

Шулай итеп, хәзерге вакытта безнең әдәбиятта тарихи роман жанры түбәндәге төрләргә бүленә: тарихи-революцион роман, тарихи-психологик роман, тарихи-биографик роман, тарихи-романтик роман, тарихи мажаралы роман, роман-хроника, тарихи-сәяси роман, тарихи роман-эпопея. Бу бүленеш, әлбәттә, мәңгелек була алмый. Әдәби процесс барышында, киләчәктә яңа тарихи романнар иҗат ителгән тәкъдирдә аның билгеле бер дәрәҗәдә үзгәрешләр кичерүе бик ихтимал. Бу үзгәрешләр жанр үсешенең мөһим күрсәткече булачак.

Татарстан мөстәкыйльлек юлына аяк басу белән халкыбыз иркенрәк сулый башлады. Милли мирасыбызны кайтару, үткәнебезне өйрәнү һәм аны әдәбият-сәнгатьтә тасвирлау юнәлешендә киртәләр бетүгә якынлаша. Инде күп кенә шәхесләребез халкыбызга кайтарылды, аларның исемнәре акланды, әсәрләре дөньяга чыга тора. Татар укучысы хәзер Заһир Бигиев, Солтан Габәши, Һади Атласи, Садри һәм Һади Максудилар, Гаяз Исхакый, Зәки Вәлиди, Муса Бигиев, Исмәгыйль Гаспралы, Йосыф Акчура, Риза Фәхретдин һәм башкаларның иҗатлары, тормыш юллары, эшчәнлекләре, рухи дөньялары белән якыннанрак таныша башлады. Кызыксыну үскәннән-үсә бара, чыганаклар, мәгълүматлар табыла тора. Бу хәл әлеге шәхесләр турында яңадан-яңа тарихи-биографик әсәрләр иҗат ителү өчен уңай җирлек тудыра. Моннан чирек гасыр чамасы элек үк (1974 елда) әдәбият галимебез Х. Хәйри Мулланур Вахитов, Кәрим Тинчурин, Габдулла Кариев, Салих Сәйдәшев һәм башкаларның образлары үзәккә куелган романнарның язылачагына ышаныч белдергән иде. Хәер, әлегә ул шәхесләр турында әсәрләр күренми. Әмма аның тарихи-биографик романның киләчәген уңай фаразлавының хаклыгы расланды дия алабыз. Соңгы вакытта гына К. Миңлебаевның татарның мәшһүр рәссамы һәм скульпторы Бакый Урманче тормышын һәм иҗатын яктырткан «Бакый» романы иҗат ителү — моның ачык мисалы.

Без тулы мәгънәдә тарихи, мөһим вакыйгаларга бай чорда яшибез. Бер империя таркалды, аның варисы булган икенчесе, тарихи үсеш-үзгәреш кануннарына каршы килеп, җан-фәрман тырышып әлеге процессны тоткарларга омтыла. Халкыбыз зур кыенлыклар, авырлыклар белән милли дәүләтчелегебезне аякка бастырып килә. Әлеге шартларда тарихи-сәяси романнарның, тарихи роман-эпопеяләрнең һәм тарихи роман-хроникаларның әһәмияте кискен үсә. Көчәя-үсә барган ихтыяҗ иҗат процессына этәргеч ясый, яңа әсәрләр туа.

Соңгы ун елда борынгы тарихыбызга игътибар арту, бу юнәлештә дистәгә якын роман басылып чыгу — шулай ук сөенечле күренеш. Бу иҗат киләчәктә дә тукталып калмас, Алтын Урда дәверен, Казан ханлыгының башлангыч чорларын, Мәүлә Колый заманнарын яктырткан романнар да һәм башка тарихи әсәрләр дә барлыкка килер дип ышанып калабыз.



# ТҮЗЕМНӘР ГЕНӘ БӘХЕТКӘ ЛАЕК

Фәнис Яруллин.

Җир шарының төрле кыйтгаларында бу исемне ишетмәгән берәр татар гаиләсе, соңгы утыз биш ел эчендә аның китапларын укып үсмәгән берәр татар баласы калдымы икән? Ай-һай, юктыр... Шикләнми әйтергә була: «Татарстанның халык язучысы» дигән рәсми исемне әлегә алмаса да, Фәнис Яруллин чын мәгънәсендә татар халкының яраткан әдибе.

Фәнис Яруллин күпкырлы, киң диапазонлы әдип. Әдәбият сөючеләр аның хикәя-повестьларын, фәлсәфи-лирик һәм юмористик шигырь-поэмаларын, балаларга атап язылган әкиятләрен, сәхнә әсәрләре буенча куелган спектакльләрне яхшы белә. Татар һәм урыс телләрендә Фәниснең өч дистә китабы,— шул исәптән 100 табаклы (!) өч томлык сайланма әсәрләре,— дөнья күрде.

Татарстанның ерак почмагында — Ютазы районының Кызылъяр авылында 1938 елның 9 февралендә туган, шунда сигез класс тәмамлаган, хәрби хезмәткә алынганчы «Татнефть» берләшмәсендә монтер булып эшләп йөргән егет була Фәнис. Гап-гади авыл егете...

Бүген исә Фәнис Яруллин — күренекле татар әдибе.

Арттa — үтелгән гомер, һәр көне айларга-елларга тиң алтмыш яз, алтмыш җәй, алтмыш көз, алтмыш кыш... Азмы бу, күпме? Фәнис Яруллин өчен озын-авыр, газаплы да, татлы да, ил-халык алдында, ниһаять, үз вөҗданы алдында йөз кызармаслык итеп үтелгән гомер юлы бу.

Артта — алтмыш ел. Шуның кырык елы — урын өстендә. Ә күз алдында һаман да ямьле Ык буйлары, аның тугайлары, болыннары... Малай чакта, егет чакта җиләк җыеп, кызлар белән куышып, уйнап йөргән киртләч тау битләре... Әллә алар бары да татлы төш кенә булдымы икән соң?..

...1958 елның кояшлы, көләч июль көне. Хәрби күнегүләр. Совет Армиясе солдаты, укчы-радист Фәнис Яруллин өчен әнә шул көләч кояш кинәт сүнде. Егерме яшьлек егет караңгы, ерак бушлыкка очты... Аннары... Аннары — госпиталь...

Үле куллар, үле аяклар, үле гәүдә... Тик коңгырт кара күзләр хәрәкәтләнә дә, авыз бераз кыймылдый. Муен һәм арка умырткалары сынган... Йокысыз төннәр, операция бүлмәләре. Перевязкалар. Әнисенең яшьле күзләре...

Тагын хастаханәләр: Урыссуда, Баулыда, Казанда...

Казанда...

Казанга кадәр Фәнис Яруллинның тормышында зур үзгәреш булды. Мәктәптә укыганда ук рифмалап такмаклар чыгарырга һәвәслеге бар иде. Хәзер ул чынлап торып яза башлады. Яза башлады, дип әйтүе генә ансат! Ничек башланды соң әле ул? Яшерен-батырын түгел: үлем хакында да аз уйланмады Фәнис. Җан көеге булып яшәүдән ни мәгънә бар?! Тукта, ә Николай Островский? Әнә ул ничек яшәгән. Һәм ничек кенә яшәгән әле! Димәк, көрәшергә, соңгы сулышка кадәр бирешмәскә кирәк... Инде Фәнис башын бора ала, аз булса да, куллары хәрәкәтләнә иде. Каләмне уң кул бармаклары арасына кыстырып, уңына караганда бераз хәрәкәтчәнрәк сул кул белән терәтеп, этеп йөртергә ни гомер өйрәнде икән ул?

Һәм менә Фәнис яза! Шигырьләр, хикәяләр яза...

Дөрес, тәүге шигырьләре республика матбугатында күренә башлаганчы да күп вакытлар үтте әле. Авыру егетне өенә кайтарып салганнан соң, янә дүрт ел вакыт кирәк булды моңа. Әнә шулай, баштарак дөнья бетте, кояш сүнде кебек тоелган иде. Шуңа күрә дә беренче шигырьләре төшенке хисләрәк булдылар шикелле.

...Гомер буе җыйган күкрәк көчен
Сынар чакта эшнең зурында,

Канатлары сынган бөркет кебек,
Ятамын мин, дуслар, урында...

Башта шулай үз авыруын, үз язмышын кешеләргә ишеттерергә тырышып кулына каләм алды Фәнис Яруллин. Көннәрдән бер көнне, 1962 ел башларында булса кирәк, тәвәккәлләп, балалар газеты «Яшь ленинчы»га хат юллады ул, хаты белән бергә берничә шигырен дә җибәрде. Ничек кабул итәрләр икән аның шигырьләрен Казанда? Түземсезләнеп җавап көтәргә генә калды...

...Мин ул вакытта «Яшь ленинчы»да әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире булып эшли идем. Фәниснең хаты минем кулга килеп керде. Шигырьләре, дөрес, өйрәнчек кенә әле, әмма сәләт чаткылары бар иде. Аларның, бераз төзәткәләгәч, газетта бирердәйләрен сайлап алдык. Шигырьләреннән бигрәк, мине Фәниснең хатындагы «үзем, авырып, урын өстендә ятам» дигән сүзләре сискәндерде. Үзем дә белмим, никтер тынычлыгымны җуйдым. Хат авторы ни яше, ни белеме турында бер сүз дә язмаган. Язуы-почеркы да бик сәер, табигый түгел шикелле. Мине төрле сораулар борчый: «Шигъри сәләте сиземләнеп торган бу кеше кем? Яшьме ул, картмы? Авыруы нинәрсә? Ни өчен барысын да әйтеп язмаган?» Ниндидер бер аңлашылмас көч мине Фәнис янына барырга өнди иде.

Түзмәдем, җыендым да юлга чыктым.

1962 елның шактый салкын, аяз февраль ае башлары иде. Мин Кызылъяр авылына килеп төштем. Сораша-сораша, Фәнисләрнең йортын эзләп таптым.

Мин барып кергәндә, түрдәге тәрәзә буендагы караватта кулларын баш артына куйган, ак күлмәкле, аксыл-ябык чырайлы яшь кенә бер егет ята иде. Күзләре җете тере үзенең! Йөрәгем кысылып куйды: йа Хода, бу — Клячкин хастаханәсендә ятучы Тукай үзе түгелме соң?! Тукайның нәкъ шундый фоторәсеме бар ич. Булса да булыр икән шул кадәр охшашлык!

Без бер-ике авыз сүздән үк бер-беребезне аңлаштык, күптәнге дуслар-танышлар шикелле сөйләшеп киттек. Фәниснең шигырьләрен укыдык... Соңрак ул:

Бер кешегә дустым артты бүген,
Бер кешегә дөньям киңәйде,—

дип шигырь дә язды.

Икенче көнне Фәнис укып чыккан мәктәпкә бардым. Анда укытучылар, укучылар белән очраштым. Авыру егет турында әрнеп тә, кызып та сөйләдем: Фәнисне бөтенләй онытканнар икән. Оялттым да бугай үзләрен. Казанга кайтышлый, Ютазыга сугылып, райкомолда да сөйләшеп чыктым.

Шуннан башланды...

Казанда кайбер эшләр майтаргач, Фәнискә хат юллаганмын. Ул хатның күчермәсен әле эзләп таптым. Анда мондый юллар бар икән: *«...Сездән киткәнгә ун көн дигәндә ике газетада күтәреп чыга алдым үзеңне (Сүз «Татарстан яшьләре»нең 1962 ел, 20 февраль санындагы «Егет үлемне җиңә» һәм «Яшь ленинчы»ның 1962 ел, 21 февраль санындагы «Корыч менә шулай чыныга» дигән мәкаләләр турында бара. М. Ш.). Син инде күргәнсеңдер, шулай булса да, җибәрәм әле. Минем әйберләр ошадымы? Нәрсә җитми? Нинди мәсьәләләр күтәрелми калган? Яз әле. Шигырьләреңә шактый кул тыгарга туры килде. Минем төзәтмәләрдән ризамы син?*

*Инде эшләнгән эшләр турында кыскача...*

*Кайтуга дәфтәреңнән сайлап, эшкәртеп машинкада бастырырга кирәк иде. Бу эшкә ике көн вакыт китте. Менә егермеләп әйбереңне сайлап бастырдым. Үзеңә дә җибәрәм, сакла һәм җыеп бар. Үзең турында язып 3—4 көн үтте. Аларны иптәшләргә укып, газеталарга тәкъдим итеп йөрдем. Ниһаять, син дөньяга чыктың, Фәнис!*

*...Бер 5—6 шигыреңне «Совет әдәбияты» журналына бирдем. Апрель санында чыгарачаклар. Кыска шаяруларыңны Шәүкәт Галиев белән киңәшеп «Чаян»га тәкъдим итәргә исәп. «Ялкын»дагы әйбереӊ икенче санда чыгып килә, озакламас. Подписканы, шигырең чыккач, шуның гонорарына яздыралар. Өченче саннан ала башларсың. «Яшь ленинчы»га подписка алдым синең исемгә. Квитанциясен җибәрәм. Шулай ук марттан башлап газета үзеңә киләчәк. ...Дәфтәреңне җибәрәм. Мин кушканнарын төзәтеп эшлә.*

*...Укучылар киләме? Хәзер, газетада күтәргәч, килүчеләр күп булыр. Үзеңне иркен тот, дәрәҗәңне төшермә, кирәген таләп ит, тыйнаксызлык та күрсәтмә.*

*...Апа (исемегезне дә белми кайтканмын, гафу итегез!), бик борчый башласалар, карагыз инде, Фәнисне җәйгә Казангамы, башка җиргәме больницага салу турында хәл итәргә тырышырбыз...»*

Фәнис исә җавап хатында болай язган: «...Тормыш бөтенләй үзгәреп китте. Һәр көн саен диярлек мәктәптән киләләр. Райкомолдан да килделәр. Китап-журналлар-

ның төрлесен китереп кенә торалар. «Тугызынчы класста укыйсыңмы?» — дип килгәннәр иде. Алтынчы классның алгебрасын калдырып, кабатлый торырга кушып киттеләр. Бик онытылган икән...»

Икенче бер хатында: *«...24 майда Гомәр ага Бәшировлар килеп киттеләр. Алар дүртәү иделәр: Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов, Рәшит Гәрәй, Абдулла Гомәр («Совет әдәбияты» журналы редакторы)...»* — дип язган.

Инде еллар үткәч, бу юлларны бераз шәрехләп үтү кирәктер.

Тормыш гаять катлаулы бит ул. Инде шулай Фәнис Яруллинның эшләре азмыкүпме җайга салынып, язганнары газет-журнал битләрендә ешрак күренә башлагач, бер көнне Абдулла Гомәр (ул әле язучылар оешмасының партия секретаре да иде) мине чакыртып алды. Арада мондыйрак сөйләшү булды. «Кара әле, иптәш Шабаев, син күтәреп чыккан Фәнис Яруллин хакында төрле сүзләр йөри. Шигырьләрен үзең язып бирәсең икән, диләр. Шул дөресме?» Минем йөземә кан бәрде. Кирәк бит, шунда да Фәниснең язмышыннанмы, миннәнме көнләшүчеләр бар икән... Йа, Ходай! Бу көтелмәгән әшәкелектән,— ә башкача аны ни дисең? — бераз аптырап та калдым шикелле. «Соң, Абдулла ага, кайбер шигырьләрен төзәткәлим инде... редакциялим...» «Шулай гынамы?» «Шулай гына! — тавышым ныгыды.— Кирәксә, кульязмаларын күрсәтә алам.» «Кирәкми... ышанам...» «Әй Фәнискә ярдәм кирәк, Абдулла ага. Медицина ярдәме...» «Һы... Уйлашырбыз, иптәш Шабаев, киңәшербез...»

Менә шундый сөйләшү булган иде. Һәм,— миңа әйтми-нитми генә! — Фәнис янына әнә шул хатта телгә алынган «инспекцион командировка» оештырылган да иде инде. Янәсе, чынлап та бармы ул Фәнис Яруллин? Язамы? Сәләтле-өметлеме? Әллә «иптәш Шабаев» күпертеп-уйлап кына чыгарган берәр кешеме?

Сүз уңаеннан, Абдулла Гомәрнең искиткеч эшлекле һәм кешелекле шәхес булганлыгын да ассызыклап әйтеп үтәргә кирәк. Аларның җыелышып Фәнис янына барып кайтулары бик яхшы булды. Үз күзләре белән күреп кайткач, Абдулла Гомәр җиң сызганып Фәниснең язмышын хәл итәргә тотынды.

Тагын бер хатында Фәнис: «...Бүген, 20 июньдә мине Казан больницасына китерделәр»,— дип яза.



*«Бәкер» санаторие. 1964 ел. Фәнис әнисе Гафифә апа белән.*

Бу эшне дә Абдулла Гомәр оештырды, аның абруе зур иде. Фәнисне Казанның «Иске клиника» дип йөртелә торган хастаханәсенә урнаштырдылар.

Аннары тагын бер гыйбрәтле вакыйга.

Фәнис бу хастаханәдә бер еллап яткач,— кем әле... Рита Григорьевна иде бугай...— бүлек мөдире иде шикелле, шул минем белән бер сөйләшүендә: «Без

Яруллинны һәр яклап тикшердек, булдыра алган кадәр дәваладык. Медицина бу очракта көчсез, аны аякка бастырып булмый. Йөрәге таза, ихтыяры нык егет. Язсын... Әмма без аны еллар буе клиникада тота алмыйбыз...» — дип кисәтте. Аяусыз кырыс, әмма хак сүзләр иде болар. Нишләргә? Йөри торгач, вакытлыча булса да, бер җае табылды: Фәнисне «Бәкер» санаториена озаттылар. Әмма бит анда гомер буе яшәп булмаячак. Димәк, Казанда фатир алу мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Чөнки Фәнисне ерак Кызылъярына кайтарып җибәрсәк, укуы да өзеләчәк (әйе, ул 18 нче эшче-яшьләр мәктәбе укытучылары һәм укучылары ярдәмендә урта мәктәп программасы белән укый башлаган иде), язуы-иҗаты да үсеп китә алмаячак иде, янә Абдулла Гомәр ярдәмгә килде. Яңадан Казанга кайтарып, берничә хастаханәдә янә берничәшәр ай яткач, ниһаять, Фәниската мин яшәгән тирәдәнрәк бер йорттан бер бүлмәле фатир бирделәр. 1963 елның сентябре иде инде.

Әмма анда да эш шома гына барып чыкмады әле. Ордер алырга кирәк, ә Фәниснең бер документы да юк икән! Миңа бирмиләр — фатирым бар. «Әдәбият жене» кагылган, флотта хезмәт итеп кайткан Котдус Дәүләтшин исемле бер егет бар иде. Аның хикәяләр язгалап йөргән чагы. Ышанычы кәгазе яздыртып, ордерны аңардан алдырдык. Яңа фатирда урын-җир, өстәл-урындыклар да булдырылды. Эш көйләнде шикелле. Фәнис хастаханәдән законлы үз фатирына күченде. Ә, юк икән әле! Алай гына булмый икән. Карыйм: Фәниснең әнисе Гафифә апа йөгереп килеп җиткән: «Марс, безне фатирдан куалар! — ди.— Бер тәүлек срок бирделәр...» — апаның күзләрендә яшь. Баксаң, икесенең дә паспорт-фәләне булмагач, «алдап-йолдап фатир алгансыз» дип, ниндидер бер томана түрә кисәге шулай маташтыра икән. Мин янә Абдулла Гомәргә кердем. Килеп туган хәлне аңлаттым. Абдулла аганың күзлеге астында ачулы күзләре ялтырап китте. Ул телефонга үрелде. «Алло! Эчке эшләр министрлыгымы! Мин — язучылар партия оешмасы секретаре Гумеров булам. Иптәш Япеев кирәк иде. Срочно! Бик мөһим эш!» Абдулла Гомәрнең шундый ышанычлы һәм кырыс сөйләшүенә исем китеп торам. Тоташтырдылар бит үзен министр Салих Япеев белән! Абдулла ага кыска гына итеп Фәниснең кемлеген сөйләп бирде, мәсьәләне аңлатты, миннән сорап Фәнисләрнең йорт адресын хәбәр итте. Соңыннан: «Рәхмәт, иптәш Япеев! Ышанабыз!» — дип сүзен бетерде. Ике көннән соңмы, паспорт бүлекчәсеннән өйләренә килеп — бернинди документларсыз-нисез! — телдән әйтүләренә генә ышанып, Фәнисләргә паспортлар бирделәр, пропискага кертеп киттеләр.

Менә шундый игелекле, кайгыртучан шәхес иде Абдулла ага Гомәр! Шундый абруй-дәрәҗәле министр иде Салих Япеев! Аларны сагынырга гына кала...

Фәнис Яруллинның ул чордагы тормыш-көнкүрешен тәфсилләбрәк белергә теләгән укучылар аның «Җилкәннәр җилдә сынала» дигән автобиографик повестен алып укый алалар. Фәнис зур әдәбият мәйданына әнә шулай аяк басты.

Әмма әдәбият олуг тау икән — аңа менәргә дә, менәргә икән, шигърият диңгезе тирән-чиксез икән — анда йөзәргә дә, йөзәргә икән. Ул сызлауларыңны да оныттыра, тормышка мәхәббәт тә өсти икән. Сигез класс белем белән генә әллә ни ерак китеп булмасын аңлады Фәнис. Әле хастаханә палатасында ук урта мәктәп программасы белән укый башлаган иде, фатирга күченеп Казан кешесе булып киткәч, кичке эшче-яшьләр мәктәбе укытучылары һәм укучылары, җитен комбинаты, мехкомбинат кызлары Фәнистән өзелмәделәр. Фәниснең тар гына бүлмәсе уку классы да, кирәксә, уен-көлке, җыр-биюләр өчен сәхнә дә иде шикелле. Яшьләр бит! Тормыш яңа бер баскычка күтәрелеп китте, көннәр тыгызланды, вакыт җитми башлады. Шул көннәрдәге запискаларының берсендә Фәнис: «Бу эшләгән кеше вакытны ничек җиткерәдер инде?!» — дип яза. Авыру шагыйрьнең иҗади канатлары әнә шулай ныгыганнан-ныгый барды.

Иң бәхетле минутларым —
Эштә үткән минутлар...—

Фәнис Яруллинның ихластан әйткән сүзләре бу.

«Яшь ленинчы» һәм «Татарстан яшьләре» газеталарына Фәниснең хәлен, тормыш-көнкүрешен сорап хатлар күп килә иде. Һәр ике газет үзләренең укучыларына әледән-әле аның турында хәбәр итеп, шигырь-хикәяләрен бастыра тордылар.

...Әле Казанга килгәнче, Кызылъярдан 1962 елның апрелендә язган хатында Фәниснең: «Шигырьләр, сез әйткәнчә, 63 елда яшь шагыйрьләр җыентыгына эләгә алса, бик яхшы булыр иде, аерым китап итеп чыгаруны алай тиз генә өмет итеп булмый инде. 64 елда чыкса да бик яхшы булыр иде әле, исән булсак, 64 ел бик тиз килеп җитә ул»,— дигән өмет-хыялы бар иде.

Юраганы юш килсен өчен Фәнис күп тырышты: укыды, язды, бертуктаусыз шигъри каләмен чарлады. Казанга килгәч, тормышы азмы-күпме көйләнгәч һәм... өйләнгәч, дип тә өстик — ул тагын да илһамланыбрак иҗат итә башлады.

Һәм, ниһаять, менә ул беренче китап! Коймак калынлыгында гына булса да, беренче китап! «Мин тормышка гашыйк» исемле ул китапчык, өмет-хыялдагыча, 1964 елда басылып чыкты. Миңа бүләк итеп биргән нөсхәсендә Фәнис болай дип язып куйган: «Марс абый! Бу китап — икебезнең иңгә-иң куеп эшләү җимеше. Әгәр уңышларым булса, аларга үз уңышларың итеп кара. Ф. Яруллин.» Әйе, яшермим: мин дә Фәнистән ким шатланмаганмындыр ул китап өчен, мин дә бәхетле идем. Ни әйтсәң дә, явызлык-көнчелектән кара көеп йөргән кайбер бәндәләргә дәлилле җавап иде ул!

Шул ук елда «Комсомольская правда» газеты үткәргән Бөтенсоюз әдәби конкурсында Фәнис Яруллинның шигырьләре икенче бүләккә лаек булды. Аңа Советлар Союзының төрле почмакларыннан хатлар килә башлады. Бу инде ил күләмендә танылу иде. Фәнис иҗат шатлыгы кичерү белән бергә яшәү шатлыгы да кичерә иде. Тулы канлы яшәү шатлыгы иде бу. Ләкин яуланасы үрләр алда иде әле.

Иң элек югары белем алырга кирәк иде. Аның әле һаман да укырга теләвен,— һәм әле кайда? университетның үзендә! — укырга теләвен ишеткәч, Фәниснең әнисе ах! итте. «Тәнеңдә чыкмаган җаның гына бар бит, балакаем!» — дип өзгәләнде ул. Ләкин Фәнис чигенмәде, үзенекен итте. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән торып укырга керде. Урта мәктәп укытучыларын университет укытучылары алыштырды. Инде алар Фәнис фатирына сукмак салдылар. Бу уңайдан кызык кына хәлләр дә булгалаганын искә төшерик әле.

Бервакыт Зәет Мәҗитов белән очрашам. Зәет — үзе шагыйрь, фәннәр кандидаты, университетта совет шигърияте курсын укыта иде. «Йә, Фәнис ничек? Уртак тел таба аласызмы? Теше үтәме?» — дип сорыйм Зәеттән. Беләм инде юкса: Фәнис булдыра укуны! Зәет йомшак күңелле кеше, аңарда укып чыккан бүгенге күп кенә әдипләр моны хәтерлиләрдер. Ул көлемсери: «Фәнисме?.. Беркөнне Бөек Ватан сугышы чоры шагыйрьләреннән кайсысыдыр турында: «Син аның иҗатын болай да беләсең инде, әйдә, шигырьләреңне генә укып утырыйк әле,» — дигән идем: «Юк, Зәет абый, шигырьләр торып торсын. Син ул чор шагыйрьләренең кемнең кемлеген сөйлә миңа. Каһәрле утыз җиденче елларда үзләрен ничегрәк тотканнар алар?» — димәсенме егетем. Аны кемнәрнеңдер иҗаты гына түгел, шәхес буларак, язмышлары да кызыксындыра икән!»

Ә Ибраһим Нуруллин, Тукайны «су урынына эчә» торган әдәбият галиме: «Үҗәттырыш ул Фәнис! Кирәксә, бәхәсләшергә дә ярата, тиз генә сүзен дә бирми», — дип сөйли торган иде.

Менә шулай тырышып, бернинди ташламаларсыз укыды Фәнис. Университетны уңышлы тәмамлады. Хәзер инде ул тирән мәгълүматлы, чын мәгънәсендә зыялы әдипләребезнең берседер.

1968 елда Фәнис Яруллинны СССР Язучылар союзына әгъза итеп алдылар. Бу вакытта инде аның «Май төне» исемле хикәяләр җыентыгы (1966), «Бакчалар бәскә төренә» (1967), «Минем елмаю» (1968) дигән шигырь китаплары укучыларга барып ирешкән иде. Шуннан соң да ел саен диярлек аның әле шигырьләре, әле хикәя-повестьлары аерым китап булып басылып чыга килделәр. Аның әсәрләре союздаш һәм автономияле республикаларда дөнья күрде. Казанда, Мәскәүдә урысча китаплары да чыкты. Шагыйрьгә дан килде. Һәм, ниһаять, 1978 елда «Аерылмас дустым» һәм «Сулыш» исемле шигырь китаплары өчен Фәнис Яруллин Татарстан комсомолының Муса Җәлил бүләге лауреаты дигән мактаулы исемгә лаек булды. Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ф. Яруллинга 1985 елда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән исем бирелде. 1988 елда аның түшендә «Халыклар дуслыгы» ордены балкыды. 1995 елда исә ул «Җан авазы» дигән китабы өчен Татарстан Җөмһүриятенең Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген алды.

Бер шигырендә Фәнис:

> Кешеләргә бурычым бар:
> Алар хаклык табыштылар,
> Алга юллар салыштылар...—

дип язган иде.

Әнә шул «алга юллар салышучыларның» берсен, укучылар күзеннән читтәрәк калып килгәнен, Фәниснең фәрештәсен — гомер юлдашы Нурсөяне аерым телгә алырга кирәктер. Нурсөянең дә һәр көне, һәр төне Фәниска тиң батырлык, олы йөрәклелек сорый. Фәниснең уңышлары — аның уңышлары, Фәниснең сызланулары — аның сызланулары...

Әйткәнемчә, Фәнис янында яшьләр — бигрәк тә кызлар! — күп була иде. Шулар арасында — Нурсөя... Чандыр гына гәүдәле, житез-йөгрек, чибәр кыз... Сөйкемле

сөякле кыз... Барган саен диярлек мин аны Фәнис янында күрә идем. Алар инде бер-берләрен күз карашлары белән генә аңлаша башлаган иде. Баксаң, ике яшь йөрәк әле Фәнис армиягә киткәндә үк, Татвоенкомат казармасында ятканда ук табышканнар икән! Хәер, бу хакта озаклап сөйләп торырга кирәкмидер, «Җилкәннәр җилдә сынала» повестен кабат укып чыксагыз, хәтерегезгә төшәрдер. Икесе үзара килешеп-аңлашып беткәч, Нурсөя Фәнис янында берничә ел яшәде. Ул еллар һәр икесе өчен дә сынау чоры иде. Ниһаять, алар өйләнешергә карар кылалар...

Фәнис миңа үзенең Нурсөягә өйләнергә теләве хакында ни рәвешләрәк әйткәндер — хәтерләмим. Ә менә бездә хатыным Роза белән Нурсөянең туй күлмәге тегеп-төзәтеп утырганын яхшы хәтерлим. Яшермим: бу кыз баланың да, Фәниснең дә киләчәк язмышлары өчен хәвефкә баткан идем. Яшьлеккә романтика хас, аллы-гөлле матур хыяллар хас. Ә көндәлек тормыш, ай-һай ла, кырыс, ай-һай ла, кайвакытларда рәхимсез! Шундый авыр фаҗигагә тарган егеткә бөтен күңеле белән тартылган Нурсөяне киләчәктә нәрсә көтә? Язмыш аңа тагын нинди сынаулар әзерләп куйган? Әти-әниләре, туганнары ни-нәрсә әйтер? Үз өстенә төшкән авырлыктан сыгылып төшмәсме? Әгәр дә яшәп китә алмасалар? Фәнискә икенче зур рухи фаҗига кичерергә туры килсә?.. Минем башымда әнә шундый борчулы уйлар кайный иде. Бик зур саклык белән генә Нурсөядән сораштырып утырдым. Кызның карары катгый иде: «Минсез яши алмаячак Фәнис... — диде ул. Башын иеп тынып торды. Аннары күтәрелеп миңа карады да: — Мин дә...» — дип өстәде.

1967 елның декабре иде. Фәнис белән Нурсөянең өйләнешүен «Татарстан яшьләре» газеты хәбәр итте. Газет битендә аларның бик матур фоторәсемнәре дә басылып чыкты. Һәм менә Нурсөя утыз биш ел Фәнис белән бергә, аның белән һәрвакыт янәшә. Ул үзенең рух ныклыгы, ихтыяр көче белән Фәнискә тиң булды. Язмыш ялгышмаган, аларны белеп кавыштырган. Нурсөя — Фәниснең илһамчысы. Ул булмаса, белмим, Фәнис Яруллин дигән язучы әдәбиятта шундый үрләр яулый алыр идеме икән? Нурсөя, шул чандыр кыз, Фәнисне тар бүлмәдән киң дөньяга алып чыкты. Ул, укып, машина йөртергә хокук алды. Машиналы да булдылар. Туган авылларына кайтып, дус-ишләргә барып йөрергә мөмкинлек туды. Бакча алдылар, йорт салдылар. Фәнис үз бакчасында ял итә, иҗат итә ала. Шул машина алу галәмәтләреннән соң, Фәнис «Әнә килә автомобиль» дигән бик көлке комедия язды. Аны тамашачылар карап туя алмадылар.

Фидакарьлегең өчен рәхмәт сиңа, Нурсөя!

Игелекле, ярдәмчел кешеләр турында бу очракта күп сөйләргә булыр иде. Алар һаман да Фәнис янында өзелмиләр. Шуларның тагын берсен — «Татнефть» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Ринат Галиевне аерым әйтеп китәргә кирәктер. Ул Фәнис Яруллинның шигырьләр китабын эш бүлмәсендә, өстәл өстендә тота. Авыр минутларда, күңел төшенкелегенә бирелә башлаганда Фәниснең шәхси батырлык үрнәгеннән, аның шигырьләреннән үзенә көч ала, җегәр ала. Кайчандыр «Татнефть» берләшмәсе монтеры булган Фәниснең өч томлык сайланма әсәрләре дә Ринат Галиевнең тырышлыгы һәм «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең матди ярдәме белән нәшер ителде. Юкса, әдипләребез беләбигрәк тә кыен хәзер китап бастырып чыгарулары! Шул рәвешле, инде ничә еллар Ринат Галиев Фәнис Яруллинның тормышын-язмышын кайгыртып яши. Рәхмәт аңарга!



*Казанның Чехов базарында «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең азык-төлек ярминкәсе. Май, 1995 ел. Шагыйрь Нур Әхмәдиев, «Татнефть»нең генераль директоры Ринат Галиев, Нурсөя ханым һәм Фәнис Яруллин.*

Эстафета булып күчеп бара
Яхшылык та, яман эшләр дә...
Юлчылар күк, әҗерен көтми генә,
Яхшылык ит икән кешеләргә.

Эстафета... 1958 елның көләч кояшлы июль көненнән — үзе өчен бөтен дөнья челпәрәмә килгән төсле тоелган көннән соң кырык ел гомер узган. Кырык ел! Аның һәр көне,

һәр төне батырлык. Тыйнак батырлык. Кешеләр күзенә күренми торган дәвамлы батырлык...

Фәнис Яруллинның тормышыннан ныклык үрнәге алып, аның әсәрләрен сокланып укый-укый бер буын арты икенчесе үсә тора. Бу гомер эчендә татар гаиләләрендә ничәмә-ничә Фәнис, ничәмә Нурсөя үсеп җитте һәм үсеп килә...

Гел балкытыр идем үз иемдә
Кешеләргә якты кояшны—

болай дип әйтер өчен гаҗәеп юмарт күңелле булу кирәк. Фәнис Яруллин—юмарт күңелле әдип. Яхшылыкка юмарт ул. Шуңа күрә дә аның ишеге һәрвакыт һәркем өчен дә ачык. Шуның өчен дә анардан кеше өзелми. Кемнәрдер, аның «Әнә килә автомобиль», «Әти килде», «Кызлар күңеле — тирән сер» кебек әсәрләрен театр сәхнәләрендә карап рәхәтләнгән дә, бүгенге көн мещаннарының яңа кыланышларын сөйләргә килгән; икенчеләре «Җилкәннәр җилдә сынала» исемле автобиографик повестен укыган да, авторны күреп шәхсән рәхмәт әйтеп чыгарга дип кергән; өченчеләре исә... үз язмышыннан зарланырга, киңәш сорарга, рухи көч алып китәргә дип ишек ачкан... Әле менә Бөтендөнья татарларының икенче конгрессы көннәрендә аның ишеген ерак Австралиядән һәм Америкадан килгән кунаклар да шакыган иде.

Бу мәкаләдә без күбрәк Фәнис Яруллинның шәхси тормышы турында сөйләдек. Укучыларга шунысы кызыклырак булыр кебек тоелды. Юкса, шагыйрьнең шигъри стиле, образлар системасы һәм башкалар хакында да озаклап, тәфсилләп фикер йөртергә булыр иде. Анысын тәнкыйтьчеләр өлешенә калдырабыз. Шуны гына ассызыклап үтәргә була: Фәнис Яруллин гади яза, халыкчан яза. Әйтқәнебезчә, ул күпкырлы талант. «Коеп куйган шагыйрь» генә түгел, менә дигән прозаик та, драматург та, балалар язучысы да. Кыскасы, күренекле әдип. Аның иҗаты зур-бай иҗат. Тәнкыйтьчеләр, әдәбият галимнәре, ачыгыз Фәнис Яруллинның иҗат серләрен, шәрехләп халыкка җиткерегез! Ул моңа, һичшиксез, лаек.

«Җилкәннәр җилдә сынала» исемле повестенда Фәнис Яруллин болай дип яза: «Язмыш синең тез астыңа китереп сукса — егылмас өчен якасына ябыш. Утларга салса — үзең аннан да көчле ян, шул вакыт аның кызуын сизмәссең. Суларга ташласа — күбек булып өскә күтәрелмә, асылташ булып төпкә бат, ялтыравыңны күреп, чумып алырлар. Тузан итеп һавага күтәрсә — яңгыр тамчыларына кушылып җиреңә төш. Карурманнарда адаштырса — кояшка карап юл сайла. Ташлар белән бастырса — чишмәгә әверелеп ургы. Җиргә күмсә — орлык шикелле тишелеп чык. Җилкәненне җилләр екса — йөрәгеңне җилкән итеп күтәр. Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән. Көчле рухлылар гына максатларына ирешә алалар. Түземнәр генә бәхеткә лаек.»

Никадәр тирән мәгънәле сүзләр!
Әйе, түземнәр генә бәхеткә лаек.

Гомеренең һәр тәүлеген аяусыз көрәштә үткәргән әдип Фәнис Яруллинга алтмыш яшь тулды. Аның иҗатын күздән кичерсәң, хәйран каласың: күп эшләгән Фәнис, гаять күп! Әле алга таба да ул укучыларын еш сөендерер, яңадан-яңа әсәрләр иҗат итәр. Күреп торабыз: Фәнис Яруллинның иҗат уты әле һаман да дөрли, һаман ялкынлана.

Тоелса да мәңге үлмәм кук,
Бер өзелер минем гомер дә.
Язмышларга буйсынмас җанны
Калдырасы иде шигырьдә,
Язмышларга буйсынмас җанны!

«Язмышларга буйсынмас җанлы» әдипне 60 яшьлек бәйрәме белән котлыйбыз һәм яңадан-яңа иҗади янулар телибез!

Озак яшә, Фәнис!

**Марс ШАБАЕВ**

# ЧӘЧӘК АТКАН ГӨЛ



Гөлләрнең чәчәк атуы да төрлечә: бар бөтен гомерләре буена бер генә мәртәбә чәчәк күрсәтеп, аннары вак-төяк орлык калдырып, мәңгелеккә китеп барганнары; бер елга чәчәк күрсәтеп, айлар буе чәчәксез утырганнары; бар, чәчәк ата башласа, шушы күркәм гадәтен өзлексез дәвам итүчесе. Әйтик, ясмин гөле. Ул башта шактый вакытлар чәчәген күрсәтми. Күпләр аның агачныкына охшаган яфракларының тузан җыеп кына утыруын өнәп бетермичә, чыгарып ук ташлыйлар. Әмма, сабырлыгың җитеп, шул гөлнең чәчәк атуын көтеп алсаң, ул сине гомерләрең буена өйдәге хуш искә, чәчәкләренең аклыгы-сафлыгына рәхәтләндерәчәк. Син аның кайчан чәчәк атуын да бүлмәңдәге затлы бер хушбуй исен сиземләүдән башлыйсың. Шуннан... китә инде. Гөлнең һәр ботакчыгы үзәгендә энҗе бөртегедәй ап-ак чәчәкләр «кабына» да тора! Игътибарлы булырга гына онытма: суыңны сип, ашламаңны өстә.

Халкыбызның танылган артисткасы Нәҗибә ханым Ихсанова иҗаты һәм ул узган еллар турында уйланганда нәкъ менә ясминдәй өзлексез чәчәк атып утыручы рәхимле гөл хәтергә килә. Ул да бит, чәчәк гомере житкәннән бирле, безне матурлыкка өндәп яши. Ул гөл — чәчәктә, хезмәте җимешләре булган сәхнә образлары үзәгендә. Күз тимәсен!

Татарның театр сәнгате, бүгенге абруйлы дәрәҗәсенә ирешкәнче, дулкын-дулкын сикерешле, берничә үсеш дәвере кичерә. Бу данлы юлның башында ук Сәхипҗамал Волжская кебек фидакарь кызлар бар. Фатыйма Ильская, Таждарова, Болгарская, Камская, Фатыйма Камал, Булатова, Ибраһимова... Бу сәләтле артистлар, буыннар алмашынуы дигән котылгысыз агым тәэсирендә, акрынлап үз урыннарын яшьрәкләргә калдыра килделәр: Асия Галиева, Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Гәүһәр Камалова... Болары исә, үз чиратларында, тагын да талантлырак, тагын да укымышлырак, тагын да хәзерлеклерәк яшьләр каршында «чигенергә» мәҗбүрләр иде. 1961 елда Камал театры Мәскәүнең Малый Театры (!) җирлегендә оештырылган М. Щепкин исемендәге училищены тәмамлаган яшьләрен кабул итте. Бу төркемдә, бәхетебезгә, Нәҗибә Ихсанова да бар иде. Мин театрыбыз тарихында әзле талант иҗаләренең һәр буыны кызларын күреп беләм. Дөрес, мәсәлән, Сәхипҗамал апа Волжская, мин аның белән танышканда, сәхнәдә уйнамый иде инде. Мин аңардан күпсанлы интервьюлар гына алып кала алдым, ул язмалар, үз вакытында (1960 еллар башы) «Азат хатын» журналында басыла торды. Ә менә Фатыйма ханым Ильская, Гөлсем Болгарская, Гөлсем Камскаяның сәхнәдә тудырган гаҗәеп тамашасы безне тәмам хәйран калдыра иде.

Әгәр татар театры узган үсеш дәверләрен диңгез дулкыннары кагуы белән чагыштырсак, минемчә, щепкинчылар бу тарихи сикерешләрдә **өченче** һәм, әлбәттә, хәлиткеч дулкын булды. Камал театры, алар кайтыр алдыннан, шактый четерекле тыкрыкка кертеп кыстырылган иде: репертуарга киңәергә юл бирмиләр (нәрсәгә ул татар театры, тамашачы урысча да аңлый бит!), кайбер бик шәп пьесаларны уйнарга да көчләр сыегайган һәм, иң аянычлысы — тамашачы театрдан тәмам бизгән иде.

Бәлки шуны күреп торгангадыр да без, татар театрына табынып яшәүчеләр, Казанга яңа артистлар төркеме кайтуын зур өметләр белән көтеп алдык. Мин исә, редакциядә эшләгәнгә, бу хәлнең кайбер нечкәлекләрен дә белә идем. Безнең «Азат хатын»га ул елларда композитор Заһит ага Хәбибуллин, режиссер Габдулла ага Йосыпов еш кереп йөриләр, алар — безнең иң актив авторлар. Һәм, туры килсә, килә бит — алар икесе дә Мәскәүдә, безнең булачак артистларыбызны милли сәхнә,

милли музыка кебек нечкәлекләргә дә өйрәтәләр икән. Бу изге сәфәрләреннән кайткан саен алар безгә өр-яңа хәбәрләр дә ирештерәләр: төркем кайчан әзер була, диплом спектакльләре кайчан, кайда куелачак, араларында кемнәр әйбәт уйный...

— И-и кызлар,— диде берсендә Заһит ага Хәбибуллин.— Аларның һәммәсе шәп, шул хәтле әйбәт балалар алар, театрга кайтабыз дип, «аһ» итеп, көтеп, ашкынып укып йөриләр... Шулай да... араларындагы Нәҗибә исемлесенең җырлавын ишетсәгез!..

Композиторга Нәҗибәнең җырга-моңга осталыгы ошагандыр, бәлки, белмим, төпченеп тормадым. Миңа, әле үзен күрмәс борын, аның исем-фамилиясе дә бик ярап куйды. Күңелдә әллә нинди бер тартылу хисе кабынып, мин гел генә шул артистканың кайтып күренүен көтә башладым.

Шөкер, алар әллә ни зарыктырмый гына кайтып та төштеләр Казанга! Кайтып та төштеләр, үзләренең дипломнары өчен әзерләгән спектакльләрен күрсәтеп, Казан тамашачысын, инде тәмам сүнә-сүнә дип торган театр дөньябызны кабаттан терелттеләр. Бер спектакльләре (В. Маяковскийның «Мунча»сы буенча) гел урыслар гына йөри торган «ТЮЗ» бинасында булды. Бина ип-иске, моңарчы күрелмәгән тамашачыдан җимерелә язды. Икенчесе — Ә. Фәйзи пьесасы буенча куелган «Тукай» спектакле. Булса да булыр икән татар күңеленең күтәрелүе! Сәхнәне татар зыялылары тутырды, без, тамашачылар әүвәл-әүвәлдән кичереп килгән затлы асылыбызга кайткандай хис иттек. Югыйсә, үз үткәнеңне тоташтан чабаталы итеп, бичара хәлдә күпме кыйналырга мөмкин?!

Нәҗибә «Тукай»да Әминәне уйнады. Әй, аның саф татарча сөйләшүләре, әй аның хәрәкәте, ул киемнәр: калфак, ефәк шәл, озын итәкле шәп күлмәкләр!!! Әнә, бар икән бит татарның да һәммә ягы килгән кешеләре, булган бит! Нәҗибә-Әминә минем бөтен вөҗүдемне биләп алды: ул хак сүз әйтсә, мин дә аны хуплыйм, ялгышса, бетәм, үләм... Артистның тамашачыга тәэсире шул бит инде ул! Димәк, Нәҗибә шәп артистка, димәк, аның Мәскәү калаларында тырышып укып йөрүләре бушка китмәгән! Шөкер, дип, җиңел сулап куйдым. Чөнки, тирәннән аңлап яшим ләбаса: ул заманнарда Әминә ролен бу рәвешле «сүтеп» бирү «ярый торган ук» эш түгел. Татарның зыялыларын ачканчы, аны гел хәерче итеп кенә күрсәтү түрәләргә ошыйрак төшә. Элеккем гел чабатадан йөреп узган, диеп фикер йөрткән татар бүген дә бер капчык бәрәңгесенә шөкер итеп яши. Аңа зур киләчәкнең дә, бай узганның да кирәге юк. Щепкинчылар татар сәхнәсенә әнә шул тирән фикерне сеңдерергә тотындылар. Әле бит ул бик «куркыныч» еллар иде, әмма хәзер өздереп әйтергә була, Нәҗибә Ихсанова башкарган рольләр арасында, ясалма рәвештә, властька табак тоту кебек һичнинди алым да булмады. Ул, әгәр шулай мөмкин булса, бүген дә моңарчы үзе башкарган рольләрнең (алар йөзләргә баса) һәммәсен уйнап бирер иде дә, тамашачысы алдында ап-ак, сап-саф килеш елмаеп торыр иде. Чөнки иҗаты халыкка, хак идеалларга тугры калган.

Нәҗибәне татар театрын биеклеккә менгезүче дулкыннар арасында күрергә теләвем дә шуннан чыккандыр, мөгаен. Әмма, дулкын үзе дә әллә ничә баскычтан тора бит әле ул. Бар иң югарыга менеп җемелдәгән тамчылар, бар әллә ни биеклеккә ирешә алмаган җиңел күбекчәләр, бар астан, дәрьялар төбеннән, иң авыр йөкне үз җилкәсендә күтәреп, үргә менеп җитүчеләре. Минемчә, Нәҗибә әнә шундый — төптән күтәрелгән һәм, бинибая авырлыкларны җиңеп чыгып, уңышка ирешкән артистка ул. Сүз дә юк — аның уңышлары уртак. Монда аны Казаннан барып укытып йөргән шул ук Габдулла абый да, Заһит ага да, аларның төркемен укытучы Михаил Гладковның да мең-миллион өлеше бар. Әмма кайчак, ниләр генә сибеп карама — гөл үсми, ниләр генә «тукыма» — бала гел кирегә китә. Нәҗибә Ихсанова исә, олыларның аңа сеңдерергә тырышканнарын гел уңга алган, еллар узган саен, Нәҗибә зуррак нәтиҗәләргә ирешә, тырмаша да җиңә, тартыша да түзә. Үз алымының дөреслеген аңлата ул тамашачыга. Аңа адәм баласы «эләккән» теләсә нинди хәл таныш. Ул безнең татарның авыл хатынын да «өздереп уйнап» күрсәтә: нәкъ аларча көлә, сөйләшә, җырлый...

«Җырлый» дигәч, коры гына узып китеп булмый инде, чөнки композиторыбыз сүзен дә раслап күрсәтергә кирәк. Бүгенге тамашачы да аның җырлавын ишеткәләп кала калуын. Һәр спектакльдә диярлек, Нәҗибә юри генә булса да берәр көй сузмый калмый. Әмма аның безнең дөньяга өр-яңа җыр алып килүе «Акчарлаклар» спектаклендә, Газизә ролен башкарганда булды. Спектакль Ш. Камалның шул исемдәге әсәре буенча Г. Ахунов тарафыннан язылган пьесага нигезләп куелды. Әсәр күпләргә таныш, шуңа да аңа йөрмәүләре дә ихтимал иде. Әмма спектакль еллар буе барды. Минемчә, бу уңышта спектакль өчен махсус яздырылган «Акчарлаклар» җыры (Х. Вәлиуллин көе, Р. Әхмәтҗанов шигыре) хәлиткеч рольне уйнагандыр. Җыр яңгырау — бер хәл, аны ничек җырлыйлар, кем җырлый бит әле?! Бу җырны дөньяда беренче башлап, Нәҗибә Ихсанова яңгыратып җибәрде, әй сузды, әй үтте үзәкләргә! Бичара балыкчы кызы, җәйгелеккә генә эшкә ялланган егетен озатып кала:

...Кораб китте еракларга, зур юлларга,
Карыйм күздән югалганчы шул якларга.
Сез китмәгез, акчарлаклар, акчарлаклар!
Чит җирләрдә каерыла пар канатлар...

Бу җырга Нәҗибә канатлар куйды. Аны хәзер опера җырчылары да, эстрада артистлары да җырлый, әмма аңа беренче җан өргән оста җырчы Нәҗибә булды.

Артистның осталыгы шундадыр да инде ул: аңа нинди рольне башкару да килешеп тора. Әмма кайбер артистларның кыяфәте үк, алынган эшенә «ятып ук бетми». Әле тамашачы хәтерлидер: безнең Фатыйма Ильская да, Шәхсәнәм Әсфәндиярова да авылдагы хатын-кызлар ролен бик үк килештереп җиткермиләр яки бөтенләй авыл тормышына караган әсәрләргә катнашмыйлар да иде. Нәҗибәнең — бәхете, ул мондый спектакльләрдә рәхәтләнеп уйный, «йөзә», рольнең тәмам маен чыгарып, тамашачыга шуның ләззәтен татытып бирә. Шул осталыгының серен сорасаң:

— Безнең Яңа Ташлыяр авылында Нәсимә апа бар иде, бригадир...— дип, бик ерактан аңлата башлый.— Ире белән берничә көн генә торып калдылар, сугыш башланды. Әй, тырышты шул Нәсимә апа авыл өчен, әй тырышты. Әйтерсең лә, шул безнең авыл басуыннан күбрәк уңыш җыелса, аның япь-яшь ире сугыштан кире кайта инде... Кайтмады, Нәсимә-бригадир кире китеп барды, ул бит үзе күрше авылныкы иде. Фатыйма ролен уйнаганда («Тормыш җыры», М. Әмир) мин гел шул Нәсимә апаны күздә тоттым. Бу роль безгә — Шәһа апа белән икебезгә бирелгән иде. Шулай да премьерада миңа уйнарга туры килде. Мин бу рольнең шәһәр кызларына авыр икәнлеген бик аңлыйм.

Инде тагын бер сорау туа: тамашачы алдына килеп чыккан беренче адымы ук, сәхнәдән башкарган җыры ук аңа зур уңышка юл ярган икән — хикмәт нидә? Әллә кай төбәккә урнашкан кеп-кечкенә авыл кызы ничекләр итеп Мәскәүләргә барып чыккан да, ничек бүген театрыбызның тарихи шәхесләре рәтенә менә алган? Мин, бу сорауга үземчә, гадәти генә җаваплар эзләп маташканчы, артистканың үзенә мөрәҗәгать итәргә булдым. Аның сөйләгәннәреннән күз алдымда менә мондыйрак язмыш кичергән авыл балалары басып калды.

Сугыш бетеп, тормышыбыз «аякланып» азапланган еллар. Кулларына яңа гына өлгергәнлек аттестаты алган дүрт бала: Яңа Ташлыярдан — Нәҗибә белән Әзһәр (хәзер бу егет театрыбызның умыртка сөяге, Татарстанның — атказанган, Русиянең халык артисты), Буралыдан Расих белән Әсләх җиде юл чатына чыгып басалар. Ул елларда ниндидер маршрут буенча йөрүче автобуслар гына түгел, йөк машинасы да районына берле-икеле генә иде. Шулай да Азнакайның әлеге балалары (ул чактагы Тымытык районы) өметләрен өзмиләр. Һәм... килеп чыга бит каршыларына кирәкле машина! Тиз-тиз әрҗәгә менеп кунаклыйлар. Моңарчы ук менеп алган бер агай дүрт яшүсмерне күргәч, кулларындагы букчаларына да күз салгач, күңелләндәгән әйтеп куя:

— Нәрсә, әллә сез чыннан да театр училищесынамы, егетләр?

— Ю-у-ук! — дип иң алдан Нәҗибә кычкырып җибәрә.— Без — университетка!

— Ә-ә,— ди агай.— Мин әле генә урамдагы репродуктордан ишеткән идем: татар балаларын театр училищесына чакырып яталар иде. Нинди ата-ана баласын анда җибәрсен?!.

Бу сүзне ишетәләр дә оныталар яшьләр. Чөнки аларның — үз максатлары: Нәҗибә белән Әзһәр университетта укып, югары белемле укытучы булмакчылар, теге икесе авиация институтына барырга телиләр. Аларның омтылышын бүгенгеләр тиреннән аңлап та җиткермәсләр. Азрак кына шәрехләп үтим әле. Ул елларда кулына өлгергәнлек аттестаты алучылар бөтен районына бармак белән генә санарлык була, чөнки кешеләрнең матди хәле авыр, уку түләүле, мәктәп — районга бер. Әле шулар өстенә Нәҗибә Ихсановалар гаиләсе кебек өйдә җиде (!) бала икәнен дә исәпкә алсаң, кыз кулындагы кәгазьнең ни икәнен аңларлыктыр. Хәзер берәүләр: «Ә-әй, алай ук түгел инде, кеше ышанмаган сүзне, хак булса да, сөйләмә!» — дип куярга да күп сорамый. Ул кадәресен укучы карамагына калдырып, артисткабыз кичкән язмышка кабат күз салыйк әле. Нишләгән Нәҗибә? Әнә шул «хак булса да сөйләмә» дигән язмышка каршы төшеп юллар чатына чыгып баскан, үзенә кирәкле машинаны да көтеп алган, университет коридорына да барып кергән. Тик... баксаң, монда бөтенесе бары тик урысча гына сөйләшәләр икән бит!

Коелалар да төшәләр ун ел буе татарча укыган балалар. Нәҗибә, сабырсызланып, еларга ук тотына. «Сорауларын беләм мин аларның, урысча җавап кына кайтара алмам шу-ул»,— ди-ди елый. Егетләр аны тынычландырырга ашыгалар:

— Ярар, бик бетерешмик, әле театр училищесы да бар бит, анда гел татар балаларын гына алалар, диделәр. Елама! Барыйк шунда, синең бер сыйфатың да артистларныкыннан ким түгел!..

Нәҗибә Әзһәргә карый:

— Әйдә, Әзһәр, син дә шәп уйный идең бит авыл клубында...

Менә шул рәвешле тәвәккәлләп тотынган эш икән бу. Керә Нәҗибә, Әзһәр дә кабул ителә училищега. Анда да бер урынга җиде кеше конкурс тота. «Этюд» дигән сүзнең ни икәнен дә белми йөргән балалар җиңеп чыгалар, чөнки, бердән, талантлары булган (алар монысын кырык еллап иҗат итеп расладылар), икенчедән, бу мисал — татар баласының тырышлыгына бик кечкенә бер дәлил. Ярый ла, болары мәктәпкә йөри алган, ярый ла, болары очраклы машинаны көтеп торырга сабырлык тапканнар, ярый ла боларына шул елны училищега кабул итү имтиханы белдерелгән!!! Инде уйлап карыйк: татарның ничәмә-ничә баласы бу тәвәккәллеккә барып җитми, көтә, уйлана һәм... шул тын гына яшәп яткан җирендә торып та кала. Күпме алар, безнең әрсезләнә алмаган һәм төп сәләтен ачып җиткерә алмаган затларыбыз? Йөзме, меңме, әллә миллион укмы?..

Нәҗибә Ихсанова әнә ничек рәхәтләндерә татар тамашачысын! Театрыбызда ул эшләмәсә, сәнгатебез күпне югалтыр иде бит! Күпме тырыша ул, нинди генә корбаннарга китерми үзен! Барысы да — үзе яраткан иҗаты хакына, безнең хакка, театрыбыз хакына. Кемнәр образына гына кереп, нинди генә язмышлар «кичермәде» инде ул, ничә тапкыр авыргандыр, ире белән ызгышкандыр, гаделлек өчен тарткалашкандыр — ул башкарган рольләрдә бары да бар: көлә, елый, усаллана, җирәнә, барыбер яши һәм, кирәксә, үлә дә. Әйе, әйе, үлә, артист, уенына кирәксә, үлә дә икән ул.



*«Ак чәчәкләр» спектакленнән күренеш. Нәҗибә Ихсанова (Гөлшаһидә ролендә) һәм Әзһәр Шакиров (Мансур ролендә).*

Берсендә журналистлык әрсезлегемнән файдаланып, мине Фатыйма Ильскаяга «илче» итеп җибәрделәр: «Бар, рактан үлүче шәп ана ролен уйнатырга ризалаштырып кайт!» — диделәр. Бардым. Хәлне сөйләп бирдем. Артистка, бәхеткә, пьесаны белә икән. Озак аңлатырга туры килмәде:

— Юк, Кояш, — диде Фатыйма ханым. — Әсәрендә минем уйнауны теләсә, ул драматург профессор хатыны ролен язсын. Минем профессор хатыны буласым килә. Ә бу карчык ролендә уйнасам, мин үзем рак элэктерәчәкмен...

Аның белән сөйләшкәндә көлемсерәп кенә утырган идем, ә соңыннан хәйран калдым: теге рак зәхмәте эләктергән карчыкны уйнаган Галимә ханым Ибраһимова да, урыс театрында шул ук рольне башкарган артистка Павлова да — икесе дә рактан үлделәр. Теләсәң ничек фикер йөрт!

Шушы бер генә мисалда да йөзләрчә роль башкарган Нәҗибә ханым Ихсанованың нинди хисси киеренкелектә һәм, үзенчә әйткәндә, рәхәтләнеп иҗат итүе ачык аңлашылса кирәк.

— Йөзләрчә булса да, аерым яратканнары бардыр әле?— дип сорыйм.
Нәҗибә уңайсызланыбрак куйды. Аңлагандай итеп тагын сорыйм:
— Ә-ә,— дим, бик зур ачыш ясаган кеше шикелле.— Белдем! Син яратмаслык роль булса, алдан ук баш тартасың — шулаймы?
Бу сорауга ул тиз үк өздереп җавап бирде.
— Юк, юк! — диде. Минем бер рольне уйнаудан да баш тартканым юк. Эш — бит ул! Җиң сызганып тотынасың да, аннары яратыла да әле ул. Миннән кайберәүләр көләләр: «Нәҗибә башың белән шул рольне уйныйсыңмы?» — диләр. Кеше аерган кебек. Мин утыз яшемнән карчыклар ролен уйнарга да алындым һәм күпләр бик авыр кичергән шул баскычны җиңел генә атлап үттем. Ә бер ролем мәңге йөрәгемдә калды. «Соңгы корбан» спектаклендәге Юлия. Әй өйрәндем, әй яраттым. Спектакль шактый озак барды, мине исә сәхнәгә бер мәртәбә дә кертмәделәр, гел дублерлар — алмашчылар уйнады...
Миңа артистлар иҗатындагы мондый ук гаделсезлек таныш түгел иде әле. Икенчедән, мин Нәҗибә ханымны бик бәхетле артисткага саныйм, чөнки аның ире — Туфан Миңнуллин. Теләсә кайсы иҗат кешесе көнләшерлек хәл: ире шәп-шәп образлары булган пьеса язып тора, хатыны, берәүдән дә сорап-нитеп мәшәкатьләнмичә генә, үзәк рольләрне уйнап яши. Туп-туры әйттем:
— Нәҗибә ханым, ничек уйлыйсың, әгәр Туфанга кияүгә чыкмасаң, шушындый да күренекле артистка була алыр идеңме?— дидем.
Башта ул өздереп әйтеп куйды:
— Әй, Кояш, әгәр мин якты караш күрсәтмәсәм, Туфаныгыз Казанда да калмаган булыр иде, бәлки бу гаиләнең беренче «корбаны» миндер әле,— диде. Аннары рольләр бүлгәләгәндә гел драматург теләге генә күздә тотылмый бит, артистныкын әйтмим дә инде. Менә, әгәр рөхсәт итсәләр, мин, әлбәттә, Диләфрүзне бик рәхәтләнеп уйнаган булыр идем. Яшь идем, җырлый идем — булмады. Сүз дә юк, янымда Туфан Миңнуллин кебек драматург яшәп яту — зур бәхет, тик андый кешегә тиң булыр өчен дә синнән күп нәрсә таләп ителә. Читтән караганда, рәхәте күбрәк күренәдер инде...
Нәҗибә гаиләләре турында сөйләгәндә дә тайчынмый, әмма, минем фикеремчә, Туфан белән бергә уку, өйләнешү, кызлары Әлфияне бергәләп үстерү, хәзер ике оныкны — Диләрә белән Даниярны тәрбияләүдә катнашу — Нәҗибә ханым иҗатына бик күпне биргәндер: табышын да, югалтуын да, шатлыгын да, хәсрәтен дә. Тагын бер тәвәккәл фараз әйтә алам, әгәр бу ике иҗади зат бергә, бер гаилә булып яшәмәсәләр, Туфан үзенең шәп трилогиясен дә яза алмаган булыр иде: «Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә» һәм «Хушыгыз!». Бу спектакльләрдә Нәҗибә ханым, әлбәттә, үзәк рольне башкара. Бу — бер божра, минемчә. Әгәр Туфан Нәҗибәне шул кадәр шәп белмәсә, трилогиянең үзәк ролен шулай иттереп яза алмас иде шикелле. Монда тагын — җыр, үзәк өзгеч, тетрәндергеч җырлар тезмәсе:

Житәр инде, тургаем, моңайма —
Минем моңлы чагым болай да...—

Трилогия буена яңгырый ул.
Бер Нәҗибә Ихсанова гына түгел, щепкинчыларның күбесе катнашты бу трилогиядә, рәхәтләнеп уйнадылар: беренче спектакльдә дә, хушлашканда да. Театрыбызның үсешен, алга барышын күзәтүче тамашачы аларны бик теләп кабул итте.
Соңгы елларда Нәҗибә ханым Ихсанова бер-бер артлы комедияләрдә дә катнаша: заманаң көлке булса, син төлке бул диюләредер инде. Һәр образына әр-яңа төсләр таба, ару-талуны бөтенләй онытты кебек ул. Хәер, аны аңларга да була, юл башын тырышудан, «барыбер минекечә булыр!» дип атлап киткән икән инде, хәзер ул берничек тә туктап кала алмый. Театрыбызны җилкендереп торучы дулкын көчләре турында уйлау да нәкъ менә Нәҗибә ханым иҗаты турында фикерләрдән туды: дулкыннар тамчылардан туплана, ә көчле дулкын исә театр сәнгатебезне биеккә күтәрә. Юбилярыбыз бүген — дулкын түбәсендә, чәчәк аткан гөл кебек балкый. Афәрин!
Аның шул дәрәҗәсен тоюдан күңелгә Лена Шагыйрьҗанның артисткага багышлап язган әсәреннән юллар килә:

...Дөрли дә дөрли Нәҗибә, рәхмәт кенә, ди дә җилгә.
Яна бирә җәеп җилгә кочакларын!
Мин кычкырам аргы яктан: кем ул анда пәрдә япкан?!
Ачыгыз! дим, кабат-кабат чаң кагыгыз!

Ә сез аңа кул чабыгыз, алкышларга күмелеп калсын шул чагыгыз!

**Кояш ТИМБИКОВА**

# ГҮЗӘЛ МИРАС КАЛДЫРГАН ӘДИП

*«Еллар узу белән чишмә, бәлки, бераз саега торгандыр, ләкин чишмәнең корыганы әле сизелми».*

*«Муеныма никадәр генә шәһәр шөлдерләре элмәсеннәр, синеке мин, авыл!.. Туфрактан актарылып чыкканмын, яңадан туфракка әйләнеп кайтканчы, синеке булып калсам иде!»*

*«Иләләшкән юргам — сикәлтәләрдән ансат кына сикереп үтә ала торган җиңел тояклы юргам-юморым...»*

Фатих Хөсни. «Минем тәрәзәләрем»

Ана телен өйрәнү мөмкин түгел: ул фәкать ана сөте белән керә, һәм аны даими рәвештә баету сорала. Шунда инде әдәби китапларның файдасы тия. Әгәр дә укучы кулына алган китапны укыган чагында, вакыйгаларга-сюжетка игътибар бирү белән генә чикләнмичә, әсәрнең язылу ысулына-рәвешенә, авторның теленә игътибар итә икән, ул һичшиксез, телебезнең шигърияте вә музыкаль икәнлеген сизми калмаячак, ана теленең искиткеч бай булуына сокланачак, бер үк мәгънәдәге сүзләрнең-синонимнарның күплегенә сөенәчәк, аларның, әлеге синонимнарның, шул ук вакытта бер-берен тулаем кабатламавын, һәркайсының үзенчәлеген, эмоциональ төсмерен шәйләп тәмам хәйран калачак.

Теленең байлыгы, сюжетларның камиллеге ягыннан татар әдәбиятында аеруча күркәм урынны Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Фатих ага Хөсни ярты гасыр буена биләде. Үзе исән чагында ук әдәбиятыбызның классигы дигән исемгә лаек табылган әдипнең, олуг талант иясе Фатих Хөснинең тууына 90 ел тулды.

Әдәбиятта һәр нәрсәне матурлап-бизәп күрсәтү хөкем сөргән бер дәвердә, Фатих Хөсни кешеләр язмышын тирән бер хәсрәтләнү-әрнү белән, гыйбрәтле вакыйгалар сыйфатында тасвирлап бирә белде.

Гап-гади вакыйгамы яки берәр мәзәк хәлме — һәр очракта да автор ана теленең илаһи мөмкинлекләрен гаҗәеп зур осталык белән кулланып, кабатланмастай хикәя, һәркем сокланырлык бер әсәр китереп чыгарырга сәләтле иде. Әле шуның өстенә искиткеч әдәпле вә инсафлы, гаять дәрәҗәдә кешелекле, олы җанлы вә көче күңелле шәхес иде ул.

Фатих Хөсни — һәр әсәрнең теленә-яңгырашына иң нык игътибар иткән, җөмләләрен сингармонизм законына буйсындырган, музыкальлеккә ирешкән әдип. Бервакыт ул шушы юлларның авторына:

— Күз белән генә язу җитми, колак белән дә язарга кирәк! — дигән иде. Сүз уңаеннан гына бер фактны искә төшереп үтү дөрес булыр: язганыңны күзең күрү генә җитеп бетми, аны әле тагын кычкырып та укырга кирәк, шунда колакка ятышсыз урыннарны төзәтүе җиңелрәк, дигән фикерне аңлап җитмәгән мөхәррирләр: «Күз күргәнне язу гына җитми, колак ишеткәнне дә язарга кирәк», — дип, ансат кына «төзәтеп» ташладылар. (*«Татарстан» журналы, 1996, 6 сан*). Юк, әдәбиятыбызның классигы һич тә, күргәнең-ишеткәнеңнең барысын да язарга кирәк, дип әйтми, бәлки язган чагында камиллеккә ирешү ягын кайгырта, шуңа өнди.



*Әдип Фатих Хөсни*

Фатих Хөснинең «Үтеп барышлый» дигән кечкенә генә хикәясендә: «...аның маңгай чәчләренә ак кыш утырып кайта» дигән бизәк бар. Шуны укыганда Фатих аганың үзенең ир уртасы чаклары искә төшә: 15—20 ел буена бер тотам маңгай чәче нәкъ әнә шундый иде, болай да матур вә күркәм кыяфәтле йөзенә ямь өстәп тора иде.

Әмма, кызганыч ки, бәла агач башыннан йөрми, кеше башыннан йөри, дигән сүз бар, Фатих аганың өстенә бәла-каза бер-бер артлы ябырылды: әүвәл олы улы кулын имгәтте, аннары кияве автомобиль катастрофасында үлде, әдипнең кызы ике нәние белән ялгыз калды; тагын да яманрагы — төпчек улы япь-яшь көе фаҗигале төстә һәлак булды: дуслары белән Львовка сабакташларына кунакка дип киткән җиреннән цинклы табутта кайтты... Мәрфуга апа, бичара ана, тәмам сыгылып төште, шуннан соң тернәкләнә алмады — үзе дә гүр иясе булды, авыр туфрагы җиңел булсын. Фатих ага шундый олы фаҗига кичергәндә дә биреш-мәскә тырышты, әмма шушы гайре табигый хәл, җир йөзендәге иң олы фаҗига аны да, җор телле шәхесне дә бөтереп алды, гүя зәмһәрир кыш аның чәчләренә иркен канат җәйде. Алай гына да түгел, бәгырьләренә үтеп керде, зәһәр сулышын өреп, әдипне аяктан екты, күзләрен күрмәс итте...

Фатих ага Хөсни 1908 елның 3 февралендә туып, 1996 елның 19 маенда вафат булды. Әдипнең туган-үскән авылы, Казаннан 70—80 чакрымдагы Олы Мәтәскә, әдәби әсәрләрендә лаеклы урын яулаган Олы Мәтәскә ятим калды... Без ятим калдык... Әдәбият ятим калды...

Әдәбият сөючеләргә Фатих Хөсни иң әүвәл шагыйрь буларак таныла башлый: «Дөнья матур миңа» дигән шигыре «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналында 1927 елны дөнья күрә. Аннары ул пьесалар да язып карый, әмма тора-бара хикәя (проза) жанрына күчә һәм шунда «төпләнеп кала». Әдипнең яшь чагында шигырь язуы, рифмага ярардай сүзләр сайлавы проза өлкәсендә әйтеп бетергесез файда китерә. Сүзнең тәмен-кадерен белеп кенә яза торгач, Фатих Хөсни хикәя остасына әверелә.

Әдипнең махсус балаларга атап язган хикәяләреннән «Сипкелле малай», «Җүлә — кайгылы эт», «Малай, чиләк, әби», «Чия төше» һ. б. әйтеп китү урынлы булыр. Әмма аның бүтән хикәяләрендә дә авторның үз холкына аеруча хас малайлар шуклыгы, сүз уйнату, җор теллелек гаять зур урын алып тора. Һәрхәлдә, Фатих аганың хикәяләрен елмаймыйча гына укый алмыйсың. Аларның һәркайсында авторның гаҗәеп матур тел белән, үзе әйтмешли, «җиңел тояклы юрга-юмор» белән тасвирлавына сокланасың.

Хәер, әдипнең күләмлерәк әсәрләрендә, повесть һәм романнарында да һәр-кайсыбызның гомер юлы башлаган могҗиза тулы дәвер — балачак беркайчан да

игътибарсыз, читтә торып калмый. Бу уңайдан «Йөзек кашы» повесте каһарманы Айдарны һәм «Җәяүле кеше сукмагы» романындагы Сәфәргалине искә төшерү дә житәдер. Әлеге каһарманнар малай чакларында ук хәйран зур могжизалар күрсәтеп, үзләренең дуамал һәм тәвәккәл булулары белән укучының мәхәббәтен яулыйлар. Киң күңелле булулары белән, фидакарьлекләре белән алдыралар.

Бервакыт шулай, олуг әдибебез Нәкый ага Исәнбәтнең әллә «Кырлай егете» дигән китабын, әллә инде томнарын чыгарганда, авторның үзем редакцияләгән кульязмасын күтәреп, өенә бардым. Шунда булган әңгәмәне һич онытасым юк. Искиткеч зур саклык белән генә төзәткәләгән урыннарны карап чыккач, әдәбиятыбызның аксакалы:

— Син, күрше, яңгырашка бик нык игътибар бирәсең икән, шул сизелә,— диде. (Әлегрәк без Нәкый ага белән күрше өйләрдә яшәдек, соңрак та йортларыбыз бер үк төбәктә, урам аша гына туры килде.)

Моны ишеткәч, елмаймыйча булдыра алмадым:

— Татар әдәбиятының классигы Фатих Хөсни аны му-зы-каль-лек-кә дип бәяли,— дидем.



*Әдипләр Шәйхи Маннур, Фатих Хөсни, Гомәр Бәширов һәм Әмирхан Еники.*

Телебезнең нечкәлеген-нәфислеген, сөйләгәндә гаҗәеп моңлы вә матур булып яңгыравын музыкальлек дип бәяләми һич мөмкин түгел. Фатих ага әнә шул гүзәл байлыкка чын-чынлап соклана белде. Һәм инде язган чагында ана теленә бертөрле дә хилафлык китермәүне үзенең төп бурычларыннан санады. Һәр җөмләсен төзегәндә сүзләрнең иң кирәклесен эзләде, синонимнарның арада бер урынлысын сайлады, кабат-кабат укып, текстны кабат-кабат төзәтеп, үзенә кирәкле дәрәҗәгә ирешә. Үз сүзләре белән әйткәндә, «кондициягә җиткезде». Менә ни сәбәпле аның һәр хикәясе, повесте һәм романы җырлап тора, «мине бит Фатих Хөсни иҗат итте», дип әллә каян әйтеп-кычкырып тора.

Безнең телебездә хакимлек иткән сингармонизм законнарына буйсынган, тел ягыннан сокланырлык, һәркемгә үрнәк булырлык әсәрләре арасында «Йөзек кашы» повесте исә аерым бер гүзәл урынны били. Шигырь калыбына салган очракта да, ягъни чәчмә юллар белән язмыйча, тезмә юллар белән язган тәкъдирдә дә автор берни оттырмаган буласы иде, чөнки бу повесть — шагыйрь күңелле, ана теленең нечкәлекләрен шагыйрьләрчә белгән әдип иҗат иткән, шигъри дәрәҗәгә җиткерелгән әсәр.

«Йөзек кашы» — тормышчан булуы белән кыйммәтле. Аның сюжетында һичбер төрле ясалмалылык сизелми, төп каһарман Айдарның гыйбрәтле язмышына, нәкъ шулай булган икән дип, тулаем ышанасың, хәтта әле аның башсызлык кылуына да кул куясың, чын күңелдән әрнеп утырасың.

Пушкин белән Тукайның шигырьләрен укыган чагында сине даһиларның әсәрләрендәге искиткеч гадилек сокландыра, бөтен күңелеңне җәлеп итә: син инде аларның һәр шигырьне иҗат иткәндә нихәтле эзләнү-чиләнүләрен исеңнән үк чыгарып җибәрәсең, бу авторлар һич тә иҗади газап кичермәгәннәр, тотканнар да ансат кына язып ташлаганнар, дип тәмам инанасың. Башкача булуы да мөмкин түгел, чөнки даһиларның шигырьләрен төзәтә дә, үзгәртә дә алмыйсың: алар әнә шул гадилекләре белән камилдер вә гүзәлдер, моңа фәкать даһилар гына ирешә.

Миңа калса, Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» — әнә шул дәрәҗәдәге камил вә гүзәл әсәрдер. Һәм автор андый гадилеккә ирешүе белән үзенә һәйкәл салу бәхетенә иреште, дип әйтү һич тә хата булмастыр. «Йөзек кашы» — мең еллык тарихы булган татар әдәбиятындагы иң күркәм әсәрләрнең берседер. Һәм аны кабат-кабат укып, ана теленең нечкәлекләрен күрергә, сөйләшкәндә һәм язганда телебезнең байлыгына гаять игътибарлы булырга Фатих Хөснидән өйрәнү һәммәбезгә дә фарыздыр.

Әйе, Фатих Хөсни үзенең әсәрләрендә кешенең эчке дөньясын, рухи халәтен, хис вә тойгыларын искиткеч зур осталык белән ачып бирү бәхетенә ирешкән әдип. Үзенең холкы-фигыле, яшьләргә теләктәшлек күрсәтүе ягыннан дөнья бәясе торырдай шәхес киләчәк буыннарга искиткеч зур вә гүзәл әдәби мирас калдырды.

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ**

# Укучылар игътибарына!

Үткән елның уңай тәҗрибәсен һәм күпсанлы әбүнәчеләрнең теләкләрен искә алып, «Казан утлары» журналы редакциясе, Татарстан Элемтә министрлыгы белән берлектә, 1998 елның икенче яртысы (июль—декабрь айлары) өчен **льготалы подписка** игълан итә. Ул шушы елның **1 февральдән 31 мартына хәтле дәвам итәчәк**. Журналга язылу бәяләре шушы чор эчендә 1998 елның беренче яртысындагыча калачак. Икенче яртыеллыкта журналыбызны өйләрендә алдырырга теләүчеләр **6 ай өчен нибары 17 сум (яңача) түләячәкләр**. Элемтә бүлекчәләрендә әбүнә тартмалары (абонящиклары) булган укучыларыбыз өчен безнең басманы алдыру хакы тагын да арзанрак. **Журналның индексы — 73210**. Ул Татарстан һәм Россия каталогларына кертелгән.

*Редакция.*

# ШИГЫРЬДӘ — РӘССАМ, РӘСЕМДӘ — ШАГЫЙРЬ

Гакыйль Сәгыйровның исемен беренче тапкыр «Ялкын» журналында эшләгәндә, моннан 36 ел элек ишеттем. Әдәбият бүлеге мөдире Габделхәй Сабитов, ашыгып керде дә, безгә бер шигырь укып күрсәтте:

Әй кыш килгән, кыш килгән,
Моржа ак бүрек кигән.
Кисмәктәге су туңган,
Ватып алырлык булган.

Шигырь безгә шунда ук ошады. Ләкин аның бер кимчелеге бар иде, автор, нишләптер, шигырен акка күчереп тормыйча, каралама хәлендә җибәргән. Шигырен журналга тәкъдим иттек, ә үзенә, шелтәләп, хат язып салдык. Редакциягә кульязмаларны ачык итеп, кара белән язып җибәр, алай ярамый, янәсе. Ул егет шул ук вакытта рәсемнәрен дә җибәрде. Алар гаҗәп матур эшләнгәннәр иде.

Безнең үпкәбезгә аңардан җавап хаты килде. Кыска гына язылган юлларда «мин бит инвалид» диюдән башка сүзләр юк иде.

Берничә ел узгач, «Социалистик Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе, яшь язучы Рәшит Зәкиев сәләтле бу егетнең язмышын газета аша укучыларга хәбәр итте. Үзе турында берни дә әйтмәгән Гакыйль урында хәрәкәтсез ята һәм каләмне тешләренә кабып иҗат итә икән! Аның иҗаты һәм тормышы белән укучылар ныграк кызыксына башладылар.

Яхшы шигырь безне дә ерак юлга чыгарды. Шәүкәт Галиев белән бергәләп, ерактагы Куйбышев өлкәсе Кошкинск районы Иске Фәйзулла авылында яшәүче Гакыйль Сәгыйров янына киттек. Октябрь Норлаты районында безгә Рәшит Зәкиев кушылды.

Һәм менә без аның өендә. Ул да, без дә, әнисе Хәбибҗамал апа да башта, каушап, сүз табалмыйча тордык. Китап киштәсендәге бер китап сүзне башларга ярдәм итте.

— «Хөсәен Ямашев». Автор үзе бүләк иткәндер инде?

— Әйе, күптән түгел Норлатка килгәч, Расих абый, Гөлшат Зәйнашева һәм Роберт Әхмәтҗановлар кергәннәр иде...

Без алып килгән әманәтләрне, автограф язылган китапларны, хатларны тапшырабыз. Гакыйльдән шигырьләрен күрсәтүне сорыйбыз. Менә балалар өчен язылган бер шигырь:

Антеннада ике карга
Тирбәлә кунган көйгә.
Шуларны күрде дә Дилә
Йөгереп керде өйгә.
— Әнием, телевизорны
Тизрәк инде кабыз, ди,
Анда кунган каргаларны
Күрмичә калабыз, ди.

Без рәхәтләнеп көлəбез. Балаларча, яңача, үзенчә... Шул вакыт түр бүлмәдәге телевизорга күз төште. Аны Гакыйльгә Татарстан нефтьчеләре бүләк иткән икән. Лениногорск киностудиясеннән килеп аны кинога да төшергәннәр. Гакыйльне больницага алып китеп, Лениногорск врачлары дәвалаганнар да. Вертолет туптуры Гакыйльләрнең ишек алдына төшкән.

Яшәве дә авыр, үлеме дә
Тормыш өчен көчең салмагач,
Үзең үлсәң, сине күңелләрдә
Яшәтерлек эшең калмагач.

Бу юлларны укыганда кулына кулъяулык тоткан яшь егет килеп керде. Ул сүзсез генә шигырьне тыңлап торды. Бу юллар аңа тәэсир итте булса кирәк, кызлар бүләк иткән кулъяулыгы белән күзен сөртеп алды.

— Сау булыгыз, Гакыйль абый, армиягә китәм!..

Солдатка китүче егет кай ягы беләндер Әсгать Җиһаншинны искә төшерде. 49 тәүлек океанда йөреп, дөньяны шаулатып кайтканнан соң, мин Әсгать Җиһаншинның туган авылы Шенталага, герой янына килгән идем. Ә Шентала моннан әллә ни ерак түгел. Гакыйль герой якташы турында элегрәк шигырь дә язган:

Күргәнем бар кебек,
Таныш йөзләре.
Туганнарым кебек
Якын үзләре.

Иң авыр минутларда, инде түзәр хәл калмаганда Гакыйль, мөгаен, якташы Әсгатьне күз алдына китергәндер.

Илебезне сакларга баручы егет ниләр уйлагандыр, белмим, әмма ул тирән уйга батып чыгып китте.

Гакыйльнең лирик шигырьләрен укыгач, без дә уйга калдык.

Килер бер көн — үкенүдән янып,
Газапланып, ятып үләрмен,
Әмма мәңге хәтеремдә калыр
Матурлыгы тормыш-гүзәлнең.

Әйе, болар тормышның матурлыгын раслау өчен күңелдән тулып чыккан утлы сүзләр. Гакыйльнең шигырьләре моңландыра да, түбән иелгән башны югары да күтәрә.

Без җитәсе җирләр ерак әле,
Без барасы юллар киртәле,
Бир ышанып миңа кулларыңны,
Чын иптәшем булып күтәрел!

Гакыйльнең тәрәзәсеннән карга оялары белән чуарланган топольләр күренеп тора. Гакыйль аларны менә ничек күрә:

Аяз иртәләрдә
Бәбкә казлар сыман
Топольләрем очыра мамыгын...

Моржасыннан төтен чыгучы өйне күргән шагыйрь менә нинди нәтиҗә ясаган:

Аяк-кулын бәйләп куйган язмышының
Чылбырларын өзеп читкә атты микән?—
Моржасыннан нинди кара төтен чыга,—
Әллә соң ул кайгыларын якты микән?

Гакыйль дөньяга рәссам күзе белән карый: аның сизгер йөрәге табигатьтәге, тормыштагы буяуларны, контрастларны, нечкәлекләрне тотып ала белә.

Тормыш агай алып күкрәгемнән
Бирсә бирде минем кирәкне,
Һаман саен һәрбер матурлыкка
Сизгеррәк итте йөрәкне.

Гакыйль шигырьдә — рәссам, рәсемдә — шагыйрь. Шигырь юлларына кергән теге топольләрне ул натурадан кәгазьгә дә төшергән. Әмма Гакыйль фотограф түгел. Ул топольләрне үз хыялы белән баета, сәнгать дәрәҗәсенә күтәрә. Шул ук вакытта ул топольләрне Гакыйльнең читкә киткән һәрбер авылдашы танып алыр һәм: «Аһ, шул топольләрне кайтып бер генә күрәсе иде!» — дип әйтер...

Гакыйльнең үзен күргәч, яңа шигырьләрен тыңлагач, элек язылган хатыбыз өчен уңайсызланып киттем. Шигырьдәге һәрбер хәрефне язу яки рәсемдәге һәр ноктаны кәгазьгә төшерү өчен күпме чыдамлык, тырышлык кирәк. Шулай да аның почеркының матурлыгын күреп гаҗәпкә каласың. Шигырьдә дә Гакыйль-

нең үзе генә тапкан почеркы бар. Шагыйрьнең үзенчәлеге кешенең, табигатьнең матурлыгын эзләүгә, укучыда оптимистик рух уятуга юнәлгән. Гакыйль поэзиянең төрле өлкәсендә үзенең көчен сыный: лирика, сатира-юмор, балалар өчен шигырьләр...

Бу сәяхәттән без үзебез өчен яңа шагыйрь ачып кайттык!..

Казанга кайту белән аның шигырьләрен, үз рәсемнәре белән бизәп, нәшриятта китап итеп чыгардык. Яңа шигырьләр белән тулыландырылган икенче китабын укучыларга җиткерүдә дә якыннан катнашырга туры килде. Матди яктан авыр хәлдә яшәгән Гакыйльгә Куйбышев өлкә комитеты аша пенсия дә юллап бирдек...

Аның янына баруга утыз елга якын вакыт узган да киткән. Соңгы елларда да шагыйрь-рәссам, күңелендәге өмет утын сүндермичә, иҗат эшен нәтиҗәле дәвам итә.

Могҗизалы каләмгә ия булган көчле рухлы Гакыйльне, алтмыш яшьлек юбилее белән ихлас күңелдән кайнар котлыйбыз, һаман да көр һәм хөр күңелле булып калуын телибез һәм ул яшәгән яклардан, ул иҗат иткән әсәрләрдән гамьле тормыш җиленең һәрдаим исеп торуына тирәнтен ышанабыз.

...Дошманнары, сәхнәгә чыгар алдыннан, тылсым иясе Паганининың скрипка кылларын өзеп, бер генә кылын калдыралар. Әмма бөек скрипач югалып калмый, бер кылда катлаулы көйләрне шулкадәр матур уйный, тыңлаучылар кылларның өзелүе турында уйламыйлар да.

Язмыш Гакыйль Сәгыйровның да тормыш кылларын өзәргә уйлаган. Ләкин батыр егетнең күңел кылын берничек тә өзә алмаган. Ул әнә шул өзелмәс нечкә кылда тагы да матуррак уйнар әле!..

**Илдар ЮЗЕЕВ,**
Татарстан Язучылар берлегенең Шигърият остаханәсе җитәкчесе.

# Салым инспекциясе искәртә

Казан шәһәренең Вахитов районы буенча икенче номерлы дәүләт салым инспекциясе, гражданнарга Россия федерациясенең «Аерым кешеләрдән керемгә карап налог алу» турындагы Законы нигезендә, ел дәвамында төрле чыганаклардан алынган керем 12 миллион сумнан арткан очракта, 1997 елда алган керемнәре турындагы декларацияне 1998 елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча салым инспекциясенә тапшырырга кирәклеген искәртә.

Берничә чыганактан алынган керем 12 миллион сумнан артмаган очракта декларация бирелми, әмма төп эш урыныннан 1997 елда алган керем һәм тотылган салымнар турында белешмә тапшырыла.

Әгәр, аерым кешеләр ел дәвамында керемне бары тик хезмәт урыннарыннан гына алган һәм аларга башка җирдән акча кермәгән икән, ул вакытта үз керемнәре турындагы декларацияне салым инспекциясенә тапшырырга кирәкми.

Эшкуар буларак теркәлгән һәм алынган керемнәре буенча налог турыдан-туры салым оешмалары тарафыннан исәпләнелгән кешеләр дә, ел дәвамында алынган керемнең күпме булуына карамастан, декларация бирүдән азат ителмиләр.

Шунысын да искәртәбез: декларация тапшырылмаса яисә аңа ялган мәгълүматлар теркәлсә һәм керемнәр салым түләүдән яшереп калынса салым түләүчеләр административ, финанс һәм җинаять җаваплылыгына тартылалар.

Вахитов районының икенче номерлы дәүләт салым инспекциясе үзара аңлашып һәм тыгыз элемтәдә эшләрбез дип өметләнә.

Хәбәрләшү өчен Вахитов районы салым инспекциясе телефоннары: 38-58-24, 38-98-25.

# ИМАН НУРЫ



Аның турында каләмдәшләре арасында бер мәзәк йөри. Имештер, Шаһинур, троллейбуста бик тыгыз булганда, урынын башкаларга биреп, аларга җайлы булсын өчен, үз тукталышына җиткәнче үк төшеп кала һәм кулын күкрәгенә куеп: «Рәхмәткә-хөрмәткә лаек сез, кешеләр!» — дия, имеш.

Мондый хәл булгандырмы-юкмы, гонаһысына керә алмыйм, әмма «Казан утлары» редакциясенең бер бүлмәсендә утырып эшләүче каләмдәше буларак, шуны әйтә алам: рәхмәтне аның үзенә күбрәк әйтәләр. Кайсыдыр аңардан узган сугышларда хәбәрсез югалган әтисен яки абыйсын эзләшүен үтенә, кемдер аңа фронтта яшьли һәлак булган туганының шигырьләр дәфтәрен алып килеп, шуларны редакцияләп, кайдадыр нәшер итәргә булышуын сорый, шундый ук гозер белән беренче кульязма китабын күтәреп яшь авторлар аның күзенә мөлдерәп карый. Һәм Шаһинур аларны якын туганы кебек күреп, каршы ала, хәл-әхвәлләрен сораша, хәл кадәри ярдәм итәргә тырыша. Бигрәк тә, ил-җир азатлыгы өчен сугыш кырларында шәһит киткән якташларыбызны барлау, аларны архивлардан һәм фронт юлларыннан эзләп табу һәм шул хакта документаль әсәрләр иҗат итеп, халыкка җиткерү юнәлешендә бик мактаулы эш башкара безнең Шаһинурыбыз. Бу гамәлендә ул үзенең остазы, эзтабар әдип Шамил Рәкыйповның «Аяз күктә карлыгачлар» әсәрендәге бер каһарман сүзен девиз итеп алган: «Үлгәннәр истәлеге тереләр өчен кирәк. Тереләрнең җаны тыныч түгел. Дөнья тыныч түгел. Үлгәннәр турында даими сөйләргә кирәк. Вакытсыз үлгәннәр турында... Алар онытылмаска тиеш. Алар хакы изге...»

Әнә шушы изге уйлар Шаһинур Әхмәтсафа улын, Александр Матросов (Шакирҗан Мөхәммәтҗанов) кебек, дошманның ут ноктасын күкрәге белән каплаган якташларыбызны билгесезлек томаныннан бүгенгегә кайтарырга этәрә, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең көрәштәше Фәрит ага Солтанбәков истәлекләрен редакцияләп һәм Ватан сугышында яшьли һәлак булган талантлы каләм иясе Мөхәммәт Әхмәтгалиевнең сугыш чоры көндәлекләрен һәм хатларын туплап укучыларга җиткерергә рухландыра. Вә янә дә Франциядә җәлилчеләрнең яшерен оешмасын җитәкләгән Әмир ага Үтәшев турында «Әманәткә тугрылык» дигән документаль әсәр дә язып бастыра Шаһинур. Ә сугышта сигез улын җуйган Фатыйха апа Әхмәдиеваның фаҗигаи-гыйбрәтле язмышы һәм аның истәлегендә Мамадышта куелган һәйкәл турындагы «Сигез бизәкле Сөлге» повесте өчен бу авторга якташларының рәхмәте аеруча зур булды.

Һәйкәлләр дигәннән, Шаһинур эзләп табып, дөньяга кабат «тудырган» геройларыннан кайберләренә туган төбәкләрендә һәйкәлләр дә куелды, бу игелекле эштә башлап йөрүчеләрнең берсе эзтабар-язучы үзе булды.

Әнә шушы игелекле эшләр дулкынында шигырьләр, җырлар языла, «Васыять» китабы нәшер ителә, «Алмагачлы нигез моңы» исемле әсәре туа.

Алмагачлы нигез ул — Шаһинур туып үскән нигез. Мамадыш районының Арташ авылындагы һәркем хөрмәт итә торган изге вә иманлы йорт бу. Шаһинур шушында тәүге тапкыр күзләрен ачып (12 февраль) якты көнгә карый. Ләкин аның әтисе сугыштан каты яраланып, күзләре сукыраеп кайткан... Шаһинурны, үзен белә башлаганнан алып, әтисенең әнә шушы фаҗигасе тетрәндерә, күңелендә ничек кенә булса да гаиләдә әти-әнисенә (Әхмәтсафа абый белән Гөлзәйнәп апага) ярдәмче булырга теләү хисләре уята. Үзеннән соң бер-бер артлы дөньяга килгән ун эне вә сеңелләренә абый буларак та, ул яшьтән үк җаваплылык тоеп

үсә. Башкаларга карата мәрхәмәт, яхшылык эшләүгә теләү тойгылары аның күңелендә әнә шул вакытта ук бөреләнгәндер, мөгаен. Һәм башкаларга «Абый» кеше, үрнәк кеше, ярдәм итәргә тиешле кеше итеп хис итү аны гомере буе озата бара. Мәктәптә укыганда да, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә гыйлем эстәгәндә дә, Германиядәге Совет гаскәрләре группасында хәрби хәбәрче булып хезмәт иткәндә дә, Мамадыш һәм Кукмара районнары газитләре редакцияләрендә, аннары, Казанга күчеп килгәч, Халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре буенча республика фәнни-методик үзәгендә баш мөхәррир вазыйфасын башкарганда да, Татарстан Язучылар берлегенең Әдәби фонд директоры буларак, каләмдәшләренә бик күп игелек кылганда да... Ул һәрвакыт әдәби хәрәкәтнең үзәгендә кайный, оештыра, башлап йөри, яңа-көя, төрле иҗади конкурсларда катнаша. 1982 елда Шәһинур Әхмәтсафа улы Мостафинга, авыл хезмәтчәннәре турындагы публицистик язмалары өчен, Татарстан Җөмһүриятенең Хөсәен Ямашев исемендәге премиясе бирелде. Ә 1995 ел аңа берьюлы ике сөенеч алып килде. Якташы Шәйхи Маннурның иҗади мирасын өйрәнү-саклау, якты истәлеген мәңгеләштерүдәге хезмәтләре өчен, ул әлеге әдип исемендәге бүләккә лаек булды, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы оештырган «Бөек Җиңүгә — 50 ел» иҗади конкурсында үзенең сәнгать дәрәҗәсендә язылган очерклары белән беренчелекне яулады.

Шәһинур белән очрашканда-күрешкәндә булсын, яки телефоннан сөйләшкәндә булсын, иң әүвәл ул хәл-әхвәлеңне белешер, исәнлек-саулыгыңны сорар, кыен вакытыңда хәлеңә керер, ничек тә кәефеңне күтәреп җибәрергә тырышыр. Ә үз хәлен сорасаң, елмаеп: «Әйбәт бит, дустым. Гөлләр кебек!» — дип куяр. Аны якыннан белмәгән кеше, чыннан да моның дөньясы ал-да гөл, эшләре гел асфальт юлдан элдерткән төзек машина кебек шома гына бара икән, дип уйларга да мөмкин. Әмма иңендә купләгән иңсаннар гамен күтәреп йөрткән ир-егеткә алай җиңел була алмаганын Шәһинур үзе генә беләдер. Шагыйрь күңелле кешегә җиңел була димени?! Аңа бит теге яки бу эшне башкарып чыгу өчен ничәмә-ничә авыр ишекләрне шакып керергә, үзенең хаклыгына ышандырырга, күпләрне теләктәш итәргә кирәк ләбаса. Әле бит син игелек кылган адәмнәрнең дә бөтенесе, рәхмәт кенә әйтеп тормый. Игелеккә явызлык белән җавап кайтаручылар да юк түгел бу дөньяда... Әмма боларга карап кына Шәһинур тормыштан, кешеләрдән суынмый, үзе сайлаган кыен вә мактаулы юлын дәвам итә. Шулай да мин, әнә шундый каршылыклы уйлардан аның нурлы йөзен болытлар каплап алгалаган вакытларын да күргәлим. Андый чакларда ул, сиздермичә генә, уфтанып-авыр сулап куя, кесәсеннән алып, йөрәк даруы каба... Тик аңа озак күңелсезләнеп утырырга ирек бирмиләр: йә кемдер гозер белән килеп керә, яки телефон чылтырый, аны — Шәһинурны сорыйлар... Һәм ул яңадан башкалар гаменә кереп чума... Ирексездән, шундый нурлы җанлы кешеләр күбрәк булса, бу тормыш тизрәк җайланыр, дөнья ямьләнер иде бит! — дип уйлап куям... «Гел башкалар турында кайгыртып, үзеңнең шәхси тормышыңны онытып җибәрмисеңме икән?» — дисәң, Шәһинур, гадәтенчә тыйнак елмаеп: «Кешеләргә кирәклегеңне һәрдаим тоеп тору — үзе бәхет ул, дустым!» — дип җавап бирә.

Шәһинур Мостафинның соңгы еллардагы тынгысыз эшчәнлеге «Казан утлары» журналы редакциясе белән бәйле. Ул, бүлек мөхәррире буларак, зур тарихлы, гыйбрәтле әсәрләргә бай булган энциклопедик бу басманың халкыбыз арасында мөмкин кадәр күбрәк таралуы өчен бар көчен-сәләтен, оештыру осталыгын эшкә җигә, еш кына районнарга барып, укучыларыбыз белән очраша, мәктәп һәм китапханәләрдә була, радио-телевидение аша чыгышлар ясый.

...Безнең халыкта яхшы кеше турында: «Аның йөзендә иман нуры бар», — диләр. Ә йөздәге нур — күңелдән, җаннан саркып чыгучы илаһи яктылык бит инде ул. Әнә шундый нурлы җанлы кеше ул Шәһинур Әхмәтсафа улы Мостафин, дип өстәр идем мин.

Котлы булсын юбилееӊ, Шәһинур дус! Күңелеңдәге игелек нуры сирпеп торган изге шәмнәрең сүнмәсен-сүрелмәсен!..

**Шамил МАННАПОВ.**

## Şağirlərebez tugan tel turьnda

### Ǵabdulla Tuqaj

**Tuğan tel**

**I tugan tel, i matur tel, ətkəm-ənkəmneņ tele!**
**Dənjada kyp nərsə beldem, sin tugan tel arqьь.**

**Iņ elek bu tel belən ənkəm bişektə kəjləgən,**
**Annarь tənnər bujь əbkəm xikəjət səjləgən.**

**I tuğan tel! Hərwaqьtta jardəmeņ berlən sineņ,**
**Keckenədən aņlasьlğan şatlьğьm, qajğьm minem.**

**I tugan tel! Sində bulgan iņ elek qьjlgan doğam!**
**Jarlьqağьl, dip, yzem həm ətkəm-ənkəmne, xodam!**

### Dərdmənd

***

**Tatarlьqtan tatar hic gər itərme?**
**Keșe yz ismene inqar itərme?**
**Tatarlьqta tatar uglь tatarmьn,**
**Tatar tygel dimə — başьņ watarmьn!**

### Xəsən Tufan

**Tuğan tel turьnda**

**1**

**I teļem, sansьz ğasьrnь**
**Isən-sau kickən telem!**

Sьqraular tele tygel sin,
Kykrəylər tele bygen.

I beznen batьr telebez,
I beznen gəyhər miras!
Kyplərne kyrgən basьnnь
Inde sin kytər beraz.

2

Tarixьm istəlege sin,
Bolgarьm istəlege.
Gasьrlar asa ytelgən
Jullarьm istəlege.

Cismələr isən cagьnda
Idellər kibəmeni?
Gasьrlar kymmədе sine,
Dəwerlər kyməmeni?

Iŋgə-iŋ bezneŋ teləklər,
Qulğa-qul ujlarьbьz,
Jaqtь jazmьslarğa taba
Barasь jullarьbьz.

Sin - minem tere tarixьm,
Sin - minem kiləcəgem.
Tik sində, ğaziz tuğan tel,
Bəxetkə citəcəgem.

I telem, sində nəfislek
Cisməse kibərmeni?
Ğasьrlar sina timədе,
Dəwerlər tiərmeni?

## Gamil Afzal

•••

Sular aga, qajda Suvar, Bolğar...
Sirəgəjep qalğan urmanlьq.
Biek bulmasa da taularьm bar,
Itəgenə jatьp jьlarlьq.

## Rawil Fəjzullin

### Minem telem

Minem telem -
meңərləgən işləre kyk,
tьjnaq tel ul.
Ƣəjrətlənməs, artьq ḩawalanmas,
Jaңƣьrьjm dip qabalanmas,
çegər cigen beler, jərer çiren...

Basьnqь ul:
xalьqara kongresslar,
parlamentlar acьp jərmi,
aqca, ceklar bitenə menmi.
Suƣьş acmьjlar minem telemdə,
Kapitulatsiə də jasamьjlar...

Tyzem tel ul.
Okoplarda, tərmələrdə, lagerlarda
atьlsa da, asьlsa da,
, çiңy ruxьn çujmaƣan ul.
Gil'otina əslərendə
jəşəw çьrьn çьrlaƣan ul!

Minem telem -
meңərləgən işləre kyk,
moңlь tel ul.
Yzenə çaj, yzenə jatьş anьң kəje.
"Saq-soq"larь, "Ramaj"larь, "Sarman"narь,
"Gəlçamal"ь, "Karurman"ь, "Əllyki"e...

Ƣawəmi ul,
bik ƣadi ul.
Minem teldə igen ysə,
Sət parlana, çep erlənə,
neft cьƣa, tire ilənə...
Tujьndьrucьlar,
kienderycelər digəndə
minem telem iskə təşsen!

# Zəlfət

## Tuğan tel xaqьnda

Tel acьlğac əjtə alsaņ: "Əni!" - dip,
Tel acьlğac əjtə alsaņ: "Əti!" - dip,-
Kyzlərenə jəşlər tьğьlmas,
Tuğan teleņ əle bu bulmas.

Soņ minutta əjtə alsaņ: "Əni!" - dip,
Soņ minutta əjtə alsaņ: "Əti!" - dip,-
Kyzlərenə jəşlər tьğьlьr,
Tuğan teleņ ənə şul bulьr...

*Редакциядән:*

Без үткән елгы саннарда латин имласында уку күнекмәләре өчен уртак төрки имласы нигезендә эшләнгән әлифбада кайбер үрнәкләр тәкъдим иткән идек. Быелгы беренче санда исә иске «Яңалиф»тәге язма белән дә таныштыгыз. Редакция компьютерларында әлегә яңалиф хәрефләре булмаганлыктан, бу санда «Казан утлары» журналы үз вариантын тәкъдим итә. Ул яңалифтән бары тик калын Г авазын белдерүче хәрефнең үзгәлеге белән генә аерылып тора һәм, безнең карашка, хәзер гамәлдәге технологияне куллануда шактый уңайлыклар тудыра ала.

## Сугыштан соңлап кайткач

Сугыштан мин Германиядә бер ел совет хәрби администрациясендә хезмәт иткәннән соң кайттым. Веймар каласыннан Уфага, аннан соң туган авылым Миңештегә үз җинел машинамда руль артында утырып кайтуым ул заман өчен бик шаулы булды. (Хәзер иномарка машинада йөрүчеләр Уфа урамында тулы, ә 1946 елда мин бер үзем генә идем).

Минем кайтуны сугышка кадәрле үк таныш, дус булып, бер-беребезне яхшы белгән, фронттан соң Уфага хәрби хезмәтен дәвам иткән Николай Асанбаев та ишеткән. (Хәзер ул — күренекле драматург Нәҗип Асанбаев. Яшь чагыннан ук Николай дип эндәшеп йөргәч, Нәҗип, дип эндәшкәнем юк).

Шул мин кайткан көннәрдә Казаннан Кави Нәҗми хәләл җефете Сәрвәр ханым белән Уфага килгәннәр икән.

Н. Асанбаев берчак Ленин урамында Вәли Нафиковны очрата. (Вәли Нафиков сугышка кадәр шигырьләр язды. Сугыштан соң радиода эшләде. Гомеренең байтак өлешен «Совет Башкортстаны» гәзитенең баш мөхәррире булып торды).

— Нишләп йөрү? — дип сорый Асанбаев Нафиковтан.

— Менә радио аша Нәҗминең чыгышын оештырып йөрим.

— Шулаймыни? Кайда ул?! — дип сорый Асанбаев.

— «Башкирия» кунакханәсендә, — дип Нафиков Кави Нәҗминең ничәнче номерда яшәгәнлеген әйтеп бирә.

Асанбаев кунакханәгә килә, номерга керә һәм анда урта яшьләрдәге ханымны күреп аптырап кала. «Шундый үзеннән олы яшьтәге хатынга өйләнде микәнни?» дип эчтән генә уйлап куя. Икеләнеп кенә:

— Нәҗми монда торамы? — дип сорый Асанбаев.

— Әйе, монда тора, — дип җавап бирә Сәрвәр ханым.

— Сез кем буласыз? Апасымы?

— Юк, мин аның җәмәгате булам.

— Шулаймыни?! — ди Асанбаев һәм тагын «Нигә шулай үзеннән өлкән кешегә өйләнде икән?» дип уйлап куя да, иркенләп китеп, өстәлдә торган җимеш сулы графинга күрсәтеп, «су салыгызчы», ди. Сәрвәр ханым салган бер стакан суны эчеп беткәч, «тагын салыгыз», дип стаканны суза һәм суны голткынлатып эчеп беткәч, сөйләп китә:

— Без Нәҗми белән сугышка кадәр бик дус булдык. Уен-көлкегә бай, һәр шадрасын (Кави Нәҗми дә шадра һәм уен-көлкегә бай булган диләр) кызлардан яраттырды.

Шулвакыт Сәрвәр ханым: «Мондый бала-чага белән Кави нишләп йөрде икән?» дип уйлап утырганда, Асанбаев аңа сорау бирә:

— Машинагызны кая куйдыгыз соң?

— Без машинада түгел, пароходта килдек.

Шулчак Асанбаев кычкырып җибәрә:

— Сез Кави ага Нәҗми җәмәгате Сәрвәр апамыни?

## Гариф Ахуновның ике тапкырлыгы

### 1

Хәсән ага Туфанның 70 яшьлек юбилее. Котлаулар беткәч, аңа сүз бирделәр. Юбиляр трибуна артына басты да сүз башлады:

— Кадерле татарларым!..

Зал гөж килеп кул чапты. Моның сәбәбен аңламый калган, президиумда утырган КПСС өлкә комитеты секретаре Мөҗәһит Вәлиев, рәислек итүче Гариф Ахуновтан:

— Что? Что он сказал? — дип сорады.
Ахунов шунда ук җавап бирде:
— Кадерле батырларым! — диде.
Татарча бик үк шәп белмәгән М. Вәлиев тынычланды булса кирәк.

2

Мәҗит Гафуриның йөз еллыгы. Шул көннәрдә генә Мәскәүдән миңа «Ветеран 2-ТА» («ТА» — танк армиясе) дигән медаль җибәргәннәр иде һәм мин шуны тагып алган идем.

Агыйдел буенда оештырылган табын башланыр алдыннан кул чайкап торган бер урыс язучысы: «Что за медаль? Что это значит «ТА»? — дип сорады миннән. Янәшә торган Гариф Ахунов шунда ук җавап бирде:

— «ТА» — «Татарская армия», — диде.

**Наҗар НӘҖМИ.**

## «Файдалы җанвар»

1972 елның октябрендә Нури Арсланның 60 еллык юбилее булды. Бер-бер артлы трибунага күтәрелеп, тәбрикләүләр, билгеле инде, иң хуш, иң җылы сүзле котлаулар, чәчәк бәйләмнәре, кул чабулар...

— Сүз атаклы композиторыбыз, юбилярыбыз шикелле үк Казакъстанда туып үскән, якташы һәм дусты Заһид Хәбибулинга, — дип игълан итте мәҗлесне алып баручы Зәки Нури. Заһид ага трибуна артына килеп баскач, һәрчак маңгаена төшеп йөдәтә торган чәчен кулы белән артка сыпырды да болай диде:

— Җәмәгать, дуслар, бирегә минем дустыма карата бик күп җылы сүзләр әйтелде, мин аларны кабатлап тормыйм, Нури Арсланга лаек итеп шуны гына әйтәсем килә. Менә, җәмәгать, дөньяда бик күп төрле хайваннар бар, менә әйтик, фил бар, ул бик явыз, маймыл бар, ул гел бер җирдән икенче ботакка сикерә, ишәк бар, ул гел кирәксез урында бакыра, юлбарыс бар, анысы инде ерткыч. Шулар арасында арслан дигән җанвар бар. Менә ул ичмасам җанвар дисәң җанвар! Чөнки ул көчле, курыкмас, үзе юаш кына, кешегә бик тә файдалы җанвар. Менә безнең Нури Арслан да шундый инде...

Өстәл артындагылар уңайсызланыбрак башларын аска иделәр, ә залдагылар Заһид аганың ни әйтергә теләгәнен барыбер аңладылар, келә-келә кул чаптылар. Ә Заһид ага үз-үзеннән бик канәгать кыяфәт белән сәхнәдән төшеп, елмая-елмая үз урынына килеп утырды да, маңгаена төшеп йөдәткән чәч учмасын биш бармагы белән янә артка сыпырып куйды.

## Читлектәге Һарун

Тел, әдәбият, тарих институтының директоры профессор Мөхәммәт ага Гайнуллин иде. Профессор булса да, русчаны өстән генә сукалаганын барыбыз да белә идек. Бер мәлне Мәскәүдән танылган тюрколог академиклар Борис Александрович Серебренников, Эдванд Владимирович Севортян, Николай Александрович Баскаков килеп төштеләр. Берничә көн буенча институт эшләре белән танышып йөргәннән соң, безне — тел бүлеге фәнни хезмәткәрләрен, директор кабинетына, йомгаклау әңгәмәсенә чакырдылар. Эшебезгә гомумән уңай бәя биреп, СССР Фәннәр Академиясе исеменнән канәгатьлек белдерделәр. Йомгак ясаучы академик Баскаков, бер урында әйтеп куйды:

— А у вас есть перспективные кадры, вот, например, в Москве, в издательстве «Наука» вышла очень талантливая книга вашего сотрудника Харуна Юсупова «Введение в татарскую эпитафию»...

Бу урында авызы колагына җиткән Мөхәммәт ага, шатлыгын тыя алмый сикереп торды да, арабызда утырган Һарун абыйга күрсәтеп, Баскаковка:

— Вәт ун сам! Юсупов, катурый в клетке сидит! — дип кычкырды диярлек.

Карасак, Һарун абый чыннан да «клетка»лы — «кызыл шакмаклы» күлмәк кигән икән.

**Рәис САФАРОВ.**

* * *

**Хөрмәтле милләттәшләр!**
**Редакция хезмәткәрләре!**
**Редколлегия әгъзалары, укучылар!**

Сезнең кебек, без дә — газиз халкыбыз сибелеп яши торган һәр төбәктә — кадерле кунак кебек сагындырып килә торган «Казан утлары»ның 75 еллык олуг юбилеен күтәп алдык. II Бөтендөнья татар конгрессы ачылган тарихи бер вакытта үтүе белән икеләтә истәлекле булды ул бәйрәм! Бу үзе генә дә яраткан журналыбызның милләттәшләребез арасында нинди зур абруй казанганлыгын бик ачык дәлилли. Төрле кыйтгалардан, мәмләкәтләрдән килгән делегатлар, кунаклар тарафыннан «Казан утлары» адресына күпсанлы мактау сүзләре яңгырады, журнал эшчәнлеген тагын да яхшырту буенча кызыклы-файдалы тәкъдимнәр әйтелде. Без бу хакта «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе тапшырулары аша ишетеп-белеп тордык, халкыбызның зурлыгын билгеләүче журналыбыз өчен эчке бер горурлык хисләре кичердек.

Үзем әлеге журналны ун яшемнән укый башладым (тумышым белән — Актаныштан, Ахун авылыннан булам). Ул чакта журнал «Совет әдәбияты» исеме астында, латин хәрефләре белән басыла иде. Әмма 1944 елда солдатка алынып, шул чак кигән шинельне утыз ел буе салмыйча, хәрби хезмәттә гомер үткәрергә туры килде. Ул елларда төрле җирләргә еш күченеп йөргәнлектән, журналны рәтләп укый алмадым. Ә инде отставкага чыгып, бер яшәү урынында төпләнгәч, яраткан журналымны, 1980 елдан башлап, эзлекле төстә алдыра башладым. Дөрес, өч ел (1994—1996) дәвамында, ни сәбәптәндер, Татарстаннан газет-журналлар яздырып алу мөмкинлеге булмады. Аллага мең шөкер, 1997 ел башыннан бу мәсьәлә дә уңай хәл ителде — өебез түрендә янәдән «Казан утлары» балкый!

Инде менә журналның 900 нче саны да чыккан! Димәк, бер елда ике зур юбилей насыйп булган «Казан утлары»на!

Журнал килгән көн — бәйрәм ул минем өчен! Аны уку телне баета, милли анны үстерә, тарихи белемне арттыра. Журнал, чын-чынлап, рухи байлык-хәзинә, йөрәккә ята торган җан азыгы!..

Хәзерге көндә, минем кебек, туган якларыннан читтә яшәүче милләттәшләребезгә татар дөньясы белән ныклы рухи элемтә, төп бәйләнеш чарасы да ул «Казан утлары».

Журналны укыган саен телебезнең байлыгына сокланам, туган телем, милләтем, тарихыбыз белән горурланам...

Редакция хезмәткәрләренә, редколлегиягә, авторларга, укучыларга сәламәтлек вә иминлек, иҗат өлкәсендә һәм көнкүрештә уңышлар теләп калам!

**Санияф Фатих улы ГАРДАНОВ,**
*отставкадагы подполковник.*
*Гродно шәһәре, Беларус Республикасы.*

## Хөрмәтле дуслар, кан кардәшләр!

Күренекле шагыйрь, прозаик һәм драматург — Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Фәнис Яруллинның күп санлы укучыларыннан берсе буларак, аның киңкырлы иҗатына карата «Казан утлары»на кайбер фикерләремне язып җибәрергә булдым әле.

Әлеге көчле рухлы язучының әсәрләре белән яхшы ук танышмын: вакытлы матбугатта күренгәннәрен дә, китаплар булып чыкканнарын да яратып укып барам. Уйландыра, моңландыра аның әсәрләре — үзенчәлекleләр, тирән фикерләр алар. Мин Ф. Яруллинның иҗатын «фәһемле иҗат!» — дип атар идем. Чөнки аның нинди генә әсәрен кулыңа алма — шигырь-поэмамы, хикәя-повестьмы, драма-комедиямe...— тирәннән бәреп чыккан саф чишмә суы кебек, табигый һәм тормышчан. Кайсыбер язучыларныкы кебек, фәкать аларның үзләренә генә «аңлаешлы» телгә, катлаулы философиягә нигезләнмәгән аның әсәрләре. «Аяк астындагы» гадәти күренешкә дә шагыйрь күзе белән багу, гадәти хәлләрне мәгънәле сөземтәләргә китерү осталыгы хас Фәнис каләмдәшебезгә. Шуңа күрә аның иҗаты язучыларыбызга гына түгел, киң катлам укучыларыбызга да (яшенә дә, картына да!) аңлаешлы һәм якын.

...Сагышларны миңа Язмыш бирде,
Ә моңнарым булган тумыштан...
Бәхет белән шатлыкларны гына
Гел көрәшеп алам Тормыштан! —

дип яза Ф. Яруллин.

Тирән хөрмәткә лаек бу Шагыйрьне якыннан күреп белмәсәм дә, аның тирән мәгънәле шигъри юлларын укыгач, битараф булып кала алмыйсың. Бөтен гомере тоташ Батырлыктан һәм Кеше җанының Матурлыгы өчен көрәштән тора. Ф. Яруллинның. Әсәрләре аша Фәнис каләмдәшебез күз алдыбызга үз халкының әрнү-югалтуларын, тарихи фаҗигаларын тирәннән аңлаучы һәм кыйбла-яктылыкка юл сабучы изге бер илаһи җан, фидакарь зат булып килеп баса... Әйе, Ф. Яруллин — без яши торган Башкортстанда да киң танылган, халыкның күңелен яулаган, Шигъриятнең канатлы Шигъри Атында җитез җилдерүче чын ир-егетләрнең берсе!

...Үскәчтен дә, кеше булгач та
Шул ук исем белән калабыз...
Тик тормышта аны кабаттан
Без үзебез яулап алабыз! —

дип язган иде заманында Татарстан яшьләренең М. Җәлил исемендәге республика бүләге лауреаты Ф. Яруллин. Хәзер дә шагыйрьнең йөрәгендә Яшьлек уты дөрли. Ул үр арты үр менә. Мул җимешле иҗатына исә Тукай-Җәлилләр үзләре хәер-фатиха биреп, аны һәрдаим туган халкы өчен изге эшкә рухландырып торалардыр кебек...

Без киң колачлы әдипне 60 яшьлек мөбәрәк юбилее белән ихлас күңелдән кайнар котлыйбыз, аңа һәм хәләл җефетенә рухи ныклык, бәхетле тигез-тату гомер, яңа иҗади ачышлар телибез!

**Фәния ЧАНЫШЕВА.**
*Уфа каласы.*

*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

## ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫН ХӨРМӘТЛӘҮ

23 гыйнвар көнне Җөмһүриятебез Илбашы М. Шәймиев Казан Кремлендәге резиденциясендә татар әдәбиятының аксакалы — Татарстанның халык язучысы Аяз ага Гыйләҗевны кабул итте. Президент, олуг әдип белән җылы әңгәмә корып, аны 70 яшьлек юбилее белән ихластан тәбрикләде.

Очрашуда ТР Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин, язучылар оешмасы җитәкчесе Р. Мөхәммәдиев катнашты.

24 гыйнварда исә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында А. Гыйләҗевка багышланган тантаналы кичә булды. ТР Премьер-миинистры Ф. Мөхәмммәтшин юбилярга, татар әдәбиятын үстерүгә керткән олы хезмәтләре өчен, Татарстан Республикасының Мактау грамотасын тапшырды. Атаклы каләм остасын Сарман, Зәй районнарыннан килгән якташлары, күпсанлы әдәбият-сәнгать әһелләре, киң җәмәгатьчелек вәкилләре кайнар котладылар, үзләренең аңа карата булган тирән ихтирам хисләрен җиткерделәр.

## КОЛЛЕГИЯ УТЫРЫШЫ

22 гыйнварда К. Тинчурин исемендәге театр бинасында Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы коллегиясенең киңәйтелгән утырышы булды. Анда ТР Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов республикабыз матбугат органнарының, полиграфия предприятиеләренең 1997 елдагы эш нәтиҗәләре, 1998 елга тәгаенләнгән планнар турында тәфсилле чыгыш ясады. Аннары базар икътисадына күчү шартларында матбугат органнарының, полиграфия предприятиеләренең эшен, китап сәүдәсен оештыру буенча эшлекле фикер алышу булды.

Коллегия утырышында ТР Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин катнашты.

*ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ*

## ШАГЫЙРЬ ҺӘМ РӘССАМ ДУСЛЫГЫ

29 гыйнвар көнне Г. Тукай музеенда күренекле рәссам-график, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Эрот Зарипов әдәбият-сәнгать сөючеләр игътибарына «Багышлау» сериясеннән булган яңа шәхси күргәзмәсен тәкъдим итте. Бу юлы ул үзенең әсәрләрендә шагыйрь Равил Фәйзуллинның тормыш һәм иҗат юлын чагылдырган — экспозициягә 70 кә якын әсәр тупланган.

Күргәзмәне ачу тантанасында республикабызның Рәссамнар берлеге рәисе Абрек Абзгильдин, Мәгълүмат һәм матбугат министры Ислам Әхмәтҗанов, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Индус Таһиров, Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов, Татарстан язучылары җитәкчесе Ринат Мөхәммәдиев, Казан шәһәренең Вахитов районы хакимияте башлыгы Сабирхан Мөхәрләмов, Балык Бистәсе районы хакимияте җитәкчесе Хатыйп Газизов һ. б. чыгыш ясады. Халкыбызның яраткан җырчысы Гөлзадә ханымның Р. Фәйзуллин шигырьләренә язылган популяр җырларны һәм татар халык җырларын башкаруы нур өстенә нур булды.

Очрашуны Г. Тукай музее директоры — язучы-галим Фәрит Яхин алып барды. Соңыннан рәссам Э. Зарипов белән шагыйрь Р. Фәйзуллин күргәзмә ачу тантанасында катнашкан республикабызның күренекле шәхесләренә, зыялы затларына, мәркәзебез кунакларына рәхмәт сүзләре белән чыктылар.

## КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ БӘЙРӘМЕ

«Казан утлары» журналында бүлек мөхәррирләре булып эшләүче танылган әдипләрдән Шамил Маннаповның — 60 яшьлек, Мансур Вәлинең 50 яшьлек юбилейлары уңаеннан, 15 гыйнварда Пресса йортында тәбрикләү кичәсе үткәрелде. Анда чыгыш ясаучылардан Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев, «Мәгариф» китап нәшрияты директоры Мөдәррис Вәлиев, Татарстан китап нәшрияты вәкилләре — Галимҗан Гыйльманов, Солтан Шәмси, Фирая Зыятдинова, Равил Рахмани, Татарстан радиосының нәфис тапшырулар редакциясенең баш мөхәррире Җәүдәт Дәрзаман, «Сөембикә» журналының баш мөхәррире урынбасары Марат Әмирхан, «Чаян» журналының баш мөхәррире Рәшит Зәкиев, Татарстан Фәннәр академиясеннән язучы-галим Фарсель Зыятдинов һ. б. һәр ике юбилярның да халкыбызга үз иҗатлары белән кылган игелекләрен югары бәяләделәр, аларга киләчәктә дә нык сәламәтлек, уңышлар юлдаш булуын теләделәр.

Кичәне «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин алып барды.

## КУКМАРАДА — «ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ АТНАЛЫГЫ»

26—31 гыйнвар көннәрендә Кукмара районында, җирле хакимият һәм Татарстан Язучылар берлеге инициативасы белән, «Татар әдәбияты атналыгы» үткәрелде. Би-

регә Казанда яшәүче кукмаралыларның якташлык җәмгыяте президенты — язучы-галим Фоат Галимуллин җитәкчелегендә бер төркем каләм әһелләре килде. Алар арасында Мәгъсүм Насыйбуллин, Газинур Морат, Рифә Рахман, Заһид Мәхмүди, Вакыйф Галимов һ. б. бар иде. Язучылар районның күп кенә мәктәпләрендә мәдәният йортларында булып, укучылар белән очраштылар.

### ИСТӘ, ҺАМАН ДА ИСТӘ...

Тукай бүләге лауреаты Мәхмүт Хәсәновның тууына 70 ел тулу уңаеннан, заманында ул эшләгән Азнакай төбәгендә байтак кына чаралар тормышка ашырылды. Шәһәрнең иң матур урамнарының берсенә күренекле әдипнең исеме бирелде, 1959-1980 елларда Мәхмүт ага яшәгән йортка истәлек тактасы куелды. Хәзер исә район газетасы редакциясе бинасында аңа багышланган музей бүлмәсе ачарга ниятлиләр.

* * *

19 декабрьдә Татарстан язучыларының Тукай исемендәге клубында М. Хәсәновны искә алу кичәсе булды. Анда язучылардан А. Гыйләҗев, Р. Мөхәммәдиев, М. Хәбибуллин, Ф. Галимуллин, Р. Кәрами, Ф. Бәйрәмова, М. Галиев, Н. Гамбәр, Ф. Гыйззәтуллина һ. б. чыгыш ясады.

### ИҖАТ ОСТАХАНӘЛӘРЕНДӘ

Татарстан Язучылар берлеге каршында эшләп килүче «Проза һәм драматургия остаханәсе»нең чираттагы утырышы әдәби әсәрләрдәге тел-стиль мәсьәләләренә багашланды. Утырышта остаханә җитәкчесе — Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов, ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев, Әдәбият фонды идарәсе рәисе Әхсән Баянов, әдәби консультант Рөстәм Мингалимов, язучы Хәйдәр Гайнетдинов, мөгаллимә Гөлчәчәк Галиева һ. б. чыгыш ясады.

* * *

9 февральдә «Шигърият остаханәсе» (җитәкчесе — Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев) үзенең чираттагы утырышында яшь автор Шәүкәт Гаделша (Сибгатуллин) иҗатын тикшерде. Чыгыш ясаучылардан Гариф Ахунов, Гөлшат Зәйнашева, Рөстәм Мингалим, Рәдиф Гаташ, Мөдәррис Әгъләм, Марсель Галиев, Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Галимҗан Гыйльманов, Рафис Корбан һ. б. Себер төбәгеннән килгән бу шагыйрьнең иҗатына, нигездә, уңай бәя бирделәр. Остаханә исеменнән, Ш. Гаделша Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп тәкъдим ителде.

### ГИМНАЗИЯ КУНАКЛАРЫ

«Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире — яшь прозаик Алмаз Гыймадиев һәм Казан шәһәрендәге 21 нче музыка мәктәбе укытучысы — яшь композитор һәм җырчы Вәис Бәйрәмов катнашында мәркәзебезнең 5 нче татар гимназиясендә «Уйларыбыз һәм эшләребез синә, Татарстаным!» дигән әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.

### РӘССАМНЫҢ ЮБИЛЕЙ КҮРГӘЗМӘСЕ

Башкалабыздагы Шәриф Камал музеенда «Ш. Камал һәм татар язучылары» дип исемләнгән рәсемнәр күргәзмәсен ачу тантанасы булды. Ул танылган рәссам Мансур ага Рәхимовның 80 яшьлек юбилеена багышлап үткәрелде. Күргәзмәгә күренекле татар әдипләренең һәм шагыйрьләренең әлеге оста тарафыннан эшләнгән бихисап портретлары куелган иде. Тантанада чыгыш ясаучылардан Казан шәһәренең Мәскәү районы хакимияте башлыгы Гүзәлия Минкина, Татарстанның халык шагыйрьләре Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев һ. б. фронтовик-рәссам иҗатына югары бәя бирделәр, аңа нык сәламәтлек, яңа иҗади уңышлар теләделәр, истәлекле бүләкләр тапшырдылар.

### БАШКОРТ ДУСЛАР АТНАЛЫГЫ

8—15 февральдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Башкортстанның Арслан Мөбәрәков исемендәге Сибай дәүләт драма театры артистлары башкалабыз тамашачыларына Заһир Исмәгыйлев һәм Баязит Бикбайның «Кодача» музыкаль комедиясен, Флорид Бүләковның «Кызлар ни өчен елый?» мелодрамасын, Хәбибулла Ибраһимовның «Башмагым» музыкаль комедиясен, Гөлшат Әхмәтҗинаның «Абыстай» драмасын, Зәйнәб Биишеваның «Тылсымлы курай» драматик легендасын күрсәттеләр. Спектакльләрне тамашачы җылы кабул итте.

### УКУЧЫЛАРГА — ДРАМАТУРГ БҮЛӘГЕ

Казандагы 154 нче татар гимназиясенең V, XI сыйныфларында укучы Ләйсән Гыйльметдинова белән Римма Гыйльманова күренекле драматург, Татарстан халык депутаты Туфан Миңнуллин фонды премиясе лауреаты булдылар. Аларга әлеге бүләк татар телен һәм әдәбиятын өйрәнүдәге зур уңышлары өчен бирелде. Укучыларга акчалата премияне Гимназия көнендә Т. Миңнуллин шәхсән үзе тапшырды. Моңарчы мондый бүләкне дүрт укучы алган иде инде.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Радиотапшырулар өлкәсендәге уңышлары өчен, «Татарстан» дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе дикторы Фәйрүзә Мәсхүт кызы Исхаковага «Татарстан Республикасының атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

# ТАРИХ БАШЫ — ЕРАК ГАСЫРЛАРДА

Рәссам Канәфи Нәфыйков әсәрләреннән оештырылган күргәзмәне карагач, Бакый ага Урманче фикерләр дәфтәренә, «Күп эшләве белән, тирәнтен, төптән алдыручы бердәнбер рәссам», дип язып калдырган.

Иҗатын олуг шәхес шулай югары бәяләрлек рәссам Нәфыйков кем икән соң ул? Үзенең шәкертләреннән берсе булганга гына Канәфи хакында мондый сүзләр язмас бит инде кальбе эчкерсезлек белән сугарылган Бакый ага.

Күпмедер вакыттан соң үзем дә Канәфи Нәфыйков белән якыннан таныштым, берничә күргәзмәсен карадым, остаханәсендә булдым. Соңрак аның иҗатына багышлап видеофильм эшләргә дә насыйп булды. Шул чагында мин үзем өчен К. Нәфыйков иҗатының чыннан да тирән, эчтәлекле, төпле фикерләргә ия, эзлекле, кыюлыгы белән игътибарны яулап алырлык, милли хисләргә үтә дә бай иҗат икәнлеген ачыклаган идем.

Нәрсәгә нигезләнгән соң рәссамның мондый сәләте, дигән сорауга җавапны аның халкыбыз тарихын җентекләп өйрәнүеннән генә табарга мөмкин икән.

Рәссамның «Ага базар», «Хан анты», «Чүлмәкчеләр», «Өмет», «Чичәннәр ярышы» кебек һ. б. әсәрләрен халык тарихының кайсы дәвере белән булса да чикли алабызмы соң? Юк, бу мөмкин түгел. Әйтик, «Өмет» картинасының үзәгендә буразна башына тезләнеп намаз укучы агай сурәтләнгән. Ел уңышлы булсын дигән өмет белән ул чәчүлек җиренә күкәй тәгәрәткән. Шул ук вакытта агай үз янында торучы атына, дөньялыкта нәселен дәвам итәчәк малаена зур өмет баглый.

Җиргә күкәй тәгәрәтү мәҗүсилек заманнарыннан ук килә торган йола булса, намаз уку исә төрки халыкларга ислам динен кабул иткәннән соң гына кергән дип уйларга һәм картинаның тарихын соңгы мең ел чамасы вакыт белән чикләргә мөмкин булыр иде. Ләкин җиргә тезләнеп Тәңрегә ялвару йоласы берничә мең еллар элгәрәк дәвергә алып китә. Димәк, картинада сурәтләнгән вакыйганы соңгы мең ел белән чикләргә дә, тагын да ераграк гасырларны чагылдыра дип бәяләргә дә мөмкин.

Сүзнең кадерен белүче, җор һәм тапкыр бабаларыбыз булган, үз сүз байлыгы башка милләтләрнең сүзлек составын бик нык баеткан төркиләрнең җыручылар һәм шигырь әйтүчеләр ярышлары үткәрә башлау вакытында мәгълүм бер дата белән билгеләү мөмкин түгел. Шулай ук К. Нәфыйковның «Чичәннәр ярышы» картинасында сурәтләнгән күренешне дә — җыелган халык каршында ике чичәннең сүз осталыгы буенча ярышын — якындагы гасырлардан бигрәк, тарих төпкелләреннән килүче вакыйганың чагылышы дип бәяли алабыз.

Халкыбыз тарихының мәгълүм бер дәверен чагылдыручы картиналар рәссам иҗатының байлыгы, авторның фикерләү һәм дөньяга карашының киңлеге хакында сөйли. «Болгарда чуен кою», «Хәлиф хаты», «Монгол яулары», «Йосыф китабы», «Александр Невский Бату хан хозурында», «Чукындыру», «Сөембикәнең Ватаны белән бәхилләшүе» кебек картиналар исә, исемнәреннән үк күренгәнчә, мәгълүм бер дәвер чагылышын дәгъвалый алалар. Шул ук вакытта алар да — халкыбыз тарихының аерылгысыз бер өлеше.

К. Нәфыйков әсәрләре арасында исемнәре билгеле булып та йөз сурәтләре мәгълүм булмаган тарихи шәхесләребезнең портретлары байтак. Кол Гали, Сәйф Сараи, Батырша, Мөхәммәдъяр, Утыз Имәни кебек төрле дәверләрдә акыл белән дә, корал белән дә милләт бәхете өчен көрәшкән, хәтта гомерләрен фида иткән бабаларыбыз җанлы образлар булып күз алдында гәүдәләнә. Бу гына да түгел, инде 20 нче гасырда татар милләтенең данын күтәргән Г. Тукай, С. Рәмиев, С. Волжская, Г. Исхакый, Б. Урманче кебек шәхесләр дә бүген тарих сәхифәләрендә урын алдылар.

Һәр милләтнең тарихы бүген языла, диләр. Яңгырашы белән гаҗәп тоелса да, хакыйкать бу. Милләт язмышы өчен бүген сәясәттә хезмәт итүчеләр дә, иҗатларын әдәбият-сәнгать яки фән һәм мәдәниятне үстерүгә багышлаучылар да күпмедер вакыт узуга тарихи шәхесләр булып калачаклар. Канәфи Нәфыйков иҗаты да, аның иҗатына багышлап эшләнгән «Тарих башы — ерак гасырларда» дигән видеофильмыбыз да менә шул хакта.

Бу язмада соңгы сүз итеп шуны әйтергә телим, Чирмешән районы хакимиятенең зур булышлыгы белән эшләнгән һәм Татарстан телевидениесе тарихында беренче тапкыр буларак тиражланган әлеге видеофильмны мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында милләтебез тарихын өйрәнүчеләргә ярдәмчел әсбап итеп файдаланырга мөмкин булыр иде.

**Индус СИРМАТОВ**

# ЯҢА КИТАПЛАР

Илдар ЮЗЕЕВ. **Уйлый күңелем төрлесен...** *Шигырьләр, җырлар.*— Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.—225 б., тиражы—3000 данә.

Урам ташларыннан әкрен атлап
Тоеп барам заман агышын,
Сыгылам да кайчак, бөгеләм дә,—
Төяп барам заман сагышын.




Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевнең бу китабына, нигездә, соңгы ун ел эчендә язылган шигырьләр, җырлар тупланган. Дүрт бүлектән торган бу китапта бирелгән аннотация-аңлатмада мондый сүзләр бар:

«Моңа кадәр шигърият сөючеләр Илдар Юзеевне поэмалар, драмалар, трагедияләр, комедияләр авторы буларак күбрәк беләләр иде. Шагыйрьнең бу китабында тупланган лирик шигырьләр укучыларга заманның борчуларын, газапларын, шатлык-сөенечләрен, кайгы-хәсрәтләрен ирештерер. Автор елатыр да, җырлатыр да, көлдерер дә, балачакка да кайтарыр...»

Китапта гражданлык хисләре белән сугарылган җитди әсәрләр белән бергә, юмор-сатира һәм балалар өчен язылган шигырьләр дә бар. Шулай ук, атаклы шәхесләргә (Х. Туфан, С. Хәким, С. Баттал, Ш. Маннур, Г. Ахунов, М. Хәсәен, И. Шакиров, Рәш. Әхмәтҗанов, А. Арсланов һ. б.) багышланган мәрсияләр һәм багышламалар да шактый урын алган.

Шагыйрьнең С. Садыйкова, З. Хәбибуллин, А. Монасыйпов, Ф. Әхмәтов, М. Яруллин, Р. Абдуллин, М. Имашевлар көй язган шигырьләре аерым бер бүлекне тәшкил итә.

Китапның мөхәррире — Ф. Зыятдинова, рәссамы — В. Булатов.

Индекс 73210



Язучы Зиннур Хөснияр

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)